

# Казан утлары

12.1984



# Татарстан комсомолының М. Җәлил исемендәге премияләре лауреатлары

Әдәбият һәм сәнгать өлкәсендә Татарстан комсомолының М. Җәлил исемендәге премияләрен бирү комитеты тәкъдимнәрен тикшергәннән соң, ВЛКСМ өлкә комитеты бюросы 1984 ел өчен премияләрне түбәндәге кандидатураларга тапшырырга карар бирде:

**Союзгосциркның «Яшьлек» татар цирк группасына** — 1982—1984 еллардагы концерт программалары циклы һәм СССР халыклары дуслыгын ныгыту эшенә керткән зур өлешләре өчен;

**Ризган Хәмидкә (Ризван Мирхәбибуллович Хәмидуллинга)** — драматургка,— «Китәм инде», «Синең урыныңа кайттым» пьесалары өчен;

**Алсу Бариевна Гарифуллинага** — Буа районының Күл-Черкен урта мәктәбе «Әйлән-бәйлән» татар вокаль ансамбле җитәкчесенә — яшьләргә коммунистик тәрбия бирүдәге зур эшләре өчен;

**Владимир Юрьевич Муравьевка** — үзешчән җырлар башкаручыга — яшьләргә коммунистик тәрбия бирүдәге зур эшләре өчен.

# КАЗАН УТЛАРЫ

ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ОРГАНЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС
ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-
ПОЛИТИК ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ
АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

12

1984

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ

КАЗАН

## *Бу санда*

ӘДӘБИЯТЛАР ДУСЛЫГЫ — ХАЛЫКЛАР ДУСЛЫГЫ

Ю. БОНДАРЕВ. **Дала кояшы.** Хикәя . . . . . 3
Е. ЕВТУШЕНКО. **Казан университеты.** Поэмадан өзекләр . . . . . 9
Н. ДУМБАДЗЕ. **Хазарула.** Хикәя . . . . . 12
О. ВАЦИЕТИС. **Балалар өчен шигырьләр** . . . 18
А. ЕМЕЛЬЯНОВ. **Хырвар дигән тын авылда...** Хикәя . . . . . 20
Ю. СЕМЕНДЕР. **Карт солдатны күмү.** Шигырьләр 24
П. АФАНАСЬЕВ. **Су эзлибез.** Шигырьләр . . . . 24
Л. МАРТЬЯНОВА. **Нахак сүзләр әйтеп.** Шигырьләр 25
А. ХУЗАНГАЙ. **Йөз мең сүз...** (Әдәби тәнкыйть) . 26
Й. ГӘРӘЙ. **Сармаш ярында.** Шигырь . . . . 33
Ш. БИККОЛ. **«Җир казуы — авыр эш»,— диләр** . 33
В. ПОРТНОВ. **Фронтовик агачлар.** Шигырьләр . 35

К. ТИМБИКОВА. **Ярлар биек.** Повесть . . . . 37
А. САФИН. **Күз карашы.** Хикәя . . . . . 77
Р. КУТУЙ. **Ява карлар.** Хикәя . . . . . 82
Р. ЮНЫСОВ. **Җирдә яшим!** Шигырьләр . . . . 86
А. МИНҺАҖЕВА. **Туфанны көткәндә.** Шигырьләр . 89

«БАТЫРЛЫК ДӘВАМ ИТӘ» КОНКУРСЫНА

Ф. САДРИЕВ. **Авыш басу икмәге.** Хикәя . . . . 93
Ә. ГАФФАР. **1945 елгы хат.** Хикәя . . . . . 110

ТУКАЙНЫҢ 100 ЕЛЛЫГЫНА

Т. ЗУЕВА. **Казанда Тукай урыннары** . . . . 112
Э. ЯКУБОВА. **Габдулла Тукай һәм татар музыкасы** 113

ЯШЬЛӘР ИҖАТЫ

Ш. ЖИҺАНГИРОВА. **Кечкенә чагымда.** Шигырьләр 119

Ә. БАЯНОВ. **Ватан тойгысы** . . . . . 122

БӨЕК ҖИҢҮНЕҢ КЫРЫК ЕЛЛЫГЫНА

Г. САЛИХОВ. **Идел егете** . . . . . 129

Н. ОРЕШИНА. **Ватанымның көчле канатлары** . 134

АЗЫК-ТӨЛЕК ПРОГРАММАСЫ — БӨТЕНХАЛЫК ЭШЕ

Җ. ДӘРЗАМАН. **Күңел җылысы** . . . . . . 142

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Р. МӨХӘММӘДИЕВ. **Илем кояш чыгышында** . . 147

БИБЛИОГРАФИЯ

Ә. СӘХАПОВ. **Тыңгысыз хисләр җырчысы** . . . 156

СӘНГАТЬ

М. СӘЛИМҖАНОВ. **Театр кайдан башлана** . . . 158

КУЛЬТУРАБЫЗ ТАРИХЫНА

С. АКБИЕВ. **Дагстанлылар Казанда** . . . . . 162
Н. МОРАДЫМОВ. **Фидакарь галим онытылмый** . 167
Җ. МИҢНУЛЛИН. **Рухи мирасны барлаганда** . . 170

ЮБИЛЕЙЛАР

Л. ХӘМИДУЛЛИН. **Бәхетле язмыш** . . . . . 172
**Һибәтулла Салиховның тууына 190 ел** . . . . 175
**Муса Акъегетнең тууына 120 ел** . . . . . . 175
В. ХАКОВ. **Яшәү һәм хезмәт үрнәге** . . . . . 176
Б. КАМАЛОВ. **Җан җылысы.** Скульптор Васил Маликовка 60 яшь . . . . . . . . . 179
**Кызыклы хәллләр** . . . . . . . . . . . 181
**1984 елда «Казан утлары»нда басылган әсәрләр** . 183
**Культура тормышы көндәлеге** . . . . . . . 190
Тышлыктагы сурәтләр . . . . . . . . . . 192



*Баш редактор*

РЕНАТ ХАРИС

*Редколлегия:*

МАРСЕЛЬ ГАЛИЕВ
ӘХӘТ ГАФФАР
МИРКАСЫЙМ ГОСМАНОВ
АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ
МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВ
МӘДИНӘ МАЛИКОВА
САЛИХ МАННАПОВ *(җаваплы секретарь)*
ТУФАН МИҢНУЛЛИН
ФЛҮН МУСИН
РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ *(баш редактор урынбасары)*
РӘФЫЙК НӘФИКОВ
НУРИХАН ФӘТТАХ
СИБГАТ ХӘКИМ
РИЗВАН ХӘМИД
НИЛ ЮЗИЕВ
АЗАТ ӘХМӘДУЛЛИН


## В НАШЕМ НОМЕРЕ

Представлены лучшие образцы литературы народов СССР — рассказ **Ю. Бондарева** «Быки», отрывок из поэмы **Е. Евтушенко** «Казанский университет», рассказ **Н. Думбадзе** «Хазарула», рассказ **А. Емельянова** «В тихой деревушке Хырвар», стихи **О. Вациетиса**, **Ш. Биккул**, статья **А. Хузангай** и стихи **В. Портнова**.
Печатается повесть **К. Тимбиковой** «Крутые берега», рассказы **А. Сафина** «Взгляд», **Р. Кутуя** «Падает снег», стихи **Р. Юнысова**, **А. Мингазовой**, **Ш. Зигангировой**.
На конкурсе «Подвиг продолжается»: рассказы **Ф. Садриева** «Хлеб наклонного поля», **А. Гаффар** «Письмо 1945 года».
К «100-летию Тукая»: рисунок **Т. Зуевой**, статья **Э. Якубовой** «Тукай и татарская музыка».
К 40-летию Победы очерк **Г. Салихова** «Парень с Волги».
В рубрике «Литературная критика» статья **Р. Мухамадиева**.
Статья главного режиссера ТГАТ им. Г. Камала **М. Салимджанова** «С чего начинается театр».
«К истории культуры» статьи **С. Акбиева**, **Н. Мурадымова**, **З. Миннуллина**.
**В номере отмечаются юбилеи Ф. Туишева (100 лет), Х. Салихова (190 лет), М. Акъегет (120 лет), Л. Заляй (90 лет), В. Маликова (60 лет).**
«На наших обложках» — творчество художника **Л. Фаттахова**.


Безнең адрес: 420066, Казань, ул. Декабристов, 2

Телефоннар: баш редактор — 53-07-60, баш редактор урынбасары, җаваплы секретарь — 53-07-09, проза, поэзия, очерклар бүлекләре — 53-07-61, тәнкыйть, сәнгать, хатлар бүлекләре — 53-07-63



Техник редактор *Р. Сөләйманова.* Корректорлар *Ф. Кадыйрова, Т. Сибгатуллина.*

Производствога бирелде 24.11.1984 ел. Басарга кул куелды 7.12.1984 ел. ПФ 13146. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70×108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8).
Тираж 64049. Заказ К-346. Бәясе 90 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.



© «Казан утлары», 1984 ел.

*Күренекле рус совет язучысы, СССР һәм РСФСР язучылар союзы идарәсе секретаре, Ленин премиясе һәм СССР Дәүләт премияләре лауреаты Юрий Васильевич Бондаревка быел 60 яшь тулды.*

*Аның биографиясе — тулы бер буын биографиясе. Шуңа күрә, язучы һәм җәмәгать эшлеклесе буларак, Юрий Бондарев үз буынының сугыш елларындагы язмышын, аның фаҗигасен һәм героизмын, югары идеалларын һәм драматик кичерешләрен үзенең әсәрләрендә аеруча калку чагылдырды. Сталинград яны бәрелешләрендә, Днепрны кичү, Киевне штурмлау, Польша һәм Чехословакияне азат итү сугышларында үзенең дә турыдан-туры катнашуы аңа үз тормыш тәҗрибәсе нигезендә сугыш һәм тынычлык проблемасын философик-әхлакый югарылыкта, тарихи-диалектик тирәнлектә ачарга ярдәм итте. Юрий Бондаревның «Батальоннар ярдәм сорый» («Батальоны просят огня»), «Соңгы залп» («Последний залп») повестьлары, «Тынычлык» («Тишина»), «Ярлар» («Берега»), «Кайнар кар» («Горячий снег»), «Сайлау» («Выбор») кебек романнары хаклы рәвештә киң катлам укучыларның ихтирамын казанды.*

*Әле узган ел гына Ю. Бондаревка «Выбор» романы өчен икенче мәртәбә СССР Дәүләт премиясе тапшыру вакыйгасы танылган язучының зур иҗади хезмәтенә, мөмкинлекләренә югары бәя булып яңгырады.*

*1983 елда Татарстан китап нәшрияты Ю. Бондаревның «Кайнар кар» романын татар телендә бастырып чыгарган иде. Без исә укучыларыбыз игътибарына әдипнең «Дала кояшы» исемле хикәясен тәкъдим итәбез.*

**Юрий Бондарев,**

рус язучысы

# ДАЛА КОЯШЫ

хикәя



Сугыш вакытында булды бу хәл. Казахстан җирендә, далада. Түзеп булмаслык эссе көннәр иде. Кыздырылган таба кебек баш өстендә көйдереп торган кояш нурына бер дә чыдарлык түгел, минем шундук мием кайнарга тотынды, ә бераздан инде чигәмә ни беләндер туктаусыз бәргәлиләр сыман тоелды. Өстәвенә чикерткәләр бертөзлексез чәр-чәр килә, зур көлтә арбасы — мөгәлдәккә җигелгән пар үгез камытының тимер чөйләре зәһәр шыгырдап җанга тиялэр. Ябык, ярым сөяккә калган әлсерәү үгезләр үзләре дә ачуны китерәләр: селәгәй агызып һаман күшиләр дә күшиләр. Хәер, мескеннәр шул инде алар да: шыксыз, керфексез күз тирәләренә зәңгәрсу-кара эре чебеннәр иләшеп алган да имә, җәберли үзләрен. Болар исә шуңа каршы һич ни чара күрә алмый, сабыр-күндәм генә башларын иеп, тик торуларын беләләр. Хайвани затның көн саен дәвам иткән газапка шулай күнегүедер инде бу, мөгаен.

Монда, далада, әле мин беренче көн генә эшлим. Иртән бригада утарында мине чуендай каралган йөзле, таза беләкле көлтә ташучылар бик чит күреп, мыскыллы елмаеп каршы алганнар иде. Шул хәл хәзер дә һич күңелемнән китми, күз алдымда тора. Бу дала-бушлыкта гомер иткән егетләр минем эшкә нинди кыяфәттә килүемне өнәмәделәр-аңламадылар булса кирәк. Эвакуацияләнеп яңарак кына килеп төшкән бу форсовый шәһәр малаеның аягында ап-ак парусин (чүпрәк) туфли, билендә якоре ялтырап торган каптырмалы чын диңгезче каешы, сөякчел арт санында балак очлары киңәйтелгән «клешлы» ап-ак чалбар булсын инде! Бу ничек ошасын?

Бу кием исә минем балачак хыялым, флотка дип хәзерләнүем билгесе иде. Әтинең утызынчы еллар башында киеп йөргән чалбарын үзем шулай сипләп, «клеш»латтым, якорьле ялтыравык бляханы да үзем юнәттем. Ул елларда «бригантина», «шкипер», «шхуна» кебек төрле китаплардан укып, ятлап алынган сүзләр минем күңелдә әллә нинди хисләр тудыра, хыялый сәяхәт дөньясына алып кереп китә иде. Күз алдыма ак болыттай җилкәннәр, тансык җилле, ак кояшлы җылы диңгез, җайгына чайпалып яткан диңгез буендагы үзгә, матур шәһәрләр, ят җимеш, бананнар килеп баса. Билгесез яр буйларының күгелҗем күген, шул гөмбәз астында ара-тирә чайкалгалап алган зур кораб фонарьларын «күрә» башлый идем.

Әйе, әйе, мин инде сигезенче класста ук җилкәнле корабны ничек идарә итү хакында иске уку китапларын табып укыган, төрле диңгезче язмаларын, Джек Лондон романнарына бирелгән аңлатма-искәрмәләрне яттан өйрәнгән идем. Кайда нинди мачта, кайсы төр җилкән куеласын да яттан беләм. Шуның өстенә кемнәндер диңгезче тельняшкасының бер кисәген алыштырып алып, аны үз майкама тегеп куйган һәм күкрәгемнән «диңгез чите» күренеп торсын өчен һәрвакыт диярлек күлмәк изүен чишеп йөри идем. Шул нәни генә чүпрәк кисәге дә күңелемдә иксез-чиксез горурлык хисе тудыра, гүя мин чын-чынлап җилдавыллы очсыз-кырыйсыз диңгездә йөзәм.

Тугызынчы класста укыганда исә мин, хәрби диңгез клубына язылырга теләп үземне чыныктырырга, кышның зәһәр суыгында да форточкамны ачык калдырып йокларга керештем. Иртән тору белән гантель күтәрәм, көч җыям. Шул ук кышны әлеге җиз бляханы да сатып алдым. Дулкында чайкалган палубада барган шикелле, аякларны җәеп, чайкалып йөрергә дә өйрәнеп беткән идем инде.

Һәм менә бу август көне, дала кояшы. Мин Смоленск шәһәре тирәсендә окоп казуда катнаштым, шуннан өйгә — Мәскәүгә кайттым. Өйдә инде беркем дә юк, фәкать йортлар идарәсендә әнинең нәни хаты гына көтә иде. Алар эвакуацияләнеп ерак Казахстан якларына китеп барганнар, артларыннан килә-килә, ниһаять, менә мин дә куып җиттем үзләрен. Килү белән бер нәрсәне аңладым: балачак хыяллары заманы түгел икән. Сихри диңгез уртасындагы Алтын сарай ише бу өмет-юанычларым эреп юкка чыгарга, һич югы вакытлыча онытылып торырга тиеш. Ә минем алга, иң олы бала буларак, әниемә булышу, кече сеңелләремне тәрбияләшү бурычы килеп баскан иде.

Бүген иртән, көлтә ташучылар бригадасы урнашкан утарда күренү белән үк, киң җилкәле, читтән караганда аска таба очлаеп килгән таза тимер чөйне хәтерләткән гәүдәле бригадир Бендрик мине:

— Ай-яй, кендегең ялтыравыклы икән! — дип, кимсетүле көлә-көлә каршы алган иде. Аннары ул чалбарымны тотып торган якорьле бляханы таза кулы белән эләктереп анда-монда тарткалагандай итте.— Анда, Мәскәүдә, әллә барыгыз да шушы уенчыкка табынганмы?— дип авызын ерды.

Мин эндәшмәдем. Безне урап, әйләндереп алган башка егетләр барысы да каралып, тузанланып беткәннәр, тир тозыннан култык аслары

бәсәреп чыккан гап-гади сатин күлмәкләрдән иделәр. Алар да миңа карап бертуктаусыз пыскыткан тәмәке төтеннәре аша, кәмит күзәткәндәй, мыскыллы гына елмайган булалар, ә үзләре җир идәнгә теш арасыннан гына «черт» тә «черт» төкеренгәләп куялар.

Төшенәм, аңлыйм. Алар арасында мин бу чиста-пөхтә шәһәр киемем белән, юри шулай кыланган сыман, бик ятышсыз, көлке бер кыяфәттәмендер. Ләкин үземә шулай шәһәр курчагы итеп караулары хәтеремне дә калдырды. Өстәвенә, эш бүлгәндә Бендрикның:

— Әнә, үгезләр, яннарына бар, иснә, Мәскәү көязе, башка вакытта үзеңдә борын сөрткечең белән одеколон йөртергә онытма!— дип көлүе күңелемә тиде. Инде менә шыгырдавык арба, күшәп туймас үгезләр белән генә калгач та ул мыскыллау сүзләре колак төбеннән китмиләр. Үгезләр башына тагылган баудан тартып, саргаеп торган көлтә өеменә якынлашканда күңелемдә бер генә уй бөтерелде: әйе, шушы шыр далада бүген үлсәм үләрмен, әмма дә ләкин ул ерык авызларга кемлегемне күрсәтмәсәмме? Әйе, әйе, хәзер исбат итәчәкмен мин моны!

Ашыга-кабалана килеп, ярсып сәнәкне чүмәләнең төбенә китереп тә кададым. Ниятем — бер күтәрүдә бу чүмәләнең һич югы өчтән берен йолкып алып биек арба үрәчәсеннән әйләндереп салу. Бер кизәндем, ике кизәндем, тагын бер талпынып карадым — көчәнүем бушка китте. Көчәнә-көчәнә көлтә өемен күтәреп алмакчы булам, шылтырап кипкән кыска бодай саламы сәнәк ябеннән шуа да төшә, шуа да төшә. Инде үз-үземне белештермәс халдә сәнәк белән ары да, биредә селтәнәм, нәтиҗә һаман шул ук: күтәргән саен көлтәләрнең күбесе җиргә, башыма коела, тиргә манчылган юка тенниска белән тән арасына, муен, җилкә тирәләренә кибәк, тузан тула. Күз, авыз, борын эченә дә тула, инде бөтен тәнем әрнеп әчетә башлады.

Ниһаять, тәнне тырнап торган теннисканы сыерып салып ташладым. Бу ни бу? Болай булса көн озынына да бер арбаны төяп бетерергә хәлемнән килмәсме? Тора-бара тәмам төшенкелеккә биреләдем, ә инде берәр сәгать чамасы узганнан соң башка көлтә ташучыларның тулы арба белән эскерткә таба килүләрен күргәч, мәгънәсез кизәнү-селтәнүләрдән тәмам хәлем бетеп, буылып егылыр дәрәҗәгә җиткән идем. Ә көлтә олавы янәшәсендә атлаучы егетләр чынлап та миңа карап йөзләрен чытып узалар идеме, әллә инде зәгыйфь хыялыма шулай шәйләндеме, белмим, тик шунысы хак — аларның берсе дә миннән хәл-әхвәл сорашмады.

Мин исә җәфа чигәргә дучар ителгән җан иясе төсле, тәмам хәлдән тайган килеш, инде таралып, сибелеп беткән көлтә калдыклары тырпайган җәпле сәнәк очына элеп олауга салмакчы булып азапланам... Селтәнеп чөеп ташлаган саен саламның бер өлеше, тончыктырып, үз өстемә ишелеп төшә, авызга тулган тузаннан, көннең бөркүлегеннән сулышым каба, һава җитми. Нәкъ каршымда эленеп торган кояш күземә берничә булып күренә, гүя ул, үз кызуына үзе эреп, шулай таркалган — хәзер ул минем алда кара бөҗра сыман тора! Колак туктаусыз шаулый, баш чатный — кемдер, әйтерсең лә, агач күсәк белән бер-өзлексез төя дә төя. Әлсерәтә, хәлсез тәнемне шабыр тир басты, теш арасында ком шытырдый, кашны-күзне күптән инде тузан пәрдәсе каплап алды, кояш һаман рәхимсез кыздыра — мин менә-менә озын арба янәшәсенә тәгәрәп китәрмен төсле. Мәгънәсезгә ыгы-зыгы килеп бик күп көч сарыф ителде, тәмам кешелектән чыктым, ахры.

Менә-менә авып, тәгәрәп китәм дип, соңгы чиккә җиткән бер вакытта яныма тимер чөйне хәтерләткән бригадир Бендрик килеп киткәндәй тоелды. Авызын иртәнге кебек үк ыржайтып ерган килеш үгезләр артыннан ул миңа нидер әйтте, көлтәләргә ишарәләп нидер күрсәтмәкче булды шикелле, хәтта кулымнан сәнәкне дә йолкып алмакчы итте бугай әле. Әмма мин, үзем дә төшенеп җитмәгән бер усал кирелек белән:

— Кит әле моннан!— дип аңа бакырдым, ахрысы. Аннары ярсулы ачу белән тагын бер гаепсез көлтәләрне актарырга керештем.

Шуннан соң инде минем яныма берәү дә килмәде, берәү дә сүз катмады. Аңлы-миңле килеш, инде хисап бирә алмас дәрәҗәгә җитсәм дә, үз-үземә карата туган ярсуның көчәя баруын тоям. Балаларча беркатлы бу битәрләү кыш буе форточканы ачып йоклауларның шулай рәхимсез рәвештә юк бер нәрсә булып калуын төшенүдән туган хис иде.

Бер ялгызым шулай кайнаша-кайнаша мин төш вакыты җитүен дә сизми, абайламый калганмын: көннең иң эссе, иң бөркү чагы башланды. Кыр-далада тормыш, әйтерсең, үлеп тынып калды, ни сиңа башак тибрәтеп җил йөгереп үтмәс, ни бер аваз килмәс — бар җан иясе түзеп булмаслык бу кызудан качкан, көлтә һәм камыл өсләрендә бары тик көмеш нур дулкыны, нур рәшәсе генә чайкала. Чүмәлә тирәләрендә «цооб», «цаба», дип, үгез куган авазлар, арба шыгырдаулары тәмам ишетелмәс булды. Чигәмдә ярсып үз каным сулкылдавы гына аерымачык сиземләнә иде.

Бер мизгелгә генә эскерт ягына күз салдым: буш арбалар, сары көлтәләргә килеп сыенган үгезләр күренеп калды. Эскерт ышыгына сөялеп утырган егетләр ашамлык букчаларын чишәләр, кайсы-берсе, үзара сөйләшкән арада, терсәк очларына бәреп йомырка кабыкларын ваталар. Һәм барысы да минем якка төбәлеп утырганнар, шуңа күрә мин аларга таба күз генә сирпеп алдым.

Бәлкем әле шуннан соң да берәр сәгать чамасы узгандыр, мин дә арбама далада үскән егетләр кебек, көлтәне үрәчә өстеннән үк өеп, йөрәгемнең хәлсезлектән сикереп чыгар дәрәҗәдә тибүен тоеп, колагым тәмам тонган хәлдә, алпан-тилпән атлап эскерткә таба киттем.

Әйе, әйе, колагым саңгыраулаңган, күз алдымда кояшның кара бөҗрасыннан гайре берни күренми диярлек, чөнки маңгайдан тоташ тир агып төшә иде. Менә мин калтыранган кулларым белән ул тирне күздән, биттән сыпыргалаган иттем, баягыча ук чебен җәберенә әһәмият итмәстән күшәүләрен генә белгән үгезләрем алдына чыктым, тиресе сыдырылып әрнеп торган учыма үгез төкерегә сеңгән әлеге мөгез бавын алдым һәм туры, нык басарга тырышып, әйдәп алдан бара башладым. Үгезләр елдам гына атлый, олау буразна саен ава-түнә чайкалып, шыгырдап, шыртлап куйгалый.

Үзем киләм, үзем эскерт төбендә утыручыларның сынаулы карашын тоеп һаман уңайсызланам. Өс-башым хәзер танымаслык: ыспай парусин туфлиләремне камыл ертып, тишкәләп бетергән. Иртә белән генә бик тырышып теш порошогы белән агарткан идем мин аларны — инде нинди төскә кергәнлекләрен әйтә дә алмассың. Купшы итеп киңәйтелгән чалбар балакларына да әче тир белән соры тузан сеңгән, хәзер алар ни ала, ни кола түгелләр. Тик инде боларның берсен дә — клешлы чалбарны да, җайлы, җиңел туфлиләремне дә әллә ни кызганмыйм, туфли агартып мәшәкатьләнүем генә кызганыч.

Үземне шул чаклы мескен, көч-сәләтсез итеп күрәсе килмәгәнлектәндерме, башка көлтәчеләр барыбер минем хакта яман уйлыйлардыр дип хурланудан һәм гомеремдә беренче мәртәбә шулай мәсхәрәгә калуымнандырмы, мин ирексездән ара-тирә сулкылдап-сулкылдап куйгалыйм. Ник дисәң, башка көлтәчеләр моңа кадәр һәркайсы дүртәр йөк көлтә китереп бушатты, ә мин әнә көч-хәл белән берне төяп киләм.

Әнә, алар эскерт ышыгында, нилектәндер үзара сөйләшми-нитми генә кыяр ашап утырган булалар, ә үзләренең кыяфәтләре җәза мәйданына килеп җәзалау башлануын көткән кешеләрнекеннән бер дә ким түгел, һәр хәрәкәтемә игътибар итеп, бәя биреп торулары сизелеп тора. Менә Бендрик, янәшәсендә утыручыларга хәйләкәр генә күз кысып алды да:

— Булдымы?— дип, ялкау гына сорап куйды. Аннары:— Аңладыңмы инде, тәти Мәскәү кугәрченкәе, ипекәйнең хуш исе каян килгәнне? Әллә юкмы әле?.. Әйдә, утырып кыяр капкала, соңыннан эшләп бетербез,— дип өстәде.

Минем исә боларның зәһәрле күз карашыннан тизрәк котыласым килә, күңелдә ашау, ял итү кайгысы юк. Терелай чишендереп, ялангач тәнемә әнә шулай оятсыз рәвештә карап тормасыннар гына иде. Кимсетүле шул карашларны күрмәс өчен генә дә мин хәзер теләсә нинди кирелеккә әзер идем, һәм үзсүзләнеп:

— Бушатам әле!— дип мыгырдандым да эскерт кабыргасына килеп төртелгән үгезләрем янында басып, иреннәремне тешли-тешли, көтә бирдем. Бендрик исә болай кыланасымны уйламаган иде бугай, оста гына итеп теш арасыннан «черт»ләтеп бер төкерек атты да, дала күге кебек җете зәңгәр күзе белән текәлеп мине баштанаяк карап чыкты, аннары, бик җикеренми генә сүгенеп алганның соңында, иренеп кенә эскерт башына менеп китте.

— Әйдә, бир!— дип кычкырды бу миңа югарыдан.

Егетләр ягына борылып карамаска тырышып, мин көч-хәл белән олауга үрмәләп мендем, баскан саен иңеп, сыгылып, чайкалып торган шома көлтәләрнең берничәсен сәнәгемә кадап алдым, аннары өскә күтәрдем дә Бендрикка таба чөеп җибәрдем. Чөюен чөйдем, тик шул мәлдә үк йөкнең каядыр читкә тайпылуын, үземнең исә икенче якка каерылуымны тойдым. Һәм шундук бер янтавым белән саламнарын тырпайткан эскертнең кай төшенәдер килеп тә төртелдем, терсәгем белән битем бәрелеп, сулкылдарга да керештеләр. Кайсы мизгелдәдер, Бендрикның бик яман чытылган кырыс йөзе күземә чалынып калды. Ул арада мин инде ни булганын әле белеп тә бетермәстән, аңламастан, каядыр аска убырылып төшә башлаган идем. Ярый әле алданрак шуып төшкән бодай көлтәләре мине җиргә каты бәрелүдән саклап калды, бары тик көлтә саламы белән камылның тәнемә мең энә булып кадап әрнетүен генә сиздем. Ләкин моннан да яманы — тынсыз калуым, буыла башлавым иде, бик җәһәт сикереп торып кына ул хәлдән котыла алдым.

Шунда йөкнең алды белән эскерткә иңеп, кадалып торуын, ни газап белән төялгән көлтәләремнең барысы да диярлек арба астында калганын күреп алдым. Эскерткә бәрелү белән үк, күрәсең, алар олау өстеннән җиргә мәтәлеп төшкәннәр, үрәчә теше арасыннан коелганнардыр. Үгезләр үзара тартыша-тартыша әле дә булса арбаны каядыр өстерәп азапланалар иде. Хайваннарның берсе тәмам эскерткә кысылып ук тора диярлек, мөгез төпләрендә, сыртларында — салам калдыклары, коелган башаклар. Ямьсез авыз кырыйларыннан агып төшкән куе селәгәй җепләре эскерт саламына, камылга салына, буй-буй тартылып, шунда эленеп-эленеп тә калгалый иде.

Мин, бу хәлгә аптырап, каушап калганлыктан, өстемә ишелгән көлтәләр тузаныннан өс-башымны кагарга да онытып, бер мәл салам арасыннан башымны тыгып, хәйран калып, бу күренешкә карап тордым. Аннары гына айнып киткәндәй булдым. Ярты көн буена эшләгән эшемне, түгелгән көчемне бу пошмас үгезләр бер талпынуда юк иткән, олауны аударып, көлтәләрне сибеп ташлаганнар иде. Мин әле үз хәлемне аңлар-аңламас бер халәттә идем. Нәкъ шул чакта...

Әйе, кешеләргә икенче берәүнең гаҗизлегеннән, бичаралыгыннан көлү дә хас әлбәттә. Әмма мин бу коточкыч көлүнең ни максатын, ни сәбәбен дигәндәй аңлау, аңа төшенү хәлендә түгел идем. Болай шаркылдап көлү миңа кешелекслелек сыйфатына хас нәрсә түгел, гайре табигый күренеш, вәхшилек калдыгы булып тоелды. Һәм мин үземә саклану чарасы итеп бары тик бер генә юлны сайлый алдым: миңа мондый чарасызлыктан котылу өчен, биткә карап мыскыллап көлүләрне күрмәс, ишетмәс өчен мөмкин кадәр тизрәк моннан качып китәргә,

таярга кирәк иде. Иң әүвәл мин теге егетләр ягына карап җан ачуы белән нидер кычкырдым, шуннан буш арбама сикереп менеп бастым да кулымдагы сәнәк сабы белән үгезләрнең тырпаеп, калкып торган арт саннарына, сыртларына, кабырга башларына киерелеп суга-суга мескеннәрне куаларга тотындым. Башымда бер генә уй — тизрәк, тизрәк моннан качарга, каядыр китеп олагырга кирәк. Баштарак минем төрткәләүләргә әллә ни исләре китми, һаман да әле эскерткә мөгезләрен терәп торган хайваннар, ниһаять, саламнан башларын алдылар.

Арба, ниһаять, эскерт куеныннан ычкынып, тәртипле генә тезелешеп утырган чүмәләләр арасына кереп китте, үгезләр авыртуга түзә алмыйча, тырт-тырт басып чаба иде. Ләкин миңа алар барыбер элеккечә үк эленке-салынкы гына баралар кебек, мине һич кенә дә тыңламыйлар кебек тоелды. Кемнәндер үч алу теләге, сукырларча ярсу хисе мине, сәнәкне ташлап, тимер башлы каешка тотынырга мәҗбүр итте. Һәм мин, ярсу сәбәпле, үземнең ни-нәрсә эшләгәнемне белештереп тә бетермәстән, мескен хайваннарның арт саннарын шул каеш башы белән туктаусыз кыйнарга, каезларга керештем. Янәсе, җан-фәрманга чаптырам мин аларны. Үгезләр табигатенә һич кенә дә хас булмаган нәрсә эшләттерәм.

Һәм басу читенә, соңгы чүмәлә янына җитүгә, үгезләр шып туктап калдылар. Тиз генә айный алмыйча, әле мин аларга күпмедер вакыт һаман акырып-бакырындым, тимер каеш башы белән кизәнү-сугуларымны дәвам иттем. Ләкин ничек кенә җикеренеп, ничек кенә кыйнасам да үгезләр бер карыш та алга китмәделәр, эчләрен тарткалап авыр сулаган килеш бер урында тора бирделәр. Шул чагында мин аларның арка тиреләре суелганын, анда кан күренгәнен абайлап алдым. Куркуы катыш гаҗәпләнү белән тизрәк каеш тимерен тотып карадым — якорь төшерелгән бляха танымаслык хәлгә килгән, ямьшәеп беткән иде.

Мин сискәнеп, уянып киткән төсле булдым, менә-менә йөрәгем ярылыр да шунда егылып китәрмен кебек тоелды. Бил каешымны каядыр читкә атып бәрдем дә, арбадан сикереп төштем, көчкә сулыш алып торган үгезләр каршына барып тезләндем. Малкайларның манма су булган дымлы маңгайларын, кан басса да һаман әле карусыз, күндәм генә карап торган дәү күзләрен учым белән капладым, аларны сыпыргалый башладым. Кайнар сулышлары, юеш селәгәйләре учыма уралды, кулыма тиде, әмма назлап, ягымлы гына сөю, сыпыргалауларымны туктатмадым. Ә үзем ят, ягымлы бер аваз белән һаман сөйләнәм:

— И җүләркәйләрем, мескеннәрем!.. Нишләттегез сез мине!..— дип такмаклыйм да такмаклыйм.

Үгезләр миңа сабыр гына, тын гына карап торалар, җылы сулышлары калтыранган хәлсез бармакларымны иркәли... Ә кайнар күз яше мөлдерәгән күз тирәләрендә инде карасу-зәңгәр чебеннәр йөри, чебеннәр кайнаша иде.

Русчадан **Лирон ХӘМИДУЛЛИН** тәрҗемәсе.

**Евгений Евтушенко,**
рус шагыйре

# КАЗАН УНИВЕРСИТЕТЫ

ПОЭМАДАН ӨЗЕКЛӘР

## Беренче кулга алыну

*Яхшы ниятлеләрне коткару өчен кабахәтләрне кызганмагыз.*

Магариф министры И. Д. Деляновның студентлар сходкасыннан соң Казанга суккан телеграммасы

Георгий кавалерына
тәүге тәре кадерле.
Революционерга да
кулга алыну тәүге —
истәлекле. Тоткын — исем.
Төрмә ул — үзе хөрмәт.
Тоткын булдың — хезмәтеңне
дәүләт таныды, димәк.

Кайда соң, хет күзәтүсез
бармы берәр чын кеше?
Шикләрдә йөрмәсәң дә,
граждан буларак шикле.

Кол-хуҗалар дәүләтендә
башка лозунг бармы:
«Кабахәтләр яшәсеннәр,—
кызганма яхшыларны!»

Кола ат кырын карыйдыр —
тояклары тек тә тек.
Кулга алынган Ульянов
пошынмый күк бик артык.

Нигә әле пошынырга
каплыйлар дип авызны?
Рәсәйдә куркак пошынсын,
утыртырлык явызны
сәбәп юк. Жандарм йодрыгы
авызны томаласа,
һәрчак өндәү ишетелгән
Россиядә ләбаса!

Куркыныч, туган, намусың
һәм җаның пычранса,
төрмә — нәрсә, төрмәдә дә
ватандашлар ләбаса!

Рухи тоткынлыкта булган
дөм караңгы көннәрдә
намус университеты
Россиянең — төрмәләр.

И рәхмәт сиңа, әләкче,
әләк өчен, кабахәт!
Төрмәгә китергән өчен
олаучыга мең рәхмәт.

Менә төрмәнең капкасы.
Михахайлап куя ат.
Елмая шунда Володя —
кулга алын-ач — ул хак!

Мәлҗек пристав ягымлы,
гел «сез» ди ул, «син» дими.
Аның бүген бер риясыз
ягымлылык көнеме?

«Малай йомшак, бик сөйкемле,
шундый минем үз балам.
Күренеп тора — яхшы гына
укымышлы семьядан».

Акыллы пристав искәртә:
«Төрмәләр күп, тормыш — бер.

Нигә фетнә күтәрәсез?
Алдыгызда стенадыр...»

Володяның карашында
балкый шаян елмаю:
«Стена да... Төртсәң — авар.
Инде черек бугай ул...»

Тораташ ката пристав:
«Ишетәмме мин аек?
Шундый мөмкинлек тә бармы...
Нитсәң ...ава... бугай ул...»

Аның өчен мөмкин түгел
авып төшү бу режим,
борын заман Рим өчен дә
шулай булган черек Рим.

Гаитида Дювалье да
шулай тоела бүгенгә,
һәм Мадридта коррида да,
һәм Греция җирендә.

Таптанучылар сукырлар:
карамый алгысына —
ышана аңсыз терәүләр
диварның аумасына.

Ульянов шаркылдап көлә,
кулы белән кар тота.
Кола ат бара чаптырып
туры алгы гасырга.

Анда Че Гевара һәлак,
гүя ацтек алласы,
кылларын өзеп елыйдыр
Мексика гитарасы.

Тутыккан рәшәткә артында
язу бар кадак сызган,
Володяча ап-ачык ул:
«Атларбыз башка юлдан».

Бәлки, Кытайда да кемдер:
«Стена сезнең алда...»
Җавап бер: «Черек стена...
Төртсәң, тора аварга...»

Тәвәккәл ат чабуында,—
соклануым яшермим,—
дәвам итәдер, Володя,
синең мәңге яшьлегең.

Мескен пристав, эшең яман.
Тир түкмә файдасызга.
Стеналарны җимерә
ышаныч — авасына!

## Унҗиде яшьлекләргә

*...Саумы, яшь һәм таныш түгел буын!*
А. Пушкин.

Күрендеме, төшкә кердеме соң,
күзләремдә әллә язлармы?
Чалт кояшлы апрель иртәсендә
мин яңадан күрәм Казанны.

Әле алда безнең иң-иң соңгы,
иң хәлиткеч көрәш көннәре.
Ә унҗиде яшьлек Ленин инде
студентларны әйди — күр әле!

Әле «Аврора»ның залплары
язгы күкрәү булып тумаган.
Бүген ярамаган уй-фикерләр
тәгълимат булырлар бер заман.

Унҗиде яшьлекләр, бар дөньяда
сез кешелекнең апрель җилләре.
Тормыш биргән сезнең
һәммәгезгә
күкнең шундый аяз, зәңгәрен!

Ташу вакытында зәңгәр бозны
язлар кетердәтеп кыярлар.
Яшьлек бит ул — үзе тулы ирек,
күктән зәңгәр йолдыз җыярга.

Туфрак-ана бомбалары булып
ярыласыз җирнең өстендә,
шулай ярылалар яшь бөреләр,
яфраклары шаулап үссенгә.

Бүгенге көн пәйгамбәрләрен
сез —
онытмагыз тамырларын да.
Унҗиде яшьлекләр, тырышыгыз
тамырларга лаек булырга.

Көч-куәтең күрсәтәсең килеп,
томырылырга, җилеп чабарга,
шәһәр светофорын чәчәк итеп,
очрашуга өзеп барырга!

Сөйгәнеңне өзелеп көткән чакта
апрель ботаклары астында,
онытмагыз үз чорыгызга да
очрашу билгеләү хакында.

Кыенлыклар килсә, офтанмагыз
рухи куркак булма, әйдә әле.
Ә чор белән очрашу урыны —
бөтендөнья Көрәш мәйданы.

Яшьлек бит ул — үзе тулы ирек
өстен әйбер юктыр аңардан,
ләкин өстен түгел ул халыктан,
халык өчен көрәш-дауллардан.

Әгәр эчтән калтырыйсыз икән,
һәм юк икән эчке өлгерү —
унҗиде яшь кенә дип аклану
булыр иде кеше көлдерү.

Унҗиде яшьтәге кыюлыгы
сезгә васыяте Ленинның.
Унҗиде яшьтәге олылыгы
сезгә васыяте Ленинның.

Җиде юл чатының берсен
сайлап,
атлап киткәч инде бер юлдан,
унҗиде яшьлекләр, булыгыз сез
унҗиде яшьтәге Ленindай!

## Эпилог

Рәхмәт сезгә, Казан диварлары:
сөйләдегез миңа ни бар —
барын.

Янә язмыш мәрхәмәтле булды,
бүләк итеп миңа яктысын,
Казан университеты, минем
өчен
Россияне янә ачтың син.

Мин хыялга шактый йомшак
кеше.
Тик фактка гына ышанам.
Россия тарихы хөр фикернең
изге көрәшеннән башланган.

Патша исемен ятлау тарих түгел.
Терек суын биргән җир-ана:
Лобачевскийлары үскән илнең,
магницкийлары туып торса да.

Герцен, Добролюбов,
Чернышевскийдай
якты маяклары аркылы
үзен-үзе тапкан Рәсәй халкы —
шунда көч-куәте, акылы.

Россияне түбәнсетеп булмый,
язгы ташкын төсле көчле ул.
Юкка мени аның пәйгамбәре
Петр Алексеев — эшче ул.

Тормыш дәвам итә. Казанда яз.
Иделдә боз ага. Аксын да!
Народоволка төсле кыз хушлаша
минем белән урам чатында.

Табигать, ул синең саф сулышың,
ничек җиңел оча, күр әле!
Ике зәңгәр йолдыз булып
балкый
язгы көндә аның күзләре.

Күккә ясап куйган рәсем кебек
җиңел язын кызлар-сеңелләр.
Шыбырдаша асфальт өсләренә
түбәләрдән көмеш сөңгеләр.

Ах, син, яшьлек, бозлар
челтерәтеп,
яшә яшь дөньяда, гөрләшеп!
Рухлы белән рухсыз көрәше бул,
һәм ут белән суның көрәше.

Күңелләргә кутыр үсә бара,
сиздермичә килә ул картлык.
Яшь чагында яшьлек бик
гади ул,
мәңге яшь булуың — батырлык.

Апрельдә рус даһие туып,
җир өстенә җәйгәч кулларын,
йөз ташулар узды, алмагачлар
йөз кат чәчәк атты язларын.

Анда — Пугачев һәм Стенька
Разин,
Пушкин, Некрасовлар яктысы,
Герцен үче, Маркс акылы бар—
тарих язган рольнең яхшысын.

Мавзолейга килеп башны иик.
Башны иик һәйкәл-сыннарга—
хөр фикерле яшьлек идеалына
тугрылыклы уллар-кызларга.

Пушкиннарча азатлыгың өчен,
изге уллар — батырлыгың өчен,
һәрчак хаклык сөйгән халкың
өчен,
рус шигыренең кыю холкы өчен,
һәм Володя Ульяновың өчен,
килер Ульяновлар өчен тагын,
такмакларың, табигатең белән
мин яратам сине, Ватаным!

Марс ШАБАЕВ тәрҗемәсе.

# Нодар Думбадзе,

грузин язучы:ы

# ХАЗАРУЛА

хикәя



Аның белән беренче тапкыр сөйләшкәндә миңа ундүрт яшь иде. Ә ул инде илле биш-алтмыш тирәсендәге алмагач — дәүәнинең яшьтәше дисәң дә була — Хазарула дип йөртәләр үзен.

Әле дә хәтеремдә: кыш җитү белән дәүәни аның җимешләрен Тбилисига төяп килә. Авыл исе сеңгән вокзалдан туп-туры минем йокы бүлмәсенә килеп керә ул, кочаклап ала һәм карап торырга әллә ни матур да булмаган салкын алмаларын суза:

— Бу, улым, безнең Хазаруланыкы. Алмасхан Дафиносы маңгаедай җыерчыклы инде дә, тик син аңа игътибар итмә. Ач карынга дөньяда моннан да тәмле ризык юк. Аша, улым, аша...— ди.

Аннан соң мин авылга күчеп кайттым. Хазарула белән шунда таныштым.

Хазарула ишегалдының йөзем сыту, шәраб тутырылган зур кувшин — квевриларны саклау өчен җайлаштырылган бер почмагында үсеп утыра. Биек, юан кәүсәле, киң ябалдашлы алмагач иде ул. Картаймыш көнендә кәүсәсе куышлана башласа да, Хазарула нык һәм матур иде әле. Ботакларына чүлмәк, шәраб соскычы, кувшиннарны кырып чистарта торган кыргычлар эленгән. Ямь-яшел килеш утырса да, өч ел инде чәчәк атмый, җимеш бирми икән алмагач.

Язның бер көнендә дәүәни мине бик иртә уятты. Кулында ялтыравык йөзле кайралган балта иде.

— Син нәрсә? — дидем мин, курыккан кешедәй, һәм одеал астына кереп яшерендем.

— Кыланып ятма, әйдә. Колагыңнан сөйрәп төшергәнче тор да эшкә тотын! — дип, дәүәни ачулана ук башлады.

— Нинди эш ди ул иртә таңнан?

— Шундый эш... Ир-ат кулыннан гына килә торган... Ә ул әле үчекләп яткан була! Хатын-кыз, янәсе, хисаплашып тормасаң да ярый! — дип, дәүәни йөзен җыерды.

— Кем турында син? Әллә бригадир-фәлән килгән идеме?

— Күп сөйләшмә, әйдә. Тор!

— Торам инде, торам... Шулай да, кем турында сүз?

— Хазарула турында, кем турында булсын! Ояты да, намусы да юк ул алмагачның! Шулай алдасын инде?!

— Сине нәрсә, алмагач алдадымыни?

— Шул үзе!

— Алмагачмы?! — дидем мин, үз колакларыма ышанасым килмичә.

— Алма бирмәгәч, нинди алмагач ди ул? Алмагач түгел — утын!

— Һәм мин аны кисеп ташларга тиеш... Шулаймы?

— Юк, башта куркыт кына. Акыл кермәсә — кисәбез дә ташлыйбыз, хаҗәте бер тиен! Ниемә кирәк ул.

Дәүәни алмагачны ничек куркытырга икәнне әйтте дә, балтаны минем янда калдырып, ишеккә юнәлде.

— Тыңлар дип уйлыйсыңмы? — дип көлдем мин.

— Яшисе килсә — тыңлар!

— Ә син кая?

— Аның белән икәүдән-икәү калып сөйләшергә кирәк,— диде дәүәни һәм чыгып китте.

Мин, балтаны кулыма тотып, ишегалдына төштем, алмагач янына килдем.

Хазаруланың бөреләре бүртенгән иде.

«Әллә чыннан да кеше телен аңлый микән?» — дип, уйлап алдым мин һәм елмайдым. Аннан балта сабын кысып тоттым да бар көчемә агачка кизәндем, әмма чапмадым, кулны ярты юлда туктатып калдырып, балта йөзе белән Хазаруланың тамырына кагылдым һәм Гамлет монологындагы кебек уйчан тавыш белән:

— Кисәргәме, кисмәскәме? Ки-сәр-гә-ме, кис-мәс-кә-ме?! — дидем.

Шуннан соң беравык тын гына тыңлап тордым, җавап ишетелмәгәч, барсына да кул селтәп, алмагач кына түгел, шунда аунап яткан таш квеври капкачы да аңларлык итеп:

— Әй, кадалып китсен сәнә, тагын бер ел көтик. Алмасы булса — булыр, ә булмаса — үзенә үпкәләсен, кисәм дә аударам гөрселдәтеп. Беркая да китә алмас! — дидем.

Дәүәнинең боерыгын үтәгәч, Хазарулага тагын бер күз салдым. Аның исе дә китми, тау артыннан күтәрелеп килгән кояш нурларында иркәләнеп утыруын белә.

Бу минутта мин үземә-үзем көлке булып тоелдым һәм, балтаны алмагач төбендә аунап яткан бүрәнә астына яшереп, өйгә кердем.

— Ну ничек? — диде дәүәни.

— И-и ничек кенә курыкты әле, калтырана ук башлады! Әнә күр!

Мин алмагачка төртеп күрсәттем, шулвакыт чыдый алмыйча көлеп җибәрдем — Хазаруланың ботаклары, чыннан да, тирбәлә, яфраклары шыбырдаша иде.

...Менә яз да үз көченә керә. Ул, Губазоули ярыннан чыгып, безнең ишегалдына үтте, яланаяклы, ярым шәрә кыз сыйфатында яңа шытып чыккан үлән өсләреннән атлап узды, бөтен тереклек ияләрен уятып, алгысытып җибәрде.

Миндаль һәм ткемали, слива һәм груша чәчәк атты... Ә Хазаруланың йокыдан уяныр гә һич исәбе юк, ни уйлый торгандыр, ходай үзе белсен.

Көннәрнең берендә дәүәни мине тагын иртә таңнан уятты. Уятты да, кулы белән алмагачка күрсәтеп, әйтте:

— Күз сал әле Хазарулага, улым!

Алсу күлмәк кигән Хазарула, безне күргәндәй, елмаеп карый иде.

— Исең-акылың китәрлек! — дидем, мин, соклануымны яшерә алмыйча.

Әйе, Хазарула шау чәчәктә иде. Аны умарта кортлары сырып алган! Аннан җимешләре дә күренде — нинди генә әле! Безне ул варенье, киптерелгән алма, аракы белән сыйлады — безне генәме соң! Алма ашаудан тешләре камашып беткән терлек-туар аны әйләнеп уза башлады. Һәм мин иртә саен күрше Теофан Дугладзе сыерына кәрзине белән алма кертә идем.

Бер көнне түземе беткән Теофан миңа болай диде:

— Карале, күрше, ташыма син безнең сыерга моннан соң алма, ату сөт урынына алма компоты эчә башладык!

— Бу ниткән эш инде, Хазарула, ә? Кая куеп бетерик инде бу тиклем алманы! — дидем мин аңа көзен ботагыннан соңгы алмаларны бәреп төшергәндә.

— Рас алмагач дип аталасың икән, ярамый шунсыз! — дип, карт буыннарын шыгырдатып, җавап бирде ул.

Бу аның соңгы талпынуы иде. Ничек кенә үгетләп, үтенеп, куркытып карамадым — барысы юкка. Шул җәйдән соң Хазаруланың ботакларында бер генә алма да күренмәде.

...Ике елдан соң бер көнне квевридан шәраб алып ятканда, дәүәни күккә карап алды да, нәрсәнедер ошатмыйча, үзалдына әйтеп куйды:

— Кичкә таба кар төшәчәк... Харап булабыз утынсыз... Хазаруланы кисәргә кирәк...

— Дәүәни, әллә тагын бер ел көтәбезме? Яз житкәч тагын сөйләшеп карармын, куркытырмын,— дидем мин.

— Юк, улым, хәзер инде аңа бернинди куркыту да ярдәм итмәс...— диде ул моңсу тавыш белән.

— Мин аны кисмәячәкмен! — дип кычкырдым мин.

— Ничек инде кисмәячәксең?! Мин сиңа кем, дәүәниеңме, әллә урам хатынымы — тыңламаска?

— Дәүәнием, әмма Хазаруланы мин барыбер кисә алмыйм,— дип киреләндем мин.

— Ник? — Ул миңа гаҗәпләнеп карады.

— Болай! Үзең бит агач барысын да ишетә, аңлый, ди торган идең.

— И-и улым, карчык кеше нәрсә әйтмәс! Агач әле бер хәл, монда кешеләр дә бер-берсен аңламыйлар. Мин бит сиңа шаярып кына әйткән идем, ә син ышангансың! — дип, карчык мине йомшатмакчы булды.

— Кисмим и вәссәлам! Ул бит безне ишетә генә түгел, күрә дә бит әле! Әнә, күрәсеңме, безгә аркасы белән борылган! — дип, мин агачка күрсәттем.

— Я хода, ниләр ишетәм мин! — дип, дәүәни кулларын күтәрде.— Синең нәрсә, акылыңа зыян килмәгәндер бит? Үзем, үзем гаепле! Шул кирәк миңа, акылсыз карчыкка! Күршеләр, авылдашлар, ничек тынлатыйм мин бу малайны. Зинһар, ярдәм итегез! О-о-о!

— Ни булды, Дарежан, нәрсә кычкырынасың? Алай кычкырынырлык нәрсә эшләде бу малай? — дип сорады шунда үтеп баручы Анания Селуквадзе һәм безнең ишегалдына борылды.

— И-и хөрмәтле Анания, сорама да инде!.. Сорама да!.. Узган ел мин аңа Хазаруланы куркытырга кушкан идем... Хәзер менә кисеп аудар дим, ә ул тыңламый! Агач та кешене аңлый, ди, кисмәскә итә! — дип, зарлана-зарлана дәүәни күршегә кызгылт шәраб салынган стакан сузды.

— Үзеңә дә, нигезеңә дә ходай иминлек бирсен, хөрмәтле Дарежан! — Анания стаканны шундый ләззәт һәм аппетит белән бушатты, минем авыздан сулар килде.— Кешене аңлый, ди инде алайса! — дип кабатлап сорады ул.

— И-и аның сүзенә карасаң, агач безне аңлый гына түгел, ишетә дә икән әле! Монда малайның гаебе юк, күп сөйләнеп үзем боздым малайны, үзем гаепле!

— Шәраб эчмәгәндер бит!

— Эчте...

— Алайса, сал әле тагын берне, хөрмәтле Дарежан, малайны нәрсә бозганны шуннан соң әйтермен — синме, әллә шәрабмы,— дип елмайды Анания.

Дәүәни стаканны тутырды. Анания сүзсез генә анысын да бушатты, беравык тын торгач, әйтте:

— Минемчә, монда гаеп икегездә дә бар: синдә дә, шәрабта да... Мәсьәләне ачыклау өчен сал инде тагын берне!

Дәүәни бу юлы да стаканны тутырды, әмма күршегә шундый итеп карап алды, Анания урынында булсам, шәраб тамагымнан һич үтмәс иде. Ә Анания исә дә китмичә эчеп куйды, аннан нәтиҗә ясады:

— Менә нәрсә, хөрмәтле Дарежан, гаеп, әлбәттә, тулысы белән шәрабка төшә. Ләкин бу әле куркыныч түгел. Хәзер мин ул малайның арт сабагын укытачакмын... Агач кешене ишетә дисең инде алайса? — диде ул, минем күзләремә карап.

— Ишетә! — дидем мин.
— Ә таш?
— Таш та ишетә.
— Елга да ишетәме?
— Ул да!
— Ходай сәламәтлек бирсен сиңа, улым... Ә беләсеңме, хөрмәтле Дарежан, кызык бит әле бу. Әйтик, менә сез... Үзегезне, мәсәлән, менә шул Хазарула урынына куеп карагыз... һәм сез, кире беткән шушы малай әйткәнчә, барысын да ишетеп һәм аңлап торасыз... Һәм сезнең янга минем кебек бер ир килә, ди... Кулында балта... Һәм сезне кисеп аудармакчы. Сез моны күреп, аңлап торасыз, ә менә качып китә алмыйсыз. Ә? Ничек? Монда, дөресен әйтергә кирәк, акылыңа зыян килүе дә бар.— Anания дәүәнигә тагын стаканын сузды, тегесе исә күрмәмешкә салынды.— Сал тагын берне, мин бит әле сиңа иң мөһимен әйтмәдем!
Дәүәнигә бу юлы да стаканга шәраб коярга туры килде. Anания әчеп куйды да миңа карады:
— Син шәһәр егете инде, әлбәттә... Әмма сиңа да мужик күңелен аңларга вакыттыр... Крестиян нәрсәне өендә тотмас? Кысыр сыерны, җимеш бирмәгән агачны һәм бала тапмаган хатыны...— Anания шунда лып тукталып калды, сиздерми генә дәүәнигә карап алды.
— Син нәрсә, Anания?—дип көлемсерәде дәүәни.—Балаларың булмаса, бу кире беткән кайдан килер иде?
— Ие... һәм дә бала тапмаган хатынны... Ә синең дәүәниең үз гомерендә җиде бала тапты. Аңладыңмы инде?
— Ә миннән ни кирәк сиңа, Anания абый? — дидем мин.
— Нигә алмагачны кисмисең? — дип сорады ул.
— Җәллим.
— Нәрсәне җәллисең? Алмагачнымы?
— Мондый җебегәннәр кулына калсак, хәлләр мөшкел! — дип куйды дәүәни, авыр сулап.
— Алай димә, хөрмәтле Дарежан! — Ananиянең йөзе кырысланып китте.
— Әйтмәс җиреңнән әйтерсең! Тавык суярга курка — җәл! Кәҗә бәтиенә дә тими — җәл!.. Былтыр әнә яңа ел алдыннан дуңгыз суярга кушкан идем, дуңгызын Интабуети[1] яныннан тотып апкайттылар. Шул буламы эш?!
— Дөресме шул? — диде Anания.
— Дөрес, Anания абый, һәм ташла син ул нотык укуларыңны. Хазаруланы барыбер кисмәячәкмен!
— Димәк, җәллисең?
— Әллә җәл түгелме?
— Алайса, кирәгең юк!.. Тагын берне сал да, хөрмәтле Дарежан, иртәгә иртән Хазарула бусага төбенә ятар. Бүген миннән эш чыкмас...
Дәүәни тагын салды. Anания монысын да каплады, сүз уңаеннан гына әйткәндәй, сорап куйды:
— Ә капкалап алырга берәр нәрсәң табылмасмы, кадерле Дарежан?
— Әнә, озын казык бар, хөрмәтле Anания, сыртыңа кирәкмиме?
Anания бер сүз дә дәшмәде, торды да, ишегалдыннан чыгып, югары очка менеп китте.
— Кая китүең, хөрмәтле Anания, син бит бая аскы якка төшеп бара идең?
— Эш белән чыккан идем дә, кадерле Дарежан, кайтыйм инде, миннән хәзер файда юк, председательнең йөзем бакчасы кебек мин хәзер!
— Алайса син Шакрой читәне буйлап барырга тырыш. Менеке бит болай да аварга тора! — дип үтенде дәүәни.

[1] Интабуети — авыл исеме.

Анания юлны аркылы чыкты да Шакрой читәненә килеп сөялде. Минут чамасы шулай торгач, безгә борылды:

— Хазарула күрә дисең инде, ә? Хе-хе-хе!.. Минем, агайне, үз күзем дә берни күренми, Хазаруланыкын әйткән дә юк инде! Хе-хе-хе...— Аннан ул, алпан-тилпән атлап, китеп барды.

Егет хаклы иде. Корый барган шәрә агач барысын да күреп, ишетеп торды. Хазарула авыр уйларга бирелде. Төн уртасы җиткәндә йөрәк тибеше ешайды һәм ул җиргә күмелгән кувшинны урап алган тамырларын хәрәкәткә китерде, чытырдатып кеврины кысты. Менә кеври сискәнеп китте. Хазарула аны ныграк кысты, кеври чатнап китте, аңарда беренче әзләр хасил булды. Ярыктан саркып чыккан кызгылт сыекча алмагачның тамырларын чылатты. Хазарула сәер сыекчаның беренче тамчыларын акрын гына, сакланып кына эчте. Һәм шулвакыт тәне буйлап таныш булмаган калтырану узды. Тора-бара бу калтырану рәхәт талгынлыкка, изрәүгә әверелде. Хазарула кувшинны тагын да кысарак төште һәм кеври берничә җирдән ярылып китте. Бәреп чыккан сыекча коры җәйне яуган яңгыр кебек иде.

...Яшьрәк чакта ул тамырлары җиргә китмәгән адәм затының аягүрә басып торуына, хәрәкәтләнүенә, хәтта йөгерә дә алуына гаҗәпләнә иде. Соңрак бу хакта уйланмый башлады, чөнки мондый катлаулы сорауга берәүнең дә җавап бирә алмаячагын аңлады.

Менә бүген дә бер могҗиза булды: кеври бушап калды, Хазарула кувшин эчендәге сыекчаны соңгы тамчысына кадәр чөмереп бетерде һәм, шулай итеп, кешенең дә, сәер сыекчаның да серен ачты... Хәзер ул кешеләрнең ни өчен кочаклашуларын да, кулларына касә тотып, елашуларын, җырлап-биеп алмагач тирәли йөрүләрен, уен-көлке арасында көтмәгәндә сугыша башлауларын — барысын, барысын да аңлады кебек. Һәм аларның шундый да ихтирам һәм хөрмәт белән көзләрен кеврига кызгылт сыекча тутыруы бер дә гаҗәп түгел иде... Шушыны белгәч, Хазаруланың да иркенәеп җырлап җибәрәсе, йөгереп китәсе, биисе килеп китте, ләкин ул боларның берсен дә башкара алмады — чөнки адәм заты түгел, ә гади бер агач кына иде. Шуңа күрә Хазарула кулыннан килгән белән чикләнергә булды — таңга хәтле кәүсәсен шыгырдатты, дулый-дулый ботакларын сызгыртты.

Ә иртәгесен... Иртәгесен кемдер Хазаруланың янтыгына китереп сукты. Сукты дип, Хазарула әллә ни авырту сизмәде, шуңа күрә игътибар да итмәде. Аннан тагын суктылар, тагын, тагын, тагын. Бу хәл бер сәгать чамасы дәвам итте. Берзаман Хазарула үзенең бер якка янтая башлавын сизде. Нindидер көч аны бер якка тарта һәм ул бу көчкә торган саен ныграк бирелә иде. Шулвакыт нindидер шытырдау ишетелде, Хазарула чайкалып китте, ава ук башлады — башта акрын гына, аннары тизрәк-тизрәк. Гөрселдәү тавышын, кул, кабырга, кулбашлар сынуын, буыннарның шартлап өзелүен Хазарула берүк вакытта ишетте, әмма нилектәндер авырту сизмәде. Аннан күзләрен йомды һәм йокыга талды...

— Улым, тор, Анания алмагачны кисте! — дигән тавыш мине йокыдан уятты.— Әнә, балта ал да ботакларын туна.

Дәүәнинең сиземләве дөрескә чыкты. Төнлә кар төште. Чиста итеп бизәнгән авыл туй күлмәге кигән кәләшкә охшап калды. Безнең ишегалдының гына яме юк — анда, мәет кебек, киселгән карт алмагач ята.

Егып салынган агач янына килеп баскач, мин шаклар каттым — алмагач кәүсәсеннән кызгылт сыекча саркый иде!

— Дәүәни! — дип кычкырдым мин.
— Ни бар тагын?
— Кил әле монда!
— Тагын ни булды?
— Кил әле, кил, күрерсең!

Дәүәни минем янга килде.

— Бу ни тагын? — диде ул гаҗәпләнеп.
— Белмим шул... Кан, ахры...
— Мөмкин түгел! Гыйнварда агачлар әле йоклый. Сутлары февраль аенда гына уяна...— Дәүәни сакланып кына сәер сыекчага бармагын тидерде, аннан йөзенә якынрак китереп, иснәп карады һәм куркынып миңа карап алды.— Әйдәле, ач әле квеврины!

Мин тиз генә кувшин капкачын ачтым. Квеври буш иде.

— Я хода, изге Мария, ярлыкагыз без бәндәләрне! — дип, дәүәни кулларын күккә күтәрде дә җиргә тезләнде.

Шулвакыт Хазарула туңудан уянып китте. Гайре гадәти хәлдә яткан-га дөнья аңа сәер булып күренде. Башта күзләренең әлҗе-мөлҗе килүен ул утлы сыекча эчү галәмәтедер, дип уйлады. Аннан, янында озын саплы балтага таянган егетне һәм тезләнгән килеш күккә караган кара киемле карчыкны абайлап алып, үзенең соңгы минуты килгәнлеген аңлады һәм күзләрен йомды.

Инде мәңгегә.

Солтан **ШӘМСИ** тәрҗемәсе.

**Ояр Вациетис,**
латыш шагыйре

# БАЛАЛАР ӨЧЕН ШИГЫРЬЛӘР

## Күлдәвек

Зәңгәр күлдәвек
Әллә магнитлы —
Көн дә үзенә
Тарта Янитны.

Әни тиккә тирги лә:
Әти бит сөйли белеп —
Диңгезләрнең барсы да
Күлдәвек булган элек.

Хәтта капитаннар да,
Вице-адмираллар да...
Күлдәвек яратканнар
Минем яшьтә алар да!

Өлеш тә төшкән! Ә мин
Шуны әйтә аламын:
Сайлап алыйк диңгезнең
Үзебезгә таманын.

Зәңгәр күлдәвек
Әллә магнитлы —
Көн дә үзенә
Тарта Янитны.

## Кушу

Берне бергә кушсаң — ике
була ич.
Ә икене бергә кушсаң —
була өч.

Ә песине кушкан чакта
көчеккә?
Булмас шул берничек тә.

Берсе дерелдәп утыра
әнә агач төбәсендә,
икенчесе —
саклап тора тирәсендә.

## Кояш тәме

— Нәрсә соң бу?
Сары көзме?

— Сөйләмә лә син юк сүзне!
Ул бит кояш.
Кайнар.
Әйбәт.
Мә, кабып кара кояшның
иң тәмле төшен!

Ләкин төшен йота күрмә —
Төкер син төшен!

## Диңгез бүресе турында моңсу җыр

Диңгезгә ыргытсаң бүрене,
ул диңгез бүресе булачак.

ачудан, кайгыдан көн саен
крабларны ул тотып буачак,

һәм диңгез бәрәне дип уйлап,
дулкыннар көтүен куачак.

Бәрәннәр ярата печәнне,
Клеверны, кәлшәне — төрлесен.
Күбекләр — ак бөдрә бәрәннәр
куыша диңгездә бер-берсен.

...Тик аларны ашап булмас. Бик тозлы бит.
Авырттырыр аның эчен.

Шуның өчен —
уламасын өчен бүре кайгыдан,
ташламагыз сез бүрене диңгезгә!
Шуны гына әйтә алам мин сезгә.

## Җирнең тарту көче

Агач үсә өскә таба,
өскә таба — үлән дә,
ә яңгыр ява түбәнгә,
алма да — һәп! — түбәгә!

Ә берәр хәйлә корсаң?
Баштүбән әгәр торсаң?
Булыр дисезме тылсым?
Соң әйдә шулай булсын:

баштүбән торсам әгәр,
алма өскә тәгәрәр!
Торам шулай. Баштүбән.
Аяк-өстә. Баш — түбән.

Булмый шул җирне алдап...
һәп! —
Алма түбән төште.
Җитмәсә авырттырды
иң кирәкмәгән төшне.

Роберт **МИҢНУЛЛИН** тәрҗемәләре.

**Анатолий Емельянов,**
чуваш язучысы

# ХЫРВАР ДИГӘН ТЫН АВЫЛДА...

хикәя



әр язны, чама белән апрель башларында, Хырвар авылы кешеләре көтүче эзли башлыйлар. Урман эченә утырганга күрә, авыл бәләкәй, кыр һәм болыннары да ул кадәр иркен түгел, крестьянга әллә ни җәелеп китәргә мөмкинчелек юк. Колхозның үзәк утары — башкарак нәрсә, анда кырлар да зуррак, юллар да төзегрәк, чөнки халыкның күбрәге шунда яши. Хырварлыларның да байтагы үзәккә күчеп китте, шулай булгач, авылда кырыклап кына йортның утырып калуы бер дә гаҗәп түгел. Хуҗалар аз икән, димәк, авылда маллар саны да аз, ә инде санаулы мал артыннан йөгерергә теләсә кайсы көтүче атлыгып тормый дигән сүз, чөнки аның да зур көтү көткәннән алган акчаны кесәсенә саласы килә бит. Һәм менә нәтиҗәсе: үзәк усадьбадагылар бер җәйдә сыер башына кырык сум түләсә, хырварлылар исә бер сыер көткән өчен илле сум бирергә мәҗбүрләр.

Тыныч авыл, тыныч тормыш, көтүче мәсьәләсе генә бәла: кырык яки кырык биш сумга тотанаклы, эчми торган көтүче табу шактый кыен эш, риза түгелләр, ә инде илле сум түләү ничектер кызганычрак. Һәм менә апрель җиткән саен хырварлылар баш артын кашый: ни эшләргә, ни хәл кылырга?

Дөрес, авылның үзендә бер көтүче бар барын, әгәр шулай әйтергә яраса, тумыштан көтүче — Осип дәдә, ахыр чиктә аңа ялварырга була, әмма, әйтүләренә караганда, быел ул да тиз генә бирешмәскә ниятләнә, имеш. Өстәвенә, шундый бәйләнчек ул, мал хуҗаларын тынгысызларга да күп сорамый. Шуңа күрә көтүне Осип картка тапшыру иң соңгы чиктә генә булырга мөмкин.

Хырварлылар апрельнең беренче атнасын уздырдылар — читтән бер-бер хәбәр килеп чыкмасмы, янәсе. Икенче атнаны авыштырдылар — көткән кешеләре күренми. Нишлисең, Осип картны ялларга кала, әйдә, тагын бер җәй көтеп карасын әле...

Авылда клуб сыманрак бер нәрсә бар: иске, ләкин бүрәнә-почмаклары таза (утызынчы еллар бурасы). Апрельнең соңгы якшәмбесендә хырварлылар Осип картны тагын бер җәйгә күндерү өчен шушы клубка җыйналдылар. Саргая һәм таушала төшкән утыргычлар рәтенә яше һәм карты берәм-берәм урнаштылар. Осип дәдә бригадир Илюша белән килгән иде. Яше җитмешкә җитсә дә, ул әле нык һәм күркәм күренә — кара чәче чал чәчләр белән аралашкан, сакалы һәм чигә тирәләре пөхтәләп кырылган, аякларын өстерәми генә туры атлый, башын гадәттәгедән чак кына күтәрә төшкән. Як-ягына карарга вакыты да юк шикелле.

Бригадир белән туп-туры сәхнәгә, юылган лозунг чүпрәге ябылган өстәл янына уздылар. Бераз утырып тордылар, аннары бригадир Илюша баскан уңайга йодрыгын күтәрә төшеп тамак кырды.

— Иптәшләр,— диде ул, шундук үз сүзләренә кечкенә генә төзәтмә кертте:— Дуслар, иптәшләр, Хырвар авылы кешеләре! Осип Ермолае-

вич — безнең чын мәгънәсендәге олы ярдәмчебез. Әгәр көтүне чиратка куйсак, күпме кешебезне эшеннән вакытлыча аерырга туры киләчәк. Безнең бригада, иптәшләр, үзенә тигән эшне һәрвакыт намус белән үтәп килде. Инде өченче ел рәттән безнең бригадага колхоз идарәсе һәм парткомының күчмә вымпелы тапшырыла. Әлеге вымпелда безнең хөрмәтлебез Осип Ермолаевичның өлеше дә зур. Колхоз идарәсе һәм авылдашлар исеменнән, Осип Ермолаевич, бүген сиңа зур рәхмәт белдерәсем килә.

Залдагылар кул чапты, әлбәттә, кайберәүләр үзалдына елмаеп куйдылар. Бригадир дәшми торды, аннары авыр сулап, акрын гына әйтте:

— Ә хәзер мал-туар көтү турында Осип Ермолаевичның безнең белән килешү төзүен сорыйбыз.

Залда шау-шу, үзара сөйләшү китте, нәкъ шул чакта Осип карт нидер әйтмәк булып урыныннан күтәрелде. Бригадир шундук:

— Менә хәзер ул үзе әйтер,— диде һәм сәхнәдән төште.

Карт ялгызы калды. Күзләрен хәйләкәр кысып куюы һәм мыек астыннан гына елмаюына караганда, Осип дәдә күңелле күренә иде бүген. Кәефле күренеме — аңардан берәр мәзәк көт тә тор.

— Крестьяннар! — диде Осип көчле тавыш белән, үзе колакка каты булганга күрә башкалар да начар ишетә дип уйлый иде ул.— Җир кешеләре! Осип дәдәгезне онытмаган өчен рәхмәт сезгә! — Бу урында ул берара күзләрен зал буйлап йөретеп алды: — Үзегез беләсез, мин сугыштан рматиз белән кайттым. Докторлар йөрергә кушмады. Ә карчык әйтә, күбрәк йөр, ди. Йөрүдән туктама, рматизың бетәр, диде. Әгәр буыннарың майламаган күчәр кебек шыгырдый икән, ничек инде оялмыйча йөрисең ди! Карчык мунча якты һәм мине солы суына утыртты. Файдасыз! Ярый, ак балчыктан ләм ясый бу. Ләмдә дә утырдым. Ярдәме бармы? Юк. Нәрсә эшләргә? Карчык минем беткәнче акыллы, бер стакан салып бирде дә әйтә: бар, йөр, ди. Эш юктан титаклыйм, ә үзем уйлыйм: нигә әле мин юкны бушка аударып йөрергә тиеш? Әнә шулай көтүче булып киттем мин. Утыз ел инде сезнең малларны көтәм, җир кешеләре, утыз ел, һәм әле кайсыгызның начар көтүче дип миннән зарланганы бар. Әллә алай түгелме, ә? — Карт бу урында уң кулын колагына якын китерде.

Кем инде язын көтүчегә узган ел сыерларны начар көттең, дип әйтсен! Моны көз көне, инде сыерың җылы абзарга кереп бикләнгәч кенә әйтергә мөмкин. Язын көтүчене ачуландырып кара, сөтсез утырырсың. Юк, дәшми калуың хәерлерәк.

Хәйләкәр дә карт соң, ничек оста эләктереп алды!

— Күрдеңме инде, Илюша, һәммәсе канәгать, ә син сөйләнгән буласың!..

Карт залдагы көлүләрнең басылуын көтте һәм тагын чын-чынлап сөйләп китте:

— Алладыр дип әйтәм, дөресе шул: кырык сыер, егерме биш башмак тана, йөзгә якын сарык һәм бәрәннәр — менә бит никадәрле зур көтү, хәтта син дә, Илюша, өч ярдәмчең белән өлгерә алмас идең. Син генә түгел, теләсә кайсыбызны алсак та шулай. Терлекне урманда көтү ул сиңа болын иңе генә түгел. Кайчак ешлыктагы сыерны өч адымнан да күрмисең. Ярый әле этләрем акыллы. Алар булмаса, шул тиклем көтү артыннан мин түгел, шайтан үзе дә өлгермәс иде. Сезгә көлке көлкесен, ә миңа алай түгел: сезнең тыңлаусыз сыер һәм сарыкларыгыз хәтта төшләремә керә. Кайсыгызныңдыр, кыйммәт ала, дип әйткәне бар. Ә сезнең хет бер тапкыр этләремне ашатканыгыз бармы? Юк. Ә бит һава сулап кына тамагы туймый аларның, айга утыз тәңкәне мин әнә шул ярдәмчеләремә тотам.

Карт туктап калды, йөзенә үпкәләүле кыяфәт чыгарды, шул арада сәхнәдән үк төшә башлады.

— Син сораган хакны бирәбез,— диде бригадир һәркем ишетерлек итеп.

— Бирәбез, бирәбез! — Төрле яктан көчле авазлар ишетелде.— Сүзеңне сөйләп бетер!.

Барган шәпкә картның аяклары буталды. Шушы хәтле халык җыелганда Осипның үзенең дә сөйлисе килеп тора иде шул.

— Куптәннән әйтәсем килеп йөри, авылдашлар, менә нәрсә,— Осип карт тагын элекке хәленә кайтты.— Утыз ел эчендә мин шуңа ышандым, мал-туар үзенең хуҗасына охшый икән ул, җәмәгать. Менә алыйк безнең Натальяны. Аның тавышы нинди икәнлекне кайсыгыз гына белми! Вәт шул, мин көткән дәвердә дүрт сыеры булды аның, берсенең дә тавышы чиркәү кыңгыравыннан ким түгел иде. Дөрес сөйлимме мин?

— Дөрес, дөрес! Әйдә, дәвам ит!

— Шул-шул! — Карт кыза барды.— Алдашып утырмыйм лабаса. Яки менә Хәвәдусны алыйк. Син беләсеңме, Хәвәдус? Сезнең сыер да бит тамак ертып кычкыра, һәм аның Наталья сыеры белән дуслыгын күрсәң иде! Ике тавышка көйли башласалар — түзеп кенә тор! Колакка каты булсам да ишетәм үзләрен!..

— Ха-ха-ха! — Залдагылар буылып көлә.

— Әйе... Мал иясенә охшаган шул. Менә син, Силан Терентьевич, почмакта теш агартып утырасың. Кем син? Пәһлеван дип әйтмәс идем. Кечкенә дип тә булмый сине. Русчалатып әйтсәк — середняк. Һәм менә сыерларың да, ялгышмасам — Чирнәүкә, Пегашка, Мимусь... Вәт алар да бит һәммәсе — уртача. Алга да чыкмыйлар, артта да калмыйлар — минем чыбыркыдан куркулары... Вәт, яхшы хәзәйкә сыман төгәл генә, килештереп кенә нәкъ уртада баралар. Юкка-барга тавышланмыйлар да. Ә бер-бер ыгы-зыгы килеп чыктымы, ничек уйлыйсың, Силан, синең Чирнәүкәң нишли инде? Нишләсен, тезләренә таяна, мөгезләрен куя һәм сөзешә башлый. Карахтер! Син, Силан, үзең дә тыныч, салмак кеше, ә менә фронттан дүрт-биш орден белән кайттың. Хырварда тагын кемнең шулкадәр бүләге бар. Берәүдә дә юк! Ә Силанның авылда орден тагып йөргәнен кемнең күргәне бар? Берәүнең дә күргәне юк. Вәт, авылдашлар, шундый ул безнең Силан. Үзе дә тыйнак — сыеры да шул кавемнән.

— Кичәгенәк Силанда сыйланып чыктың шул, шуңа күрә мактыйсың син аны,— дип, Данил Филиппович әңгәмәгә кушылмакчы булды.

Осип карт ишеттеме моны, юкмы — аңламассың. Ул хәтта Данил ягына күз дә салмады, сөйләвен белде:

— Яки әнә Катерина сеңлекәшне алыйк. Үзегез беләсез, күзгә төтен җибәрергә оста ул. Дөрес, ялгызак хатынны моның өчен гаепләргә дә ярамый, хе-хе-хе...

— Син үзең гөнаһлы бәндә! — дип арадан берәү уртага ут җибәрә.

— Ләкин бүген сүз минем хакта бармый, әйткәнемчә, Катерина сыерын кара син. Сыер тек сыер: әкрен, тыңлаучан, әмма зуррак бер кигәвен тешләдеме, койрыгын сыртка салып чаба башлый, һәм ә дигәнче барлык көтүне болгатып бетерә. Андый чакта, брат, бавырың кузгалганчы йөгерәсең инде. Миңа, рматизлы карт кешегә, сыер артыннан чабу түгел, ә чирәмгә кырын ятып папирос көйрәтү хәерлерәк. Өлкәннәр яхшы беләдер: туганнан бирле начар сүзне кычкырып әйтмәдем мин. Сүгенергә, фактически, фәкать Катерина сыеры өйрәтте. Беләдә, клубта, Катерина сеңлекәш сыеры артыннан чапканда урман эчендә әйтелә торган сүзләрне кабатлап тормыйм, әмма ләкин, еккыр-мыккыр, кайчан да булса үтерәм мин ул дүрт аяклы хайванны! Барлык көтүне бутый, туктале шушы, мы — гаепсез нәрсәдәй гөнаһсыз күзләре белән үзеңә туп-туры карап тора. Ах син, кыл койрык, мәйтәм тегеңәр, бу кадәр дә хуҗаңа охшасаң охшарсың икән... Син бит инде унбер бозау анасы, ә үзең яшь танадай кыланасың. Ну, яхшы кешеләр, әйтегез әле, Катерина сеңлекәш

үзе дә шулайрак түгелме? Була, усал-ачулы чакларың, ул сиңа карадымы, һәммәсе онытыла. Дөрес сөйлимме мин, Данил Филиппович?

— Үз башыңа сөйләнәсең, картлач! — Катеринаның үпкәле җавабы шул булды.

Ә залга көлке дулкыны тәгәрәде.

— Менә шулай, хөрмәтле якташлар,— дип сүзен сөйли бирә Осип карт.— Әгәр мин начар сүз әйтәм икән, сез мине кичерә күрегез. Менә син, Тәртәбаш Кузьма, әгәр мин сине саран дип әйтәм икән, гафу ит. Синең сыерыңа да һәрчак нидер җитми. Үлән тезләреннән, ә синең Карлыгачың читкәрәк китеп умыртуны ярата.

— Картлач! — дип җикеренә Кузьма Оглоблин.— Акылдан язгансың. Синең этләрең җәй буе сыерымның койрыгын чәйнәп бетерде. Юкбарны болгатасың...

— Вәт! — дип кычкыра карт.— Кем акылдан язгандыр бит әле. Синең сыерың белән акылдан язу түгел, атаң-анаң кушкан исемеңне дә онытырсың. Минем бит әле рматизм бар. Кичләрен утлы күмер өстендә утыргандай булам. Шулкадәр михнәтләрдән соң рәхмәт сүзең шулмыни?

— Ярар, нәрсә инде,— дип кычкыра Кузьма.— Әйдә, күпме кирәген әйт тә шуның белән вәссәләм. Юкса вакыт юк...

— Менә,— дип әләктерә Осип карт.— Бөтен кеше иркенләп утыра, Кузьманың гына тынлар чамасы юк!

Яңадан көлешәләр, клуб түшәменә көлү дулкыннары бәрелә.

— Чыннан да,— дип кычкыра бригадир Илюша эшлекле һәм кайнар тавыш белән.— Күпме сораганыңны әйт әйдә, килешүгә пичәт сугарбыз.

— Ә-ә, синмени бу, Илюш! — Осип карт, аның белән күптән көрешмәгәндәй, шатлыклы рәвештә сикереп тора.— Мин бит синең сыерың турында сөйләргә онытып торам икән әле.

— Нәрсәсен сөйләп торасың, сыер тек сыер инде.

— У-у-у! Син әле сыерыңның карахтерын начар беләсең икән. Әйтсәм әйтим: сыерың бик ялагай, иркә, нәкъ үзең инде!

— Син лутчы үз сыерың турында сөйлә! — бригадир Илюша чәчрәтеп җавап бирә. Аның йөзендә комачтай кызыллык.

— Үземнеке турында? Үземнең сөтлебикә турында сөйләве кыен, җәмәгать, сез бит аны яхшы беләсез. Иң яхшысы — барып күрү...

— Җитте! — дип кычкырды Илюша.— Сыер асраган буласың, ә үзең сөткә куршеләргә йөгерәсең.

— Сөт бер хәл, ә минем карчык анда бер мичкә сыра кайнатты. Ул бит белә, шушындый көтүче өчен сез кырык биш тәңкәгезне җәлләмәячәксез.

Залдагылар, мәсьәләнең шулай җайлы гына хәл ителүен аңлап, көлештеләр һәм гөрләтеп кул чаптылар.

— Ну и картлач! Ансат кына тәгәрәтте бит, ә?!.

Әмма Осип дәдәнең сөйләр сүзе бетмәгән икән әле. Ул, тынычлык һәм игътибар сорап, кулын өскә күтәрде:

— Җәмәгать! Карчык кайнаткан сыраны эчәргә кирәк. Әйдәгез, миңа кайтабыз һәм шунда сыерлар турында сөйләшүне дәвам итәрбез...

Хырвар дигән тын авылда узган язда көтүчене әнә шулайрак сайладылар. Осип карт табынында нинди сүзләр сөйләнде — анысын тәгаен генә бәрәү дә хәтерләми, чөнки картның сырасы да мул иде, мичкәсе дә тирән иде. Җырдан башка шау-шуның булганын һичкем хәтерләми.

Әгәр сезгә Хырвар урманында булырга туры килсә, биек һәм таза гәүдәле, артыш таягын саперларча оста йөрткән бер картны очратуыгыз бик ихтимал. Бу — шул инде, Осип дәдәй, бередәге көтүче. Аның янында хырварлыларның бер көтү терлеге булыр. Көтү тирәсендә ике соры эт кайнашыр. «Карахтеры» белән алар үзләренең хуҗаларына охшаганнар: усал итеп өрсәләр дә, чит кешегә беркайчан кагылмыйлар.

**Рәшат НИЗАМИЕВ тәрҗемәсе.**

## Юрий Семендер,

чуваш шагыйре

### Карт солдатны күмү

Дүрт сугышта ничә окоп
казыган ул, биргән көчен.
Җир аны үлемнән йолган
кыю, эшчән булган өчен.

Һәм ветеран дөнья куйды...
Җирдән аңа шул ук кадер —
окоплар дәвамы итеп
яшьләр казый аңа кабер...

### Идел тавышы

Дулкыннар ярга яталар
Чылбыр-чылбыр.
Тавышлары колагымда:
«Юл бир! Юл бир!»

Идел, синең юлың бар ич —
ашкын, ашкын!

Салларың бар, ак пароход —
ташы, ташы!

Су түгелдер ярларында —
көчтер, көчтер!
Шуңа күрә дә таләбең:
«Эш бир! Эш бир!»

## Порфирий Афанасьев,

чуваш шагыйре

### Су эзлибез

Җир чокыйбыз — су эзлибез.
Көн эссе. Сынды чыдам...
Бәлки шушы катламнан соң
Чишмәсе бәреп чыгар?!.

Су табылмас бу төштә —
Төкерик лә бу эшкә...

Юк! Ярамый! Эзлик, эзлик!
Хурлык ич ташланган эш.

Аркаң таш булып катса да
Тагын бераз казып төш!

Алдым берне батырып —
Урра! Чишмә ялтырый!

Су эзлибез — һәм табабыз!
Зуррак шатлык бармы соң?!
Сусаганнар, су эчегез —
Сусыныгыз басылсын!

### Дуслыкның нигезендә

Йөрәгем чатнап китте дә,
мин түзмәдем, инәлдем:
«Тизрәк килеп җитә күрче!..»
«Вакытым юк!..» — димәдең.

Миңа якты шатлык иңде.
Аңа синсез тимәдем.

«Тизрәк килеп җитә күрче!..»
«Вакытым юк!..» — димәдең.

Күңелне бүлешә алу
дуслыкның нигезендә...
...Ә мин килә алырмынмы
чакырган мизгелеңдә?..

Юк, булмады инде...
Зинһар кичер.
Чаткы чатнамады күңелдә.
Хатларымны минем тәмам
онып —
Алар башка кызга иделәр.

Һәм кочма да.
Барыбер җылысы юк.
Калтырата...
Салкын җилмени...
Көзге агач, сары яфрак ябып,
Җылыталмый инде күңелне...

Чувашчадан **Р. ХАРИС** тәрҗемәләре.

## Любовь Мартьянова,

чуваш шагыйрәсе

Нахак сүзләр әйтеп,
дусны сатып җибәргәнче —
телдән язу хәерлерәк.

Җирнең гөлен изеп,
файдасызга тик йөргәнче —
аяк булмау хәерлерәк.

Илне ташлап, читтә
солтан булып яшәгәнче —
җанны җую хәерлерәк.

Юк, сүндермә!
Яңа башлаган учакны
Син сүндермә —
янсын!..
Сине җылытмаса, әйдә,
ул бүтәнгә калсын.

Башка берәү өчен бар дәртенә
ялкынланып яна —
кул күтәрмә аңар!..
...Минем нәни учагымны
Син
сүндермә...

### Ишкәксез көймә

Ишкәксез бер көймә кузгалды —
кемнеңдер өзелгән төшедәй,
куркынган елмаю ишедәй,
иманын югалткан кешедәй...

Кирегә һичкайчан кайталмас,
каршыга йөзәргә җан атмас,
ярдәмгә килергә җай тапмас —
ишкәксез кузгалды бер көймә...

Тормыштай кайнаган дәрьяда
кузгалды ишкәксез бер көймә...

Зиннур **МАНСУРОВ** тәрҗемәләре.

# Атнер Хузангай

# ЙӨЗ МЕҢ СҮЗ...

Шигърияттә мәңгелек булган, вакыт узу белән генә юкка чыкмый торган мәсьәләләр бар. Алар эчкәредә яткан хакыйкатькә, шигъриятнең асылына кагылышлы мәсьәләләр. Шуларның берсе — традиция һәм новаторлык турындагы, әдәби традицияләр «таушаткан» сүз белән көрәш барышында яңа шигъри сүз өлгереп чыгу турындагы мәсьәлә. Бу процесс иң әүвәл шагыйрь миссиясе белән бәйле. Шагыйрьнең кылганы һәрвакыт традицияне вату, үзгәртү һәм яңа, алдагы күкрәүләр авазы салу ул. Шигърияттә яңа сүз иң элек телнең субстанциональ табигатенә яңача мөнәсәбәт, сүзләрнең мәгънәсен, яңгырашын үзгәртү белән бәйләнгән. Һәм хәтта күпмедер дәрәҗәдә шагыйрь үзенә генә хас булган, үз телен барлыкка китерә дип тә әйтергә мөмкин.

Яңа һәм традицион шигъри сүз турындагы, аларның хәзерге күпмилләтле шигъриятгәге катлаулы мөнәсәбәте турындагы мәсьәләне минем үткәндәге фольклор сүзе һәм индивидуаль, шигъри сүз нисбәте аша күздән кичерәсем килә. Хәзер традицион мәгънәдә аңлашыла торган фольклор, халык әдәбияты юк, дип әйтәм икән, бу арттыру булмастыр (һәрхәлдә, Урта Иделдәге фин-угыр халыклары һәм төрки халыклар өчен). Эчке мәгънәгә ия булган саллы халык сүзен сагыну, юксыну бар, «кара туфрактан орлык булып шытарга» хыялланган шагыйрьләр бар. Ә гомумән алганда халык иҗаты, халык сүзе күп кенә милли әдәбиятларда хәзер антик әдәбият сыман ниндидер бер борынгы хәзинә итеп кабул ителә башлады.

Икенче яктан карaганда, фольклордагы тотрыклы, специфик милли образлар саклана, кучеп бара. Әйтик, татардагы былбыл, тирәк, гөлләр, таң җилләре, чувашгагы имән, өянке, карлыгач, урманга бәйләнешле метафоралар һ. б. Болар һәммәсе культураның яшәештәге потенциалын, җирлеген, тамырларын тәшкил итә. Милли культураның тамыр системасы булмаганда язгы саф үләннәр дә була алмас иде; яңа яшеллек, үз сәгате җиткәч, табигать законнары буенча кичәге, үткәндәге аша калкып чыга, җирдән тормыш сүле ала. Дөрес, бу — традицияләр белән новаторлык арасындагы идеаль нисбәтне чагылдыручы метафора гына. Чынлыкта, шигъриятнең үзендә башкачарак. Монда көтелмәгән борылышлар, зигзаглар да булырга мөмкин.

Мин илебезнең күпмилләтле яшьләр поэзиясендә шушы процессның чагылышы турында сөйләмәкче булам. Аның аерым аспектларын, кайбер поэтик шәхесләрне— әйтик, чуваш Геннадий Айги, башкорт Равил Бикбаев, татар Равил Фәйзуллин кебекләрне һәм яшьрәкләрне телгә аласым килә. Уемда — шушы яңа шигъри төбәкнең гомуми планын бирү, координатларын билгеләү, хәрәкәт сызыкларын сызу. Моны алдан ук үземне аклап кую өчен әйтүем, чөнки бу тема һәм проблема үз әдәбиятын һәм аның иҗатчыларын яхшы белгән тәнкыйтьчеләрнең кулга-кул тотынып эшләвен таләп итә. Әлегә исә хәтта Идел-Урал төбәгендә дә, ягъни чуваш, башкорт, татар тәнкыйтьчеләре арасында да элемтә, бәйләнеш җитәрлек түгел.

Поэтиканың яңаруы ирекле шигырьнең шактый киң таралуы, лирик фикерне турыдан әйтү нәтиҗәсендә сюжетлы шигырьнең кысрыклануы, сурәтләрнең ассоциатив бәйләнеше һ. б. халык башлангычларын радикаль инкарь итү яисә милли йөзне югал-

ту дигән сүз түгел иде. Киресенчә, яңа формалар эзләү миллилекнең асылы турындагы мәсьәләне кискенрәк куйгандыр, ул, этнографик нәрсә яисә характерлы милли пейзаж булудан бигрәк, фикер яссылыгына күчерелде. Шигырьдән иң элек фикер таләп ителә башлады.

Алтмышынчы еллар уртасындагы чуваш поэзиясенә мөрәҗәгать итәбез икән, нәкъ менә шул чакта яшьләр арасында бөтендөнья рухи культурасының әлифләрен активрак үзләштерү барганлыгын күрербез. Яшьләрне иң элек Бетховен, Рембо, Ван Гог кебек олуглар кызыктыра иде. Көч-куәт җитәрлек иде, алар якындагыны гына түгел, еракталгыны да үзләштерергә ашыктылар. Ул чактагы пафос күпмедер дәрәҗәдә хәрәкәт мотивыннан килеп чыккандыр. Чуваш әдәбиятында боларның һәммәсе Геннадий Айгидан башланып китте. Аның «О, тимер юллар тимере сагындыра!» дип аваз салуында юл дәрте, үзе өчен дөньяны, илне ачу теләге чагылды. Яки менә икенче бер шигырьдә дә шул ук тема:

Русь! дигәндә күз алдында
Офыклар аһәңе яктыра...

(Юлга-юл тәрҗемә.)

Хәер, яшьрәк буын чуваш шагыйрьләре бу хәрәкәт мотивын тышкы хәрәкәт, урынны алыштыру, каядыр бару итеп, шул еллар романтикасы рухында гына аңладылар. Ә Айгиның үзе өчен «хушлашулы тимер юл офыгы» шул китүләрдә, хушлашуларда, билгесез киңлекләргә ташлануда хисләрнең чынлык мизгеле булу белән кадерле иде. Шартлар шундый — күнегеп торырга, алдашырга вакыт юк. Шагыйрь сафлык өртелгән тойгыны шушында таба.

Билгесезлек каршында кешенең эчке халәте булган сафлык «балачак», аерылышу, ялгызлык, үлем (якыннар белән бәхилләшү) темаларында үсеш ала. Шул арада Айги шигырьләрендә хәрәкәт яшәешнең тиз алмашынып торган тәэсирләрен теркәү ысулы булудан бик ераклаша. Ул эчкәре таба китә һәм катлаулы ассоциацияләр, метафорик читләтеп әйтүләрнең бөтен чылбырын да үз артыннан ияртә. Шигъри телнең синтаксисы һәм бөтен агышы үзгәрә. Айги сүзе чуваш әдәбиятында да яңа сүз. Мондый мәгънәви киеренкелекнең, сүзләрнең үзара шулай берегүенең, үзара тартылышының, бөтерелүенең чуваш поэзиясендә моңарчы беркемдә дә булганы юк иде. Гүя өермә күтәрелә һәм бөтенесен күтәреп, бөтереп ала.

Поэзия тарихын күп язмышларны, буыннар тормышын үз эченә ала торган озын чылбыр итеп күз алдына китерәбез икән, хәзерге һәр шагыйрь үзен шул чылбырның бер буыны итеп тоярга тиеш. Ул үзендә традициянең җанлы сулышын тоярга тиеш. Нәкъ менә җанлы сулышын. Чөнки халык аңы поэзия тарихын, икенче дәрәҗәдәге әдәби фон белән дә кызыксынучы филологлардан үзгә буларак, башкачарак итеп күрә. Халык каләм тибрәткән барлык шагыйрьләрне дә түгел, иң яхшыларын, уйниятләре изге булганнарын, үзе өчен түгел, кешеләр өчен, халык өчен җан атып яшәгәннәрен, тарихның драматик мизгелләрендә халык вөҗданы авазына әверелгәннәрен генә үз итә. Андый шагыйрьләр һәрвакыт бар. Татар поэзиясендә Тукай, Такташ, Туфан шундый. Чуашта алар — Иванов, Сеспель, Митта. Аларның шигырьләре һәркемнең телендә, күңелендә, шуңа күрә аларның бай һәм күпкырлы традицияләренең хәзерге һәр шагыйрьгә йогынтысыз калуы мөмкин түгел. Бу шагыйрьләрнең халык шагыйре дигән олы исеме бар, аларның стиле — үрнәк, милли норма. Ахыр чиктә төрле буыннар, шигъри язмышлар чылбыры тирәнгә, исемсез халык иҗатына, аның җырда, әкияттә, мифта сакланып калган сүзенә китә.

Ләкин башта чылбырны өзүче булып башлаган шагыйрьләр дә бар. Беренче тәэсир буенча аларның сүзе шулкадәр яңа булып тоела ки, укучы һәм тәнкыйтьче аларны үткәндәге бөекләрнең дәвамы итеп карамый, еш кына шуның аркасында аларны милли итеп тоймый. «Чылбырны өзүче» шагыйрьләр өчен сурәтләү чараларын кискен яңарту, поэтик фикерләрнең принципларын үзгәртү хас. Айги өчен, мәсәлән, хәзерге кешенең танып-белү процессы катлаулылыгын һәм тирәнлеген күз алдына бастыра торган сүзгә сукмакларны эзләү иҗади үсештә мөһим баскыч булды. Монда «чылбырны өзүче» шагыйрьләрнең бу әдәбият өчен типик булмаган традицияләргә таянуы да зур роль уйный. Чуваш шагыйре өчен француз поэзиясе шундый традиция булды. Г. Айгиның француз поэзиясе антологиясен әзерләп, тәрҗемә итеп чыгаруы — чуваш

культурасының соңгы еллардагы зур бер вакыйгасы. Антологиядә Франсуа Вийоннан алып Ив Бонфуага кадәр 77 шагыйрь әсәрләре бар. Хәзер, ун елдан артык вакыт үткәннән соң, «чит ил үсентесен чуваш туфрагына күчереп утырту» уңышлы булды дип әйтергә мөмкин. Тәрҗемәче чуваш поэтикасы рамкаларында яңа мөмкинлекләр ачты һәм, антология турындагы фикерләрдә күрсәтелгәнчә, иске чуваш силлабикасы, архаик тел синтаксисы XVII гасырдагы француз шагыйрьләрен, хәзерге француз верлибрын һәм чәчмә шигырьләрне тәрҗемә иткәндә бик табигый яңгыраш алды. Хәер, Идел буендагы төрки һәм фин-угыр телләрен яхшы белгән Н. И. Ашмарин 1895 елда ук «Көнбатыш декадентлары һәм Идел буе халыклары поэзиясе» дигән кызыклы мәкаләсендә Верлен, Метерлинк шигырьләрендә һәм мордва, чуваш, татар җырлары үрнәкләрендә якынлык таба. Әлбәттә, бу текстуаль якынлык түгел.

Тәрҗемәче Айги хезмәтенең икенче, шулай ук әһәмиятле нәтиҗәсе — яшь чуваш шагыйрьләренең үз тавышларын эзләүдә киңрәк һәм төрлерәк була баруында, аң офыкларының киңәюендә. Чуваш поэзиясе заман ритмнарына һәм бурычларына яраклаштырып сыгылмалырак, интеллектуальрәк тел белән бирелә башлады. Бераздан «Венгрия шагыйрьләре» дигән антология дөнья күрде.

Гомумән, Айгиның хәзерге чуваш поэзиясендәге ролен билгеләгәндә аның байтак әдәби процессларны азмы-күпме тизләтүе, бүгенге яшьләрнең күбесе өчен тартылыш үзәге яки, киресенчә, үзеннән читкә этәрүче булуын әйтергә мөмкин. Әлбәттә, Айгиның шигъри теле катлаулы, семантик яктан күп катламлы, аны аңлау ягыннан караганда, төрлечә мәгънәләр бирергә урын кала. Юнәлешлелеге ягыннан караганда, аның сүзе фольклор сүзенә капма-каршы, чөнки аның адресаты, бик тә конкрет «син»е бар. Фольклор исә бөтен кешегә дә юнәлдерелгән сөйләү. Айги үзе хәзер гадилеккә, ачыклыкка чыгарга омтыла. Аның соңгы вакыттагы шигырьләре яктырак, үтә күренмәлерәк, ләкин аның поэтикасының системасы үзе телне гадиләштерүгә юл куймый. Гадилеккә омтылыш җитмешенче еллар чуваш шагыйрьләренең яшьрәк буынында кызыклы гәүдәләнеш таба.

Татар поэзиясендә яңалыкка омтылу алтмышынчы еллар чигенә туры килә. Аның үсеш процесслары, яңа буынның җитлегүе турында Мостай ага Кәрим Р. Фәйзуллинның «Мой звездный час» дигән китабына сүз башында болай яза: «Хәзерге татар совет поэзиясендә, минем уемча, форманы яңарту мәгънәсендә генә түгел, яңа эстетик нормаларны яклауда һәм художество чаралары арсеналын заманның авазына, ритмына, әхлакый һәм идея ихтыяҗларына туры китереп киңәйтүдә дә сизелерлек ике шартлау булды. Егерменче еллар уртасында бу шартлау яшь Хәсән Туфанның һәм шундый ук яшь Һади Такташның формасы һәм эчтәлеге белән кыю шигырьләре, поэмалары иде. Канунлашкан әдәбият күзлегеннән караганда рифмада да, ритмда да, бөтен стильдә дә «законсызлык»ны алар закон дәрәҗәсенә күтәрделәр һәм озак-озакка төпләндерделәр...

Алтмышынчы еллар башында без икенче, ихтимал, ул кадәр үк каты булмаса да, эчке байлыгы ягыннан караганда бик әһәмиятле булган икенче шартлауны ишеттек. Шулай булуы аңлашыла да. Хәзер инде заман аша сикерү зарурлыгы, хәер, мөмкинлеге дә юк иде, хәзер аны игътибар белән һәм бик актив тыңларга кирәк иде. Бик актив, һәм аның белән ярсып бәхәсләшергә, аны каһарманлык белән якларга кирәк иде. Чөнки Заман — ул без үзебез. Минем уемча, ул чакта Рәдиф Гатауллин, Ренат Харис, Гәрәй Рәхим, Зөлфәт, Мөдәррис Әгъләмов поэзиягә шул миссия белән керделәр. Алардан бераз гына алдарак Равил Фәйзуллин килде».

Чыннан да, хәзерге татар әдәбиятында интеллектуаль пафос һәм яңага сусау иң элек шушы исемнәр белән бәйле. Мисал өчен, Равил Фәйзуллин шигырьләрен алыйк. Аның лирикасы — тартылган җәя, хәрәкәт-гамәлгә тиң булган кискен фикер. Шагыйрь тормышка, кешеләргә үтә таләпчән, ул сорау куя икән — шунда ук җавабы да бирелсен. Чын лирикларның һәркайсы кебек үк, Р. Фәйзуллин тойгы белән әйләнә-тирә дөньяның кушылуына, бер булуына омтыла. Шагыйрь бик нечкә, күрәләтә эзгыйфь ситуацияләргә кагылудан да курыкмый. Бу вакытта аның шигырьләре йомшак, интим атмосферага иңә, оялып-куенсынып кына мәхәббәт белдерүгә охшый. Ләкин икенче яктан, Р. Фәйзуллин шигърияте ндә яшьлекнең башбирмәс талпынышы, чын ирләрчә ихтыяри башлангыч тулысынча сизелеп тора.

Гомумән, бу буын поэзиясе зирәгрәк тә, җитлеккәнрәк тә һәм, кем әйтмешли, тормышның үзенә карата түземлерәк тә, сабыррак та булып әверелде. Р. Фәйзуллинның түбәндәге юллары, үзенә адресланган булса да, күпмедер дәрәҗәдә бөтен буынга да кагыла:

Багам ташка, үләннәргә,
белергә телим бераз
үзем хакында.
Бармы миң? Чынлап яшимме?
Миндә ни чагылышы бар
авазларның, төсләрнең?
Миңа ни мөнәсәбәте бар
мәңгелек җисемнәрнең?

Монда инде баштагы чорда Р. Фәйзуллинның да, башка татар шагыйрьләренең дә төп коралы булган фикер генә түгел, монда әрнү дә, Ватанга мөнәсәбәт тә, иң мөһиме — аның рухи асылын төшенү — мәңге булыр дип ышану да сизелә. Башкача мөмкин дә түгел.

Җитлегә бару процессында фольклорга мөрәҗәгать итүнең дә роле кечкенә булмады. Ренат Харис дөньяның төсләргә бай спектрына текәлеп карый, аның төс эпитетлары халыкча эпик мәгънә ала.

Мин — яфрак.
Тормышны мин
Агач итеп күрәм.
. . . . . . . . . . . . .
Аның бер генә ноктасын
Үзем белән төрәм.
Бер генә ноктасын
Коншка тартам.
Без — күбәү —
Кәүсә үрелә безнең арттан.

Яшел чылбыр — бөтен дөньяның, терек табигатьнең элемтәсе, әйләнеше. Ләкин кеше дә шушы гомуми хәрәкаттән читтә калмый. Р. Харисның шигъре еш кына шулай туа: сурәт җырдагыча салмак үстерелә, һаман киңәя бара һәм кинәт кенә, кисәк кенә өздереп ала, күкрәкнең сул ягын чәнчеп куя.

Уйнамагыз —
        унар чакрым биеклеккә
Чөймәгез агулы тузан:
Елгаларның,
Чишмәләрнең,
Күлләр,
Океан, диңгезләрнең
        өсте ябмаган!

Шигърият менә нинди кысан, шул ук вакытта очсыз-кырыйсыз пространствода барлыкка килә. Йөрәк — Ватан киңлегендә. Шигырь кылы нечкә аваз белән зыңлый. Монда дала иркенлеге дә, лирик герой аша аккан вакыт та, сәгатьләр, көннәр, еллар үлчәме булып Идел дулкыннары шаулавы, яшел үлән үсүе, бала тууы да.

Шагыйрь ашыкмый, чөнки ул вакытны дөрес аңлый. Көндәлек ыгы-зыгы һәм тәэсирләр аны кабаландырмый. Р. Харис поэзиясендә киеренке, эчке эш бара. Шагыйрьнең язганнары укучыга ышанып карау белән сугарылган. Ул үзе дә әйтә: «ак уем дусларым турында...»

Татар поэзиясе хәрәкәттә. Яшь шагыйрьләр алдында төрле юллар ачык, һәм алар сәнгать юлларыннан алга баруның яңа тәэсирләр артыннан куу гына түгел икәнлеген төшенәләр. Бу — үз-үзеңә юл, хәзер Ренат Харис өчен генә түгел, яшьрәкләрдән Мөдәррис Әгъләмов, Зөлфәт өчен дә ул халык тәҗрибәсен, халыкның дөньяга карашын үзләштерү аша үтә. Бу юлдан барганда җирдәге изге нәрсәләргә баш имичә, тугрылык билгесе итеп җирне үпмичә мөмкин түгел. М. Әгъләмов, үз дәрәҗәсен күздә тотып, болай ди:

Яралганмын кара туфрагымнан,
Идел-йорттан, халык җырларыннан...

Ак яулыклы татар карчыгының
Яргаланып беткән кулларыннан.

Яшь шагыйрь үз миссиясен киләчәк буын белән аталар буыны арасында элемтә урнаштыруда күрә. Шуның өчен шагыйрь гомере буена халык авазының гәүдәләнеше булган билгесез Карт куйган «табышмакларны чишеп» яшәргә тиеш. Мондый мотивлар, шушындый шигырь-әйтлар илебездәге башка милли поэзия вәкилләренә дә хас.

Һәм шагыйрь бервакытны халкына, теленә, ватанына мәхәббәтен аңлатып бирү зарурлыгы тоя. Бу да шагыйрьнең җитлеккәнлеге турында сөйли. Башкорт шагыйре Равил Бикбаев бу мөнәсәбәтен төгәл афористик формада әйтеп бирә:

Чишмәләрең минем йөрәк аша
Чылтыр-чылтыр агып үтәләр.
Йөрәгемә, гүя, каным түгел,
Шул чишмәләр яшәү илтәләр...
Сиңа баксам, күңелем күтәренке,
Киләчәгем шат та, тыныч та:
Чөнки беләм
Иңнәреңдә илнең
Урал дигән сынмас кылыч бар.

Шагыйрьнең индивидуаль позициясе белән халыкның күмәк тәҗрибәсе арасындагы бәйләнеш — поэзиянең халыкчанлыгы критерийларыннан берсе. Чөнки шагыйрь, шәхес буларак, үзенә кадәр һәм үзеннән башка меңнәрчә еллар яшәп килгән дөньяга керә. Ә бу дөнья тавыш-тынсыз түгел, аның үз авазлары бар. Анда чишмә чылтырый, урман шаулый, кешеләрнең җылы тавышлары ишетелә... һәм шулар арасында шагыйрь пәйда була да, оран сала: «Ә бу дөньяда мин дә бар!..»

Равил Бикбаев шигырьләренә хас булган югары гражданлык хисе һәм әхлакый байлык традицион мотивларга, сурәтләргә яңа яңгыраш, яңа мәгънә бирә. Дала кешесе өчен ялан киңлек, төпсез зәңгәр күк, тамырылып чабу — тормышның аерылгысыз һәм гадәти шартлары, алар дөньяга карашны балачактан ук формалаштыра. Яшь башкорт шагыйренең поэзиясендә чорыбызның тизлеге, тойгыларның тигезсез ритмы сизелә. Шулай да шагыйрь туктап тын алырга, чишмәдән ятып су эчәргә вакыт таба. Ул шигъри сүзнең җаваплылыгы турында гади һәм тыенкы гына итеп әйтеп бирә:

Белгән халкым сүз кадерен,
Сүзләр үткән күпме уттан.
Тыңланмагән юкка гына
Әйткән сүзләр аткан укка.
Ук беткәндә йөрәкләрдә
Уктан үткен сүзләр калган.
Ил өмете, аманәте
Өстен булган бар коралдан.

Чын шагыйрь үз исеменнән генә сөйләми. Ул галәм аһәңен, дөнья гамен белергә, ишетергә тиеш. Алтмышынчы еллар буынының иң әйбәт вәкилләре аны һаман ачыграк, якынрак тоялар, катлаулы, киләчәк дөнья турында сораулар аларның аңында тынмый яңгырап тора. Яшь шагыйрьләрнең лирик «мин»не мәгълүм дәрәҗәдә трансформацияләргә омтылуы шуның белән дә бәйләнгән. «Мин» алмашлыгы шәхесне, исемне алмаштыручы булып кына калмый. Бу, барысыннан да бигрәк, шигырьдәге гомумиләштерүнең үзәге (геометриядәге нокта кебек), лирик киеренкелекнең көч сызыклары шуның тирәсенә тартыла. Монда «мин» конкрет түгел, аерым шәхескә бәйләнмәгән: һәр укучы үзен шул «мин»гә тәңгәл итеп карый ала. Бу да фольклордагыча гомумиләштерелгән герой куллануның үзенчәлекле ысулы. «Мин-без» мөнәсәбәтенең диалектикасын Рәдиф Гатауллин менә ничек күрә:

Тагын әйтәм: көчен — «мин»ен
Кешеләр өчен җигә белсен Кеше;
Җирдә көчле «без»ләр белән кушылып,
Үзен җиңә белсен Кеше!

Без нәкъ менә халык җырының язма әдәбиятны үстерүдә иң көчле фактор булганлыгын беләбез. Нәкъ менә халык җыры, башка фольклор жанрлары белән ча-

гыштырганда, хәзерге күпмилләтле әдәбиятка актив йогынты ясавын дәвам итә. «Халык җырлары безнең бабаларымыз тарафыннан калдырылган иң кадерле вә иң бәһале бер мирастыр» дип язган Тукай. Халык җыры һәм культурада күп тормыш күренешләрен колачлый, ул күптөрле, анда фольклорның кайбер башка жанрлары (табышмаклар, туй җырлары, мәкальләр) кебек алдан бирелгәнлек юк.

Хәзерге чуваш әдәбиятында, бигрәк тә яшь шагыйрьләр арасында, җыр традицияләрен үзләштерү дәвам итә. Шагыйрьләр гүя җырдан өйрәнәләр, халыкның мәңгелек матурлыгы дөньясына кушылу өчен имтихан тапшыралар. Бу яктан караганда М. Сениэль кызыклы эволюция ясады. Башта, алтмышынчы елларда, шигырь язу өчен төп материал аның үз күңеленнән алына иде. Эчке комплексларны китапча романтик идеал белән матурлап бирү, үз-үзеңне капчыкның эчен тышка әйләндергән кебек әйләндереп салу, мәхәббәт «эңгер-меңгерләре» һ. б. Кыскасы, күптән таныш ситуация һәм монда бер яңа нәрсә дә юк. Табигый яңу процессы, шуның нәтиҗәсендә шигърият металлы коела һәм сүз шлагы аерылып чыга. Бу йомык түгәрәктән котылырга омтылып, М. Сениэль халык сүзенең яктысына чыга. Һәм бөтенесе үзгәрә дә китә. Якты, аяз дөнья ачыла. Нәрсәсе беләндер чувашларның элекке рекрут җырына тартым яңа әсәрләр языла.

Сениэльдә, һичшөбһәсез, стильләштерү, халыкча булып күренергә тырышу, аның беркатлырак булып тоелган интонациясен һәм эчке саллылыгын имитацияләү бар. Халык әдәбиятының югары агышына үтеп керү кыен һәм турыдан-туры күчереп алу юлы белән моңа ирешү мөмкин дә түгел. Фольклорга, борынгылыкка охшатып язу «модага керә» икән, бу иң элек мондый мөнәсәбәтнең уйлап чыгарылган булуы, рационализмы турында сөйли. Мифның, халык тәҗрибәсенең мәгънәсен үзләштерү нечкәрәк юл белән — хәзерге кеше психикасының үзең дә ачык тоймый торган, иррациональ моментлары аркылы гамәлгә аша,

Чуваш шагыйре Педер Эйзин халык сүзенең серенә төшенүгә үз-үзен эчтән үзгәртеп кору, күңел түрендәге эзләнүләр аша килде. Аның кайбер шигырьләре беренче карашка чуваш фольклорындагы мәгълүм жанрларның (мәсәлән, кунак җырларының) кайтавазы гына булып күренә. Андый шигырьләр үзләре күп түгел. Ләкин алар, камертон авазы кебек, аның бөтен лирикасының билгеле бер этик настроен билгелиләр. Эйзин халыкның әхлак әлифбасын бик тирән тойган. Аның лирик герое инде иң интим гамәлләрендә дә (геройны, кем әйтмешли, беркем күрмәгәндә дә) үзен шушы әлифбадан башка күз алдына китерә алмый. Сүзләр гадидән гади, чөнки әхлакый тойгы болай да барып җитә, ә бу — иң мөһиме.

Җиде диңгез кичә-кичә
Килер идем очып —
«кил, бәгърем, кил» дигән
тавышыңны ишетсәм.

(Юлга-юл тәрҗемә.)

Чыннан да, кайчакта туган телеңнең, сүзеңнең яктысына диңгез кичә-кичә озак сәяхәт итеп кенә килеп җитәсең. Янәшәңдә генә яткан нәрсә эстетика итеп каралмый. Артык якын, таныш әйбер күнегелгән, гадәти итеп карала.

Эйзин чуваш әдәбиятында фольклорга керүнең яңа ысулын ачты. Мин аны «колак салу» дип атар идем. Монда «шәхси» сүзнең һәм «бөтенесе өчен» булган сүзнең тирәнтен эчке кушылуы турында сүз бара. Шушы кушылу яңа сүзне тудырды. Ул җылы, якымлы, шул ук вакытта туры, тайпылышсыз да. П. Эйзин чуваш әдәбиятында ялгыз түгел. Любовь Мартьянова, Геннадий Юмарт, Сувар Эрдивинның соңгы шигырьләрендә Эйзин стиленә хас сыйфатлар сизелеп тора: сурәтләү чараларының тыенкылыгы, һәр сүзнең киң мәгънә сыйдырышы һ. б. Халык җырларының, риваятьләр, мифларның саф эчтәлек мотивларыннан файдалану белән бергә бу шагыйрьләр нигездә сүз өстендә эшлиләр. Тел горизонтын алар эпик нәрсә итеп кабул итәләр. Алар телнең әхлакый сафлыгына омтылалар. Яшь шагыйрьләр гасырлар дәвамында чарланып килгән афоризм, мәкаль формасына тартылалар, ә шигырьләрнең эчтәлегендә, борын-борыннан килгәнчә, яхшылык һәм яманлык, җир һәм күк, газиз һәм ят нәрсәләр. Мәсәлән, Л. Мартьянованың бер шигыре:

Ак җилкән — хыял,
Уй тын җил кебек.
Төпсез диңгез — тормыш.
Син — җан тарткан өй кебек.

(Юлга-юл тәрҗемә.)

Күмәк тәҗрибәгә, милли образлар фондына мөрәҗәгать итү шагыйрьне үз стиле өстендә киеренке эшләүдән коткармый. Шагыйрь үз сүзен әйтергә тиеш. Монда хикмәт образларда, шигырьнең тышкы пластикасында гына түгел. Фольклорга мөрәҗәгать итү шул автор иҗатының эчке эволюциясе белән акланырга тиеш. Аны этик яктан акларга кирәк. Бу шулай дигән сүз: автор ниндидер бер мөлим чиккә килеп җиткән дә, халык зирәклегеннән башка аның һич эше бармый. Бер интервьюда Чыңгыз Айтматов та болай ди: «Кайчакта мин үз әсәрләремә халык аңының иясез катламнарын кертәм. Автор исеменнән түгел һәм инде бигрәк тә герой исеменнән түгел. Бу гомуми сүз әйтергә кирәк очракларда шулай була» («Вопросы литературы», 1976, № 8).

Шагыйрьне еш кына юлчы белән чагыштыралар. Юлчы офыктан беркая да китә алмый. Заманында чуваш халкының мәгърифәтчесе И. Я. Яковлев (1848—1930) халыкның дөньяны аңлавының нигезе булган «йөз мең сүз, йөз мең җыр, йөз мең чигеш» формуласын, бик күп сыйдырышлы һәм эчтәлекле формуланы биргән иде. Мин алтмышынчы еллар башында әдәби дөньяга чыккан буынның җитлеккәнлеге турында сүз алып бардым. Бу буын вәкилләрендә уртак нәрсәләр күп. Алар әдәбиятның милли үзенчәлеген төшенергә тырышалар, үз тыңлаучылары һәм укучылары күңеленә юл эзлиләр. Бу юл гомумилек горизонты — ягъни Сүз, Музыка һәм Сурәт берлеге аша үтә. Ул горизонтка чыгу исә шигъриятнең халык язмышын үз иткән шәхес язмышына: аның шатлыгына һәм әрнүенә әверелүе дигән сүз.

## Йосыф Гәрәй,

башкорт шагыйре

### Сармаш ярында

Мең тугыз йөз унөч.
Сармаш[1] ташкан.
Үзәгеннән чыккан үзәнгә.
Яр башына, йөзен түбән куеп
Яткан берәү яшел үләнгә.

Башын җиргә бәрә-бәрә елый,
Күрәсең, зур кайгы килгәнгә.
Ә соң нинди хәсрәт чыдам ирне
Биргән шулай салкын чирәмгә?

Ник шул чаклы үрсәләнә кеше?
Мөмкинме соң сабыр түзәргә?
Сармаш мөгаллиме түгелме соң?
Шул, шул, шагыйрь Сәгыйть Сүнчәләй.

«Суга сикермәсен!» — дип күзәтә
Яшь шәкерте Риза Ишморат.
«Сәгыйть абый, һаҗәр әби көтә.
Әйдә кайтыйк. Тиздән кич була».

Башын, кулын болгый укытучы,
Ак маңгаен сала чирәмгә —
Һичбер нәрсә һич тә җуя алмас
Зур кайгылы хәбәр килгәнгә:

Якын дусы һәм сердәше Тукай
Әҗәл җитми иртә сүнгәнгә.
«Тукай җаным, ник киттең?» дип сыкрап,
Җирне тырнап елый Сүнчәләй.

## Шәриф Биккол,

башкорт шагыйре

### «Җир казуы — авыр эш», — диләр...

«Җир казуы — авыр эш»,— диләр...
Мин дә җирне бик күп казыган.
Казыган бар шашып шатлыктан,
казыган бар көеп кайгыдан;
казыган бар
үлем
кургаш булып,

[1] Сармаш — Пермь өлкәсендәге елга. Ред.

ярчык булып явып торганда:
гөл түтәле,
кара кабер,
окоп
казыган бар минем, туганнар...

Мин яңадан түтәл казыйм менә,
тирләп-тирләп алам җиңелчә...

...«Җир казуы — авыр эш»,—диләр...
Юк,
казый алмау авыр, минемчә...

## Кешеләргә барам

Куанычтан җан җылынса,
якты сукмак ярам:
шатлыгымны өләшергә
кешеләргә барам!

Күңелемне юатырга
бетсә соңгы чарам,
хәсрәтләрдән арынырга
кешеләргә барам!

Чыдамнарны сындырганда
яуда алган ярам,
сызлауларын басарга дип,
кешеләргә барам.

Кемлегемне сынарга дип
кешеләргә барам!

Әй, кешеләр!
Сезнең белән
өзелмәсен арам!

# Владимир Портнов,

рус шагыйре

## Фронтовик агачлар

Пышылдаша агач яфраклары,
Исләренә төшә яшь чаклар...
Тора алар солдат каберләрен
Тамырлары белән кочаклап.

Кемнәр аңлар юкәләрнең күңелен,
Имәннәрнең серен кем ачар?
Яфрагы кук калтырамый усак,
Агач җанлы түгел агачлар.

Үз әнисе кебек сыкрый каен,
Иңнәренә салып шәлләрен.
Каен кочагында солдат ята...
Кемнәр белә каен хәлләрен?!

Күпме алар — яуда егылганнар!—
Күпме батыр, күпме «хәбәрсез...»
Моңсуланып бераз тын калыгыз
Ялгыз каеннарны күрсәгез.

Чәчләренә сугыш төсе сеңгән...
Дошман киткән. Ул бар, ул калган.
Алланадыр нарат таңнан түгел,
Яралардан тамган ал каннан.

Һәр агачның төпләрендә бүген
Бардыр кебек солдат кабере.
Агачларга уйма үз исемең,
Ул исемсез килеш кадерле.

Тәннәрендә кургаш саклый алар.
Ул агачлар утта көйрәгән.
Туган җиргә шулай берегергә
Батырлардан алар өйрәнгән.

●

Очрашырга иде йолдызда бер...
Җирдә юктыр сөю, тугрылык.
Мең мәшәкать тулы бу хәятта
Мәхәббәткә, ахры, урын юк.

Качып китик дөнья рәхәтеннән,
Качыйк әйдә дус һәм дошманнан!
Синең күзләр чәчәкләргә түгел,
Йолдызларга күбрәк охшаган.

Очрашырга иде, кавышырга...
Юлга чыгыйк, карап йолдызга.
Күпме кеше ярын табалмыйча
Янәшәдә генә юл уза.

Мин йолдызда учак ягар идем,
Син ашыгыр идең янyма.
Элеккечә... безнең мәхәббәткә
Шаһит булыр иде таң гына.

Сине каян эзләп табыйм икән? —
Җавабың юк, күпме дәшеп тә.
Безгә шундый рәхәт булыр иде...
Рәхәт булган кебек яшьлектә.

Очрашырга иде йолдызда бер...

## Дәфтәр турында баллада

Кәгазь капчыкларны турый-турый
Дәфтәр ясый идек төннәрен.
Ул капчыклар ачы сагышларын
Ташымады икән кемнәрнең?
Кәгазьләрне тигезләргә теләп
Сыйпый иде арык кулларым,
Тик хәрефләр тертелә дә кала...
Хәтерләтеп сугыш юлларын.
Сыңар куллы әти тиз картайды
Кәгазь капчык белән хат ташып.
Өй борынча кайгы өләште дә
Төннәр буе чыкты саташып.
Хәтерлим мин һаман әтиемнең
Ил сагышы тулы күзләрен,
«Кыскарак яз, улым, мәгънәле яз,
Кәгазь сакла»,— дигән сүзләрен.

❁

Җилгә чәчеп мөлкәтен,
Ярлыланган көз, бөлгән.
...Ай тәрәзне ватар күк
Очлы мөгезе белән.

Гөнаһ кылган кешедәй
Бимазаланып беттем.
Тыны да чыкмый бүген
Төн төсле кара этнең.

Кунаклар туймый җырлап,
Туймыйлар ашап, сөйләп...
Эт канәгать, ул өрми:
Эт күңеле — бер сөяк.

Мал суйдык. Җыйдык кунак.
Күздә яшь килеш көләм.
...Ай тәрәзәне шакый
Канлы мөгезе белән.

## Үги ана яфрагы

Кемнәр сине «үги» дигән,
Үги ана яфрагы?
Читкә — үги..
Үги итмәс
Туган җирнең туфрагы.

Күрми сине ваемсызлар,
күрми чәчәк-күршеләр...
Бары хаста чакта гына
Эзли сине кешеләр.

Яр сукмагы буйлап киләм,
Киләм синнән көнләшеп.
...Мине шулай, авыр чакта,
Алсалар иде дәшеп.

Кемдер үги итсә итсен,
Кемдер көлеп карасын...
Мин бәхетле — җырым белән
Төзәтсәм җан ярасын.

## Әбиләр чуагы

Көзге урман. Малай яфрак яга,
Малай тели кызык ясарга.
...Өнсез калган агачларга гүя
Төтен түгел, ап-ак чал сара.

Урман кача томан кочагына,
Урман чума сагыш, моң-зарга.
Ялкын чәчле малай яфрак яга...
Күңелләргә көзге моң сара.

**Разил ВӘЛИЕВ** тәрҗемәләре

## Кояш Тимбикова

# ЯРЛАР БИЕК

ПОВЕСТЬ

Мәктәп ишегалдындагы шомлы балкышны иң элек Фирүзә күреп өлгерде. Укучылар, тәрәзәгә борылгач та аның өнсез калуын күреп, парта арасыннан дәррәү күтәрелделәр. Ишегалдында коточкыч* ялкын өермәсе җилпенә иде. Һичнинди төтен-фәлән юк, саргылт-кызыл ялкын, гүя җир куеныннан ургый, артканнан-арта барып, һаман биеккәрәк үрли.

— Ни бу, балалар?

Укучыларның һәммәсе, Фирүзәнең соравын җавапсыз калдырмаска тырышкандай, нәрсә дә булса әйтеп калырга ашыкты:

— Ут!

— Янгын!

— Фирүзә Галләмовна, бу бит — унынчы «Б»ларның макулатурасы!

Коридорда ашыгыч адымнар ишетелә башлагач, укытучы бүлмәдән чыгарга кирәклеген абайлап алды. Ул, тавышына ни бар тынычлыгын иңдерергә тырышып:

— Әйдәгез, укучылар! — диде. — Тәртип белән генә! Коридорда боламык ясамыйк!

Балалар, коридорда башка класс укучылары белән дә кушылгач, читлектән ычкынган кошлар сыман, кисәтүне бөтенләй онытып җибәрделәр. Мәхшәр купты: ишеккә бөялгәннәр дә, бер-берсенә комачаулап, чыгу юлын томалаганнар. Мәгънәсез рәвештә әүмәкләшә торгач, кемнәрнеңдер тышкы яктан тәртип урнаштыра башлавы сизелде. Унынчы класс укучылары икән. Алар ишегалдында хәрби дәрестә булганнар. Ике якка тыгыз рәт булып тезелделәр дә уртадан юл ачтылар.

Янгын тирәли дә өлкән класс укучыларыннан сак куелган, берәүне дә якын җибәрмиләр. Ир-атлар утсүндергечтән күбекле сыекча сиптерә. Тик ялкынның биреләсе исәбендә дә юк. Ул һаман биеккәрәк үрли бара.

Фирүзә үз күзләренә ышанмый торды: гүя әлеге утлы урында җир белән күк бергә бәйләнгән. Аларны җир авызыннан бөркелеп чыккан ут баганасы тоташтырган кебек. Астан ургылучы ут тагын куәтләнә төшәр дә, киңәер, биегәер, юанаер да һава агымы кызурак хәрәкәтләнергә тотыныр, шул чак дөнья үзе шартлап ярылыр сыман.

Фирүзә, үзен-үзе белештермәстән, күзләрен чытырдатып йомды, учлары белән колакларын томалады.

— Күрегез әле моның басып торуларын! Ни кылануың бу, Фирүзә? — География укытучысы Әминә апа тавышы иде бу. — Кәгазь чүбе янганнан да шулай курыккач... Мин тагын сине, батыр йөрәкле, дип мактап йөргән булам. Җебемә! Укучыларыңа күз-колак бул!

Фирүзә өлкән яшьтәге бу укытучыны үзе өчен өлге-үрнәк итеп

йөртә. Тик бу юлы Әминә апасының кисәтүе дә тиз генә тынычландыра алмады. Ул, күзләрен ачкач та, балаларны барлау турында уйламыйча, кабат шаккатып, янгын өермәсенә күз салды. Ут баганасына ияреп, кара пәрәвезләр, көлгә әверелгән кәгазь кисәкләре җилпенә. Кешеләр өстенә кара яңгыр ява. Кешеләр байтак — кай арада җыелып беткәннәр? Мәктәп укучыларына шәһәр урамындагы балалар да кушылган. Алар бер-берсен этә-төртә эчкә үтәргә, ни янганын күрергә тырышалар. Гел алга узарга гына омтылган кешеләрне йөрәк яргыч сирена тавышы сискәндерде. Янгын сүндерүче машинадан төшүчеләр эшкә бик тиз тотындылар. Беләк юанлыгы көпшәләрдән су сиптерә торгач, ут, ничек капылт күтәрелгән булса, шундый ук кинәтлек белән басылып юкка да чыкты. Фирүзә тынычланганда, макулатура тутырылган иске контейнерның күмергә әйләнгән кисәү башларыннан һәм бер өем кара чүпчардан кайнар бу гына күтәрелә иде инде. Чәчәккә бөреләнгән карт юкәнең көеп карачкыга әйләнүен исәпләмәгәндә, бар да элекке хәленә кайтты. Унынчы «Б» классы укучылары җыйган макулатураның гына көле күккә очкан иде.

Янгын сүндерүчеләр, үзләренә генә аңлаешлы телдә сөйләнә-сөйләнә, тикшерү үткәрделәр. Ахырдан берсе сумкасыннан кәгазь алды, яза башлады. Укытучылар, мөгаен, хәзер үк янгын сәбәбе ачылыр, югалтуның очы чыгар, дип өметләнәләр иде. Ниһаять, янгынчылар командасы башлыгы мәктәп директорына үзе язган кәгазьне сузды.

— Бар да әйбәт!— диде ул.

Мондый чакта шуннан да мәгънәсезрәк сүз булу мөмкин микән? Укытучылар шаккаттылар. Ул исә кабатлап әйтте:

— Шәп! Ни тырышып эзләсәк тә таба алмадык. Котлыйм!

Гаҗәпләнүе йөзенә чыккан директор сорарга мәҗбүр иде:

— Кемне? Нәрсәне?

Янгын сүндерүчеләр, берьюлы елмаеп куйдылар. Алар начальникларының нинди сүзеннән соң ничек елмаерга икәнен яхшы беләләр иде, күрәсең. Җитәкче кеше исә аптырап калган укытучыларга, сирәк чәчләре чалара төшкән директорга озаклап карап торды. Тагын әүвәлге сүзләрен кабатлады.

— Шәп эш һәрвакыт шәп була инде ул. Кагыйдәләрнең һәммәсенә каршы куя-куя тикшереп карагач та...— Янгын сүндерүче, сүзләренә серлелек өстәргә теләгәндәй, тукталыбрак та торды,— мәктәбегездә янгыннан саклану чараларының чәнти бәрмак кадәр дә бозылмаганлыгын гына раслый алабыз. Котлыйм! Шәп!

Мәсьәләнең бу ягы педагоглар коллективының исендә дә юк икән. Мондый шик башларына алданрак килсә, ихтимал, алар әле шатланырлар да, яңа булып узган дәһшәттән соң бераз тынычланырлар да иде. Юк, бу минутларда укытучыларның берсенә дә, бездә янгыннан саклану шартлары әйбәт икән, дигән уй килмәде. Аларның барысын да, башка уй биләгән. Мәктәп, гадәттә, макулатураны күпләп тапшыра, шуның өчен аларга иске бер контейнер да биргәннәр иде. Бу айларда аны унынчы класслар карамагына тапшырдылар... Балаларның тырышыптырышып җыйган кәгазьләре ничек болай күз ачып йомганчы юкка чыкты соң әле?

Янгынчылар башлыгының соңгы сүзләре бу сорауны катлауландыра гына төште. Саклану чаралары да җиренә җиткерелгәч, ут ник кабынган? Ничек? Бу сораулар Фирүзәнең телен чиште.

— Алайса, янгын ник чыккан соң?

Янгын сүндерүчеләр китә башлаганнар иде инде. Фирүзәнең соравына көлкегә саптырып кына җавап кайтардылар:

— Ут бит ул, җаныкаччаем, кабынып өченгә барлыкка килгән нәрсә. Кабына ул. Безнең бурыч — сүндерү. Аны кабызмау безнең кулдан килми. Анысын табигать үзе генә хәл итә...

— Шулай да, бу очракта утның нидән чыгуы ихтимал соң?— Директорның бу соравы янгынчыларны сагайтып җибәрде.— Завхозыбыз бу контейнерны кай төштә тоту турында сезнең оешма белән киңәшкән дә иде. Кәгазь бит үзеннән-үзе янып китә алмый. Нилектән кабынган соң ул?

— Сез дөрес әйтәсез.— Ут сүндерүчеләрнең җитәкчесе тәмам җитдиләнгән иде.— Кәгазьне саклау урыны дөп-дөрес сайланган. Күрәсезме: хәтта ки, ишегалдындагы спорт нәмәрсәләренә дә зыян тимәде. Ике генә метр ундарак утырса, әнә теге баскетбол баганасын эләдерие. Инде килеп, утның ничек үрләп китүеме?.. Юньсез бәндәләрне ышык урын кызыктыра. Контейнер андый төштә түгел. Аңа бөтен мәктәп карап тора. Ул тагын тирә-юньгә күз ташлады.— Эшсезлектән азганнар да бу урынга кызыкмас: аларны моннан бөтен дөнья күрә. Кача-поса гына тамак чылатырга да җайлы җир түгел бу. Урамда килеш тәмәке төпчеген дә мондый ераклыкка ыргыта алмыйлар, ара зур. Димәк ки, бер генә нәрсә кала: кеше-кара юк чакны туры китереп, ут салганнар.

— Абау, җаным!— География укытучысы Әминә тыела алмады.— Шул балаларның хезмәтен юкка чыгару кемгә кирәк булды икән?

Янгын сүндерүче бу сорауга өздереп җавап бирде:

— Үзләренә! Түлке үзләренә. Бер-берсенә үчләшәләр дә башка да килмәгән этлекне эшләп ташлый ул чучка танаулар...

Балаларның нәрсәгә сәләтле икәнен укытучыдан да күбрәк белүче юк. Мәсьәлә алар дөньясына кагыла икән, монда инде янгынчыларның ярдәме кирәкмәячәк. Шуңа күрә директор: «Ярый,— дип сүзгә нокта куйды.— Хезмәтегез өчен рәхмәт. Хушыгыз!»

Баксаң, бер-береңә рәхмәт әйтерлек хәл идеме соң! Әлеге янгын — бәхетсезлекнең бер ягы гына. Кәгазьләрнең юкка чыгуы да әллә ни борчылырлык нәрсә түгел. Мәктәп бу айда макулатура җыю планын үтәмәде, дигән шелтә бирелергә мөмкин. Үз тәрбияләрендәге баланың яман юлга басуы укытучыларны кайгыга төшерде. Педагоглар күңелендә бер үк сораулар кайнаша иде: кайсы класстан? Кем баласы? Нинди максат белән?..

Сораулар куера торды, тик берәүнең дә җавап табасы килмәде, чөнки чишелештән... дөнья җимерелер сыман. Бу җинаять коллективның еллар буе алып барган тәрбия эшләренә кара тап булып төшә. Мәсьәләне гадиләштерү хәерлерәк. Әйтик: «Бу — безнең мәктәп укучысының эше түгелдер». Шаярту гынадыр, бераздан гаепле кеше үзе килеп аңлатыр әле»...

Директор, чал башын игән килеш, укытучылардан үтенде:

— Белешең карагыз әле! — диде.— Берәр укучы контейнер тирәсендә йөрүчене күрмәгәнме?— Аннары, тамагын кыргалап, уңайсызлануын яшереп тә тормастан, өстәп әйтте:— Мәсьәләне артык куертырга кирәкмәс... Югалтуның материаль бәясе — юк дәрәҗәсендә. Телгә керсәк, үзебезгә үк кыенга килер...

* * *

Ул көнне дәресләрнең рәте-чираты булмады. Соңгы өч сәгатьтә укытучыларның күбесе яңа темага кереп китә алмый азапланды. Фирүзә дә, җиденчеләргә кергәч, катлаулы җөмләдәге тыныш билгеләрен аңлатасы урынга, балаларның үзләрен эшкә кушты:

— Ике нокта куелу очрагына мисаллар уйлагыз!

Укучыларның фикерен дәрестән читкә җибәрмәү өчен шактый отышлы чара шул иде. Балалар гына түгел, Фирүзә үзе дә һаман ут дәһшәте тәэсиреннән котыла алмый.

Укытучы күпме генә тырышса да, класстагы бер шук малай дәресне кысадан чыгарыр әмәл тапты. Ул, кагыйдә кушканча, кулын күтәрде, үзе:

— Фирүзә Галләмовна, минем мисалны тыңлагыз әле!— дип сабырсызланды.

— Кулың күтәрелгәч, күрәм бит инде, Саттаров, ул кадәр үрсәләнмәскә кирәк! Әйдә, чык, җөмләңне тактага язып куй! Тикшерәбез.

Бусы тагын да әйбәтрәк чара: мондый чакта классның игътибары тактага юнәлә. Һәм Фирүзә, салмак атлап, тәрәзә ягына үтте. Саттаров тактага яза, акбур тавышы ишетелеп тора.

Кинәт классны көлү, пышылдашу авазлары тутырды. Фирүзә, ялт борылып, тактага карады. Малай кагыйдәгә тач туры килердәй җөмлә язып куйган: «Көчле яңгын унынчылар җыйган кәгазьнең соңгы көлен күккә очырганда, мәктәп ишегалдына күп төрле һөнәр ияләре керен тулган иде: укытучылар, янгын сүндерүчеләр, каравылчылар, кибетчеләр, һәм шоферлар».

Фирүзәнең күңеленнән берьюлы берничә фикер йөгереп үтте: «Укучы тыныш билгеләрен дөрес куйган, орфографик хаталар да юк», «Балалар да һаман шул ут турында уйлыйлар...», «Ничек тынычландырырга?» Аннары, җанын телеп, тагын бер шом баш калкытты: «Ни өчен җөмләдә тиндәш кисәкләр аз?..» Бу хакта икеләнеп торырга Фирүзәнең вакыты юк иде, өздереп сорады:

— Саттаров, ни өчен «һөнәр» ияләренә «укучылар» сүзен өстәмәдең, ә? Ул чакта җөмләнең яңгырашы бөтен, тиндәш кисәкләрең тагын да күбрәк булыр иде.— Укытучы шундый иттереп әйтте ки, соравы дәрескә кагылса да, сүзләрнең мәгънәсе тирәнрәк икәнен класс тиз аңлап өлгерде. «Шым» булдылар. Саттаровның да моңарчы уйнаклап янган күзләре, шардай ачылып, укытучыга текәлеп калды. Фирүзә исә үҗәтләнеп тагын сорады:

— Ник? Ни өчен син җөмләңнән укучыларны төшереп калдырдың? Алар бит анда иң зур күпчелек иде.

Үз тавышында шикле киная тоеп, Фирүзә калтыранып куйды. Нишли ул? Үз тәрбиясенә тапшырылган балалар арасында шымчылык итәргә аның ни хакы бар?..

— Ярый, Саттаров. Дөрес. Сөрт тактаны. Тагын кемнең мисаллары әзер?..

Фирүзә Саттаровны тактага чакырганда ук хаталанды, бугай. Иң әүвәл укучысының мисалын тыңлап карарга кирәк иде. Дәрес агышына комачаулардай җөмлә булса, аны тактага яздырмаска мөмкин. Барысы да уй-фикерләрнең таркаулыгыннан килеп чыга. Ярамый, дәрес өчен бүленгән кырык биш минутны башка хисләргә исраф итәргә рөхсәт юк.

— Кемнең мисалы әзер?

Шул чак ишек шакыдылар. Класс җитәкчесе Әминә апа килеп керде. «Ачуланма, Фирүзә, мин хәзер үк, тәнәфескә чыккалаганчы класста сөйләшү уздырыр идем,— диде ул.— Директор кушканча...»

Фирүзә өстәлдәге кәгазь-дәфтәрләрен җыештырырга тотынды. «Мин дә үз классыма барыйм әле,— дип уйлады.— Анда кем дәресе икән?»

— Журналны калдырыйммы?

— Калсын! Миндә исемлек юк.

Расписаниедән үз классының кайсы кабинетта икәнен ачыклаган арада Фирүзә алдагы сөйләшүнең нindирәк тәртиптә узачагын күз алдыннан кичерде. Аңа хәзер бер нәрсә ачык: балаларга шикләнеп карарга ярамый. Сүзләрен алар күңеленә, укытучылар җинаятьчене безнең арадан эзли икән, дигән фикер сала күрмәсен!

Класста Фирүзә үз дәлилләренә үзе үк гаҗәпләнеп, мавыгып китеп сөйләргә тотынды. Күңеле түрендә күптәнге бер хаким әйткән гыйбарә яңарды: «Тел кешегә фикерен яшерер өчен бирелгән».

— Укучылар, мин сезнең белән әле генә булып узган хәл турында сөйләшмәкче, дөресрәге, фикер уртаклашмакчы идем,— дип алып китте

ул.— Бер яктан, әле генә булган бу фаҗигадә әллә ни юк та кебек, әмма, иптәшләреннең хезмәте итеп карасаң, ул — шактый зур югалту.

— Яңып бетте бит инде, аны хәзер тегеләй яки болай карауның кемгә кирәге бар? — Бәйрәмов фамилияле укучы үз урынында утырып тора алмас хәлдә иде. Миң басты, мең утырды.— Нәрсә баш ватарга?!

— Я! Сөйлә инде, алай булгач, Кодрәт! Әле мин бетермәгән идем.— Фирүзә, чыннан да иң кирәклесен әйтә алмый калды.— Сабакташларыгызның хезмәтен җилгә очыручы гаепле кешене табуда, бәлки, сез булышырсыз? Мин шуны гына әйтмәкче идем.

Кыбырсык Бәйрәмов тынды. Башкалар төрлесе төрле яктан җавап кайтара башладылар:

— Без аны каян табыйк?

— Кем белсен?

— Бәлки, гаепле кеше юктыр да әле, ут үзе чыккандыр?

Фирүзә, кайсы яктан нинди сүз әйтерләр дигәндәй, бер мәлгә укучыларның ыгы-зыгылы бәхәсенә юл куйды. Аннары, ишетелеп калган соңгы сүзгә ялгап, сабыр гына аңлата башлады.

— Бөтен хикмәт тә шунда шул, балалар: кәгазь берничек тә үзеннән-үзе генә кабынып китә алмый. Ут сүндерүче абыйларыгыз да шуны әйттеләр. Макулатура өеме янында мәктәптәге кешеләр күренмәгән. Укытучылар, җыештыручылар бүген ул тирәдә булмаган. Шуңа күрә сез хәзер хәтерләп карагыз әле: контейнер янында йөрүче берәр укучыны күрмәдегезме?

Класста тагын шыбырдашырга тотындылар, арттагы рәтләрдә шактый ук кычкырып сөйләүләр куерды, Фирүзә эндәшмичә генә һәрберсен күзәтүен дәвам иттерде. Кинәт:

— Нәрсә миңа карап торасыз?— дип, тагын Бәйрәмов кузгалды.— Әллә мин дип уйлыйсызмы?

Һич көтелмәгән бу тавыш Фирүзәне чарасыз итте. Укучыларның теләсә нинди соравына җавап бирер кебек иде, әмма Бәйрәмов аны аптырашта калдырды. Җитмәсә, арттан:

— Һе, каракның бүреге яна!— дип тә кычкырдылар.

Малайга шул сүзләр генә кирәк булган диярсең, ул күкле-яшелле тавышлар чыгара-чыгара акланырга тотынып:

— Әллә минем башка тай типкән дип беләсезме? Башта ул кәгазьне минем кадәр җыеп күрсәтсеннәр әле! Яндырырга булгачтыннан, ник җыеп азапланыйм ди мин аны?!

Малайның соңгы сүзләре Фирүзәгә таяныч булды.

— Дөрес, Бәйрәмов!— Син — безнең классның иң эшчән укучысы. Синнән берәү дә шикләнми. Гомумән, кемнәндер яманлык эзләргә безнең хакыбыз да юк. Синең кызып китүең генә мине бик гаҗәпләндерә.

Малай, үзенә шик төшерүдә үзе генә гаепле икәнен сизеп, өр-яңадан боргалана башлады. Хәтта урыныннан ук сикереп торды.

— Елмаеп-елмаеп миңа сораулар бирәсез. Ник бәйләнәсез?— диде.

— Утыр, Бәйрәмов, сиңа берәү дә бәйләнмич. Бу — бөтен мәктәп алдына куелган сорау: кем, кайчан һәм ни сәбәпле контейнер тирәсендә йөргән?

— Аны ник миннән сорыйсыз соң әле, ә?— Малай торып басты, күзләрен кыса төшеп, укытучысына туры карады.— Сез, беләсезме, кемнән сорарга тиешле? — Соравына җавабы да әзер икән.— Иң беренче иттереп, кайтыгыз да, үз улларыгыздан сорагыз!— Аңа, күрәсең, иң кыены шул сүзләрне әйтү булган. Шулардан соң, ул, җиңеләеп китеп, урынына утырды.

Фирүзә тынып калды. Шушы ук мәктәптә аның ике улы укый, моңарчы йөзгә кызыллык китергәннәре юк иде. Ни булган? Ник бүген аңа шулай диләр? Классның кызлары шундук күтәрелеп чыкты. Фирүзә аларның бүлмәне тутырган сүзләрен генә ишетә иде:

— Акылың бармы синең, Кодрәт?

— Каян килсен аңа акыл, җүләр ич ул!

— Алай димә, җүләрдән дә акыллы сүз чыгып куя!

— Хәзер үк гафу үтен, ахмак! Фирүзә Галләмовнаның балаларына тел тидерергә ни хакың бар?!

Бәйрәмовны кызлар «һөҗүме»ннән ничегрәк коткарырга икәнен дә чамалап өлгерә алмады Фирүзә — кабинет ишегенең шапылдап ябылуы гына аны упкын төбеннән чынбарлыкка алып менде. Класстан атылып чыгып киткән Бәйрәмовның ярсулы тавышы инде коридорны яңгырата иде.

Яман төшкә охшаш бу эш көне тәмамланып, урамдагы кешеләр агымына кушылгач Фирүзә үз өенә кайтырга ашыкмады әле, бөтенләй икенче тарафка, әниләренә китте: Анда шәһәрнең икенче бер мәктәбендә укыта торган абыйсы да яши. Күңелен бушатасы килә Фирүзәнең.

Абыйсын ул дөньядагы иң изге кешеләрдән санап, аның сүзләренә, һәр кылган эшенә табынып йөри. Кыз үзен-үзе белә башлаганда, абыйсы сугышта иде. Өйдә аның фронтка ничек китүен әкият итеп сөйлиләр. Сугыш башланганда абыйсы яшьрәк булган, үзе бик теләсә дә, аны фронтка алмый интектергәннәр. Ниһаять, военкоматтан повестка килгән. Ул көнне абыйсы Идел аръягында колхозга печән чаба икән. Шуннан туп-туры район үзәгенә киткән. Әниләре улын озатырга коймак пешереп алгач, күрше карчыгы әйткән:

— Ашасын дус-ишләре белән! — дигән. — Соңгысын, улыңнан бер генә тешләт тә, кире ал! Әйләнеп кайтканчы сакларсың. Шул ризыгы тартып кайтара аны, менә күреп торырсың!..

Фирүзә, әнисе сандык ачкан саен, таштай каткан коймакны кулына ала, әйләндереп-тулгандырып карый, капмакчы була иде. Авыз итәсе килсә дә, тешләми, үзалдына сөйләнә: «Ярамый, абыемныкы, ул кайткач, бүлешеп ашарбыз...»

Каты коймак сандык тартмасында ята бирде. Абыйсы фронтның иң хәтәр юнәлешендә сугышка керде. Аннары хәбәр өзелде.

Алар гаиләсен, укытучылар кирәк булганга, башка авылга күчергәннәр иде. Әти кешене директор итеп билгеләделәр. Беркөнне абыйлары сугышка киткәнче яшәгән авылдан бер хатын килеп керде. Фирүзә үзе генә иде. Кунак апа:

— Сеңелем, әнием мәктәптән кайтмадымыни әле? — дип сорады.

— Бик кирәксә, алып чыгам, апа, мәктәп монда гына безнең.

— Алар дәрестәдер бит, үскәнем?

— Дәресләре әллә кайчан бетте инде: әниемнең классы иртәгә әдәбияттан сынау бирә, шуңа әзерләнәләр.

— Абау, җаным, бөтенесен белеп торасың икән! Бар, алай булгачыннан, кереп сөенче ал, абыйдан хат китергәннәр, диген!

Мәктәпкә керергә сәбәп кенә булсын! Шундук яланаяклап кына чыгып чапты ул. Өйләре мәктәпкә терәлеп тора диярлек. Бер-ике минуттан, әнисен ияртеп, кайтып та җитте. Аннары ни булганын Фирүзә бик озак аңламый йөрде. Кунак апа:

— Улыгыздан хатлар бар бит, апа. Кайдадыр бөялеп ятканнар, безнең авылга бөтенесе берьюлы килеп төште...— дигән иде, икәүләшеп кочаклаштылар да еларга тотындылар. Кешеләрнең шатлыктан да елауларын Фирүзә ул вакытта белми иде әле.

Аннары күрше авыл апасы чыгу ягына борылды:

— Мин китим инде,— диде.

Әнисе:

— Тукта, самовар куйыйм, хатларны да бергәләшеп укырбыз! — диде.— Әллә ни сыем юк югын да...

— Юк, апа, зинһар, кыстый күрмә, гаеп тә итмә, ара шактый ерак,

шатлыклы хәбәр булганга гына китердем, почтага яңадан илтергә кулым бармады, сез бит — мине укыткан кадерле кешеләр. Китим...

Әнисе, өйнең астын өскә актарып, әйберләр җыярга тотынды.

— Мә, ал, зинһар, сөенчегә!— диде.— Юньле-башлы нәрсәсе дә калмады бит аның, ашамлыкка алмашып бетердек... Менә шәлъяулык, исле сабын...

Өй эченнән башка әйбер табарга өмете беткәч, ул атылып ишегалдына чыкты, яшелчә бакчасына керде. Анда әле берничә яфрак кына чыгарып өлгергән чөгендер, күпьеллык суган түтәлләре яшәреп утыра иде. Фирүзәнең әнисе, күптән тилмереп эзләгәнен тапкандай, шуларга барып капланды. Умырып-умырып чөгендер йолкый, суган өзә. Үзалдына: «Чөгендерне без көздән сибеп калдырдык, яфраклары зур инде»,— дип сөйләнә.

— Мә, ал, зинһар, сабыйларыңа пешереп ашатырсың, чөгендер яфрагының кабартмасы да бик тәмле була, шулпасы да...

Хат китерә килгән хатын аны юата:

— Кирәкмәс, апа,— ди.— Үзмә, әрәм итмик! Рәхмәт яусын инде! Болай булгачыннан, бүген туйганчы ашыйбыз икән!..

Фирүзә әле дә абыйсының хатларын китергән хатынның төпкә баткан зур күзләрен, башындагы ямаулы шәлен, йөзенең сарылыгын ачык төсләр белән ясалган рәсемдәй хәтерендә тота.

...Фирүзә ишек кыңгыравын зыңгылдаткач, каршысына абыйсы килеп чыкты. Өйдә үзе генә икән.

— У-у-у! Минем иң бәләкәй сеңел килгән!— дип, ул, гадәттәгечә, ачык йөз белән каршы алды.— Чәйне үзең куярсың инде, әни белән җиңгәң мунчага киттеләр.

Зал идәне, түрдәге өстәл өсте — һәммәсе эреле-ваклы тимер-томыр белән тулган. Фирүзәнең шаккатып шуларга карап торуын абайлагач, абыйсы, тия күрмә, дигәндәй, каударланып, аңлатырга тотынды:

— Тегеләр чыгып киткәч, рәхәтләндем әле: бөтен байлыгымны тараттым да салдым, кирәген сайлап алуы җиңел. Яңа радиоалгыч җыям.

— И-и, абый, бу кадәр сакаллы сабый булырсың икән! Болай да бүлмәгез саен икешәр радио бит инде, артыгы ник кирәк?

— Һи-и, үз кулларың белән җыйганга җитәме соң!— Ул әллә ничә тартмадан торган зур радиоалгычка ымлады:— Күршеләрдән күрмәкче, өй тыгызлап, тутырып куйдылар инде! Минеке шырпы тартмасы хәтле генә булачак.

Фирүзә мәктәпләрендәге күңелсезлекне, Кодрәт исемле укучысының киреләнүен сөйли башлагач, абыйсы радиосын онытты. Сеңелесенең сүзе беткәч тә ул әле шактый ара эндәшми торды. Бераздан:

— Синең ул Кодрәтең тугызынчы класста ук бит инде,— дип уйлаганнарын сеңелесенә дә төшендерә башлады.— Ялгыштыгыз сез. Кулында ут уйната торган ул баланы, сигезенче класстан соң ук һөнәрле итүягын карарга кирәк булган. Урта белемне училищеда алыр иде, теләсә, соңыннан институтка да керергә мөмкин. Андыйларның тизрәк эшкә тотынуы хәерле.

— Әнисе күзебезне ачтырмады бит: «Әллә минем улымны укытырлыгым юкмы, мин кайсыгыздан ким, ник берегез дә үз балагызны училищега җибәрмисез?!»— дип, кырт кисте.

— Син, сеңелкәем, әнисе, дигән булып, көчсезлегеңне аклап азапланма. Физика укытучың, хезмәт дәресләрен алып баручың белән бергәләп киңәшергә иде! Андый балалар физиканы бик яратучан. Әнә минекеләр! Һи-и, алсалар, алтынчы класстан ук училищега китәрләр иде. Миң аларны металл, электр, радио белән сихерләп бетерәм. Үзебезнең улыбызны да ияләндердем. Авылда укытканда, малайларым гына түгел, кыз балалар да, шофер я тракторчы булам, дип шашыналар иде.

Берсендә, алтын медаль алган укучыбыз, институт турында уйларга да теләмичә, механизатор булып калды.

— Беләм инде. Ул чакта үзенә дә РОНОдан шелтә эләгә язды.

— Нишлисең бит, безнең эш шундый, сеңелем. Шелтәсен дә күтәрергә туры килә. Ә ул медальле егет, беләсеңме, хәзер кайда?

— Юк инде, каян белим.

— Һаман шунда ук, «Наратлы» колхозының баш механигы. Урак өстендә комбайнга да утыра. Үткән ел үзенә ВДНХдан «Москвич» биргәннәр.

— Авылда әйбәт хәзер.

— Эш кешесенә кайда да бер, дияр идем мин. Шәһәр заводларына токарь, фрезерчы, расточник җитми. Без балаларны тырыша-тырыша югары белемле итәргә азапланабыз. Дөрес түгел. Хәер, безнең мәктәптә ул проблема юк. Безнең малайлар сигездән соң һөнәр училищесына китәргә атлыгып торалар. Завод-фабрикалар белән бер сүздә без. Директор бик өнәми: ну, Галлямыч, ди, ичмасам, начаррак укыганнарны котырт, яхшылары калсын, сәгатьләр кими бит, класслар азая, ди. Ә нигә классларга кырыгар-иллешәр бала тутырырга? Чирек азагына кадәр бер билге куеп өлгерсәң, өлгерәсең, өлгермәсәң — юк. Егермесен калдыр да рәхәтләнеп укыт! Укытучы — бик зур кеше ул. Тирәннәнрәк уйлансаң, җир шарының язмышы безнең кулда, сеңелем! Һәр балага без теләгән шәфкать иңсә, дөньякүләм мәсьәләләрне чишүе дә җиңеләер иде. Әйтик, Җирнең бөтен педагоглары бердәм программа белән эшләсә! Ә? Яхшы укытучыга эләккән бала начар була алмый. Шулаймы?

Фирүзә, бу сорауда үзен сынау кебек ишарә сизеп:

— Мин үз укытучыларымнан зарлана алмыйм, абый,— диде.— Торып-торып шатланам әле: авыл мәктәбендә уку мине күп нәрсәгә өйрәткән. Ул укытучыларым мине үз һөнәрләренә гашыйк иткәннәр.

— Белә-әм мин ул синең укытучыларыңны: Закия, Нурания, Сәкинә. Минем яшьтәшләр иде. Дәреслекне ятлатырга осталар иде инде. Үзләре дә кысадан чыгарга куркып яшәделәр.

— Укытучы да кысадан чыкса, ни була?

— Ә тормыш? Тормыш без укучыларга күрсәткән кысага сыямы? Дәреслектән башкага өйрәнмәгән балалар, әнә шул һөнәр училищесына гына барсын, көткәннәренең капма-каршысы белән күзгә-күз очраша. Мәктәпләрне тормышка ныграк бәйлисе бар әле безнең. Хәзергә без иң четерекле якларны уратып үтәргә тырышабыз шикелле. Яшьләр хакыйкатьнең иң кырысын очраклы кешеләрдән белә.— Абыйсы үзен акыл сатучы итеп калдырырга теләми иде, тукталып калды.— Хәер, мәктәптә дә шактый четерекле сораулар ишетергә туры килә.

— Бер караганда, ачыктан-ачык сораулары хәерле, абый.

— Шулай. Менә синең ул Бәйрәмовны тәртәгә кертү өчен эштән дә яхшысы юк. Әйбәт егет булачак ул — абый әйткән иде, диярсең. Бөтен кешедән дә барлык фәннәрне «отлично»га белүне таләп итү дөрес түгел. Бертөрлелек — табигатькә ят нәрсә. Кадак та кага белмәүче академиклар булырга мөмкин. Кем белә, бәлки, безгә Бәйрәмов кебек эшкә атлыгып торучылар күбрәк кирәктер әле. Теория алда бара.

— И абый, син гомумдөнья мәшәкате өчен борчыласың, миңа бүгенгесен үткәреп җибәрүе авыр. Бәйрәмовның дәрескә килмәве мөмкин.

— Борчылма, килер ул, беркая да китмәс...

Кодрәт Бәйрәмов исә шул китүеннән мәктәпкә шактый вакыт аяк та басмады. Бүген килер, иртәгә килер, дип, Фирүзә шактый көннәр сабыр итте. Малай берничә көн рәттән күзгә-башка күренмәгәч, өйләренә барырга кирәк санады.

Бу юлга укытучының аягы тартмый иде. Күңеле һич күтәрелмәде,

чөнки Кодрәт класстан чыгып киткән көннәрдә Фирүзәнең үз гаиләсендә күңелсез хәлләр булды. «Үз улларыннан сора!» дигән сүзләрнең серенә төшенер өчен ул балаларына сүз кушып караган иде. Тик: «Юк. Белмим», кебектән башка җавап ала алмады.

Бәйрәмовларның өенә барырга җыенган көнне Фирүзәнең җаны меңгә өзгәләнде. Җитмәсә, кичтән Зиннәте өйгә кайтмаган иде. Ул соңарачагын хәбәр итте итүен. Фирүзә соңгы дәресен биреп чыккач, аны укытучылар бүлмәсендәге телефонга чакырдылар. Трубкада Зиннәт иде:

— Мине икенче сменага калырга кыстыйлар,— диде.— Кичке ашка көтмәгез. Ай азагы бит, үзең беләсең...

Иренең икенче сменасы тәмамланыр вакыт җиткәндәрәк, хатын, дәфтәрләр тикшерүеннән аерылып, кухняга кабат керде. Ашын кайнарлатты. Тагын сәгатьтән артык вакыт үтте, әти кеше кайтмады. Әйткән вакытында да күренмәгәч, хатын күңелен шом басты. Йокы алмаячагын белсә дә, балаларын борчудан куркып, залдагы утны сүндерде, сабыр атлап, әчке бүлмәгә кереп ятты.

Ул гомерендә беренче тапкыр өйләрендә телефон юклыкка битәрләнде. «Аһ, булсын иде ул телефон! Зиннәт туры килмәсә, эниләргә шалтыратыр идем, абый белән киңәшер идем»,— дип ачыргаланды.

Нihаять, елдай озынга сузылган төн үтте. Балалар, әтиләре төнлә кайтып ял итә, дип уйладылар, ахры, сорап та тормадылар. Юыну бүлмәсе, кухня, зал арасында тулгандылар да:

— Әнием, киттек!— дип, мәктәпкә йөгерделәр.

Өй эче тып-тын калды. Фирүзә, кабаланып, үзен караштыра башлады. Мәктәбенә соңга кала язган бит! Гомер булмаганны! Ярыймы соң?!

Өлгерде ул. Хәтта үз классының хәлен белешергә дә өлгерде. Өметләнеп көргән иде дә — юкка булган. Бәйрәмов юк иде класста. Инде Зиннәтнең заводына шалтыратырга кирәк. Фирүзә башта телефонга кагылырга кыймый торды. Кайгылы хәбәр ишетелер сыман. Күңелендә ике уй тартыша: берсе — Зиннәт муеннан эшкә чумгандыр; икенчесе... юк, анысын ачыклыйсы килми.

— Алло! Кырыгынчы цехмы? Әйтегез әле, Зиннәт Нуриевич ничәнче сменада эшли?— Бу сорауга җавап бирмәүләрен сизенеп, тагын өстәде:— Хатыны мин аның.

— Зиннәт Нуриевичның сменасы тәртиптә,— Ап-ачык тавыш өзеләп аңлатты.— Ул кичә кичке биштә кайтып киткән иде, әлерәк кенә килде. Кирәксә, тоташтырам.

— Юк, юк, рәхмәт, мин соңрак шалтыратырмын...

Кичә иренең ялганлавы билгеле булгач, Фирүзәне кеше холкындагы яман тойгылар биләп алды: ышанмау, шикләнү, көнчелек. Соңгысы барыннан да көчлерәк иде. Фирүзә үз эшендәге көнчелекнең ни икәнен дә белми. Киресенчә, башка укытучылардагы яңа алымнар, өлгерлек — аның өчен бер этәргеч кенә. Әмма Зиннәт белән икесе арасындагы мөнәсәбәткә җил дә тидерәсе килми. Кулыннан килсә, Зиннәтен бер генә мизгелгә дә яныннан җибәрмәс, аның күзләрен үзенә генә каратып торыр, сүзләрен үзе генә тыңлар иде. Фирүзә бу хисенең урынсызлыгын, ир белән хатынның гел-гел рәттән торып кына яшәмәгәнлеген, Зиннәтне көнчелек кебек яман хис белән кимсетергә хакы юклыгын да аңлый. Шулай да һични чек тыеп тормаслык көч вакыт-вакыт хатынны уттан алып утка сала. Андый чакларда Фирүзә үз хәрәкәтләренә, сүзләренә, кылган гамәлләренә сак куя алмый башлый.

Аның җаны тагын кыйналырга тотынды. Эштә булам, дип тә, башка җирдә кунып калган ире, Фирүзә уйлавынча, кырын юлга аяк баскан, аңа хыянәт иткән кебек иде...

Тәнәфестә ул кабат телефон янына килде. Иренең төнлә нишләп

йөрүен ачыкламыйча, Фирүзәнең җаны тынычланмаячак, дәресләренең дә рәте-башы булмаячак.

Аппарат янында берәү дә юк. Тик... нәрсә сөйләшергә соң? Бүлмә тулы — укытучылар. Алар алдында иреңнән: «Син кайда йөрдең?» — дип ничек сорарга?

Ул да түгел, җанны сискәндереп звонок чыңлады. Укытучы гомере шул чыңнар белән меңгә бүлгәләнгән. Муеннан мәшәкатькә алып керсә дә, алар берзаман бәхет китерә. Укытучы әнә шуның белән яши.

Ниһаять, Фирүзә үз классына керде. Монда рәхәт — үзең үстергән бакчада йөргән кебек.

Гадәттә, алар башлангычны тәмамлаган берәр классны кабул итәләр дә, урта белем биргәнче, шуларга җитәкче булалар. Фирүзәнең үз канаты астына алган балаларны өйрәнүдә ышанычлы тәҗрибәсе бар. Иң әүвәл һәркайсының холык-фигылен, сәләтен ачыклый, аннары гына төп гамәлгә күчә. Укытучы хезмәтенең табигый осталык таләп итүчән иң четерекле ягы, мөгаен, шушындадыр. Бала фән кагыйдәләрен ятлап та үзләштерә ала, педагогның бурычы — аңарда шәфкать, булдыклылык, матурлыкка омтылыш та тәрбияләү.

Фирүзә, яңа класс белән танышканда, ачыктан-ачык әйтә:

— Укучылар, әлегә без бер-беребезне яхшы белмибез. Әйдәгез, якыннанрак өйрәник.

Хикмәт, әлбәттә, исем-фамилияләрне хәтергә сеңдерүдә түгел. Теләсәң ничек аңлат: Фирүзә балаларның исемен, аның йөзенә карауга ук чамалый кебек. Журналдагы фамилияне класска кычкырып әйтә дә нәкъ шул балага тутырып карый. Фаразы хак булып чыга. Икенче көнне инде ул үз классы укучыларына бары тик исемнәре белән генә эндәшә.

Фирүзә беренче очрашуларны эчкерсез танышуга багышлый.

— Укучылар, без үзебезнең әдәбият кабинетында кичә оештырыйк әле!— ди ул.— Сезнең әти-әниләрегезне чакырыйк!

Танышулар мәҗлесенә әзерлек йөзеннән Фирүзә «Безнең гаилә» дигән темага сочинение яздыра. Монда ул укучылары өендә кемнәр барын гына түгел, ул йортлардагы шәхесләргә карата баланың фикерен дә чамалап ала. Алдан кисәтә: «Бу юлы орфография, пунктуация кагыйдәләренә игътибарны артык юнәлтмәсәгез дә мөмкин, мин эчтәлеккә карап бәя куячакмын». Әллә шуңа кызыгып, балалар бу сочинениене гадәттәгедән озын иттереп язалар. Нәтиҗәдә, Фирүзә һәр укучысының нинди даирәдә яшәвен ачыклый. Шул беренче язмалар укытучы күңелендә әлеге класс өлгергәнлек аттестаты алганчыга кадәр ап-ачык саклана. Күп очракта авыр холыклы балаларның язмасы хикмәтле була. Мәсәлән, Фирүзә Бәйрәмов сочинениесен бүгенгедәй хәтерли. «...Безнең әби әйбәт,— дип язган иде ул.— Көне буе үзенең авылдан алып килгән җиз самовары төбендә утыра, чәй эчә. Мин көләм. Әби, суы суынып беткәндер бит инде аның, дим. Ул да көлә. И улым, ди, мин бит аны, син мәптегендә чакта, мең мәртәбә шаулатып алдым инде, ди. Кил, утыр яныма, сыйлыйм әле үзеңне!— ди...»

Башка балалар күбрәк этиләренең эшен, әниләренең өлгерлеген мактадылар. Бер Бәйрәмов кына әбисен, аерып алып, язды. Аның сочинениесендә «әти» сүзе бөтенләй юк иде. Әнисе турында да малай аз сөйли: «Әнием — кибетче. Ул эштән арып кайта».

Бу классның беренче язмалары белән танышкач, Фирүзәнең күңеленә яңа исем-фамилия кереп урнашты: «Кодрәт Бәйрәмов».

Беренче мәгълүматлар белән танышкач, Фирүзә очрашу кичәсен уздырырга әзерләнә башлый.

— Укучылар, минем инде сочинениеләрдә телгә алынган якын кешеләрегез белән очрашып сөйләшәсем килә!— ди.— Бер көн билгелик әле, чәй табыны әзерлик, җырларга-биергә өйрәник!

Балалар риза. Барысының да үзенең җырга-биергә яки шигырь сөйләргә һәвәслеген күрсәтеп каласы килә, табын тезешергә дә каршы түгелләр. Башта Бәйрәмов кына актан-карадан сүз катмый торды. Бары азактарак:

— Әбине алып килергә ярыймы соң?— дип сорады.

Кырык бала кырык яктан, дөнья яңгыратып, көлеп җибәрде: «Әбиенә сәлам әйт!»— диде кайсыдыр. Фирүзә моңа әзер иде. Малайны авыр хәлдән чыгару өчен ул бик житди иттереп:

— Рәхмәт, Бәйрәмов!— диде.— Класстагы кырык укучы арасында син берүзең әбиеңне дә яратасың, хөрмәт итәсең икән. Мин моны синең сочинениеңне укып та сизгән идем. Әгәр әбиең безнең белән танышырга килсә, мин бик шат булыр идем. Беләм: аниең авыр эштә, ул соң кайта...

Укытучының хуплавын ишеткәч, кинәттән аңа кызыгып караулары тоеп, Бәйрәмовның башы күккә тиде. Тик аның укытучыга бирәчәк соравы бетмәгән иде әле:

— Әбигә нинди чәй эчерәбез соң?

Беренче көлүеннән «уңышсызлыкка» очраган класс житдиләнгән иде инде. Арадан бер кыз:

— Бездә «Индийский» бар,— диде.— Алып килермен.

Аңа теләктәшләр табылды. Төрле яктан тавышлар ишетелде:

— Бездә Шри-Ланкадан килгәне дә бар, сәйлүн чәе!

— Мин Вьетнамныкын алып килә алам.

— Кытайныкы кирәкмиме?

Бәйрәмов бу сүзләрнең берсенә дә сыгылып төшмәде.

— Безнең әбигә жиз самавырда кайнаган чәй кирәк!— диде. Аннары, сүзенең озакка тартылуын чамалап, үзе үк нәтиҗә ясады:— Мин аңа кирәк нәрсәләрне үзем табармын.

Әти-әниләр белән очрашу-танышу кичәсе уздырылачак көндә Кодрәт Бәйрәмов мәктәпкә бер чиләк сыешлы жиз самавыр күтәреп килеп керде. Самавыр затлы сарайларның ишек тоткасы кебек ялтыратылган, утырмага килгән кунак кызы кебек елмаеп тора.

Малай Фирүзәне күргәч:

— Менә, апа,— диде.— Әби үзе биреп җибәрде!

Дәресләр түгәрәкләнеп, озак та үтмәде — балаларның әти-әниләре килә башлады. Фирүзә аерым бер кызыксыну белән Кодрәтнең әбисен көткән иде.

Әнә ул: чәмчәле читеген, мең бәби итәкле шау ефәк күлмәген киеп, борынгыдан калган карталы шәлен бөркәнеп, жиз самавыр янында утыра. Чәен дә, чынаяк тәлинкәсенә салып, өреп-өреп, бөтен шартын китереп эчә. Кунакларның күңелен күрер өчен Фирүзә, сары майда гына чыжлатып, кош теле пешергән иде. Карчык аны яратты бугай, гел шуны гына кетердәтеп утыра.

Мәҗлес бер эзгә төшкәч, Фирүзә бу очрашуның төп максатын аңлатырга кирәк тапты, ата-аналарның мәктәпкә карата булган теләкләрен белеп калырга теләвен әйтте. Баштан ук дәррәү күтәрелмәсәләр дә, кызыклы гына фикер әйтүчеләре булды. Иң азактан Кодрәтнең әбисе тамагын кырып куйды. Ул инде чынаягын тәлинкәсенә каплап куйган, ягъни ашау-эчүен түгәрәкләгән иде. Озын чуклы шәлен рәтләгәндәй итте дә иплән кенә торып басты. Мәҗлес тып-тын булды. Чөнки әлеге карчыктан да өлкәнрәк, аннан да мөлаемрәк кеше юк иде. Бөтенесенең карашы — аңарда. Фирүзә аны хупларга ашыкты:

— Фәхерелхаят апа, сезнең дә әйтерегез бармы? Рәхим итегез!

— Олыны олы итә белүегезгә рәхмәт!— дип башлады ул.— Тавышы көр. Каушауның эзе дә юк. Күрәсең, әйтерен уйлап куйган.— Олы күңелен олыламаган олыгаймаган, диләр иде. Безнең күңелләрне күреп, мәктәпкә чакырып китерүегезгә, чәй-суларыгыздан авыз иттерүегезгә бинһая рәхмәтләр яусын!— Барысы да, сүз беркеткәннәр дияр-

сең, бердәм кул чаптылар.— Инде, килгән-килгән, күңелдәгене әйтми китәргә дә ярамас. Уйланып утырдым әле: нинди һәйбәт мәктәп, дим, ихласыннан тырышып йөрүче мөгаллимә! Болар барысы да — безнең балалар бәхете бит! Әүвәл без ни күрә идек? Илтеп бирәләр иде остабикәгә, әнкәй мәрхүмәнең бер кулында — остабикәгә дигән биш тиенлек бакыр, икенчесе белән мине сөйри. «Менә, ди, кызымны китердем ите — синңа, сөяге — безгә. Хәреф танырга өйрәнсә, саный белсә, хак тәгаләдән мең рәхмәтләр сорап, дога кылыр идем...» Остабикә әнинең кулына карап каткан була. Биш тиен генә икәнен күргәч, күгәреп чыга.

— Ярар!— дип кычкыра.— Тезләнсен әнә мич буена!

Без әнә шулай укыдык.

Укучылар әбинең сүзен, тын да алмый, тыңлыйлар. Кодрәт сабырсызланып кычкырып куйды: «Җитте инде, әби!»

— Дөрес, балам. Күп сүз — чүп сүз. Туктыйм.— Карчык күтәрелеп Фирүзәгә карады.— Безнең Кодрәтнең язмышы сезнең ихтыярга тапшырылган, өебездә аның белән шөгыльләнерлек укымышлы затлар юк. Зинһарлап сорыйммн: яхшылыкка өйрәнә күрсен!

Урта яшьләрдәге берничә хатын да сөйләде. Алары сугыш чоры авырлыкларын, салкын мәктәпләрне, дәфтәр-каләмсез укуларын искә алдылар. Балаларына бүгенге әйбәт шартларда яхшы укырга кирәклекне аңлатырга тырыштылар.

Очрашу кичәсе, Фирүзә теләгәнчә, әйбәт узды. Фирүзә бу кичәдән соң Кодрәт Бәйрәмовның әбисе белән уртак тел табуына аеруча шатланды. Әмма мең дә берне белүче карчык, класста авыр холыклы күренгән бердәнбер укучысының иң кирәкле терәге, очрашу кичәсеннән соң озак та тормый дөньядан китте. Кодрәт белән эш итү авырайганнан-авырая барды.

Көннәрнең берендә малай хәтта милициягә эләкте. Үзеннән олы яшьтәге егетләр белән берләшеп, төнге сменадан кайтучы эшче кызларны куркытып йөргәннәр. Берәвендә пәке дә табылган. Участок инспекторы мәктәпкә килде.

— Сезнең укучы җинаятькә турыдан-туры катнашмаган, әмма ул шул төркемдәгеләрнең серен белергә тиеш, әйттереп кенә булмый.— Ул Фирүзәдән шул серне чишүдә ярдәм сорады.

Фирүзәнең моңарчы милициягә эләккән бала белән эш иткәне юк иде әле. Өйләренә баргач, әти-әнисенә ни әйтергә кирәген дә белмәде. Урынсызга ачуланып ташласаң, баланың мәктәптән бөтенләй читләшүе бар. Шуңа күрә Фирүзә алдан, Кодрәткә әйтеп тә тормастан, аның әнисе эшли торган кибеткә китте. Алдан телефон аша сөйләшкән иде. Кибетче хатын:

— Килегез. Сәгать бер белән ике арасында әбәткә туктыйбыз, шул чакта булса, әйбәтрәк,— диде.

Алар кибет бухгалтериясенең тар бүлмәсендә очраштылар. Бәйрәмов әнисенең арыганлыгы йөзенә чыккан иде. Фирүзә:

— Ачуланмагыз инде!— димичә булдыра алмады.— Кодрәт өчен йөрүем. Милициягә эләккәннәр бит — яшереп торып булмый.

— Беләм. Минем малайның гаебе юк. Яман юлга басса, мин аның милициягә эләгерлеген калдырмыйм...

Фирүзәне шом басты. Хатын үз-үзенә шулкадәр нык ышанып сөйли иде-ки, әйтерсең, улының берәр хатасы булса, аны тота да юк итә. «Үз балам — аның язмышын да бары тик үзем хәл итәм!»— ди кебек. Гогольның Тарас Бульбасы сыман: «Үзем таптым — үзем үк синең җаныңны да алам!» Шулай да, малайның гаебе юк, дигәне укытучыны берaз тынычландыра иде. Чөнки ул сүзләр дә бик җитди һәм тирәннән ышанганлык белән яңгырадылар.

— Сез барын да белеп торасыз икән. Анысы яхшы. Ничек булды соң ул?

— Кодрәт күрше малаена ярдәмгә генә чыкты. Сорагач. Аның әнисе химзаводта мастер. Вак-төяк нәрсәләр ясый торган цехта. Ай азагында исәпләп караганнар икән, план тулмый. Әйбер ясалуын ясала, тапшырганчы кими. Аптырыйлар. Мастер бер-ике кыздан шикләнә, тегеләр әзер әйберне читкә алып чыгалар кебек. Урамда да сүз йөрде: кибеттәге ике тәңкәлек кавырсын чиләкне бер тәңкәгә сатучылар бар, имеш. Бизәкле целлофан пакетларның да унысын бер тәңкәгә бирәләр, ди. Мастер хатын өенә кайтып зарланган, күрәсең. Малай тыңлап торган. Анда эшләүчеләр билгеле бит, барысы да шул тирәдә яши. Малайларга әтәчләнергә генә булсын: имеш, каракны тоталар. Әнисе шикләнгән кызларның төнге сменадан чыкканын көтеп торганнар... Мин бит үзем дә соң кайтам. Кайбер көнне бүлмәсенә баш тыгарга да вакыт калмый. Алар төне буе теге каракларны аулап йөргәннәр...

Химзавод хәлләрен ачыклавына канәгать калса да, Фирүзәнең башында меңләгән сорау туды: әнисе белән тәүлегенә бер мәртәбә дә күреп сөйләшә алмагач, бу бала ничек тәрбияләнә? Әтисе кайда? Бала язмышын кем кайгырта? Тик беренче очрашуда ул бу сорауларны берсенә дә ашыкмады.

Ярый, ял итегез!— диде.— Минем дә икенче сменадагыларга дәрес бирәсем бар. Бер иркенләбрәк очрашырбыз әле!

— Колбаса-мазар кирәкмиме соң?

Фирүзә бу сүзләрне ишетмәмешкә салышты. Баласының язмышы турында сөйләшкәндә анадан мондый сорауны һич тә көтмәгән иде.

— Бүген ысланганын китерделәр. Сирәк була ул. Берәр кило үлчәтеп алыйк соң!

Монысын җавапсыз калдырырга ярамый иде инде.

— Андый гадәтем юк.— Фирүзә кабаланып-ашыгып, чыгу юлын эзләде. Нииндидер әрҗәләргә бәрелә язды, такталарга абынды. Борылырга мәҗбүр булды.— Озатыгыз әле!

Сатучы хатынның йөзенә гаҗәпләнү билгеләре чыкты.

— Сезнең кебекне беренче күрүем. Әйдәгез алайса! Яхшы сортлы конфет кирәктер, бәлки? «Индийский» чәй?..

Фирүзәнең кинәттән кырысланып калуы кибетчене дә җитдиләндерде. Кабат баласы хакында сүз кузгатты:

— Рәхмәт инде,— диде.— Безнең Кодрәт турында сез кайгыртмагыз, күз-колак булырдай башка кешебез дә юк. Аталары башта эчте. Мәрхүмә кайнанамнан күрәдер идем. Шул карчык булмаса, алай азгынлыкта йөртмәм, эчүеннән туктатырмын кебек тоела иде. Гөнаһысы үземә төшсен: өебезнең бөтенлеген шул карчык тотып торган икән. Ул үлгәч, рәтебез китте. Аталарына бик яман бер тузынган идем, икенче көнне кайтмады. Заводның тулай торагында, диләр. Артыннан эзләнеп йөрергә хурланам. Малай да бик гарьләнде. Ул хәзер атасының китүенә дә мине гаепле саный, бугай. Сөйләшми дә...

Кодрәт Бәйрәмовның холкына һич төшенеп бетәрлек түгел иде. Класска аннан-моннан тикшерү килсә, малай, бер җаен табып, Фирүзәне тынычландырырга ашыга:

— Фирүзә Галләмовна, сез минем өчен борчылмагыз, минеке «дүрт»ледән дә ким булмас! Гарантия! Отличницагыз артына утырам да, рәхәтләнеп күчерәм. Борчылмагыз гына!

Фирүзә ирексездән елмаеп куя:

— Ну, Бәйрәмов! Кызлар синнән күчерергә ашкынып торсыннар иде — менә булыр иде ул гарантия!..

Малай дәрестә тыныч утыра алмый, әмма аңа кулга тотып эшләрдәй берәр эш тапшырылса, ялт иттереп үти дә куя. Җәйләрен исә, хезмәт һәм ял лагеренда ул үзе оештыручыга әйләнә. Металл калдыклары яки иске кәгазьләр җыйганда Фирүзә бөтен җаваплылыкны аңа йөкли.

Кодрәт иң ялкау балалардан да норманы тутыртмый калмый. Аннары рапорт бирә:

— Фирүзә Галләмовна, приказыгыз үтәлде! Без — беренче!

— Яхшы, Бәйрәмов! Мин ышанган идем. Инде уку...

Сүзне очлап өлгерә алмыйсың, малай китеп тә барган була. Үткән чиректә дә макулатура җыюда иң алга чыкканнар иде алар, шунлыктан Фирүзә шомлы янгында Кодрәтнең катнашы юклыгына нык ышана.

Тиздән аларның классы кабат лагерьга китәчәк. Ике укытучы берләшеп, үз классларыннан егерме бишәр баланы алып барырга тиешләр. Фирүзә киләсе елга пенсиягә китәргә тиешле Әминә апа белән парлашты. Ул алдан ук әйтеп куйды:

— Фирүзә-алтыным, тыныч кына ял итәрлек булсын дисәң, алмыйк әле шул Бәйрәмовыңны!— диде.— Мәктәп янындагы бакчада эшләргә калдырыйк!

Кайчак Кодрәт аркасында кыенлыкка очрап торса да, Фирүзә аңа ышана. Малайның һич көтмәгәндә башка сыймаслык ахмаклык кылуы да ихтимал, тик ул аны явыз нияттән эшләми. Фирүзә малайның хаталану сәбәпләрен эзләп, аклау ысуллары табарга тырыша. Малай холкындагы матур якларны башкаларга күрсәтә алмый аптырый. Малай исә үзен якларга ярдәм итәсе урында киреләнә дә ката.

Унынчыларның макулатурасы янганның өченче көнендә Фирүзә янына Бәйрәмовлар күршесендә яшәүче бишенче класс малае килде:

— Фирүзә Галләмовна, Кодрәт укырга йөрмәс инде. Сезгә әйтергә кушты,— диде.

— Шаяртып кына әйткәндер ул.— Фирүзә агарынып чыкты.— Тугызынчы класста мәктәп ташларга ярыймыни?!

— Ә-ә, ул ни диде әле: Фирүзә апага минем аркада эләгер инде, диде.— Малай елмая иде.— Сезнең өчен кайгыра.

Фирүзә шушы көнне директор янына киңәшкә керде.

— Федор Федорович, макулатуралар тапшырылгач та, сез актив укучыларга рәхмәт кәгазе яза торган идегез.

— Рәхмәтне, иптәш Нуриева, үзегез беләсез, сорап алмыйлар. Бу юлы, милиция чакыртмавым өчен, ул рәхмәтне, бәлки, тәртипсез укучылар миңа әйтергә тиештер әле.

— Шулай да дирекция Кодрәт Бәйрәмовка рәхмәт язсын әле!

...Кичен Фирүзә Кодрәтнең өенә китте. Кулында дирекция имзасы салынган, мәктәп мөһере сугылган приказ кәгазе иде.

Бәйрәмовлар өендә Фирүзәнең булганы бар. Бәйрәмовлар иске урамда үз йортлары белән яшиләр. Өйләренең төп бинасына, такталардан гына караштырып, тагын әллә ничә бүлем кушып салынган. Кайсы — пар казаны өчен, башкасы — веранда, чолан. Бакчасы биек койма белән томаланган, чыпчык очып үтәрлек тә түгел. Фирүзә белә инде: капка бикле була, ачтыра алмый йөдәп бетәсең. Ике ул үстергән бу тол хатын шактый мул яши. Аңа җиңел түгел, әлбәттә. Ананың күп чакта кәефсез булуын да аңларга мөмкин...

Йорт янына җиткәч, Фирүзә аптырабрак калды — капка шәрран ачык. Кодрәт язгы сулардан калган чүп-чарны урам чокырына ташый икән.

— Исәнме, Кодрәт? Әниең өйдәме?

— Юк,— малай сөзгәк үгез кебек аска карап катты.— Ул соң кайта бүген?

Укытучыга бүген малайның үзе белән сөйләшү кирәгрәк тә иде әле.

— Ярый,— диде ул.— Аңа йомышым да юк, сиңа гына килдем.

Малай башын күтәрде, йөзе яктырган иде. Ул, кул арбасын читкә куеп, өстен-башын каккалады да:

— Әйдәгез, Фирүзә Галләмовна, өйгә керик!— диде.

Укытучы малайның теләгенә каршы килмәде. Керделәр. Бусагадан атлауга Фирүзә өйдәге чисталыкка, һәр нәрсәнең үз урынында икәнлегенә сокланды.

— Узыгыз!— Кодрәт аны эчкә чакырды.— Ишек төбендә тормагыз!

— Абыең кайда соң?

— Ул өйләнде бит. Заводтан квартира бирделәр.— Малайның йөзе кинәттән суырылып калды.— Безнең абый китте шул, апа...

Бу турыда тагын берәр сүз әйтсәң, малай кычкырып елап ук җибәрер төсле иде. «Абыйсын бигрәк яраткан икән инде!» — дип уйлады Фирүзә. Сүзне икенче якка борырга кирәк иде.

— Дәресләр беткәч кенә күрдем, директор яңа приказ язып куйган икән. Укучылар да бүгенгә белми калдылар. Мин сезнең күрше малаен эзләгән идем, ул да китеп өлгергән.

Бәйрәмов утырган җиреннән сикереп торды:

— Хәзер дәшеп керәм мин аны, апа, кайтты ул, күрдем.

— Утыр, утыр, миңа бит ул кирәкми.— Фирүзә портфелен ачты.— Приказ синең турыңда бит...

Кодрәт тагын сикереп торды. Абыйсы турында сөйләшкәндә генә моң белән сугарылган карашларында кисәктән усаллык ялтырады:

— Нәр-сә-ә?— дип кычкырып ук җибәрде.— Приказ әзер, дисезме?!

Ярымкараңгы бүлмәне малайның ямьсез тавышы тутырды. Фирүзә бер мизгелгә генә онытылып торды: кайда соң әле ул? Ни булды? Малай йолыккалана, як-ягына карана, куллары белән өстәлне төймәкчә була, әле утыра, әле торып баса. Бу хәлендә ул класс җитәкчесе китергән рәхмәт приказына әйләнеп тә карамаячак. Башта аны тынычландырырга кирәк иде.

— Энем, сез үзегезгә килгән бөтен кешене дә шулай каршы аласызмы?

Көтелмәгән мондый сорау малайны кызартып җибәрде. Укытучысы:

— Безнең халык килгән кешегә ачык йөзен, такта чәен кызганмый,— дигәч, кабат үзенең гадилегенә кайтып төште.

— Чәй хәзер кайнап чыга ул, апа!— Кодрәт кухня ягына ашыкты.

Мәктәптә укытучыларга «апа», «абый» дип эндәшү тыела. Еллар буе саклаган бу гадәт укучыларның да, педагогларның да канына сеңеп беткән. Фирүзә, мөгаен, авылда үскәнгәдер, Бәйрәмовның «апа»сын үзенә карата күрсәтелгән аерым бер ышанычтай кабул итте. Хәзер мөнәсәбәтләрне әнә шул җылылыгыннан чыгармаска иде.

— Үзең бигрәк уңган инде син, Кодрәт. Әниеңә дә булышасың икән. Мин мондый зур хуҗалыклы өйдә бернигә дә өлгерә алмас идем.— Фирүзә үзалдына сөйләнгән кебек утыра иде.— Хәер, безнең авылдагы өй дә болай зур түгел иде шул. Әти-әни укытучылар иде, терлек тә асрамадылар. Гел китап та дәфтәр. Сугыштан соң бигрәк авыр иде...

Олылардан берәүнең дә Кодрәт белән болай, ачылып китеп, сөйләшеп утырганы юк. Ул бирелеп тыңлый башлады. Тик бераздан кече якта суы кайнап чыккан чәйнекнең капкачы сикергәләве ишетелде, малай тагын кузгалды:

— Хәзер, апа, мин чәйнекне генә алып килим!

Малай «киребеткән укучы» икәнлеген онытты шикелле. Аның өчен хәзер иң мөһиме — табын янындагы кунакны сыйлау.

— Апа, сез чәйне вареньe белән эчәсезме, шикәр янсә конфет куйыйммы?

— Әйдә, вареньe белән эчәбез: сезнең бит үз җиләгегез, әйеме?!

— У-у, күп ул бездә җиләк. Вареньеның былтыргысы да калды әле. Бакча зур безнең, әнинең вакыты юк, гел мин эшлим анда.

— Беләм, Кодрәт, әниең әйткән иде.

— Бакчада рәхәт ул. Мин күпьеллык чәчәкләрне яратам: пионнар,

лаләләр, флокслар. Кар да эреп бетми — аларның шәмәхә шытымнары күренә башлый, күп тә үтми куш йодрык кадәре кып-кызыл яки ап-ак чәчәкләр ачыла.

— Безнең эштә дә шундыйрак бер нәрсә бар, Кодрәт. Орчык буе гына балалар җыела мәктәпкә. Синең чәчәкләрнең шытымнары кебек. Алар үсеп җиткәнче, ун ел вакыт үтә. Без аларга күп вакыт кырыс булып кына күренәбездер, бала чакта башкасы турында уйламыйсың. Укытучы баланың матур бер сыйфатын ачса, үзен җиңүчедәй хис итә. Ялгышса, башыңны кая куярга белми интегәсең...

Фирүзә, сөйләгәннәрен расларга теләгәндәй, баягы приказ кәгазен Кодрәткә сузды: «Иң кирәген һаман әйтә алмый торам икән,— диде.— Әле килүем дә синең шатлыкны уртаклашырга ашыгудан иде бит. Мена, укы, әниеңә дә әйтерсең. Дирекциянең рәхмәте бу!»

Малайның битен комач каплады. Ул маңгаена төшкән шома сары чәчен кирегә сыпырырга тотынды. Яшел күзләр мөлдерәтеп Фирүзәгә карап калдылар.

— Мин бит әле, приказ, дигәч, теге пожар турында дип уйладым. Шелтә-фәлән дип. Ачу чыкты. Укуны да ташларга уйлаган идем.

— Ялгышма, Кодрәт. Синең тырышлыгыңны бөтенебез күреп торабыз бит. Нигә шелтә бирсеннәр сиңа? Шикле-микле сүзләрне син үзең куертып җибәрдең.

— Шулайрак килеп чыкты шул, апа.— Малай елмая иде.— Үзем дә сизми калдым.

Малай табынга күз салды:

— Эчегез инде, апа!— диде.— Чәегез суынып бетте. Мин менә хәзер чын дөресен әйтәм: ут чыгуда минем бер катнашым да юк, ну ул турыда беләм мин.— Малай башын аска иде. Аңа артыгын сөйләве авыр иде, күрәсең.— Мине ияртеп кенә барды берәү. Ут без дәрескә кереп утыргач күтәрелгән. Мин әле һаман аңламыйм: ник алай иткән ул, мине хурлатыргамы, әллә мактаныр өченме?

— Җинаять эшләп мактаналармыни, Бәйрәмов?

— Юк та...— Малай тирән сулап куйды.— Әле мин аны шул килеш кенә үтеп китсә, аңлар да идем инде, гаепне миңа сылтый башлагач, ул эндәшми йөри. Үзеннән-үзе курка кебек.

— Андыйларны яшереп калу да — батырлык түгел.

— Кеше серен ачу гадәтем юк, апа.— Малайның бу сүзләре, кеше булсаң, минем сөйләгәннәрне мәктәпкә барып чәчмә, дигән кебек яңгырады.

Фирүзә калганын сорашып өлгермәде, малай да күңелен.ачып бетерә алмады, бүлмәгә Бәйрәмовның әнисе килеп керде. Ул кулындагы сумкаларын урнаштырган да талган беләкләрен берөзлексез уа иде.

— И, кунак бар икән!— диде.— Саумысыз?!— Аннары ул Кодрәткә кырыс кына эндәште:— Ичмасам, каршы килеп торыр идең, улым! Кулларым өзелеп төшә бит инде, һәркөнне шулай ташып ашатам.— Ул тагын Фирүзәгә борылды.— Мәктәбендә ни булган тагын? Сабагына йөрми башлады?

Кыен булып китте.

— Мин Кодрәткә директор рәхмәтен ирештерергә килдем,— диде Фирүзә.

— Аларга нинди рәхмәт тагын? Олы башыгызны кече итеп йөрисе түгел.— Хатын малайга карап: — Ник капканы бикләми кердең?..

— Монысына мин гаепле бугай,— дип укытучы Кодрәтне якларга ашыкты.— Ярый, шөкер әле, ул-бу булмаган, мин бит болай гына. Бала-чаганы гел өйрәтеп тормасаң, гомер буе җыйган малың минут эчендә юкка чыгар, аллам сакласын!

Фирүзә эндәшмәде. Хуҗабикә укытучы кешенең өс-башына текәлде. Укытучы исә хатынның ничек киенүен күздән кичерде. Кибетчегә бу

«ярыш» ләззәт бирә иде шикелле. Ул, менә кара, дигән кебек, кулларын җәеп җибәрде. Эреле-вaклы, яшелле-кызыллы каш куелган йөзекләр, киң-киң балдаклар, елкылдап торучы, каптырмалы беләзек... Фирүзә уйлап куйды: барын бергә кигәч, ямьсез. Без кешеләрне киенү һәм бизәнү культурасына өйрәтмибез. Бәлки, мәктәптә үк махсус курс ачаргадыр? Менә бу хатын, болай ук чуар бизәнмәсә, нинди матур күренер иде! Аңарга табигать чибәрлекне мул биргән: әллә каян үзенә тартып ала торган сөрмәле, зур күзләр, якты йөзе алсуланып яна, юанаебрак киткән гәүдәсе дә, хәтта кырыслыгы да килешле.

Хуҗа хатын, укытучының уйларын укыгандай, йөзек-алкаларын сала башлады:

— Мә, улым, җыеп куй!— Кодрәт куш учын әнисенә сузды. Тегесе әле бармакларыннан, әле колагыннан кыйммәтле нәрсәләрен йолкайолка улының учына ташлады. Үзалдына сөйләнгән шикелле генә серен дә ачып салды.— Күнел күтәрелмәсме, дип алган булам, тагып йөргән булам инде шунда. Тиле тимер җыйган кебек. Күңелсез...

Аның нур бөркеп, гайрәт чәчеп торган күзләрен яшь томалады.

— Авыр бит. Башта — әтиләре... Аннары олы улым өйләнде дә китте. Мин, һаман өйгә булсын, өйгә булсын, дип тырышам. Юк, бер булмаса, булмый икән ул...

— Ярар инде, әни, гел шул турыда гына сөйләмә! Баш ярылып, күз чыкмаган, дия иде эби.— Кодрәт учындагы зиннәтле бизәнгечләрне шкафтагы бәллүр вазага илтеп салды.— Утыр син, ял ит!

Әнисе тынычлана төште. Фирүзә, шул хәлдән файдаланып, китү ягына кузгалды.

— Миңа вакыт җиткән икән,— диде.— Кереп кенә чыгыйм дигән идем, озакладым.

Хуҗа хатын укытучының кисәк кузгалуыннан каушап төште:

— Ю-уук! Улым, чәйне кайнарлат! Бу салкын чәй белән җибәрәммесоң?! Әллә нигә бер килеп, иркенләп сөйләшеп тә утырмагач. Мине гаеп итмәгез, әле сүз кушар кешем калмаганга гына җебедем...— Үзе, малай юкта дигән кебек, ашыгып барып, стенаны тоташ иңләгән шкафның бер капкачын ачты.— Әйтегез, зинһар! Сезгә кайсы ошый...

Капкачын ачкач та «елт» итеп саргылт уты кабынган көзгеле тартма эчендә төрле эчемлек шешәләре икән. Хатын байлыгындагы коллекцияләр. Эреле-ваклы, матур этикеткалы, төрле кыяфәткә кертеп ясалган шешәләр ут яктысында серле җемелдәшәләр.

Фирүзә катгый рәвештә баш тартты.

Ана, оялып, шкаф тартмасын тиз-тиз генә бикләргә ашыкты.

— Минем үземә дә ярамый,— диде.— Кунак-төшем өченгә генә җыям. Ярамый миңа.— Ул билен сыйпаштырып алды.

Укытучы Кодрәт турында иң мөһимен әйтеп калырга теләде. Мәктәпне ташлауга юл куярга ярамаганлыгын кисәтте.

* * *

Фирүзә утлы күмергә баскандай өтәләнеп өенә кайтып бара. Бу соңарып йөрүеннән класс эшендә файда булса, ул барына да мең риза, бик бәхетле. Тик кирәген хәл итә алдымы соң ул? Кодрәт Бәйрәмов иртәгә мәктәпкә килерме? Укуын ташламасмы?

Фирүзәнең үз улларында Бәйрәмовка карата дустанә мөнәсәбәт уята алганы юк әле. Бер көнне, сүз нәрә сүз чыгып, Кодрәт турында нидер сөйләгәч, олы улы әйтә куйды:

— Әни, һаман шуның турында сөйләп, өйнең ямен җибәрмик әле...

— Бәйрәмовтан мин барыбер ут чыгуда кем катнашканын сөйләтәм әле, ул белә икән бит аны...

Бу сүзне ишеткәч, улы югалып калды.

— Кирәкми, әнием,— дип ялварырга тотынды.— Онытып тор син бу хакта!

Хәлнең шактый җитдилеген сизенеп, Фирүзә керфекләрен аска төшерде, кашларын җыерды.

— Вакыты җиткәч, бары да аңлашылыр, әнием, син аны башкалардан сорап йөрмә, үзем үк аңлатырмын!

Ана йөрәген борчулы уйлар басты. Ул, гадәттә, дәфтәрләрен тикшереп, планнарын төзеп, иртәгәге дәресләренә әзерләнеп, йокы бүлмәсенә кергәндә, Зиннәт инде күптән йокыга киткән була. Хатын, аны уятудан куркып, аяк очларына гына баса-баса үз караватына үтә. Әлеге көнне исә Фирүзәнең сабырлыгы сынды.

— Йоклыйсыңмы әле син, Зиннәт?— дип, ирен уятырга җөрьәт итте.

— Кем инде йоклап яткан кешедән шулай сорый?— Иренең йокысы ачылды бугай.— Ни булган?— дип аннары тыныч кына эндәште.

Фирүзә, иренең теләр-теләмәс кенә сөйләшүен сизмәмешкә салышып, соңгы көннәрдә күңелен көйдереп торган хәлләрне сөйләп китте. Бәйрәмовның уку ташларга йөрүе дә, олы улының тупаслануы да — берсе дә калмады.

— Мәктәп турында гына сөйләнеп, син әтине дә аптыратып бетерәсең, ди, белдеңме?

Иренең сөйләшергә теләмәве Фирүзәнең кайгысын куерта төште. Кинәт ул үзен япа-ялгыз хис итте. Көннең-көн буе диярлек йөзләрчә укучылар арасында булу, ата-аналар белән әңгәмәләр, үз улларының сорауларына җавап эзләү, инде, ниһаять, бердәнбер аңлаучысы саналган иренең дә бу минутта хупламавы — барысы берьюлы көчле ташкындай аның рухына ябырылды, хәлсезләндерде. Ул калтыранган иреннәрен көчкә җыеп:

— Нишләдең син, Зиннәт?— дип сорады.— Син бит мондый түгел идең, түгел идең... Без мондыйлар түгел идек. Нәрсә үзгәрде? — Фирүзә, соңгы вакытта үзен бастырыклап куйган борчуларны өстеннән сыдырып ташларга теләп, һаман сөйләшү-аңлашу ягында иде.— Син хәзер минем белән санашмый башладың. Элек син минем хезмәтемне олылый идең, дус-ишләреңә, минем исемне әйткәнче үк, укытучым ул минем, дип таныштыра идең...

Зиннәт күз ачып-йомганчы ятагыннан суырылып чыкты да хатыны янына килде.

— Сиңа нәрсә булды соң әле? Ә?— диде.— Кирәк икән, мин ул сүзләремне тагын мең тапкыр кабатлый алам! Әйдә, шәһәр урамына чыгабыз, бөтенесе алдында күкрәк киереп кычкырачакмын: «Әй сез, белеп торыгыз, бу — минем укытучы хатыным, дөньяда аннан да гаделрәк кеше юк, беләсезме сез шуны!» — диярмен. Минем бер тамчы да үзгәргәнем юк. Син үзең әллә нишләгәнсең. Ни булды?

— Хәзергә башкасын сөйләшик! Әйт әле, теге кичне кайларда йөрдең син? Телефоннан ник ялган сүз сөйләдең?

Зиннәтнең хатын билендәге кулы йомшап калды. Ул башта эндәшми торды, тирән итеп сулады. Аннары гына:

— Укытучым минем, аз гына иреңә дә кешеләр рәтендә яшәргә ирек бир инде!— диде.— Кешенең үзе генә ниятләгән эшләре дә булырга мөмкин бит. Син белмәгәннең бары да начар гына дип уйларга да ашыкма. Яме?! Мин дә — җитәкче, мин дә кешеләр белән эшлим. Синең Кодрәтнең әтисе — минем цехта. Әнисе дә безнең заводка бәйле кибеттә икән.— Зиннәт җитдиләнә барды.— Әйдә, йоклыйк, якын көннәрдә сөйләп бирермен мин сиңа...

Заводтан арып кайткан, таң яралуга, тагын эшкә китәчәк ирен бимазаларга базмады Фирүзә. Яңа көннең тизрәк тууын көтә-көтә газаплы минутлар санап ятты.

* * *

Язгы яшәрү мәктәпләргә дә мең төрле үзгәреш китерә. Кыңгырау да башка төрлерәк, дәртлерәк чыңлый башлый кебек. Класс житәкчеләре отчет язалар: чирек нәтиҗәләре, башкарылган тәрбияви эшләр, ел йомгаклары — барысы да бер тәңгә төйнәлеп, киләчәккә тапшырыла. Җәйге каникул җитә...

Фирүзәләр мәктәбе шәһәр янындагы «Бөрлегән» исемле яшелчәчелек совхозында үзенең хезмәт һәм ял лагерен оештырды. Анда мәктәп карамагына бирелгән басу бар. Тактадан йортлар салдылар. Урынжир, өстәл-карават — һәммәсе житәрлек.

Укучылар лагерьны бик яраталар, жәй буе шунда ятарга ризалар. Фирүзә монда мәшәкатьнең иң зурларын Бәйрәмовка тапшыра иде. Кодрәт моңа бик шат. Ул группаны нәкъ вакытында ашарга алып кәрә, басуга да соңаручы юк. Эшләр бүленгән, норма арттырып үтәлгән була. Ярышта Фирүзәнекеләр беренчелекне тота.

Тугызынчы классны тәмамлаган җәйдә, Фирүзәләр сменасына житәкче итеп билгеләнгән географ Әминә апа таләбе буенча, лагерьга Бәйрәмовны алып бармаска булдылар. Бу сменада лагерьга укытучылардан өчәү килде: Әминә апа, физкультура укытучысы һәм Фирүзә. Физрук балаларның ял вакыты өчен җаваплы иде. Әминә апа белән Фирүзә үз классларының файдалы эшкә катнашуы һәм исән-имин булуларын тәэмин итәргә тиешләр.

Совхозга барып урнашуның беренче көннәре шактый күңелсез үтте. Тоташ явып, желеккә төшүчән салкын яңгыр балаларны басуга түгел, ишегалдына, саф һава суларга чыгудан да мәхрүм итә иде.

Бишенче көнгә китте дигәндә Фирүзәләр бүлмәсенең ишеген шакыдылар. Йокыдан торырга иртәрәк иде әле. Укытучы, ашыгып халатын киде, балаларны уятмаска тырышып, ишеккә килде.

— Исәнмесез, Фирүзә Галләмовна! Кодрәт Бәйрәмов «Бөрлегән» совхозына исән-сау килеп житте. Менә, директорның язуын карагыз.

— Бу вакытта нинди транспорт белән килдең?

— Мин кичә кичтән үк килә башлаган идем инде, җәяүләп...

— Әниең ничек кичтән җибәрде? Кыяфәтеңнең ниндилеген чамалыйсыңмы азрак? Юл пычрагы борынына кадәр менеп житкән!

— Әй, юлныкы түгел лә ул! Елга аша басма юк икән, сикергән идем — батарга туры килде...

Шул чак Фирүзә малайның баштанаяк манма су икәнлеген күреп алды...

Лагерь уянганда; Кодрәт, класс житәкчесенең бумази халатына төренеп, мәмрәп йоклый, Фирүзә исә малайның бер өем киемнәрен уган да, яңгыр тимәстәйрәк ышык урынга бау сузып, кервләр элеп йөри иде.

Әминә апаның гаҗәпләнүенә чик-чама булмады.

— Бу нинди тамаша бу, Фирүзә җаным?— дип сорады.— Кем чалбары?

Фирүзә:

— Котлыйм сезне!— дип, сүзне шаяртуга борырга теләде.— Сезнең иң яраткан укучыгыз Бәйрәмов та безнең янга килгән!

Географ телсез калгандай булды.

— Аны директор үзе җибәргән, Әминә ханым, язуы бар.

— Бу лагерьда, синең белән мин директор! Педсовет раслаган исемлеккә өстәп, безгә каршы килеп, кемнедер көчләп тагарга берәүнең дә хакы юк!

— Бәйрәмов өчен үзем җавап бирермен, Әминә ханым.— Фирүзәнең тавышы таләпчән иде.— Эш вакытында әйбәт ул.

— Минем үгетләүнең кирәге юк: ул баланың ниндилеген беләм.

— Ул сезне бик хөрмәт итә, Әминә ханым!— Фирүзә монысын өл-

кән укытучының күңелен күтәрү өчен әйтте.— Иң яраткан фәнем — география, дип сөйли.

Географ, ниһаять, елмаеп куйды.

— Әй, оста да инде син, Фирүзә җаным! Ярый, килештек!

Бәхеткә каршы, көн дә ачылыр кебек: өер-өер болытлар ертыгы арасыннан күкнең зәңгәрсу йөзе күренеп-күренеп киткәли. Бу — кояшлы көннәр башлану билгесе.

* * *

Башка җәйләрдә, лагерь тормышы бер эзгә салынгач, укытучылар үзара чиратлашып, Казанга кайтып киләләр иде. Быел ял турында уйлый да алмыйлар. Фирүзәнең күңеленә борчулы уйлар сарыла башлады. Ул, балаларны сагынганга шулай бу, дип, үзенчә нәтиҗә ясый. Башка елларда балалар Зиннәт белән шәһәрдә калалар иде. Кайттыңмы күреп киләсең. Быел кечкенәсе, укулар бетүгә, пионер лагерена китте, олысы — армиядә. Зиннәт саубуллашканда көлдереп:

— Сез мине өр-яңадан егеткә әйләндердегез,— дигән иде.— Эштән соң паркка йөрермен инде.

Өенә кайтып килү теләге бик көчле булса да, Фирүзә бу хакта авыз да ачмады. Кодрәт Бәйрәмов килгәч, бу мөмкинлеге тагын да ераклаша төште. Әмма, кеше өмет итә, тәңре әмер итә, диләр — юлга чыгу бөтенләй көтмәгәндә үзе каршыларына килеп басты.

Басуда дәртләнеп эшли башлаган чак иде. Фирүзә көткәнчә аның группасын Бәйрәмов үз кубызына биетергә тотынды. Малай ярышны бик ярата. Ул, Әминә апа группасының никадәр эшли алачагын чамалап куя да, үзләренә буразналар бүлә. Ничек саный — Фирүзә бу кадәресен сизми дә кала.

Аларга өч-дүрт кенә яфраклы чөгендерләрне утап, сирәкләп чыгу йөкләнгән. Көн азагында басу хуҗасы эшне кабул итәргә килә. Нәтиҗәсе — күз алдында, яшькелт буразналар сызылып ята. Беренче көннәрдә санадылар да кайтып киттеләр, санадылар да кайтып киттеләр. Совхоз вәкиле дә актан-карадан сүз әйтмәде. Өченче көнне, эш азагында, бу кешенең Әминә апа белән шактый кырыс сөйләшүе ишетелде. Алар икесе дә Фирүзә группасы эшли торган якка карап басканнар, һәр икесе нидер расламакчы, бәхәсләшәләр.

— Бер үк яшьтәге балалар, сан-исәпләре дә тип-тигез,— ди басу хуҗасы.— Ник сезнекеләр бермә-бер азрак эшли?

— Бәлки, безнекеләр чистарактыр? — ди Әминә апа.

— Әй, шулай булса-а-а! Юк шул, чисталыгын да аерып алып мактап булмый. Нахакка рәнҗетү булмасын, дип, мең энә күзеннән үткәздем эшегезне. Кичә, сез кайтып киткәч, аркылыга-буйга йөреп чыктым. Юк, сыйфат ягыгыз әллә ни түгел, эшләгән буразна саны да кимрәк.

Агай чөгендер басуын дер селкетердәй баһадир адымнар белән ары китте. Шуны гына көтеп торган кебек, Фирүзә янына авызы колагына житкән Бәйрәмов килеп басты.

— Эшләрен чуалттыкмы, Фирүзә Галләмовна?! Мине лагерьга алып килмәскә тырышкан өчен бу.

— Ярыш, Кодрәт акыллым, бер-береңне уңайсыз хәлдә калдырыр өчен оештырылмый. Син шуны аңламыйсың икән әле.

Кичен Әминә апа Фирүзәгә үзенең яңа карар чыгаруы турында хәбәр итте. Моңарчы группалар, малайларга-кызларга бүленеп, икешәр бүлмәдә яшиләр иде. Ике бүлмә арасында, караваты һәм өстәле булган урындыкта, тәрбияче-педагог урнашкан. Такта стеналар аша өч бүлмәдәге кешеләрнең сүзләре бер-берсенә яхшы ишетелә. Алар кич буе кычкыра-кычкыра сөйләшәләр, көлешәләр. Фирүзә дә аларга кушыла, сорауларына җавап бирергә тырыша, әңгәмәнең үзәгендә була иде. Икенче йортта нәкъ шундый ук тәртиптә Әминә апа группасы яши. Тын кичләрдә хәтта аларның да шулай гаплашеп ятуы ишетелгәли иде.

Эшләрдәге тигезсезлек фаш ителгәч, Әминә апа, ике группа өчен дә баш кеше буларак, яңа тәртип тәкъдим итте.

— Группаларны кушып карыйк әле, Фирүзә җаным,— диде.— Өйләрнең берсендә малайлар гына яшәсен, икенчесендә — кызлар. Болай үзара дуслаша алмыйлар. Эшләренә дә шул зарар итә бугай.

— Балалар ни дияр икән соң, Әминә апа? — Фирүзә турыдан-туры каршы килеп тормады.— Әйтеп карыйк!

— Менә минем яшемә җитсәннәр, минем кадәр эшләсәннәр, укучыларның язмышы өчен җавап бирерлек дәрәҗәгә ирешсәннәр, анннары үз теләкләрен алга сөрерләр! Хәзергә мине аларның фикере кызыксындырмый...

Яңалык, Фирүзә шикләнгәнчә, лагерьда тавыш-гауга чыгарды. Группалар әле аерым-аерым, әле зур төркемнәргә оешып кычкыра-кычкыра бәхәсләшәләр. Укучыларга хәлне мөмкин кадәр йомшартыбрак аңлатырга кирәк иде. Хәзер үк Фирүзә янына килергә ашыкмасалар да, бераздан алар үз кысаларына кайтып төшәрләр, мең төрле сорау яудырырга тотынырлар.

Ике өйнең берсендә гел малайлар гына калгач, Әминә апа андагы күзәтү-тәрбия эшләрен физкультура укытучысына тапшырды. Каравылчы карт та шул тирәдә күбрәк йөрергә ризалашты. Физрук иртәкич күбрәк елга буена китәргә яратучан, шуңлыктан Әминә апа каравылчыга аерым әйтте:

— Син, агай, олы кеше, күз-колак була күр! — диде.— Уннан соңармый йокларга ятсыннар! Берүк тәмәке тартырга өйрәнә күрмәсеннәр!

Фирүзә сүзгә кушылмый булдыра алмады:

— Әйдә, Әминә апа,— дип, өлкән укытучыны читкә алып китте.— Кирәкмәс, бу агайдан тәрбияче ясарга тырышмыйк!— диде.

Әминә апа бу күрсәткечне дә авыр кичерде. Шунда ук үзенең яңа күрсәтмәсен әйтеп калырга ашыкты:

— Син минем группа кызлары янында яшәрсең, Фирүзә җаным. Минем кызларның саны кимрәк, бүлмәдә буш урыннар бар. Гомумән, без монда ике төрле класс икәнен онытыйк! Чын дуслар булып берләшик. Менә шунда күрербез: эшләр тип-тигез булачак безнең!

Мондый ясалма кушылуның әллә ни нәтиҗә бирмәвен белсә дә, Фирүзә каршы төшәргә кыймады.

Күк күкрәүле яңгыр алдыннан табигатьнең беразга тып-тын калуын хәтерләтеп, балалар сәер битарафлык күрсәтәләр иде. Лагерь ишегалдындагы чыр-чу, дөнья күтәреп шаярулар, шатлыклы көлүләр бетте.

Басуда исә һич уйламаган сәер үзгәреш булды: Әминә апа группасындагылар элеккедән дә аз эшли, Фирүзәнекеләр норманы үтәп бара, аерма элеккечә бермә-бер.

Көн азагында эш кабул итәргә килгән кеше тагын аптырады:

— Нәрсә булды соң сезгә? Кичәгенең яртысын гына сирәкләгәнсез бит?!

Әминә апа Фирүзәгә ялынырга тотынды:

— Әллә син үзләре белән әйбәтләп сөйләшеп карыйсыңмы?

— Бергәләшеп сөйләшик, Әминә апа!

Ул арада Әминә апа нидер уйлап алды:

— Беләсеңме нишләтәбез: иртәгедән буразналарны да аралаштырыйк, бер буразна — синең укучыга, икенчесе — минекенә. Бүген кичтән үк үзләренә дә аңлатыйк!

Физрук, нәкъ Әминә апа кушкан вакытка балаларны иркен мәйданга чыгарып тезде. Көне буе эшләп тә, уйнап-шаярып та шактый талчыккан укучылар җитди мәсьәләләр хәл итүгә әзер микән соң? Фирүзә Әминә апага:

— Әллә иртәгә генә белдерербезме? — дип караган иде.

Әминә апа үз уеннан кире чикмәде.

— Минемчә, белдереп калу хәерлерәк. Йоклар алдыннан үзара фикерләшергә дә җайлы булыр.— Әминә апа үз теләгән аклардай терәк тә тапкан иде инде.— Без аны илдәге яңалыкка нигезләп аңлатыйк. Хәзер бит бөтен җирдә коллектив подряд ысулы мактала. Без ике классны бергә куша алмый интегәбез.

Һәм ул үзенең кыска гына чыгышын нәкъ шуннан башлап та җибәрде. Соңыннан:

— Безгә, укучылар, гомуми нәтиҗәнең әйбәт булуы кирәк! — диде.—Ярышып, бер-беребезне оятлы итәргә тырышмыйк!

Фирүзә шактый тынычланган иде, чөнки Әминә апа шактый шома итеп аңлатты. Тик, балалар үз урыннарына таралышканда, аның янына Кодрәт килеп:

— Фирүзә Галләмовна, ник соң безгә рәхәтләнеп эшләргә рөхсәт юк? — дип, күңелгә тагын вәсвәсә салып китте.

Малай, сорау белән, юкка да чыкты. Мондый сүзнең ник әйтелгәнен ачыкларга җай калмады. Әминә апага әйтергә дә базмады Фирүзә. Кәефе бозылыр, тагын Кодрәткә кырын карый башлар кебек тоелды.

Барысы да урыннарына кереп яттылар. Фирүзәне йокы алмый интектерде. Колак төбендә Бәйрәмов соравы яңгырап торды.

Такта стена белән генә аерылып торучы бүлмәнең икенчесендә Фирүзәнең гаҗәпләнүенә каршы, башка көннәрдә бик тиз йокыга талучан Әминә апа да караватында әйләнеп-тулганып азапланды.

Таң алдыннан Фирүзә сискәнеп уянды. Бу таң, бу вакытсыз уяну шомлы тоелды аңа. Ул гомерендә дә болай кисәктән, бу рәвешле тәшвишләнеп уянмый иде. Фирүзә тиз генә халатын киде дә ишек төбенә чыкты. Чалт аяз көн туып килә. Чистарынып, шатланып күтәрелүчән кояш та чыгып өлгермәгән әле. Күк йөзенә аның алсулыгы гына таралган. Табигать, гүя җан ияләрен дәррәү кузгатырга базмыйча, тирә-юньдә тынлык саклый.

Фирүзә малайлар йоклый торган йортка күз салды. «Шылт» иткән тавыш та юк. Бу вакытта каравылчы шул тирәдә йөрергә тиеш иде. Физрук уянып чыккач кына, ул ял итәргә китә. Ник соң каравылчы күренми?

Фирүзәнең карашы, лагерьны узып китеп, алда күтәрелгән тау сыртына күчте. Олы юлга алып чыгучы сукмак буйлап кемнәрдер китеп бара. Бер, ике өч... Фирүзә азагына кадәр санарга теләмәде, ул инде болай да аңлады: бу — аларның егерме биш укучысы, малайлар, лагерьны ташлап, шәһәргә юл алганнар.

Укытучы, йөгереп барып, малайлар йортына керде. Ишек төбендәге караватта каравылчы зарланып ята. Аны ятакка бау белән бәйләп салганнар. Фирүзә керүгә, ул дөньяны каһәрләргә тотынды. Аннары:

— Хәер, үзем җүләр. Гомердә ата-бабам эшләмәгән эшкә алынгач, мин җүләр булмый, кем җүләр булсын?— дип, үзалдына сукранды.

— Абзый, әйбәтләп кенә аңлатыгыз әле! Ни булды?— Фирүзә ашыга-кабалана аның кулларын чиште.

— Ул сорауны сезгә бирергә кирәк! Мин бит пенсионер гына. Исән башка тимер таяк алган шыр тиле мин, ник миннән сорыйсыз? Үзегезгә тапшырылган ристаннар, үзегез карагыз. Минем берсенә дә катнашым юк! Әҗәлем болай да әллә ни ерак йөрмидер...

— Ни сөйлисез соң сез? Тапкансыз бер сүз — әҗәл, имеш!

Әле, рәхмәт, анысын да сезнең малайлар искә төшерде: абзый кеше, теленне тик тот, диделәр. Яшь булсалар да, акыллары минеке өше генә түгел! Кала баласын тәрбияләү минем кулдан киләме соң инде!

Фирүзә эндәшми-нитми генә бүлмәгә караш ташлады. Караватлар пөхтә җыештырып куелган. Малайлардан хәтта чүп тә төшеп калмаган.

Фирүзә ашыгыч рәвештә юлга җыенырга кирәген чамалады. Хәзер

ук Казанга китеп һәр баланың өендә булырга, әти-әниләре янына кайтып житүләрен ачыкларга һәм хәлне мәктәп директциясенә аңлатып бирергә кирәк.

Үз классындагыларны ул яхшы белә, Әминә апаныкыларның адресын каян алырга?! Өлкән укытучының ифрат борчылачагын күз алдына китерсә дә, Фирүзәнең бу хәлне белдермичә хәле юк. Мондый гадәттән тыш вакыйганың район мәктәпләре арасында булганы юк иде әле.

Әминә апа, малайларның качып китүен ишеткәч, еларга ук тотынды. Аңа карап: «Педагогларча!» — дип уйлады Фирүзә һәм яшьлеген искә төшерде.

...Университетны тәмамлагач, Фирүзәне ерак районнарның берсенә, урта мәктәпкә эшкә җибәрделәр. Ап-ак чәчле карт директор яшь укытучыны классска үзе озата керде.

— Укучылар, бүгеннән сезнең класс житәкчесе Фирүзә апагыз Галләмовна булыр,— диде.— Ул — әдәбият укытучысы. Югары белемне Ленин бабагыз укыган университетта алган. Ул биргән гыйлемне сез үзегезгә сеңдерергә тырышыгыз!— өлкән педагог Фирүзәгә борылды:— Уңышлар телим!

Директор чыгып киткәч, дәрес матур гына дәвам итте. Фирүзә иң соңыннан, дәресне йомгаклау өчен һәм балаларның сорау-фәләннәре булса дип, бераз вакыт та бүлеп калдырды. Дәреснең темасы буенча бик тырышып әзерләгән сүзләрен түкми-чәчми сөйләде-сөйләде дә:

— Аңлашылдымы, укучылар?— дип сорады.

Класс күмәк, көр тавыш белән:

— Юк! — дип җавап кайтарды.

Фирүзәнең тез буыннары калтыранып куйды. Дерелдәгән куллары, ашыгып, өстәл өстендәге дәфтәр-китапларны җыештырды. Әле кыңгырау чылтырарга берничә минут калуга игътибар да итмәстән, классны калдырып чыгып йөгерде ул. Укытучылар бүлмәсендә директордан башка берәү дә юк. Хәер, Фирүзәгә барыбер иде. Ул күзенә чалынган беренче урындыкка ауды да, йөзен учы белән каплап, елап җибәрде. Директор башта дәшми торды. Өлкән педагог Фирүзәнең елау катыш: «Күпме тырыштым, бу көнне күпме көттем бит мин!.. Мин аларга ни начарлык эшләгән? Ник алар шул кадәр шәфкатьсез?..» дигән сүзләреннән күп нәрсәне аңлаган иде инде.

Кыңгырау чыңлады. Фирүзә елавыннан «кырт» туктады, ашык-пошык күзен сөрткәләде, астан гына директорга карады.

Карт елмая иде. Аның күзләрендә дә, елмайганнан соң бөтен битен ермачлаган тирән җыерчыкларында да, хәтта басып торышында да сөенеч балкый. Юк, директор яшь укытучының үксүеннән яки дәрес ташлап чыгуыннан көлми, ул ихластан шатлана иде. Ул кинәттән житдиләнде. Бүлмәгә башка укытучылар кереп тулачагын белеп, ашыгып кына кыз янына килде, аркасыннан сөйде:

— Синнән чын педагог чыгачак, кызым. Һөнәр сайлаганда ялгышмагансың. Бу елавың — шәп нәрсә!

Фирүзәнең мәктәптәге эшкә бәйле төстә тагын да елардай чаклары булгандыр, мөгаен. Әмма хәтердә иң нык сакланганы — әнә шул беренчесе. Инде менә аның каршында, олы башын кече итеп, Әминә апа елый. Фирүзә белә: аны хәзер һичнинди сүз белән дә юатып бетерә торган түгел, аңа кушылып еларга гына мөмкин. Укытучы күз яшендә башка бер һөнәр иясе дә кичерми торган хисләр: теләкләр сафлыгы, киләчәк өчен хафалану өмете, кешелек хаталары өчен өзгәләнү чарасызлыгы — барысы да җыелган.

— Әминә апа, сездә малайларның адресы үзегез белән юктыр инде, мин башта мәктәпкә барырмын, ахры...

— Яз, Фирүзә акыллым, әйтеп торам, барысын да яттан беләм.— Ул, кайсыннан башларга кирәклеген чамалаган шикелле, әзрак сабыр

итеп торды да тезеп китте. — Айнуров Мансур, Морской урамы, бишенче йорт, беренче кат, егерме беренче бүлмә. Ул йортның ишеге бер генә. Аптекалы биек йорт.

— Беләм, минем Бадыйкшанов та шунда яши.

Фирүзә Әминә апаның тиз тынычлануына, укучыларының өйләрен китаптан укыгандай яхшы хәтерләвенә, малайларны үз баласыдай якын итүенә сокланып утырды. Соңгы адресны яздырганда өлкән укытучы кисәтергә тиеш тапты:

— Яковлев Васяның әтисе — эчкече, әтисе өйдә булса, зинһар, Вася турында начар сүз катма. Юк сәбәпне бар итеп, гаиләсен бимазалый торган дуамаллыгы бар аның...

* * *

Казанга аяк басуга Фирүзә өйләренә ашыкты.

Нәкъ алдан уйлаганча, өйдә берәү дә юк иде. Зиннәтнең заводта чагы, балалар — еракта. Ишекне ачуга йөзгә тынчу һава килеп бәрелде. «Бүлмәләрне җилләтмәде микәнни Зиннәт?» Кулындагы төеннәрдән котылырга ниятләп, Фирүзә кухняга керде. Аш бүлмәсе савыт-сава белән тулган. Зиннәт, 'тамагын туйдырган саен, тәлинкә һәм чынаякларын кран астына гына өя барган. Хәтта идән дә юмаган. «Әй, бу ирләр! Ике сүзнең берендә, без — солдатлар! дип, мактаналар, ә инде үзләре генә калсалар...» Фирүзә үзалдына елмая-елмая залга үтте. Үзенең Зиннәткә кирәклеген тою Фирүзәгә рәхәт иде. «Ул шуңа өйрәнгән инде, сабый бала хәлендә калган, гел күзәтеп-төзәтеп торырга кирәк аны».

Суыткычта ризык беткән. Туңдыру тартмасы шыкырдап калган, капкачын да ачып булмый, сөт шешәләре өчен ясалган уентыкта сәер сынлы карасу пыяла савыт кукраеп утыра. Зиннәтнең аракыга исе китми. Кунаклар җыелганда капкаласа да, соңыннан үзен-үзе битәрләп йөри: «Тиле дә инде мин, — ди. — Кешеләр эчсен өчен, кирәкмәгән нәрсә йотып утырам. Ике тиенгә ярамаган гадәт...»

Фирүзә ят шешәне кулына алды. Эчендә бераз эчемлек бар. Бөкесен ачып караган иде, тынны бугыч куәтле ис бөркелде. «Портвейнфәлән генә дә түгел бу. Бичарам, бөтенләй гаҗизләнгән икән, ялгызлыкка нәләнә алмаган, башларын кая куярга белми, шушы нәрсәне эчеп карагандыр инде. И-и, бу ирләр! Ялгыз яшәргә бер дә генә яраклаша алмыйлар шул. Хатыннар гына барына да чыдый. Күпме тол хатын бар, өйләрен гөл кебек тоталар...»

Санаулы сәгатьләрне мөмкин кадәр файдалырак үткәрергә кирәк иде. Фирүзә иң элек юасы керләрен ваннага изрәтергә салды. Савыт-сабаларны да зур табакка, содалы суга чумырды. Укучылар артыннан йөреп кайткач, чайкап кына алачак.

Урамга чыккач, Фирүзәнең уй-фикерләрен лагерьдан качкан егерме биш бала язмышы биләде. Ул укучыларны туры китермәүдән, эш көне беткәләгәнче директор белән очрашуга соңарудан шикләнә иде. Бәхетенә каршы, беренче йортта ук малайларның шактыен берьюлы очратты ул.

— Исән-сау кайтып җиттегезме, бөркетләр?

Укучылар педагогның эзгә бастырып ук килеп җитүен бөтенләй көтмәгәннәр, шүрли калдылар, акланырдай сүзләр эзләп маташтылар.

— Без бит, ни, э-э, чиста киемнәр алырга гына кайттык.

— Яңадан барабыз әле без...

— Төштән соңга анда булабыз...

— Хафаланмагыз, анда барып йөрергә кирәкми. — Фирүзә тыныч сөйләде. — Лагерьга авылның үз укучылары килде. Мин сезне чакы-

рырга кайтмадым, юлда андый-мондый балагэ очрамадыгызмы дип кенә борчылдык.

Малайлар укытучының сүзеннән боегып калдылар. Алар, күрәсең, ялыну, ялвару, үгетләү сүзе көткәннәр. Фирүзә, саубуллашып, китәргә борылгач, арадан берсе хәтта:

— Фирүзә Галләмовна, безнең бит анда барасы килә,— дип тә ычкындырды.— Тик һәр класс үзе бер йортта яшәсен иде!

— Ул турыда сөйләшергә соң инде, укучылар. Кичә, гомуми җыелышта әйтергә кирәк иде аны! Барыгыз да исән-сау кайтып җиттеме соң?

Малайлар, әйтергәме-юкмы дигәндәй, бер-берсенә карашып алдылар. Аннары арада чаярагы тәвәккәлләде. Әминә апа классыныкы иде ул.

— Сезнең классныкы Кодрәттән кала, барысы да кайтты.

— Бәйрәмовны кайда калдырдыгыз?

Малайлар көлешеп куйдылар:

— Без түгел, үзе калды ул...

Фирүзә, алардан артык файдалы хәбәр ишетмәячәгенә ышангач, юлын дәвам итте.

Әминә апа кисәтеп җибәргән Яковлевлар өеннән Фирүзә тынычланып чыкты. Вася кайткан. Әнисенә ни булганны сөйләп биргән, әти кешегә аны-моны әйтмәгәннәр. Укытучы да мәсьәләне куертып маташмады. Ана рәхмәт әйтеп калды.

Иң ахырдан Фирүзә Бәйрәмовлар ягына борылды. «Ник берүзе аерылып калды икән инде? Хәзер ул йортка ни йөз белән барып керергә?»

Капканың бикле икәнен белгәч, укытучы хәтта сөенеп куйды. Эчтәгеләр ишетә күрмәсен дигән кебек, звонок та акрын чалтырады. Үзенең башка чарасы юклыкны аңлагач, Фирүзә капканы да шакып карады. Ахрысы, өйдә берәү дә юк иде. Укытучы, сабыр атлап, кирегә борылды. Инде мәктәпкә, директор каршына барып басарга кирәк. Фирүзә иң каты шелтә ишетергә әзерләнде.

Коридорлар буп-буш булганга, биек үкчәле туфля тавышы әллә кай почмакларга яңгырый: чак-чок, чак-чок... Бу авазлар Фирүзәгә директорның шелтәсе, укытучылар коллективы һәм ата-аналарның гомуми үпкәсе, балаларның дәгъвасы кебек тоелды. Коридоры да бүген кирәгеннән артык озын тоелды. Гаепле кеше хөкем залына кергәндә, мөгаен, шундыйрак хисләр кичерәдер...

Әллә, чыннан да, аның аяк тавышын ишеткән — кабинетында утырган директор аңа каршы атлады. Фирүзәне күргәч, күзлеген салды, хәтта укытучысының сәламенә дә җавап бирмәде:

— Ниләр булды, сөйлә, зинһар, тизрәк!

Фирүзә бер-ике сүз белән хәлне аңлаткач:

— Бөтенесенең өйләренә барырга кирәк! — диде.

— Мин иртүк кайткан идем, барысында да булдым инде.

— Башлары исәнме?

Фирүзәдән уңай җавап ишеткәч:

— Шөкер! — дип куйды директор, күзлеген киде, башын күтәрде.— Калганын рәтләрбез!

Фирүзә баштарак Бәйрәмов хакында ләм-мим бер сүз әйтми торды. Директор тынычлангач, читләтебрәк сүз башлады.

— Анда Бәйрәмов та килде. Ул бит монда эшләргә тиеш иде.

— Мин кызгандым ул баланы. Аның, беләсезме, үз өендә яшисе килми?! Гаҗәп хәл бит. Мин аны лагерьга җибәрүдән дә кулайрак чара тапмадым. Тоттым да сезнең янга озаттым. Аларның гаиләсе белән элемтәләрне югалтасы иде!— Директор кинәттән Фирүзәгә текәлеп карады.— Нәрсә? Әллә ул да качканмы?

— Әйе. Өенә дә кайтмаган.

Директорның ак мыегы сизелер-сизелмәс кенә дерелдәргә тотынды. Ул җир астыннан чыккандай тонык, салкын тавыш белән:

— Эзләргә! Табарга! — дип күрсәтмә бирде.

— Мин иртәгә иртүк лагерьга китәм, анда да күренмәсә, башкача эзләргә туры килер.

Директор сәгатенә күз салды.

— Бүген соң икән шул инде. Арыгансыздыр да. Ярый, барыгыз, ял итегез.

Алар коридор уртасында ук саубуллаштылар. Фирүзә, Зиннәте кайткан шәпкә тәмлерәк аш әзерләү әйбәт булыр иде, дигән уй белән, кибетләргә кергәләде. Кайтса, гаҗәпкә каршы, өй буш булып чыкты. Зиннәт әле кайтып өлгермәгән. Ашык-пошык кухняга узды, кичке аш әзерләргә тотынды, савыт-сабалар юды. Табалары, чәйнекләре, кәстрүлләре чыш-пыш килә башлагач, җаны тынычлана төште. Зиннәт кайтып, ашап-эчеп алырлар да Фирүзә керләргә тотыныр, өйне җыештырыр.

Зиннәт исә һаман күренмәде. Үзенең шактый эш башкарганлыгын чамалап, Фирүзә сәгатькә күз салган иде, уелып китте: заводтагы беренче смена тәмамланганга байтак икән бит инде!

Өй эшләрен түгәрәкләп бетергәндә җәйге кич якынлашкан иде. Һавасы сафландырылган, идәннәре юылган, җанга рәхәт биреп торучы өйнең уртасында басып, Фирүзә, ниһаять дертләп китте. «Кая булыр бу Зиннәт?..»

Ярый әле озак көтәргә туры килмәде, ишек йозагында ачкыч борылган тавыш ишетелде.

Фирүзә ишек катына килеп басканын үзе дә сизми калды. Зиннәте керүгә үк сорарга ашыкты:

— Кайда идең? Ни булды?

Гаилә башлыгы Фирүзәсенә нәрсә дә булса аңлатырга, аны тынычландырырга ашыкмады. Диванга килеп утырды да: «У-ффф!» — дип тирән сулап куйды. Өнсез басып торучы хатынына карап, үзе сорады:

— Син бит әле кайтырга түгел идең, ничек кайтасы иттең? Мәктәп тә мәктәп бит синең.

— Кайтасы булды шул.

— Ярый, мин өйрәнеп барам инде. Ләкин ялгыз тормышның, бик беләсең килсә, рәхәте аз икән. — Ир башын чайкап куйды. — Ник эчтем инде кичә...

Башка җәйләрдә Зиннәт балаларны да алып кала иде. Ял саен я Фирүзә өйгә кайта, я алар җыйнаулашып, әниләре янына баралар иде. Быел исә, кәкрегә чалыш дигәндәй, бөтенесе җайсыз чыгып тора.

— Ашыйсың киләме, Зиннәт? Мин кайтканга аптырап утырма! Безнең лагерьда гомер ишетелмәгән хәл булды, шуңа җибәрделәр, иртүк кире китәргә кирәк, бер малаебыз югалды безнең. Тагын шул Бәйрәмов инде...

— Беләм, беләм, — диде Зиннәт. — Шул бер малайны тыя алмадыгыз инде! Тотарга иде дә әллә кайчан тапшырырга иде гэпэтэуга! Заводларда эшче куллар җитми, белмисезме шуны? Минем цехка ук килсен иде, биетер идем мин аңы!

— Әнисе киреләнде бит. Министрлыкка барган, унны бетерсен, училищега бирмим, дигән. Дирекция берни дә эшли алмады.

— Белә-әм! Мин барын да беләм. Малайның әнисе барын да сөйләп йөри. Ул сезнең мәктәпкә нигәдер ачулы күренә. Беркөнне, сине эзләп, монда да килгән иде әле.

Фирүзәнең кызыксынуы чиктән ашты. Ул хәтта нинди дә булса сорау бирерлек чамасын да югалтып торды. Зиннәт, хатынының ашыктырмавын сизеп, башлаган сүзен түгәрәкләү ягын чамалады:

— Өйне ничек тапкандыр, белмим. Берничә дусны нияртеп эштән кайткан гына идем. Әллә юри көтеп торган, килеп тә керде, сөйләп тә бирде. Минемчә, ул урынлы зарлана. Улымны, ди, башта мәктәптә эшләттеләр, инде лагерьга барырга да ясаганнар, ди, башкалар икенең берсенә генә катнаша, ди.— Зиннәт читкә борылды.— Мин тынычландырырга тырышып карадым аны, тик үзем дә аңламыйм, ник алай иткәнсездер? Ялгыз ананың бердәнбер баласын армия хезмәтеннән дә азат итәләр...

— Зиннәт, Кодрәтнең әнисе тагын килсә, син аңа аңлат: борчылмасын, яме?

Ир каршы төште:

— Әтисен күрәм әле мин аның! Нигә ул ирнең баласы өчен синең белән мин генә борчылырга тиеш?! Әтисе белән сөйләшәм...

* * *

Автобус Фирүзәне лагерьдан бер-ике чакрым чамасы ераклыктагы тау итәгендә төшереп калдырды. Килү-китү вакытлары билгеле булса, аларны ат яки җиңел машина белән каршы алалар. Совхоз директорының күрсәтмәсе шундый. Фирүзә бүген кайчан киләчәген лагерьдагыларның белмәвенә сөенеп куйды. Көн матур, юл такыр. Шәһәр ыгы-зыгысында телгәләнгән җанны бу юлда бераз басарга мөмкин. Аңа тынычлык кирәк, ул Бәйрәмовка бәйле сорауларның очына чыгарга тиеш. Бу — Фирүзәнең үзе сайлаган һөнәре алдындагы йөз аклыгына, педагог намусына тоташа. Малайны эзләп табарга да телен язу әмәлен ачарга иде! Шунсыз такыр сукмактан өч чакрым юл үтү түгел, җәһәннәмгә кадәр барсаң да, иркен суларга мөмкин булмаячак.

Казанга бу кайтуында Фирүзәнең сабыр савытына өр-яңа хәсрәт мая салып куйды. Ул бу хакта җитди итеп уйларга да курка. Гүя ул кулындагы бәхет чүлмәген төшереп җибәргән дә, аның ватылу-ватылмавын ачыкларга кыймый тора. Күз сирпедең исә, аның чатнаганлыгын күреп өметсезлеккә бирелачәксең. Адәм баласының гомерендә өметсезлектән дә куркынычрак ни бар?!

Мәгълүм ки, баш миен бораулап торучы әлеге борчу Зиннәткә тоташкан. Ни өчен кайгыга бирелүен Фирүзә үзеп кенә әйтә дә алмый, чөнки аның күңелендә иренең соңгы тәртибен акларлык мең-миллион дәлил бар. Аларны ул әллә кайчан тапты, ире турында яман фикергә ирек бирергә теләми. Хатын күңелендә Зиннәт турында бәхәс купты: «Ник ул болай соң кайтты? — Чөнки ир кешенең аш-сусыз өйдә япаялгыз утырасы килми! Ник аракы эчкән? — Сүз кушар кешесе булмаганга?»

Фирүзә шуңа охшаш бик күп сорауларга җавап бирә килде, соңыннан үзе дә гаҗәпләнде: ул сорауны түгел, ә иң әүвәл җавапны уйлап таба икән. Чөнки аның Зиннәтен югалтасы килми. Зиннәт-Фирүзә — болар икесе бер җан.

...Алар урта мәктәптә укыганда ук танышлар иде. Сигезенче классны тәмамлагач, күрше авылга йөреп, урта мәктәптә укырга тотындылар. Юл мәшәкате, яңа мәктәпкә ияләнү мәшәкатьләре, салкын көннәрдә авыл читендәге йортка кереп җылынулар аларның кайгы-шатлыгын уртак итте.

Берсендә Фирүзә белән Зиннәт ике авылны тоташтырып торучы биш чакрымлык юлга икәүдән-икәү генә чыктылар. Беренче Май бәйрәме алдыннан иде бу. Язның җәйгә авышучан көннәре. Табигатьтәге сафлык кешеләр күңеленә дә үтеп кергән шикелле. Хыялга бай кешеләр җиргә басканнарын да тоймыйлар. Зиннәт тә сүзен шулайрак башлады:

— Ник дөньяда гел язлар гына булып тормый икән?

Алар күздән саламы җыелмый калган чуар басуны үткәннәр инде инде. Ике ягына да шактый киң алдыртып каеннар утыртылган күркәм юлга килеп керделәр.

— Сиңа бик кирәк булгач, әйтергә иде аны: «Әй-әй, яз әфәнде! Син болай тиз генә узып китмә әле! Әнә, безнең Зиннәткә синең тагын берәзга кирәгең бар!» — Фирүзә көлә-көлә кычкыра бирә.

Егет җитди.

— Син бит берни дә белмисең, Фирүзә. Яз миңа мең газаплар алып килә. Җаным өзгәләнә, йокым кача.

— Ул бит ләззәтле газаптыр?

— Фирүзә, әйт әле менә, синең шигырь язганың бармы?

— Нәр-сә-ә?

— Шул-шул! Син аның нинди газап икәнен дә белмисең. Мин төннәр буе шигъри сүз уйлыйм. — Зиннәтнең тавышы ярым пышылдауга күчә. — Өйдә кап-караңгы, тәрәзәдән күк йөзендә җемелдәүче йолдызлар күренә, күңелгә шигырь иңә. Аннары ул шигырь сүзләре бер җепкә тезелә дә тышка бәреп чыга...

Фирүзә, егетнең берәр сүзен ишетми калмыйм тагы дигәндәй, аның каршына баса да авызына гына карап тора башлый.

— Мин урынымнан торып, болдырга чыгам, өйдәгеләрне уятмас өчен. Тыштагы лампочка яктысында гына яңа шигырь язам.

— И-и Зиннәт, син әллә кем булырсың инде болайракларга киткәч...

— Юк-ла, мин аларның кайберләрен соңыннан ошатмыйча ертып ташлыйм.

Зиннәт адымын акрынайта төшә. Җилкәсендәге сумкасын ача да дәфтәрләрен актарырга тотына.

— Әйдә, ник артка каласың?

— Тукта әле, Фирүзә, син миңа киңәш бир! Менә, укып кара әле! Шигырь диярлекләре бар микән?

Фирүзә юлдашына тагын сәерсенеп карап тора башлый. Үзенә сузылган куен дәфтәрен алганда да күзләрен мөлдерәтеп Зиннәткә текәлә. Куен дәфтәре кулына кергәч, дөньяның зур музейларында бердәнбер данәсе генә сакланып калган кулъязманы тоткандай була.

Ашык-пошык укый. Зиннәт ник биргәненә үкенер дә, дәфтәрне кире тартып алыр кебек тоела.

Бераздан, инде шигырьләрнең шактые белән танышкач, Фирүзә шагыйрь классташына күз сала. Зиннәт, теләсәң ас, теләсәң кис, дигән кебек, хөкем көтә, гаепле кеше кыяфәтенә кергән.

— Кай арада бу хәтле язып өлгердең соң син?

— Бу — меңнән бере генә әле. Әйтәм ич, ертып ташлый барам мин аларны.

— И тиле...

Кыз кабаттан дәфтәр битенә текәлә. Хәзер инде ул, бер строфаны укыган саен, күтәрелеп Зиннәткә карый, аңа ни әйтергә кирәклеген дә чамаларга тырыша. Нәкъ шул сүз Зиннәт шигырьләренең киләчәген хәл итәр кебек. Ни дияргә соң? Язылган әсәргә бәя бирү ансат түгел икән. Ул арада Зиннәт, сабырсызланып:

— Үзеңә ошаганын кычкырып укы әле, Фирүзә! — ди. — Син бит шигырь укырга оста, шәп чыга ул синең, тыңлап туярлык түгел.

— Кайсын укыйм икән соң?

— «Язларга мин үпкә саклыйм бугай» дигәнне...

*— ...Язлар, язлар! Сезгә нигә кирәк*
*Миңгә теләнүе җанымның?!*
*Берөзлексез нигә пышылдыйсыз*
*Серле исемен сөйгән ярымның?..*

Фирүзә шигырьне укып та бетерде:

— Менә сиңа — пәрәмәч! — дип, ризасызлыгын да сиздереп өлгерде.

— Ник алай дисең, Фирүзә?

— Соң! Шундый матур язга үпкә белдерергә ярыймы инде?

— Кызык... — Егет башын чайкап куйды. — Бүген үк үзгәртәм мин аны!

— Син аны стена газетасына бир!

Зиннәт куен дәфтәрен сумкасына яшерә.

— Газета өчен язылган шигырь түгел лә ул!

Алар юл уртасында туктап калганнар икән бит.

Кыз, авылдан икәү генә юлга чыккач та, егет күзләрендә әллә нинди серлелек, сөенеч, ашкыну сизеп алган иде. Менә хикмәт нәрсәдә икән!

— Фирүзә, мин ул шигырьне төзәткәч, тагын укып карарсыңмы?

— Ник алай дисең, Зиннәт?

— Мин бит аларның барын да синең өчен язам, Фирүзә!..

Кыз эндәшмәде. Күңелне кытыклап торучы мөнәсәбәтләренә шулай бер мизгел эчендә ачыклык керер дип ул башына да китермәгән иде.

Зиннәт тә шуннан артыгына кыюланмады. Сүзсез генә атлый бирделәр. Авылга кереп, юллар аерылыр чак җиткәч кенә егет:

— Сау бул, Фирүзә! — диде. — Иртәгә алгебра китабы эченә тыгып бирермен, яме? Укырсың да ертып ташларсың...

Кайсы кыз үзенә багышлап язылган шигырьне ертсын инде?! Фирүзә Зиннәт биргән шигырьне гомерендә күргән иң кадерле бүләк итеп әле дә саклый. Бераүнең дә Фирүзәгә багышлап шигырь чыгарганы, бераүнең дә аулак юлда очратып, куен дәфтәрен аңа сузганы булмады.

Шул елны Фирүзә университетка укырга керде. Зиннәт армиягә китте. Барысы да, балалык мавыгуы кебек, онытыла башлар кебек иде. Тик Фирүзә дус кызлары егет-җилкән белән чуалып йөргәндә дә Зиннәтнең шигырьләрен исендә тотты. Фирүзәнең киңәшеннән соң төзәтелгән юллар кыз күңеленә аеруча якын иде:

*Язлар, язлар, сезгә меңмең рәхмәт*
*Җиде күккә чөеп җанымны,*
*Һәрчак күз алдымда тотасыз сез*
*Фирүзәмне — сөйгән ярымны!..*

* * *

Лагерьга сузылган сукмак әрәмәлеккә керде. Монда шомлы, монда караңгы. Фирүзә адымнарын ешайта төште. Шулчак ул куаклар арасыннан бераүнең килүен шәйләде. Якында гына кемнеңдер аяк астында коры-сары чыртлап сына. Куакларның чайкалуы да билгесез бер кешенең килүен раслый.

Фирүзә шикле тавышлар килгән якка күз сала-сала кызурак атлый башлады. Тез буыннары җиңелчә калтырый, аяклары тип-тигез җирдә сөртенеп китмәкче була...

Ниһаять, бераү куаклар арасыннан:

— Апа! — дип эндәште.

Фирүзә, таныш авазны төсмерләп, туктап калды, артына борылды. Чытырманлык эченнән сукмакка атылып чыгучы кеше Кодрәт Бәйрәмов иде.

— Уф-ф! — дип тирән сулу алды.— Син икәнсең, балакай! Котны ала яздың бит!

— Мине эзли идегезме, апа?

Малай шушы кыска гына югалып тору вакытында да шактый йончып өлгергән: яшел күзләре төпкә баткан, йөзе сузаеп калган кебек, чәчләре кучкылланып оешкан, өсте-башы тәмам таушалган.

— Ник соң Казанга гына кайтып китмәдең ичмасам? Анда әнием шәһәр бетереп сине таптыра икән бит, хәтта безнең өйгә дә килгән...

— Ничек китим инде мин, апа?! — Малай күзләрен мөлдерәтеп Фирүзәгә карады. — Аннары сезне нинди хәлдә калдыра идем соң? — Ул оялгандай башын түбән иде. — Мин бит сезне белэм, апа, яратасыз бит мине... Әби кебек... — Ә-әй, апа... — Малай укытучысы алдында ачылып китүдән уңайсызланып, сүзне кисәктән башка якка борды. — Әни дә әйбәт минем, аны аңламыйлар гына.

Соңгы сүзләрнең Фирүзәгә кирәге калмаган иде инде. Укучысының «...яратасыз мине» дигәнен ишетү рәхәт, күңелле иде. Үзен яратуларына ышанган укучыны теләсә нинди эшкә күндереп була.

— Әйдә, киттек, Бәйрәмов, лагерьга! Анда безне көтәләрдер...

Әминә апа авылдан килгән балаларны да, аларның җитәкчеләрен дә лагерь тәртипләре белән таныштырып өлгергән иде инде. Кодрәтне авыл малайлары яшәгән бүлмәдәге бер караватка урнаштырдылар. Малайлар барысы берьюлы аңа текәлде. Арада иң зур гәүдәлесе сорады:

— Нәрсә, саттың, да?

Бәйрәмовны иң куркыткан сорау иде бу.

— Минем кайчан китеп, әле генә килгәнне күрмәдеңмени?

— Нәр-сә-ә-ә? — Озын малайның тавышында янау төсмерләре. Сугышмый котыла торган түгел.— Тагын да бер этлек эшләргә килдеңме? Синең мондый җырны ишеткәнең бармы?: «...без андый малай түгел, без мондый малай түгел...» Ә? — Ул кул астында яткан мендәрне умырып тотты: — Теләсәң, кеше төсле генә яшә, югыйсә, авызыңдагы тешләрне учыңа салып санатабыз!

Озын малайның мендәре Бәйрәмов өстенә очкан мизгелдә бүлмәгә авыл мәктәбе тәрбиячесе белән Фирүзә килеп керде. Бәйрәмов: «Миңа тансык дип, ике мендәр бирмәкче булалар. — Ул озын малайга ишарәләп: — Кирәкми, дус кеше, рәхмәт яусын. Медицина башны биеккә салып йокларга кушмый.— Мендәр авыл укучысы ягына очты.— Җыештырып куй караватыңны!»

Көндезге эш тә, кичке уеннар да тыныч кына узды. Инде йоклар вакыт җитеп килә иде. Авыл мәктәбенең бер малае башкаларга сиздермәскә тырышып кына килеп, Фирүзәне чакыртып чыгарды.

— Апа, сезнең теге малай баядан бирле елый да елый.

— Ник?

— Белмим апа, ник елаганын берәүгә дә әйтми.

— Ярый, бар, акыллым, мин аның белән үзем сөйләшермен.

Фирүзә Кодрәт күңелендә катлаулы кичерешләр кайнаганын сизенә килде. Тик малайны мәҗбүрән сөйләштереп булмый, андый сөйләшүдән кача ул...

Уйларының очына чыга алмагач, Фирүзә, бу малай әллә берәрсенә гашыйк булды микән, дип тә шикләнде. Көндезләрен ул кызлар бүлмәсенә кергән бит. Биредә, лагерьда, кызлар мәктәптә укыган чакларына карый, иркенләбрәк тә сөйләшкәлиләр. Фирүзәгә төрле сораулар ишетергә туры килә, балаларның әти-әниләре, гаилә хәлләре турында да яңалыклар ишетә ул. «Минем бер дус кызым», «безнең күршедәге апа» дигән булып, кызлар-егетләр турында бик ачылып фикер алышалар. Кисәктән кырысланып, чик куеп өлгермәсәң, кызларны бу әңгәмәдән аерыр хәл юк. Алар еш кына турыдан-туры:

— Апа, егетләр турында сөйләшик әле! — диләр.— Үзләре оялып, елмайган булалар.

Лагерьга авыл балалары килеп кушылгач, мондый сөйләшүләр аеруча ешайды. Кызлар авыл малайларының берничәсен инде үз итеп үк өлгергәннәр, алар белән хат алышырга теләүләрен дә белдерделәр.

— Ярыймы, Фирүзә Галләмовна? — дип тә сорадылар.

— Нигә ярамасын?! Ошаткан, дус иткән кешеңә хат язу бик әйбәт нәрсә.

«Әй, кадерлеләрем, — дип уйлый Фирүзә. — Күңелләрегез нинди саф сезнең! Әле сезгә кемнәр генә очрамас,ниләр генә кичермәссез. Үзегезне ихластан аңлаучы егет кенә табылсын!»

Фирүзә кызларның бәхәсенә үзе дә кушылып китә. Бервакыт яратуны бер-береңә ничек аңлату турында бәхәс киткәч, ул:

— Безнең заманда егетләр шигырь язып аңлата иде, — диде.

—А-а, яздырырсың безнең егетләрдән шигырь!

— Нигә? Әнә Вася Миләүшәгә язган бит!

Фирүзә шушы сөйләшүләрдән Бәйрәмовның ары сугылып, бире кагылып йөрү сәбәбен ачыкларга тырыша. Тик турыдан-туры сорасаң, кызлар шикләнеп калачак. «Мәхәббәт әңгәмәләре»нең чираттагысын шуңа китереп ялгыйсы иде!

Әминә апа Казанга кайтып киткән кичләрнең берсендә Фирүзә танцы оештырырга рөхсәт бирде. Сәгать буе радиоладан заманча көйләр яңгырады. «Ду» китереп биеделәр.

Бүлмәгә кергәндә дә кызларның телендә һаман бию тәэсирләре иде. Фирүзә җитди генә:

— Бүген биюләр дә булды, — диде. — Арыгансыздыр, йоклыйк!

Кызлар башта тын тордылар, аннары арадан берсе:

— Апа, бер-ике генә минут сөйләшеп ятыйк инде! — диде.

— Иртән үзегезгә кыенга килә бит?!

— Торабыз, апа, менә күрерсез!

Фирүзә, балаларны үзенә кирәкле әңгәмәгә тарту өчен, вакытны сузарга тырышты.

— Биегәндә дә сөйләшеп туйгансыздыр инде?

— Биегәндә ничек сөйләшәсең анда? — Нурия исемле кыз үзенең кичерешләрен аңлатырга тотынды. — Мин, көй ишетелүгә бөтенләй онытылып калам. Беркемне дә күрмим, көйгә туры килерлек хәрәкәтне табарга гына тырышам.

— Партнерыңа ышанмыйсыңмыни? — ди Фирүзә. — Без танцыга йөргән елларда биергә өйрәтүче абый башны бераз артка ташларга, партнерның билендәге кулына ята төшәргә һәм бары тик аңа елмаерга куша иде безгә.

— Миңа бернинди партнерның да кирәге юк — дип кырт кисте Нурия. — Минем бию дәресләренә йөргәнем юк югын. Кая — кинодан, кая телевизордан күреп калам да шуларны кабатлыйм. Көй генә булсын! Ритм! Иң яхшысы — чатнап торган ритм! Мелодия артта, фон өчен генә яңгырасын! Ритм булса, минем аякларым үзеннән-үзе бии башлый кебек. Шул ритм билгеле бер ноктага җиткәч, очам гына! Биектә! Тезләр бөрөзлексез бөгелә, аяклар тыпырдый, куллар биеккә сузыла, бил, кысасыннан чыгып китәрдәй булып, тирбәлә башлый.

— Юк, мин барыбер егетләр чакырганны көтәр идем, — дип Фирүзә кызларның сүзен үзенә кирәкле якка борырга тырышты.

— И-и, авыл малайларының чакырганын көтсәң, апа, сез бүлеп куйган вакыт үтә дә китә бит ул...

— Монда бит әле безнең егет тә бар.

— Бәйрәмовмы??? — Кызларның берничәсе берьюлы кычкырды.

— Аңа тагын!

— Ул бит бичара җан.

— Аптыраган башын кая куярга белми интегә.

Фирүзә тел очындагы соравын әйтә алмый калды, бию остасы Нурия ялгап алып китте:

— Ник ул кадәр бетеренеп йөри икән соң ул, кызлар?

— Әй, шул әнисе аркасында инде.

— Монда әнисе юк бит!

— Аныкыннан лагерьга качып та котылып булмый.

— Әниләрнең берсе дә, танцыга бар, дип тормый инде ул.

— Кодрәтнең әнисе безнең бөтен урамга бер оятсыз бит ул.

— Гуляйть итә, дип сөйлиләр. Әтиләре дә шуның өчен киткән. Инде Кодрәтнең абыйсы да чыгып сызды, хурлыгына чыдаша алмады. Кодрәт шуңа аптыраган ул. Өенә кайтып та керәсе килми аның...

Фирүзә кызларның башка сүзләренә артык игътибар итмәде инде. Укучысының һәр тарафыннан муллык бөркелеп торган йортына кайтырга теләмичә ни сәбәпле каңгырап йөрүен аңлады ул. Хәзер бу очракта класс җитәкчесе нишләргә тиеш, баланы бу күңелсезлектән ничек коткарырга мөмкин икәнен генә хәл итәргә кирәк...

* * *

Тагын бер ел узды...

Фирүзә классындагылар мәктәп белән бөтенләйгә саубуллашырга әзерләнәләр иде инде. Балачактан мәңгегә китү, алда торган мөстәкыйльлек җаваплылыгын тоеп, укучылар көннән-көн җитдиләнә бардылар. Укытучыларга да, алар куйган билгеләргә дә мөнәсәбәтләр үзгәрде. Тиздән чыгарылыш имтиханнары башланачак!

Шундый ифрат җаваплы көннәрнең берсендә Кодрәт Бәйрәмов тагын мәктәпкә йөрүдән туктады. Яшүсмер күренмәгәч, Фирүзә җанын кая куярга белми йөдәде. Кәефсезлеге дәрес алып баруында да сизелеп тора. Ник икәнен үзеп әйтүе дә авыр, әмма гел шулай килеп чыга: Бәйрәмов мәктәптә күңелсезлек тудырдымы, Фирүзәнең өендә дә дөньяның асты өскә әйләнә...

— Фирүзә Галләмовна, звонок булды, чыгарга мөмкинме?

Бөтенләй онытылып китүен Фирүзә шунда гына абайлады. Дәресен йомгаклаган булса да, һаман журнал битенә карап утыра икән. Ул елмаеп җибәрде. Шул гына кирәк булган — балалар дәррәү күтәрелделәр.

— Хушыгыз, Фирүзә Галләмовна!..

— Сау булыгыз!

— Яңадан очрашканчыга кадәр!.. — дигән сүзләр ишетелде.

Малайлар коридорга атылдылар, кызларның берничәсе укытучы өстәле янына килде. Андый вакытта аларның берәрсе дәрестә аңлап җиткермәгән соравын бирә, я класс хәлләренә кагылышлы тәкъдим белән мөрәҗәгать итә. «Болар, бәлки, Бәйрәмов турында да берәр нәрсә әйтмәкчедер?» Бу юлы Фирүзәгә кызлар әйтәчәк сүз әһәмиятсез булыр кебек тоелды.

— Сау булыгыз, кызлар!

Кызлар, ачкан авызларын йомарга онытып, Фирүзә Галләмовна артыннан карап калдылар.

Шул сәгатьтән Фирүзәнең расписание буенча күрсәтелгән эш көне тәмам. Укытучы хезмәтенең ни икәнен белмәгән кешегә, син көнгә әнә ничә сәгать генә эшлисең бит, дияргә дә урын бар кебек. Янәсе, әнә, дүрт-биш мәртәбә кырык биш минутлык дәресен уздырып чыга да — вәссәлам! Дәресеңне бала зиһененә сеңдерерлек итеп бирү өчен төннәр буе әзерләнүләрне, дәрестән тыш эшләрне класс җитәкчелеге вазифасын һәм башка мәшәкатьләрне исә һичнинди расписаниеләргә сыйдыру мөмкин түгел. Педагогның эше гомер буена бара — һаман да шәкертләрең өчен борчылып яшисең...

Укытучыларның бөтен өмете киләчәккә тоташкан: кайчак, әйбәт кенә укучы, мөстәкыйль яши башлагач, танымаслык булып үзгәрә дә китә. Укыганда Бәйрәмов кебек үзәккә үткәне, киресенчә, эзгә әйбәт кенә төшә дә куя.

Фирүзә урамга чыккач та шуңа охшаш уйларыннан арына алмады. «Бәлки, берничә елдан ук әлеге Бәйрәмов мәктәпнең ышанычлы терәге булып китәр. Мәктәпкә шефлык итүче заводка эшкә урнашып алса, берничә елда уңганлыгын күрсәтеп, күтәрелеп, үсеп китсә...

Әйтик, заводның берәр мастеры яки профком председателе үк булып куйса...»

Болай уйлау рәхәт иде... тик кинәттән барыр юл начарланды. Җиңелчә генә яңгыр явып үтсә дә, Бәйрәмовлар урамында күлләвекләр хасил була. Фирүзә, туфлиларын пычратмас өчен, тар сукмакка керде.

Келәне күтәрүгә, капка үз авырлыгы белән ачылып китте. Бәйрәмовның әнисе, ничектер җайсыз гына атлап, болдыр баскычыннан менеп бара иде. Капка тавышына борылып карады, Фирүзәне күрде. Ишегалдына укытучының килеп керүе ананы каушатты булса кирәк, ул баскан җирендә чайкалып китте, йөзе агарынып чыкты. Үзе актанкарадан сүз әйтә алмый торды. Бу уңайсыз хәлдән котылу өчен иненә элеп чыккан җилфердек плащын төймәләргә теләде. Сәдәфләрен таба алмадымы, чабуларын яба алмый интекте. Аннары ул гәүдәсен учлары белән капларга теләгәндәй итте, бил тирәсен сыйпады. Фирүзә шунда гына хатындагы үзгәрешкә игътибар итте: хатын авырлы иде. Йөкле хатын һәркем күңелендә шәфкать уята. Укытучы елмаеп сәлам бирде.

— Исәнмесез!

Хатын исә, сәламләшәсе урынга, уңайсызланып башын аска иде.

Ана кеше баскычтан кире төшә башлады, соңгы басмага җиткәч, кабат югарыга талпынды. Фирүзәгә текәлеп карады.

— И-и, мин бит, э-э-э, сезне танымый торам әле,— диде.

Бу сүзнең дөрес түгеллеген икесе дә бик яхшы аңладылар. Укытучы эндәшмәде. Хатын теләр-теләмәс кенә:

— Мин сезне башка берәү артыннан килгән дип уйладым тагы. Кодрәт өйдә, әйдә, керегез! — диде.

Укучысын күреп, аны әнисе белән бергә утыртып, кичекмәстән мәктәпкә килергә кирәген аңлатудан да мөһимрәк бурычы булмаганга, Фирүзә, хуҗа тавышында өзгәләнеп чакыру сизмәсә дә, алга атлады, баскычка менде.

Баскыч тар иде. Бер басмасыннан күтәрелүгә, укытучы әле һаман да урыныннан кузгалмый торучы хуҗа хатын янына ук килеп җитте.

— Кирәкми, бүгенгә кермәгез! — диде кинәт ана кеше.

— Миңа аны күрмичә китәргә ярамый, аңлагыз сез! — Фирүзә вәгазь укыгандай аңлатырга мәҗбүр булды.— Инде унынчы классны тәмамлар чак җиткәч, борын төбендә имтиханнар торганда, дәрес калдырырга ярыймы соң? Сез дә әйтегез: шушы бер-ике ай эчендә аның гомерлек язмышы хәл ителә. Битараф булмыйк, зинһар!

Хатын бу юлы елмаеп җибәрде.

— Түгел, түгел, андый түгел мин. Укысын! Каршы сүзем юк. Барыр, барыр, иртәгә үк! Мин бит...— Хуҗа хатын, сүзне дәвам итәргә ярармы, дигәндәй бераз чамалап торды.— Мин бит сезне ирегез артыннан эзәрлекләп йөрисез дип курка калдым. Уф-ф!

Хатынның күзләренә мөлдерәп яшь тулды. Ул инде үзенең сәер хәлен яшерергә дә теләми иде.

— Сезнең кебек кешене беренче күрәм. Ирләре безнең ишеләр янына кереп чыкса, кайбер хатыннар көнчелектән буыла башлый... Әйтерсең, тол хатын кеше түгел дә, әйтерсең лә аңа дөнья мәшәкате белән керергә ярамый... Сезгә рәхмәт. Чын кеше икәнсез. Безнең балалар хакына җан аямыйсыз...

Шуннан соң Фирүзә бер ни ишетмәде, шактый вакыт нәрсә булганын белми барды да барды...

Кодрәт Бәйрәмовның әнисе аның турында ниләр уйлап калгандыр, Фирүзәнең җанын исә кинәттән өметсез тойгылар биләде. Лагерьда чакта кызлардан ишеткән ямьсез сүзләр янына Зиннәтнең бу өйдә булуы бергә кушылды...

Дөнья кинәт бар кызыгын җуйды. Пычрак, тар урамның ничек артта калганы да сизелмәде. Аяк астында күлләвекләр чүп кенә икән

ул — аны урап узып була. Ә менә каршында яшәү мәгънәсен, балалар язмышын, иң газиз хисләреңне билгесезлеккә төреп куйган коточкыч чытырманлык торса...

Кодрәтнең әнисеннән соңгы сүзләрне ишеткәч, нишләде соң әле ул? Тел тибрәтерлек тә көче юк иде аның, аякларын ничек кузгата алгандыр. Ниһаять, ул капкадан урамга чыгуын аңлады. Әлеге ямьсез хәбәрне ишеттергән ишегалдына караганда урам — оҗмах иде. Фирүзә үзен әле генә яктылыктан мәңгегә аерылгандай хис иткән иде, дөрес түгел икән бит, урам әнә нинди якты! Һавасы да саф, сүнгән җанны кабат терелтерлек. Аяклар да төзрәк атлый башлады. Алга барырга! Инде әнә өйгә үк кайтып җителгән. Фикере дә ачылып китте. Барган җирендә төп максатына ирештеме соң ул? Бәйрәмов дәрескә килерме? Ә Зиннәт бу йортка ник, ни өчен барган? Аның белән сүзне нидән башларга? Ни дияргә?

Сораулар күп — җавап кына юк. Фирүзә кабат сабыйлыгына кайтып төшкән кебек булды. Улларының өзлексез яудырып торган сорауларына җавапны таба ул. Ә менә Фирүзә башына төшкән сорауларга кем җавап бирер? Чарасызлык аңа тын алырга комачаулый, буа, кыса. Кемгә генә барып егылырга да кемнән төпле җавап ишетергә?..

Фирүзә инде подъездга кергән, өченча катка күтәрелгән, ишекләренә килеп сөялгән иде. Аны-моны уйламастан гына сумкасыннан ачкычын эзләп тапты, ишекне ачып эчкә үтте.

— Улым, син өйдә мени? — Фирүзәгә үз тавышы ят иде. Чыннан да, өйдә бер таяныч — төпчек улы барын онытып җибәргән ич ул? — Кайчан кайттың, улым?

Өс киемен анда-монда элгәләп, туфлиларын ишек төбендәге көзге шкафы астына этеп, Фирүзә балалар бүлмәсенә үтте.

— Абау, улым, ни булды сиңа?

— Мин сугыштым, әни.

— Кем белән? Ник?

— Әйтмим, әни, сорама!

— Тагын кай җирләрең авырта, имгәнеп беткәнсең бит?

— Чепуха!

— Бу килеш дәрестә ничек утырдың?

— Мин анда булмадым, иртәгә дә бармыйм, әни, яме?

— Әй, улым, улым! — Фирүзәнең башка чыдар чамасы калмаган иде инде, елап җибәрде. Улының күкрәгенә сак кына башын салды да күз яшьләре ихтыярына бирелде.— Ниләр генә булды соң әле безгә?..

Әнисе елавына кайсы бала битараф кала алсын? Фирүзәнең улы да, җаны тулы үпкәләрен онытып, әнисенә омтылды.

— Елама, әнием, — диде. — Елама! Менә абый армиядән кайтсын әле, кирәген бирәбез без аның, күреп торырсың! Абыйның кайтырына күп калмады инде. Киткәндә җырлаган иде бит: «...кайтырга да күп калмады, егерме дүрт ай гына. Табыныбыз мулдан безнең — солдат ашы — май гына»...

Малай, бу шаян такмакны искә төшергәч, әнисе көлми калмас, дип өметләнгән иде, тик Фирүзә елмая алмады, аны улының алдарак әйткән сүзе тетрәндергән иде.

— Кемнең кирәген бирмәкче буласыз, аңламыйм?

— Сорап торган буласың тагын, шуны инде, Бәйрәмовны. Мин бүген үк кирәген бирәдер идем дә... барып чыкмады.

— Ник бәйләнештегез? Ни җитми сезгә?

— Телен тыйсын, күп сөйли башлаган.

— Аның ни гаебе бар соң? Икегез дә дәрес калдыргансыз. Әле менә Бәйрәмовның әнисе белән сөйләшеп кайттым.

— Тагын шуларга барып йөрдеңме? — Малай урынынннан сикереп торды. — Китче!

— Минем Кодрәтне аттестатсыз калдырырга хакым юк, улым. Хәзер дәресләрен ташлый икән, ояты минем җилкәгә төшәчәк.

Малай, әнисенә хәлне аңлату өчен, теләсә-теләмәсә дә Бәйрәмов турында белгәннәрен сөйләргә булды.

— Аның әшәкелеге мәктәптә түгел, әнием, урамда чакта ачыла.

— Каян килгән сүз бу? Бәйрәмов нишләп әшәке булсын?

— Аңлатам алайса. Син, әни, хәтерлисеңме: абый армиягә киткән елны алар классының макулатурасы янган иде. Аңа бит абый ут төртте. Үзара бәхәсләшкәннәр дә, син укытучы баласы, булдыра алмыйсың, дип үчекләгәч, абый яндырырга мәҗбүр булган.

— Ничек?! — Фирүзә учлары белән битен каплады. — Нидер сизенгән идем аны. — Аннары ул кинәт башын күтәрде. — Әле анда да сез Бәйрәмовны гаепле санарга тырышып йөрдегез түгелме?

— Анысын абый белән икәү уйлап чыгардык. Кичтән. Юри. Ул малай актыгын гаепле күрсәтер өчен.

Фирүзә инде улын тыңламый да кебек. Ул үзалдына:

— Барына да мин гаепле, мин! — дип сукранырга тотынды. — Үз балаларымның нишләп йөрүләрен дә белмә инде. Ояты үземә!

— Ник, әнием, алай дисең? Ә эти?

Фирүзә улына сәерсенеп карады. Ул әле аны болай ук житди фикер йөртердәй кешегә санамый да иде.

— Әтиең, улым...— Фирүзә, нәселләрендә элек-электән кабул ителгән гадәт буенча, бала алдында ата кешегә тел-теш тидерергә базмады. Күңелендә Зиннәткә карата шикчеллек, ышанмау кебек тойгы куера баруны да улыннан яшереп калырга теләде. — Әтиеңнең эше — муеннан, улым...

Икенче көнне Фирүзә иртүк директорга кереп, олы улының җинаяте, теге вакыттагы янгын вакыйгасының сәбәпләре турында белгәннәрен әйтеп чыгарга ниятләде. Андый чакта Фирүзә сүзне һәрвакыт кирәкле җиреннән башлый. Бу юлы да:

— Федор Федорович, беләсезме, теге макулатураны минем олы улым яндырган икән бит,— дип әйтеп салды.— Аңа үзенең бу зур гаебен белдерү безнең мөһим бурыч.

Гаҗәпләнүенә каршы, директор тып-тыныч тавыш белән:

— Беләм, — диде. — Мин аны күптән беләм инде. Фирүзә Галләмовна. Армиягә китүенә бер генә,ай үткән иде бугай, улыгыз миңа хат язды. Барын да әйтеп язган. Сезгә әйтергә кирәк санамадым. Үткәндәге күңелсезлекне нигә яңартырга?! Онытыйк...

Фирүзә башын аска иеп утыра бирде. Директор ул арада:

— Шулай да бүген миңа керүегез әйбәт булды, — дип өстәде. — Педагог ихлас күңелле булырга тиеш. Мин сезнең эштән канәгать. Бәйрәмовлар гаиләсенә баруларыгыз да бушка китмәгән икән. Беркөнне миңа малайның әтисе керде.

— Әтисе юк бит минем ул малайның, чыгып киткән бит ул...

— Баласы турында онытмаган шул, дөресрәге, уйлый башлаган. Көтик, Фирүзә Галләмовна, көтик! Сезгә рәхмәттән башка сүз юк. Бәйрәмовның әтисе дә шулай ди.

Фирүзәгә, әйтерсең, ак канат куйдылар. Кабинеттан чыкканда аңа күкләргә ашарлык көч иңгән иде. Тизрәк класска, үзенең укучылары арасына ашыкты ул. Дәресне ничек башлап җибәрәсен, кайсы укучыга нинди сорау бирәчәген уйлап алды. Алдагы кырык биш минутын ифрат та файдалы үткәрәчәгенә нык ышана иде ул.

* * *

Фирүзәләр гаиләсендәге гадәти кичләрнең берсе иде. Зиннәт эштән кайткач та Фирүзә кыяр-кыймас кына сүз башлады:

— Син Бәйрәмовның әнисе янына йөрисең икән. Хакмы шул?

Зиннәт сәерсенеп хатынына туп-туры карады. Аннары зал буйлап әрле-бирле йөренергә тотынды.

— Мин бала-чага түгел, Зиннәт. Ул хатын янына йөрүең юньлегә түгелдер. — Каян гына килеп керде соң бу сүз Фирүзә теленә?

Ахмаклыкка тәһарәт кирәкми, дип, шундый дуамаллыкка әйтәләрдер инде. Җитмәсә, Зиннәте дә хатынының нинди уйлар белән газапланып йөрүен чамалап тормады, аның үз-үзен тотышындагы сәерлегенә бәйләнә башлады:

— Минә синә педагог! Син башкалар турында шундый түбән фикердәдер дип, башыма да китерми идем, — диде. — Кемнәр сиңа пычрак гайбәт ташый? Син инде миңа ышанмыйсыңмы?..

Сүзләр кыза барды, яннарында бала утыруын да онытып, һәркем үз сүзен әйтеп калырга ашыга иде кебек. Ата кеше, ниһаять, бу бәхәскә чик куярга теләгәндәй:

— Бер-береңә ышанмагач, безгә аерылырга гына кала, бергә яшәүдән ни мәгънә? — дигән иде, кече уллары урамга ук чыгып чапты.

Аны бу хәлендә ялгыз йөртергә ярамавын Фирүзә бик яхшы аңлый иде. Ул кабаланып баласы артыннан йөгерде.

Малай трамвай юлы аша чыгып, каршы яктагы бакчага ашыга иде. Фирүзә аны куып җиткәндә, ул аулак почмактагы эскәмия аркасына капланган да елый иде. Ана кулларын сабыр гына итеп улының җилкәсенә салды.

— Кирәкми, улым, ярамый алай!

Малай, кинәт борылып, яшьле күзләрен әнисенә төбәде:

— Ул бит: «Аерылышабыз», ди. — Аерылышмагыз, әни! Кирәкми!— Әнисе бер сүз дә әйтмәгәч, үпкәле тавыш белән кычкырып ук сорады. — Мине кая куярсыз соң? Мин моны теләмим!

— Улым, егетләрчә фикер йөртик әле! — диде ана. — Әтиең дә, мин дә исән-саулар. Сине бик яратабыз. Инде әтиең белән безнең мөнәсәбәт... — Тавышына еламсырау кушылганны сизеп, Фирүзә аз гына туктап торды. — Анысы бит, улым, сиңа кагылмый.

Икесе дә тынычлана төштеләр.

— Әйдә, улым, кайтыйк. Без гомер буе бергә булырбыз!

Фирүзәнең генә үзен юатыр кеше юк. Ялгызлыкка исә ул бөтенләй яраклаша алмый икән. Хәтта эшендәге кечкенә генә бер күңелсезлек турында да ул иң элек Зиннәт белән киңәшә иде. Халыкта кабул ителгән гадәт буенча гомер итә иде алар: атка сыенып тай үсә, иргә таянып хатын яши. Хәзер менә таянычы какшады Фирүзәнең...

• • •

Ишекне абыйсының олы улы ачты. Фирүзә өйдә әнисеннән башка кеше очрамас дип өметләнгән иде дә, алай булып чыкмады. Сәгъдия карчык, күзлеген киеп, яңа килгән газетаны укып утыра иде. Кызын күргәч ул, бөтен шөгылен онытып, аңа таба атлады:

— Нәрсә булды? — дип сорады.

— Исәнме, әни! Ник алай дисең?

— Дәрес вакыты бит. Шуңа әйтүем.

— Мәктәп эшеннән болайрак хәлләр килеп чыкты әле, әни.

Карчык, олылар сүзен тыңлап үзләре тирәсендә кайнашкан оныгына сүз кушты:

— Ваннага керәм, дигән идең бит, бар, улым, юын!

— Юк, әби, минем юынырга уйлаганым да юк.

— «Әби» түгел мин сиңа, «дәү әни». Инде ничә кат әйттем?

— Минем «әби» диясем килә.

— Ә менә минем «әби» буласым килми.

— Сиңа бит инде житмеш биш тулды, кайчан «әби» буласың соң?

Карчык, ярдәм сорагандай, Фирүзәгә карады.

— Менә шулай иртәдән кичкә кадәр әрепләшеп утырабыз инде без аның белән. Ата-бабада булмаган гадәткә кайдан гына өйрәнгәндер?

Малай:

— Бетте, әби, бетте,— дияргә ашыкты.— Керәм, ваннага да керәм, зарланма гына!

Бу гөнаһсыз бәхәсне тыңлаганда Фирүзә онытылып торды. Әнисе дә кеткелдәп җибәрде.

— Бар, улым, бар!— дип, оныгының аркасыннан кагып куйды.— Апаң белән бер тынычлап сөйләшик әле, очрашмавыбызга ничә көннәр үтте!

— Мин озакка түгел әни.— Фирүзәнең кинәттән күңеле тулды. Еларга иде дә, әнисенең чәч сыйпаганына рәхәтләнеп барлык кайгылардан арынып калырга иде. Сабый чактагы кебек. Тик карт анага тагын күпме хәсрәт сыяр соң? Аны шулкадәр мөлдерәмә итеп тутырырга кызының хакы бар микән?— Мин озакка түгел, әни, Хәлеңне белеп чыгыйм, дип кенә керү иде. Менә чәй янына кучтәнәч.

Алар карчыкның пөхтә җыештырылган, җанга рәхәтлек бөркеп торган бүлмәсенә үттеләр.

— Кучтәнәчләр күтәреп йөри торган гадәтеңне ташла, кызым. Миңа дигән мул табыннар теге дөньядадыр инде.

— Кирәкмәгәнне сөйләмик әле, әни! Бер дә соңгы адым атлаучы кешегә охшамагансың, күз тимәсен!

— Соң бу балалар белән шул инде. Менә Гатаулла Шәмсенисасына әйләндереп бетерделәр болар.

— Анысы кем тагын?

— Безнең Каргалыныкы Шәмсениса исемле бер карчык көннәрдән бер көнне әҗәле җитүен сизгән икән. Барып түшәгенә яткан. Шунда гына ялгыз икәнлеге исенә төшкән. Сикереп торган бичара. Ишекне ачып кычкырган: «Гатаулла кер, ясин чык, үләм!»— дигән.

— Шуннан?

— Шуннан шул, карты кереп, баш очына тезләнүгә, Шәмсениса җан бирә.

— Ярар, әни, тәндә җан барында, яшик әле без!

— Сөйлә, ниләр бар, кызым?

— Без аерылышабыз, әни.

Карчык керфек тә какмады, гүя бу коточкыч сүзне ишетмәде ул. Кызы белә: әни-карчык күңеле белән кабул итмәгән хәбәрне, шулай илтифатсыз калдыра. Әмма Фирүзәнең башка чарасы юк, ул дәвам итте:

— Зиннәт минем класстагы бер укучының тол әнисе янына йөри, берсендә өйгә дә кайтмый калды. Ничекләр түзим, класска ни йөзем белән керим?

Баласының бу дәлилләре дә карчыкны кысасыннан чыгара алмадылар. Ул Фирүзәсенең сүзләрен сабыр гына кире кага башлады.

— Мин монда аерылырлык сәбәп күрмим. Сорашасы идең, әше булгандыр. Шөкер: миңа килен-кияүләрнең дә, балаларның да яхшылары насыйп булды. Шуны бел: безгә ирдән кайткан, балаларын ятим иткән кыз кирәкми! Йөрмә нәсел таплап!— Иң төпчеге, иң иркә баласы, Фирүзәсе кинәт мендәргә капланып үкси башлагач кына, карчык тавышын йомшартты.— Әй, кызым көнчелегең котырта сине. Безнең нәселдәге яман гадәт ул. Үзем дә көнләшә идем. Әтиең-мәрхүм сөяләп торган каенны кочаклап та елаган чакларым буладыр иде. Имеш, ник әле бу Галләметдин миңа түгел, каенга сөялгән? Аңа сөялеп кемне уй-

лый, кемне юксына? Көнчелекнең астыртын көче хатыннар, балалар башына гына түгел, дәүләтләр өстенә афәт китерә ул.

Фирүзә тынычланырга тырышып карады.

— Гомер эчендә бер генә тапкыр укытучылыгыңны онытып тор әле, әни,— диде.— Акыллы бер киңәш бир син миңа!

— Мин бер вакытта да бүлгәләнә алмадым. Укытучылыгым да, синең әниең булуым да, бүгенге пенсионерлыгым да — барысы да үзем.

— И-и, әни...

Баласы күңеленә юл яра алмавына аптыраган әни-карчык:

— Син кызым, бу көнчелек галәмәтен генә җиңәргә тиеш,— дип, тагын сүз башлады.— Берәүнең дә кайгы савыты буш тормый, шуны җиңә бару инде ул — яшәү. Аерылышуларыгыз турында син әйтмәдең, мин ишетмәдем.— Ана кеше кабаттан кырысланды.— Зиннәт кияүнең андыйлыгына ышанмыйм да әле мин. Бүгенге кебек исемдә: сине сорарга килүләре...— Карчык елмаерга тырышты.— Син бит укытучым, Сәгъдия апа, ди. Фирүзә дә укытучы булды, ди. Минем өчен дөньяда алардан да зур кеше юк, ди. Шундый кешеләр белән туганлашуның нинди зур җаваплылык икәнен аңлыйм, гомерем буе сезнең ышанычны аклар өчен тырышырмын, ди...

Үткән көннәрне искә төшерү бик рәхәт булса да, Фирүзә әнисенә каршы төшеп маташты:

— И-и, әни, кыз сорарга килгән кеше нәрсә димәс.

— Мин Зиннәтне сабый чагыннан беләм. Ликбез сәгатьләрендә этиәнисен дә укыткан идем. Сине ул сорарга килгәч: «Төпчегемнең бәхете бар икән»,— дип куйдым.

Фирүзәнең тынып калуын карчык аның килешүе дип аңлады.

— Син, кызым, әллә бүген мәктәбеңә бөтенләй бармыйсыңмы?

— Мин абыйны да күреп киңәшим дигән идем, әни.

— Аларга бу кирәкмәгән хәбәрне ишеттермик, эшеңә бар! Мәктәп — барына да дәва ул.

Фирүзә абыйсы белән мәктәп каршындагы тын бакчада очрашты. Тәнәфес вакытында. Әнә, малайлар арасында чатанлый-чатанлый атлап баручы кеше Фирүзәнең абыйсы иде.

«Алтмышына бара, үзе һаман бала-чага кебек!» — дип, Фирүзә абыйсына сокланып карап торды. Аннары ул утыргычтан сикереп торды да абыйсына каршы атлады. Аралары шактый якынайгач, абыйсы да сеңлесен күреп алды. Әле һаман янында уралучы ике-өч малайга, елмаеп, нидер әйтте, аннары Фирүзә янына килде.

— Ни булды, сеңел? Әйдә, утырыйк әле! Сөйлә!

Фирүзә сабыр булырга, вакыйгаларның асылын тасвирларга, сүзенә кирәкмәгән төсмерләр кыстырмаска тырышты. Сөйләп бетергәч, абыйсы: «Шул гынамы?»— дип сорады.

Фирүзә абыйсыннан: «Кайгырма, сеңел! Сиңа тел-теш тидертмәм!»— дигән сүзләрне көткән иде.

Абыйсы исә бөтенләй башкача тота үзен.

— Мин тагын сине, егетләргә алыштырґысыз, дип мактап йөрим,— диде.— Син әнә ничек йомшап төшкәнсең.

— Миңа төпле бер киңәш бир, абый. Кайсындыр ташларга кирәк миңа: Зин...— Фирүзә тотлыкты.— Зиннәтнеме, эшнеме...

Абыйсы кашларын җыерды.

— Ни сөйлисең булмаганны? Ә беләсеңме әле күптән түгел Зиннәтне заводта синең Бәйрәмов белән бергә күргәннәр.

— Мин, ирләрнең мондый җүләрлеге озакка бара микән, дим. Абый, менә бит син бөтенләй башка.

— Син, сеңел, Зиннәтеңне минем белән чагыштырма!— Абыйсының карашлары еракка юнәлде.— Авылга ике култык таягына атланып

кайтып кердем мин. Кулда — педрабфак документы. Мин бит, сугышка кадәр, рабфакка кергән идем. Сугыштан соң шуңа күрә мәктәптә эшли башладым. Күзем — колхоз алачыгында. Авылга берән-сәрән кайта башлаган машиналар тавышы әллә нинди затлы музыкалардан болайрак тоела иде. Җан теләгән һөнәргә өйрәнеп, шуның белән шөгыльләнергә җай булмады. Сугыш харап итте барын да.

Фирүзә шаккатты, ул бит абыйсын мәктәптән башка яши алмас кеше дип уйлап йөри иде.

— Балаларны яратасың бит син, абый?

— Ул тишек борыннарны кем яратмый? Инде укытучы да икәнсең, балалар өчен җаныңны бирергә әзер торырга тиеш син. Мин шулай дип беләм. Фәнем дә әйбәт минем — физика. Яраткан һөнәремнең теориясе. Мин үзем кулга металл тотып эшләү турында хыяллана идем. Яшь чакта... Инде менә пенсиягә китәр көннәремне санап яшим. Ә бит башкача булырга мөмкин иде. Сугыш тартып алган бәхетне кире кайтарып булмый, сеңел. Сугыш аяусыз! Анда кем көчле, шул җиңә. Без җиңдек. И һәм мин үкенмим. Укытучы мин кызыккан һөнәрдәге кешеләрне дә әзерли бит. Моны миңа, бик беләсең килсә әйтим, синең Зиннәт төшендерде: аһ-ваһ килеп йөрмә, Галлямыч, ди, син, инде ничә буын токарьлар әзерләп чыгардың, ди. Сез бит, кешелеккә иң төп өлге, ди.

Абый кеше аягының протезын җайлап куйды — аңа китәргә вакыт җиткән иде.

— Ярлары биек, сеңел, без ага торган елганың, агышы кызу. Яр сазына батып каласың килмәсә, кыю булырга туры килә.— Фирүзә дәшми торгач, ул тагын өстәргә ашыкты.— Зиннәт өчен кайгырып йөреп, мәктәбеңә суынма. Мәктәпкә хыянәт итәргә синең хакың юк. Әниең ни кичергәннәрен хәтерлә! Чын педагог шундый гына була ала. Әти, бичара, больницага да илткән иде үзен. Бер атна үтте — үзгәреш юк. Мәктәптә укытучылар җитешми торган чор. Әни, палатасыннан чыгып киткән дә, төне буе авылга җәяү кайткан. Имеш, программаны үтәми кала. Ул елларда бала табучыга озын ял бирү юк иде. Ике көннән соң сине укыткан җирендә тапты. Телең ачылуга, син дә укытучы булып уйный башладың... Педагоглык синең каныңа сеңгән, син аны ташлый алмыйсың... Ә Зиннәт мәсьәләсендә аңла: син бәхетле генә булырга тиеш, мәктәптәге балалар синең йөзеңнән хәсрәт галәмәте түгел, җирдә яшәүнең зур бәхет икәнен күреп торсыннар!

Фирүзә абыйсының бер сүзен аеруча хәтерләп калды. «Ярлар биек сеңел...» Юк, Фирүзәнең яр ләменә буталып каласы килми. Ул күрәшәчәк, алга ашкыначак! Кайтып җитүен дә сизми калды.

— Син хәзер ирдән дә уздыра башладың, ә?— дип каршы алды аны Зиннәт.— Нишләп йөрисең, кайларда булдың?

— Бәйрәмовларга бардым.— Ялганына үзе үк гаҗәпләнде Фирүзә.

— Шаяртасың бит?!— Зиннәт аңа тагын да якынрак килде.— Син анда юк идең. Мин бит үзем яңа гына шуннан кайттым...

«Ичмасам, яшереп тә тормый...»— Фирүзә, өстен алмаштырып, кухняга кергәндә Зиннәт әле һаман залдагы диванда таш сыңдай утыра иде.

Күпмедер вакыттан соң Фирүзә аркасына җылы бер кул килеп сарылганны тойды. Аңа сихри куәт иңгәндәй булды. Бу кулны бик яхшы белә Фирүзә: Зиннәте бу аның...

Авыз ачып сүз әйтергә берсе дә батырчылык итмәде. Беренче башлап Зиннәт:

— Хаталык — миндә,— диде.— Шул Бәйрәмовның этисе белән күпме чиләндем бит. Өенә кайтармакчы булдым. Сиңа әйтми генә...

Фирүзәнең җилкәсеннән, әйтерсең тау төште. Менә бит ничек...

— Бәйрәмовның әтисе нишләде соң?

— Үзләренә кайткан булырга тиеш.— Зиннәт тавышында ясалмалык сизелмәде.— Ул бит минем сменада. Без шуннан танышып киттек тә инде. Миңа барын да алдан сөйләргә кирәк булган да бит сиңа...

* * *

Авызы-күзе көлеп торган Кодрәт Бәйрәмовны мәктәптә күргәч, Фирүзәнең хәтеренә әнисе сүзләре килеп төште: дөнья рәхәтенең бер ишеге ябыла, мең ишеге ачыла, эзләп таба гына бел!

— Ничек килергә уйладың, Бәйрәмов? Бүген сочинение бит.

— Апа, кайгырмагыз, мин сезнең отличница артына утырам.— Малайның мөһимрәк сүзе барлыгы әллә кайдан кычкырып тора иде.— Безнең әни бәби тапты, апа! — диде ул. Малайның авызы-күзе тоташтан көлә иде.— Кеп-кечкенә, тотар җире дә юк. Әти белән барып алдык.— Малай җитдиләнеп калды.— Безнең әти кайтты бит, апа.

— Менә әйбәт. Сеңелең бәхетле булсын! Укуыңа да зыян китермә.

— Юк, апа. Юк, Фирүзә Галләмовна.

Мәктәпнең зәңгәр коймасы Фирүзәгә күкләр киңлеге булып тоелды. Гүя ул да, Кодрәт тә җирдә басып тормыйлар, күктә очалар. Укытучы коймага сөялде. Кодрәт аның авыр портфеленә сузылды:

— Бирегез, бу — безнең дәфтәрләрдер инде?!

Укытучы портфельдән бушаган кулы белән болай да шома чәчләрен төзәткәндәй итте:

— Бүген сезгә барырга туры килер болай булгач,— диде.

— Ник инде, апа?

— Гаиләгезне котларга кирәк. Теләсәң, бергә кайтырбыз...

Фирүзә, дәресләр башланганчы ук биология укытучысын табарга ашыкты. Зөләйханың оранжереясында зәйтүннәр чәчәк атты. Сорарга кирәк. Урам тутырып, бер кочак кып-кызыл зәйтүннәр күтәреп узсын әле! Күргән һәр кеше сокланып калсын!

## Альберт Сафин

# КҮЗ КАРАШЫ

хикәя

Алик иртәнге кофедан соң өч бүлмәле фатирында үзенә шөгыль таба алмый арлы-бирле йөренде дә телевизор алдындагы кәнәфигә килеп утырды. Кызыл агачтан сырлап ясалган тәбәнәк өстәл өстендә сибелешеп ятучы газета-журналлар арасыннан программаны эзләп тапты, тиз генә күздән кичерде һәм кире өстәлгә ташлады: телевизордан документаль фильмнар күрсәтәләр — аны карыйсы килми иде. Ни эшләргә соң? Алик урыныннан кузгалмый гына сузылып стерео-уйнаткычны кабызып җибәрде һәм кәнәфи аркасына ята биреп күзләрен йомды.

Дәртле, кайнар ритмга төренгән илаһи моңсулыгы белән җанның һәр күзәнәген әсир итүче музыка авазлары уянды, күңелләрне тибрәндереп, татлы уйларга күмде.

Нинди гүзәл нәрсә бит бу тормыш, дип уйлады Алик, шатлык-куанычлар һәм ләззәт белән мөлдерәмә тулы ич ул, тәнеңне дә, җаныңны да сизмичә балык кебек йөз дә йөз шул ләззәттә, яшә, рәхәтлән — шәп бит. Күрсеннәр ничек яшәгәнеңне,— дип әйтә торган иде әтисе, күрсеннәр кем икәнеңне, көнләшсеннәр. Бу дөньяда яши белсәң генә көнләшәләр. Ә Алик яши белә ул һәм ничек кенә әле!

Электромузыканың серле авазлары агыла да агыла. «Спейс» ансамбленең яңа язмалары тупланган дискны Алик моннан берничә көн элек кенә кулына төшерде. Әшнәлек белән, билгеле. Өстәвенә шушы диск аркасында үзе өчен бик тә кирәкле кеше белән танышты. Фердинант атлы бу кеше шулай ук дисклар җыю белән мавыга һәм, иң әһәмиятлесе, туристлар бюросында эшләүче агасы аркылы теләсә нинди дефицит язмаларны таба ала. Шуңа күрә искиткеч файдалы танышу булды бу.

Аликның шактый бай коллекциясендә иң модалы ансамбльләр һәм җырчыларның тавышы язылган дисклар да, магнитофон тасмалары да аз түгел түгелен. Джаз дисеңме, битлзлар дисеңме, рок, поп-музыка, эйтик, кантри, ретро, диско стилендәге көйләр дисеңме — бар да бар. Ишләре арасында ул, гомумән, замана музыкасын иң әйбәт белүчеләрдән санала, коллекциясенең зурлыгы белән генә түгел, ә дефицит язмаларны таба белү белән дә тиңдәшсез авторитеты бар. Ничек таба ул аларны? — Монысы инде Аликның үзенә генә мәгълүм.

Дөресен генә әйткәндә, үзе җыйган җырларның һәм көйләрнең бөтенесен үк өнәп бетерми ул. Ләкин, нихәл итәсең, вакыттан артта калырга ярамый. Өендә иң соңгы сериядән төсле телевизор, япон магнитофоны, румын мебеле, супердисклар булмый торып замана кешесе дип уйлама да үзеңне. Суперджинсы киеп йөрмәсәң, рок-музыка яратмасаң ничек яшьтәшләрең белән аралашмак кирәк. Дусларың белән коктейль эчеп утырганда сүз җиленә өчен генә, мәсәлән: «Кичә «Роллинг стоунз»ның соңгы альбомын табу бәхетенә ирештем, ишетсәгез иде, уникаль язмалар», яисә, «Иглз» ансамбленең яңа супердискысы чыккан, оранжировка искиткеч», дип әйтеп куясың. Һәм алдан ук белеп торасың: дусларыңда синә карата хөрмәт һәм көнләшү уяна, алар, һичшиксез, әлеге язмаларны тыңлатуыңны үтенерләр, ә син үзеңнең өстенлегеңне тоеп ләззәт кичерәсең.

Алик теләр-теләмәс кенә үрелеп газеталар арасында яткан «Совет-

ское фото» журналын алды һәм аны кулында тоткан килеш яңадан уйга бирелде. Иң әүвәл ул үзенә ничек уңай булуын уйлап алды: зәвык белән җиһазландырылган фатирында йомшак кәнәфигә чумган хәлдә татлы көйгә төренәсең дә, ләззәтле ялкаулыкка бирелеп, башыңа килгән рәхәт уйларны кичереп утырасың — шәп бит. Аннары кичә китаплар кибетенә керүен һәм буш кул белән чыкмас өчен генә «Советское фото» журналының былтыргы саннарын сатып алуын исенә төшерде.

Бу журналның берәр саны күзенә чалынды исә, Алик ниндидер якты дулкынлану белән үсмер елларын сагынып куя иде. Чөнки яшьлегендә фото эше белән мавыгу сәбәпле ул әлеге журналны һәрдаим укып бара, анда басылган рәсемнәргә сокланып туя алмый иде. Кайчагында фоторәсемнәр аңа шул тикле нык тәэсир итә иде, ул бик озак йоклый алмыйча әлеге сурәтләрне күз алдына китереп ята, аннары утны кабыза да, күңелен дулкынландырган берәр фотога озак-озак карап тора, гүя аларда ниндидер сер һәм хикмәт яшеренгән диярсең. Мәктәптә фото эше буенча аңа тиңнәр юк иде. Бервакыт, унынчы класста укыганда, аның фотосурәтләре шәһәр күргәзмәсенә куелды. Алар төрле газета-журналларда күренә башлады. Ә «Күз карашы» дигән рәсеме шәһәр газетасы уздырган фотоконкурста беренче урынны алды.

Күз карашы... Рәсемдәге эңгер эченнән, билгесезлек һәм серлелек тойгысы уятып, беленер-беленмәс кенә булып ниндидер агачлар шәйләнә. Ә алгы планда исә зур кара күзләре белән туп-туры сиңа төбәлгән яшь һәм гүзәл кыз портреты. Аның саф һәм матур йөзе мөлаем елмаюдан балкый: эңгер эчендә торса да, кызның бите якты, ул ап-ачык булып күренә. Ә зур күзләре соклану, сөенеп гаҗәпләнү һәм олы рәхмәт хисе белән туп-туры сиңа төбәлгән. Бүтән һичкайчан кабатланмас һәм һичкемдә кабатланмас мизгел — күз карашы сине әллә нишләтә, синең дә күңел төбеңдә гаҗәпләнү, соклану һәм рәхмәт хисе ярала, синең иреннәреңә дә елмаю килеп куна...

Күз карашы.

Юләр һәм кызык чаклар... Алик кайчандыр үзенең күңелен, бөтен рухын ашкындырып торган илһамлы хисләрен хәтерләргә теләде, тик булдыра алмады. Ә шулай да ярыйсы гына ясый идем бугай мин фотоларны. Гаҗәп. Ышанасы да килми хәтта.

Теләгән хатирәләр урынына ул этисенең бервакыт төрекмән келәме алып кайтканын исенә төшерде. Мәмрәп пешкән кура җиләге төсендәге келәмне идәнгә җәеп салды да этисе, өстендә биергә кереште. Аннары, искиткеч зур эш майтарган кешедәй, тантана белән мактанып алды: «Күрсеннәр ничек яшәгәнеңне. Күрсеннәр, көнләшсеннәр!»— дип кычкырды ул кемгәдер янап.

Алик иренеп кенә журналны актара башлады. Аны изрәткән татлы ялкаулык юкка чыккан иде инде, күңел төбендә ниндидер ризасызлык күтәрелеп килә иде. Кинәт...

Кинәт ул сискәнеп куйды: журнал битеннән аңа гаҗәп үткен һәм искиткеч таныш күз карашы текәлде. Бу караш шулхәтле тере һәм шундый хәрәкәтчән иде ки, Аликка хәтта куркыныч булып китте. Ул ирексездән, кулын пешерә диярсең, журналны өстәлгә ташлады һәм кискен хәрәкәт белән урыныннан сикереп торды. Аннары нигәдер журналны яңадан кулына алды, яңадан фоторәсемгә карады. Олы яшьләрдәге ир кешенең эре планда төшерелгән фотопортреты иде бу. Карадан киенгән ябык-какча йөзле карт беренче карашка гомерен тауларда үткәргән көтүчене хәтерләтә. Әмма нечкә иреннәренең сизелер-сизелмәс кенә итеп киная белән елмаюы, йомшак җыерчыклар сызылган ак йөзе, гаҗәп зирәк һәм тирән, шул ук вакытта сынаулы күз карашы аны акыл иясенә охшаталар иде. Сурәт астына «Күз карашы. Р. Әхмәтов фотосы», дип бары ике җөмлә язылган. Алик, тылсымланган кешедәй, әлеге

кара күз карашыннан аерыла алмады. Бу караш, әйтерсең лә, аны күренмәс нурлар белән урап алды һәм үзенә буйсындырды. Күңеленә үтеп керде, йөрәген айкап ташлады, ялкыны белән анда гаҗәпләнү, шөбһәләнү һәм курку уятты. Әйе, әлеге күз карашы аңа бик тә таныш иде. Сурәттәге кешенең күзләре генә түгел, йөз сызыклары да, киная катыш түбәнсетү белән елмаюы да, хәтта киеме дә таныш иде. Шунысы гаҗәп, Алик аны шунда ук исенә төшерде, әйтерсең лә, кайчандыр бары бер генә күреп калган ят, билгесез һәм сәер кешенең сурәте күңеленең бер почмагында посып торган. Ул беркая да китмәгән, югалмаган, ул үзенең үткен һәм каты күзләре белән һәрвакыт аңа карап торган, аны сынаган. Һәрвакыт...

...Бүгенгедәй хәтерендә: Алик аның барга килеп керүен күз кырые белән генә күреп алды, әмма игътибар бирмәде, җиңел һәм йомшак хәрәкәтләр белән коктейль ясавын белде. Шулай да күңелендә әллә нидән бу кешегә карата ачу катыш ризасызлык уянды: була ич шулай: кайберәүләр үзенең килеш-килбәте, йөзе белән генә дә сине читкә тибәрә, борчый башлый. Ә яңа кергән кунак өстенә озын буйлы иске кара плащ кигән, муенына соры шарф ураган, башында таушалып беткән киң кырлы кара эшләпә, аягында озын кунычлы резина итекләр — киеме белән ул гади авыл агаена охшаса да, бу тойгыны йөзенең аклыгы һәм тирән утырган күзләренең акыллы карашы шунда ук юкка чыгарды, гомумән, аның бөтен кыяфәтендә ниндидер сәерлек сизелеп тора иде. Ул кергәч тә, икеләнеп, ишек төбендә туктап калды, бар эчен күзләп чыкты һәм стойка артына килеп утырды. Алик аның ягына карамаска тырышты, шулай да бу кешенең үзенә текәлүен һәм, һәр хәрәкәтен өйрәнергә, отып калырга теләгәндәй, дикъкать белән күзәтүен сизде. Бармен — һәрвакыт кунаклар күз алдында. Алик моңа күптән күнекте. Хәтта, дөресен генә әйткәндә, үзенә карап торуларын ярата да иде ул. Чөнки белеп тора: берәүләр аның затлы костюмына соклана, икенче берәүләр прическасына игътибар итә, өченчеләре исә үз-үзен тотышында, елмаюында мөлаем кунакчыллык билгесе күрә — берсе дә аңа битараф калмый. Күз карашлары астында Алик үзен һәрвакыт гаҗәп иркен хис итә. Чөнки иң соңгы мода белән тегелгән киеме дә, кулындагы алтын браслетлы Швейцария сәгате дә, каштан төсендәге дулкын-дулкын чәчләре дә, артистларныкыдай матур йөзе дә сокланыр өчен яратылган. Аның борчылу белмәс бәхетле тормышы да күз карашлары өчен. Шуңа күрә бит ул уйнагандай итеп яши, шаяра, ләззәтләнә; үзен күзәткән дистә, йөз һәм мең кешегә яшәп күрсәтә. Шуңа күрә дә һичкем алдында кызармый, кыенсыну, оялу, югалып калу, яисә вөҗдан газабыише китап хисләрен кичерми... «Ничек кеше күзенә күренәсең инде», дигән тойгыны да белми. Чөнки күз карашлары алдында аның бер ким җире, бер гаебе юк. Ләкин менә шушы иске киемле, уйчан йөзле билгесез бер кешенең (Алик аны бар эчендә беренче тапкыр күрә иде) үткен һәм каты күз карашы аны ни өчендер борчый, тынычсызлый башлады. Ул бер күз карашы астында үзен, ятьмәгә эләккән балыктай, искиткеч уңайсыз һәм кыен хис итә иде. Һаман да әлеге сәер агайга илтифат итмәскә тырышып, Алик галстук таккан егет алдына коктейль китереп куйды; тегесе «сдача кирәкми» дип бишлек сузгач, йөзенә үзеннән-үзе ялагай елмаю бәреп чыкты һәм ул, шушы елмаюдан котылырга теләгәндәй, сатучыларга гына хас елгырлык белән акчаны җәһәт кенә тартмага ташлады. (Ә теге кешенең кара күзләре бу елмаюны барыбер күреп алды.) Иртәнге сәгать булуга карамастан шактый ук кәефләнеп алган ир уртасы кешегә акча кайтарып биргәндә егерме тиенне үзендә калдырды, өстәвенә аңа дигән коктейльга сокны күбрәк өстәде. (Кара күзләр моны да сизде, бугай.) Үзенең танышына кәгазьгә төреп яшертен генә бер шешә болгар шәрабе бирде. (Әлеге кеше

моны да күреп торды.) Алик тәмам чыгырдан чыкты. Сәер кунак үзен чакырып алыр дип көткән иде ул, әмма тегесе һаман сүзсез карап утыра бирде. Бармен түзмәде, мөмкин кадәр салкын канлы булырга тырышып, янына килде, өстенлеген күрсәтергә теләп, кимсетүле карашын плащына төбәде һәм мөлаем тавыш белән «Тыңлыйм сезне», диде. Бик теләсә дә, ул күзләрен күтәрмәде, чөнки әлеге кешенең карашы белән очрашудан курыкты.

— Аракы салып бирегез әле. Туңдым,— диде агай йончыган тавыш белән.

— Бездә аракы сатылмый,— диде Алик һәм борылып икенче бер кеше янына китеп барды.

Сәер кунак бераз утыргач, барменны үзе чакырып китерде.

— Алайса берәр төрле шәрәп китерегез.

— Бездә шәрәп тә аерым гына сатылмый.— Алик, үзенең хуҗа икәнлеген сиздерергә теләп, янә борылып китте, ашыкмыйча гына атлап, прилавканың икенче башында яткан менюны барып алды һәм, дәрәҗә саклап, аны әлеге кешенең алдына китереп ташлады. «Йолкыш, авыл гидае,— дип уйлады ул.— Нинди мәхлүк кешеләр бар бу дөньяда. Җитмәсә барга килеп керә бит әле».

Агай менюга кагылып та карамады, күзләре белән бораулагандай, һаман шулай барменга карап торды. Аннары яңадан эндәште.

Алик аның чакыруын ишетмәмешкә салышты, берни булмагандай, менюны килеп алды һәм, яңа гына күргәндәй, тегеңә борылды. Ул кешенең нечкә иреннәрендә мыскыллы елмаю туып килә иде.

— Монда өс киеме белән утырмыйлар,— диде Алик.— Һәм, гомумән, эш киеме белән кергәннәрне кабул итмибез без.

Әлеге кеше барменны бүтән чакырмады, аңа текәлгән килеш сүзсез генә утырды, утырды да кинәт чыгып китте.

Алик аны чишенеп яңадан керер дип уйлаган иде, тик ул бүтән күренмәде. Шулай булса да бармен сагаюлы уйдан көне буена арына алмады. Ишек ачылган саен ниндидер шөкатьсез борчылу белән шул якка борылып карады — ул аны көтте.

Бу кеше барга бүтән беркайчан да кермәде. Алик аны күптән оныткан иде инде. Тик хәзер һич көтмәгәндә фотосын күргәч кенә...

Хәер, ни эшләп фото аныкы булсын ди әле? Бөтенләй икенче кеше сурәте бит монда. Әйе, әйе. Күзләре генә охшаган ич аларның. Күз карашлары гына. Алай дисәң, ник мыскыллы елмая соң бу портрет? Аликтан көлә түгелме соң ул?..

Алик ярсуга бирелеп журналның фоторәсем төшерелгән битен умырып алды да йомарлап идәнгә ташлады. Тик нигәдер шунда ук бөгәрләнгән кәгазьне кире алып җәеп җибәрде, куллары белән тигезләде һәм ихтыярсыздан аңа текәлде. Ул үзенең әлеге күз карашына тартылуын тойды. Аны моңарчы һичкайчан кичермәгән ачу, шомлану һәм үч алу теләге биләп алды. Шушы рәсемне, андагы күз карашын һәм үзендәге курку хисен юкка чыгарасы, мәңгегә-мәңгегә алардан арынасы, әүвәлгечә, хәтта үз җанын да тоймый җиңел итеп яшисе килә иде аның. Алик ашыга-ашыга кәгазь битен вак-вак кисәкләргә ертты, ул кисәкләрне идәнгә сипте. Тик күңеле тынычланмады. Аның хәзер үз-үзенә ачуы килә башлады. Кем инде, ниндидер ир затының рәсемен күреп, мәгънәсез рәвештә шөбһәгә бирелә ди шулай? Җитмәсә, рәсемнән үч ала. Юләрлек дими ни диясең инде моны. Ул мәмрәп пешкән кура җиләге төсендәге келәм өстендә чәчелешеп яткан кәгазь бөртекләренә карады һәм шул мизгелдә бөтен гәүдәсе буйлап эсселе-суыклы ялкын йөгереп узды: күпчелек кәгазь кисәкләренең рәсемле ягы түгел, ә чиста ягы өстә калган һәм шушы ап-ак кисәкләр арасыннан туп-туры итеп, бораулап аңа күз карашы текәлгән иде. Кәгазь ертыгындагы күз

Аликны мыскыл итә, аңардан көлә, әнә ул күздә әллә нинди салкын чаткы ялтырап китте, әнә ул күз кысыла төште һәм аңардан каһкаһәле елмаю сирпелде: «Мәхлук, котыла алмассың миннән, беркайчан да котыла алмассың!» — ди иде бу күз карашы. Кинәт Аликка бүлмәдә ул берүзе түгел, ә тагын кемдер бар сыман тоела башлады. Ниндидер билгесез кеше стенка артына яшеренгән һәм аны күзәтә, хәзер ул килеп чыгар да... Алик үзе дә сизмичә, кабаланып, телевизорны кабызып җибәрде, бөтен көченә тавышын ачты һәм, бүлмәне тутырган экскаватор гөрелтесеннән качарга теләгәндәй, ишеккә ташланды.

Урамның салкынча һавасы аны сәер һәм шомлы халәттән айнытып җибәрде. Ни эшләргә дә белми аптырап, ул эскәмиягә килеп утырды һәм, гадәтенчә, кесәләрен актарып, сигарет эзли башлады — кесәләр буш иде. Экскаватор гөрелтесе белән күз карашы калган фатирына кире менеп тәмәке алып чыгарга дигән уйдан күңеленә яңадан курку салынды. Ул кемнән булса да тартырга алу нияте белән як-ягына каранды һәм, тротуар буйлап баручы урта яшьләрдәге ир кешене күреп, урыныннан торды. Әлеге кеше Алик турысына җиткәч, кинәт аңа күз ташлады. Берни белгертмәгән битараф һәм йөгерек бер караш иде бу. Ләкин Алик аңарда үзенә карата яшеренгән ачу һәм түбәнсетү билгеләрен күреп алды. Ул, тәмәке сорарга теләгәнен дә онытып, югалып калды. Урамның икенче ягыннан атлаучы егет белән кыз, шулай ук, нигәдер сәерсенеп, аның ягына карап уздылар. Ком сибелгән мәйданчыкта шаулаша-шаулаша уйнаган балалар да кинәт тынып аңа текәлделәр. Алик кинәт үзе өчен шаккаткыч ачыш ясады: һәр кешенең күзләре бар икән ич, аны һәрчак күреп торалар икән ич. Һәм ул бу күз карашларыннан берни белән дә яшеренә алмаячак бүтән. Күпме күз карашы аңа төбәлгән. Ул гомере буе шушы күз карашлары өчен яшәде, ә бүген менә табынган алиһәсе аның үзен мыскыл итә. Күз карашы... гаҗәп күп ич алар бу дөньяда. Кара, яшел, зәңгәр, коңгырт, күксел, зур, түгәрәк, кечкенә, хәйләкәр, ачулы, мыскыллы, назлы сынаулы, назлы, вәкарь, акыллы, мәгънәсез, нарасый күз карашы аны бөтен яктан чолгап алган. Алар нидер белергә тели. Алар аны һәр яктан капшый, аның күңелен актара, йөрәгенә сузыла. Бу күз карашлары нидер эзли аңардан. Качарга кирәк алардан. Качарга! Дачага китеп барырга кирәк, урманга. Тынычланырга, онытылырга кирәк бүген. Дачадагы холодильнигында бер шешә виски һәм бер шешә «Мартини» бар. Ул телефоннан Неллины чакырыр. Алар су коенырлар, виски эчәрләр, музыка тыңларлар. Неллиның кочагында ул бар дөньяны күмеп киткән күз карашларын, бүгенге көнне, бүгенге куркуны онытыр...

Ә Неллиның күзләре мәченеке шикелле төссез, яшел икән бит ләбаса. Елмайганда, көлгәндә бу күзләр шундый матурлар, шундый назлылар, магнит сыман һәрвакыт үзләренә тартып тора. Әмма ул күзләрнең шундый вакыты була: аларның карашы белән очрашсаң, ирексездән күңел сискәнеп куя. Аларның төбендә ялтыраучы салкын нәфрәт очкыннарын ничә тапкыр күргәне бар бит Аликның. Игътибар итмәскә генә тырышты ул моңа. Шундый чибәр кызга каян килә ул шул тиклем нәфрәт?

— Ни эшләргә Неллины чакырсаң, аның күз карашы белән очрашасы була. Үзенә дәшеп торучы назлы, матур, әмма шул ук вакытта салкын нәфрәт тулы күз карашы белән.

Һәм Алик көтелмәгән уйдан калтыранып куйды: бүгеннән башлап бөтен күз карашлары алдында да гаепле һәм кыен сизәр ул үзен, бүгеннән башлап кеше күзенә күренергә оялып йөрер. Аңлаешсыз шикшөбһәдән һәм куркудан качып котыласы килер...

Фикерләү сәләтен җуйгандай, һичкемгә игътибар итми шәһәр урамы буйлап йөргән кешегә килеп юлыксагыз, текәлеп карамагыз аңа.

БАТЫРЛЫК ДӘВАМ ИТӘ

## Рөстәм Кутуй

# ЯВА КАРЛАР

хикәя



Бик тә озынга, иксез-чиксез озынга сузылды бу кыш. Очы-кырые күренми. Ярый әле кар явып үтте... Югыйсә җирнең өсте тиресе туналган җәнлек кебек иде, әллә нинди каты төерләр белән капланган. Шәрә килеш туңдырды, шакырайтты. Агачлар җылынырга теләгәндәй ботаклары белән шакылдап утыралар иде.

Шул чакта, рәхмәт төшкересе, бар дөньяга беренче карның хуш исе тулды. «Ак аюның» пәйда булуын күреп, тирә-як үзалдына пышылдый башлады.

Кар ява да ява. Кар бөртекләре җиргә төшәргә ашыкмыйча һавада бөтереләләр, арлы-бирле очалар.

Күңелгә шундый уй килә: шәм утына һәм тыныч кышның җанлы кар бөртекләренә карап утыру миңа ошый икән ләбаса. Шәм ул мәңгелек илчесе, кар бөртекләре исә тормышны яктыртып алучы мизгел юлдашлары.

Тәмам яктырып бетәр алдыннан кышкы көн карангылыкны капшап йөри. Кышкы көнне тиз генә уятырмын димә. Әйтерсең, вакыт яктылыкны тагын куып җитә. Шулай соң гына яктыра, иртә караңгы төшә

Минем әнием бөтенләй олыгайган инде. Әниемнең баскыч култыксасына тотына-тотына бишенче каттан төшеп килүен йортлар, тыкрыклар аша күрәм. Аннары ул подъезд төбендә тирә-ягын көрт баскан эскәмиягә чыгып утыра. Тирә-юньдәге бар нәрсәләр ашыкмый-кабаланмый гына күченеп йөриләр кебек, күз алдында дөнья иркенәеп китә. Кар яву җанны жиңеләйтеп җибәрә.

Агачлар артында, шау-гөр килеп торган тау артында күренеп-күренеп киткәләгән әйберләр арасыннан әниемнең күзләре нәрсәнедер шәйлиләр кебек...

Ишле гаилә өстәл янына тезелешеп утырган, өй эче чыңлап тора. Чәчәкләр чигелгән ашъяулык өстендә куллар хәрәкәтләнә. Утлы күмер кисәкләре ата-ата мич яна. Гомер үтүен искәртергә теләмичә генә маятнигын атындыра-атындыра сәгать йөри. Ә тәрәзәнең теге ягында кар ява да ява. Пыялалар яп-якты. Өй эченә кызган үтүк исе таралган. Бөтен җирдә пөхтәлек. Фикус гөленең кара яшел яфракларын-

да кар тавының җемелдәвс чагыла. Подноска нәни генә күмерләр һәм сулыш кебек җиңел көл коя-коя ялтыр йөзле самовар шаулый.

Гаилә бөтен — ике кыз һәм бер малай, сау-сәламәтләр, әнә, терсәкка терсәк утыралар. Җылы, өстәл өсте дә буш түгел.

Диваннан өстә стенада сугышка хәтле төшкән фоторәсем — ул чакта без бишәү идек.

Болай караганда бернәрсә дә үзгәрмәгән сыман — шул ук самовар, чәчәкләре уңган шул ук ашъяулык, шикәр тутырылган зәңгәрсу ваза, әчендә мамык түшәлгән катлы тәрәзә... Әмма хәзер дүртәү генә шул...

Нигә соң шушы хатирә әледән-әле искә төшә икән? Әнием миңа моны үзе сөйләгән иде: шул ап-ак карлы кышта әни әтинең кайтуына өметен өзә. Аның үлеменә ул инде тәмам ышана һәм караңгылыгын юып алынган якты тәрәзәләр каршында басып торганда үзен тол итеп тоя... Караңгыдан торып Чехов базарына барып кайта, барлы-юклы акчасына тигәннең һәммәсен дә сатып ала. Әтинең якты истәлегенә шундый табын әзерләргә уйлаганмы, әллә балаларына бәйрәм оештырырга теләгәнме — мөгаен, икесе дә булгандыр.

Кар аның башына, иңбашларына ява, кар бөртекләре иркәләп кенә мамык шәлен бизи һәм шул чакта мескен тол хатынның тамагына кайгыдан каты төер утыра. Балаларым бар бит әле дип, үз-үзен азмыкүпме юата ул.

Кар-бураннар уйнатып янәшәсеннән чыңлый-чыңлый трамвай узып китә. «Монда икәү бергә йөргән идек»,— дип уйлый ул. Капка астыннан эт өрә. Аз гына яктыра башлый.

Өйгә кайтып җиткәндә бөтенләй яктырып беткән була.

Битләре кызарган әни ишек катына басып, өстендәге карларын каккалап төшерә. Мамык шәлен битенә каплап елап та ала.

Аннары кухняга керә, балаларының йоклауларын тыңлап утыргannan соң, якшәмбе көн икәнлеген уйлап бераз тынычлана.

Күңеленә тагын моңсуланырга ирек бирмәс өчен кинәт кенә кузгала да, өйне җылыту нияте белән, кухнядагы кечкенә мичне ягып җибәрә. Дөге белән ит юып куя. Кара җимешләрне чистарта. Суган, кишер турый.

Шул чакта күршедә яшәүче ябык Газизә керә, иснәнеп тора.

— Пыла-ау!

— Сыйларга уйлыйм әле,— диде әни.— Эремчек белән каймак та сатып алдым әле. Син утыр, утыр. Бездә бүген тәмле исләр чыкты...

— Ай, нинди кеше иде! — дип, авыр сулый Газизә. Аның шулай йөрәкне авырттырып әйтеп куя торган гадәте бар.— Син яшьләй калдың. Өч бала белән... Нишлисең инде, тол килеш тә яшәрсең әле. Түзәрсең.

— Тол хатынның бусагасы да алтын була диләр. Минеке — боз.

— Нихәл итәсең инде,— ди Газизә тагын.

— Утын бар, җылыда яшәрбез.

— Җылынырга калды инде...

Алар бер-берләрен бүлдермиләр, йон эрләгән кебек ярымпышылдап кына сөйләшәләр. Сулыш алуларыннан да билгеле — җанландылар.

Мин әниемнең сулыш алуын, аның сүзләрен тыңлап ятам. Торырга иртә әле — тау шуарга, йөгерергә-уйнарга өлгерермен.

Кинәт кенә куллары белән авызларын каплап көләргә тотыналар. Аларның йөзләрен күз алдына китерүе кыен. Чәй кашыгы чыңлаталар. Каймак белән чәй эчүдән дә тәмле нәрсә юк шул.

Тәрәзәдән төшкән балкыш аларның йөзен яктырта. Мичтә ялкын бии.

Алар тиздән чынаякларны җыештырып куйдылар, саубуллашты-

лар. Газизә папирос кабызды һәм тәмле төтен исе ишек ярыгыннан бүлмәгә саркып керде.

Менә без дә кар ялкыны кочагында калган пөхтә өйнең өстәле янында тезелешеп утырабыз. Бу чынлап та ялкын, әнә ич тәрәзә төбендә көрт өеме дә күренә. Шаян җил бөтерә-бөтерә тәрәзәгә кар сибәли, түбәдән дә кар коела, көрттән кар фонтаны күтәрелә. Шулкадәр якты ки, күрше йорт артыннан әлеге зәңгәр упкын өстенә менә-менә кояш күтәрелеп чыгар да бөтен көченә яндырырга тотыныр, һәм шулвакыт кар кинәт кенә кабынып китәр, ниһаять, бәйләнчек җәяүле бураннан котылыр.

Ачылып киткән ишек ягына карап дүртебез дә катып калабыз. Дүртебез дә берьюлы бер үк нәрсә турында уйлыйбыз — кинәт әтиебез пәйда булса!.. Ләкин бу яңа көннең яңа өмете генә, тормышыбызның бетмәс-төкәнмәс теләге, күңелне матур ялган белән юатып алу.

Карның аклыгы әниемә больницаның чиста, тирән маза бүлмәсен хәтерләткәндер. Анда исә һаман да яшәү сәләтен югалтмаган ялкынлы яшь гомер үлем белән көрәшә, янында ак халат кигән әни йөри...

Әни эскәмиядә, һавада җилпенгән кар бөртекләре астында озак уйланып утырды.

Бер-бер артлы кызларын кияүгә бирде ул. Идел аръягына, Уралга озатты. Хәзер инде эш ярата торган ярдәмчел улы белән генә калды.

Шатлык арттымы яки кимедеме, каян белергә, ничек төшенергә бизмәннең кайсы ягы аска тарта, нәрсә йөрәкне авырайта, җимерә, ә кайсысы мамык кебек кенә кагыла да җирдән өскә күтәрә? Гомернең ашыгуы кая яшеренгән — басу ашалыгындамы, әллә кырның урманга таба бөкрәеп килгән урынындамы?

Стенадагы фоторәсем исә картаюны һич тә белми.

Иске йортны ташлап киткәндә аңа ут төрттеләр. Бары тик җиңелчә әйберләрне генә үзебез белән алган идек, инде үз вазифасын үтәгән әйберләрне юк кына бәягә сатып җибәрдек — балкып торган заманча фатирга авыр, тузган комодны, чайкалып торган этажерканы, никельләре куба башлаган тимер караватны алып бармассың бит инде... Акшарына битне куеп мич белән дә саубуллаштык. Ашык-пошык ишекне яптык: әй, дөньялык, үзгәреп торуың никадәр яхшы синең.

Үзгәрешләр яшьлекне кире кайтарырга вәгъдә итә сыман, әмма ян гыннан соңгы харәбәдән ачы төтен исе килә.

Кая ул яшь чакта, кызган чакта ташландык ояны йөрәккә якын алып торырга...

Шуннан китте, китте, барысы да чәрдәкләнде...

Теге кышкы аяз көндәге кебек дүртәү өстәл янында утыру кабат насыйп булмады инде.

Кайгылар ишәйде, юллар урауга әйләнде.

Ә әни улы белән китте, улы кайда — әни шунда. Кызлар белән хат аша хәбәрләшә.

Кая да сыеша алмаган горур хатынны каксалар, суксалар, шайтанны яки ятим баланы куган кебек кыерсытсалар, нишләргә? Бәлки ул горур кешедә талчыккан йөрәген саклау хисе, татлы хыяллар, җимерелгән ояны саклау теләге яшеренгән булса? Аңламаган килеш кычкыралар, пычрак аяклары белән таптыйлар ич.

Шәфкатьлелек шәме, кайда синең кыюсыз һәм учка йомылган яктылыгың?

Киленнәр имән урманындагы каен кебек, яки алар җилгә охшаш, яисә кояшка — аларга күбрәк яктылык, һава, иркенлек бир, тау башыннан җил исүе дә әйбәтрәк күренә, һәр шылт иткән авазны ачык

ишетергә була. Түбәнлектә караңгы, юеш, елга буендагы янган нарат-ка, кайчандыр яфраклары шаулап торган корыган ботакка яшь, көн-чел күңел белән кем генә орынырга теләр икән. Әйтерсең, ул гына бу җиргә мәңгелеккә килгән...

Юк, килешә алмады карт ана киленнәре белән — беренчесе белән дә, икенчесе белән дә... Оныкларны да алар үз кочакларына суырып ал-дылар. Кайчакта янәшәдән генә чаналарда үтеп китәләр — ул да озак-ка түгел. Кулың белән кагылырга өлгермисең — саубуллаш! Күңелең булгандыр, житте, янәсе.

Ә улы? Нишлисең бит, күңелендә нәрсә барын белгәнче улы ялан-баш килеш тормышта арлы-бирле чапты, сукыр килеш бәрелде-сугыл-ды, яраланды, очраган кешеләрне нәрсә белән гаҗәпләндерергә, шат-ландырырга белмәде. Ул — ул инде, аны кичерергә дә була. Аның ир-ләргә генә тиеш үз ихтыяҗлары, үз борчулары... Тик менә ул үз-үзен гафу итәрме? Ә кызлар хат аша хәбәрләшәләр.

Иренең кабере генә чит җирләрдә вәйран булып ята.

Хәзер улы да аннан өлкәнрәк инде.

Кар ява да ява.

Карт ана өй тирәли әйләнеп чыкты, кире эскәмиягә килде, җылын-ган урынны кар каплаган иде инде.

Бишенче катка күтәрелү — күз алдына да китерү кыен.

Кайчандыр җиргә якынрак фатирга күчәргә ризалашкан иде — со-ңыннан үзе үк үеннан кире кайтты. Нәрсәдән курыккандыр? Күрәсең, картлык баса. Беркем дә аны хупламады, үгетләмәде, аңа уралган пә-рәвезне алып ташламады. Дөньяда үзе кебек үк япа-ялгыз калган һәм аңа әледән-әле саташулы төшләрен сөйләүче ахирәтен тыңлаган булыр иде бәлки... Горур булып бишенче катта, нәкъ түбә астында яшәгән килеш калды...

Хәзер, әнә, кая барырга инде дип, баскыч култыксасына таянып тора. Теге вакыттагы кебек өстенә кунган кар бөртекләрен дә кагып төшерми...

Кар ява да ява...

«Минем әни карт инде... Бөтенләй картайган...» — дип пышылдыйм мин бозлы тәрәзәгә. Дөньяда моннан да ачы хәсрәт җыйнаган башка сүз юктыр.

Гаепләмәскә дә, гафу да үтенмәскә, күз карашларыннан оялып битне учың белән капламаска да. Озын-озын кышның күктән савылган кары белән бер ул, күзләреңне йомсаң да барыбер явачак, явачак һәм күз кабакларын туңдырачак.

Хәйдәр ГАЙНЕТДИНОВ тәрҗемәсе

## Рәфикъ Юнысов

# ҖИРДӘ ЯШИМ!

❀

Җирем минем, зәңгәр йолдызым!
Миңа кадәр булып үткәннәр
Яңа гөлләр, яңа күлләрме —
Ни дә булса бүләк иткәннәр,
Синең якты, уйчан йөзеңә
Яңа нурлар өстәп киткәннәр.

Ә мин, бәлки, синең йөз суың,
Куанычың була алмадым? —
Синнән бары соклану тулы
Күзләремне ала алмадым.

Хәтәр мизгелендә берәүләр
Яшен итеп атты үзләрен!
Ә мин андый була алмадым —
Томан сарды бары күзләрем...

Рәсем бүләк иткән сабый күк
Җырлар язам менә көнозын.
Алар бар да синең турыда,
Җирем минем, зәңгәр йолдызым!

## Ялвару

Тимә, зинһар, кешегә!
Кеше бит ул! Җанлы моң!
Җир миллиард ел эзләгән
Аның һәрбер чалымын!

Кояш тулы чишмәдә
Битен-кулын юган ул.
Кызган, зинһар, кагылма:
Яшәргә дип туган ул!

Кеше бит ул йокыдан
Өмет белән уяна.
Үлән үссен, җил иссен —
Ул шуңа да куана.

Кайнар бите — бүтән бит
Җылысын тояр өчен.
Бу колаклар — иң назлы
Сүзләрне җыяр өчен.

Йолдыз кебек бу күзләр —
Матурлык эзләр өчен.
Кеше бит ул. Бу куллар —
Дөньяны бизәр өчен.

Кеше бит ул! Ерткыч та
Зурлап читкә тайпыла.
Ничек бер син күрмисең —
Йөзеннән нур агыла!

Калкансыз яши кеше,
Ак күлмәк киеп кенә.
Тәнендә тормыш уты —
Шәм уты кебек кенә.

Аны таптап сүндерү
Берни тормый көчлегә.
Аһ, зинһар, кагылма!
Кеше, тимә кешегә!

## Барабыз

Мин сүз язып өлгергәнче
Күпме ара үтәсең!
Кая ашыгасың, Җирем,
Безне кая илтәсең?

Беләм, беләм, җиңел түгел
Кояшыңа өлгерү!
Парсеклар белән үлчәнә
Синең-безнең юл йөрү.

Яктырткыч снаряд кебек,
Утлы сызык сыздырып,
Киек Казлар Юлы буйлап
Оча Кояш ыжгырып.

Бөтерелеп кереп бара
Билгесезлек күзенә
Коточарлык тизлек белән
Галактика үзе дә.

Кайтулар юк — кайтыр юлны
Белмәдең ни, белдең ни!
Борылу юк — алда нәрсә —
Күрмәдең ни, күрдең ни!

Кара упкын, салкын упкын —
Ниләр генә юк анда!..
Ә без курыкмыйбыз, Җирем,
Синең белән булганда!

## Галактикадашларга

Беләм, сез дә, безне уйлап,
Хәзер күккә карыйсыз.
Аксыл, кызыл, сары, зәңгәр
Җем-җемнәрнең кайсы — сез?

Галактика — көмеш табак —
Зәңгәр моң белән тулган.
Әйтерсең лә һәр йолдызы
Яңгыр белән юылган —

Шундый чиста! Матур бит ул
Безнең олы өебез!
Сез ничектер, ә без аны
Киек Каз Юлы дибез.

Бу — безнең дә хыял юлы!
(Әлегә бик аз йөрдек).
Тормыш нәрсә? Яки — очыш,
Яки — аңа әзерлек.

Булсын гына очрашулар —
Сөйләр сүзләр табылыр!
Абсолют ноль суыгында
Уртак утлар кабыныр.

Авылдашлар кебек бит без
Чиксез Галәм каршында!
Ә мин үзем Җирдә яшим —
Кояш системасында!

## Гипотеза

*Пасха утравында таш сыннар бар. Алар һәммәсе дә күккә карап тора.*

Сөйли мифлар: бу сыннарны
Куйган күктән килгәннәр.
Ник куйганнар — белми беркем.
Исән түгел белгәннәр.

Бер мин беләм. Минем өчен
Салкын түгел салкын таш.
Йөрәгемдә янган утлар
Шушы сергә аваздаш...

Бу күзләрдә сагыш яши.
Түгел ләкин без белгән.
...Чит дөньяга килгән алар —
Кайтыр юллар киселгән.

Калган алар — ятим түгел,
Илсез түгел — дөньясыз!
Бу хис сезгә таныш түгел —
Аңламассыз моны сез.

Ят томаннар кагылудан
Бәгырьләре өшегән.
Тау-тау сагыш булып җанга
Ят дулкыннар ишелгән...

Яшәгәннәр төнне котеп.
Төн Галәмне ачканда,
Карашларын күккә төбәп,
Яр буена басканнар.

Чиксезлекнең иң ягымлы,
Иң сөйкемле ягыннан
Зәңгәр нокта булып кына
Зәңгәр йолдыз кабынган.

Янган йолдыз! Һәрбер нурын
Җыеп барган күзләре.
Йолдыз булып калтыраган
Кара төндә күз яше...

Шулай озак яшәгәннәр.
Елмаюсыз. Көлүсез.
Көч-кодрәтле булсалар да
Булмаганнар үлемсез.

Сүнсен алар бу җептән дә
Аерылган килешме?
Тиңсез сагыну шулай эзсез
Югалырга тиешме?..

Шул ук караш... Җиргә иңеп
Еллар йөге астында,
Тора ташлар тугрылык
Һәм сагыну постында!

Эчтән сызып елый ташлар.
Булмый, булмый юатып!
...Җирем, мин дә изаланам
Төштә сине югалтып!

## Төш

Космик сәяхәтем тәмам итеп,
Инде Җиргә кайтып барганда,
Мин адаштым кинәт.
Ракетамда — көмеш арбамда
Элеккечә иде бар да.
Тик...
Яңабаштан ничек җыясы?
Җирне, бары Җирне югалттым мин —
Чәчелде дә китте дөньясы!
Матурлыктан һушсыз идем лә мин —
Кичәгедән бүген ни калды?
Бер тузанын бары җуйган идем —
Бөтен Галәм сүнеп югалды!
Бу йолдызлар нәрсә? Черек уты...
Янда Җирем балкып тормагач.
Бу чиксезлек — төрмә камерасы,
Тузан кадәр Җирем булмагач!..
Кораб эчем — нәни җәннәт. Юлда
Олылары тагын табылыр...
Башта — җаным, аннан — тәнем, аннан—
Сөякләрем Җирне сагыныр...
Космос кебек салкын күзләремә
Бер зәңгәр нур кинәт чалынды.
Төзекләнде Җиһан! Галәм тиңсез
Фейерверк булып кабынды!
Егерме ел минә сискәнәм мин,
Хәтерлим дә шушы төшемне...
Бөтен аермасын тойдым шунда
Яшәү белән
Җирдә яшәүнең!

# Асия Минһаҗева

## Туфанны көткәндә

*Университетның тарих-филология факультетындагы очрашу истәлеге*

**1**

Фойе...
Әрле-бирле чайкала яшьлек диңгезе.
Кайный-бәрелә ярга...
Ашыгалар бар да,
Вакытлары тарга.

Дипломатны өстәл итеп,
Бармаклары белән сызып,
Фидель улы белән Гете оныгы
Бәхәсләшә кызып.

Грузиянең кояш йөзле кызы,
Толымнарын үреп-сүтеп,
Кемне тора көтеп?

Сайлап җыйгандай төркемдә —
Башкорт, казакъ, кореяның сылу йөзе.
Үзбәк, таҗик, төрекмәннең энҗе күзе.
Әрмән белән молдаванның кайнар каны
Һәм кыргызның Манас булган үлмәс даны.

Бар да кайный, дулкынлана
Нидер көтеп.
Сизмәделәр... Яннарыннан
Тарих бара иде үтеп.

Әйе, әйе,
Әле менә, әле генә
Чал башын ия-ия,
Карашы белән барысын да сөя-сөя,
Хисе белән барысын да иркәләп,
Картлыгына чак-чак кына үпкәләп,
Тарих бара иде китеп...

2

Ул тарихның гасырлары
Лорка белән Петефиның
Йөрәкләрен саклаган.
Шуңа, бәлкем, беркайчан да
Үз йөрәген сатмаган.

Ул тарихның елларында —
Че Гевара,
Виктор Хара куллары.
Ул тарихта кемнәрнеңдер
Башланмаган юллары.

Ул тарихның хәтерендә —
Тукайларның, Мусаларның хак сүзе.
Еллар сыкрый: «Такташ»,— дисәң,
Еламыйча чак түзеп.

Ул тарихның төннәре бар —
Кулдан төшми каләме.
Мөмкин булса, башын сыйпап,
Сөяр иде галәмне.

Искәрмичә йөргәнбез без
Тарихның ак чәчләрен.
Яшьлек диеп уйлаганбыз
Язларын һәм чәчәген.

Кысып кочаклардай булып,
Күз алалмый карыйсың:
Сабыр гына үтеп бара
Бер халыкның тарихы...

## Кыргый көрәш

Ишеткәнем бар:
    маралллар
    көрәшсез сөю яуламый.
Көндәшсез сөюнең кадере юк.
Яши алмый алар
    мөгез көчен сынамыйча.
Тояклары белән җирне тырнап,
Үкереп,
    борын тишекләрен киереп,
ташланалар дошманына.
Куаклар чытырдап сына,
    мөгезләр — шарт та шорт!
Янда гына иркә басып
    сылу йөри, үлән чемчеп...
Күз кырлары белән сирпеп,
    башны горур чайкап, чөеп,
Аякларны аерып басып
    хәлиткеч дауны күзәтә.

Исе китми: аның өчен
үләсең ни,
каласың ни...
Һәм аның бөтен торышы
тормышның Олы законы —
Яшәүгә хокукны яклый.
Аның өчен: таза бул син,
аның өчен: сәламәт бул,
Көчле бул һәм ыру башы...
Аңа ят хис — кызгану да,
гафу итү...
Ул гаҗәп каты күңелле —
Гладиатор тамашачылары сыман;
Башын исә — ярлыкарга.
Башын чөйсә...
Мәрҗән күзләре ялтырап
рәхимсез азакны көтә...
Хәвефле азакны көтә,
Берсенә — газапны көтә...

...Хайваннарга хас закон бу —
таза нәсел өчен көрәш;
Кырыс яшәештә бәлки
шулай булу дөрестәдер;
Акланадыр бәлки:
көчсезгә — хурлыклы бетү,
ырудан китү,
Гарьлектән үзен җәзалап,
батып үлү тынчу күлдә.
Аңа көче җитми икән:
сөзеп үтерә ырудашлар...
Бәлкем шулай кирәктер дә...
Киләчәк буыннар өчен.
Тик бу хайваннар законы...
Ә менә мин аңым белән
аңлый алмыйм,
Таба алмыйм җепнең очын —
Кайчан безгә күчкән икән,
Кай буыннан катып калган
Нәкъ шундый ук кырыс закон?
Ә бит
чиста арий нәселе өчен
кешелекнең канын эчкән
сөлек тә бер күбенеп үлгән!..

Җир шарын тибеп уйнарга
теләп, аяк сындырганны
дөнья белә!..

Мәңгелеккә мисаллар юк —
Җир белән тигезләп барып
тарих килә...

Кайчан салынган безгә бу —
Хайваннарча кыргый алыш?
...Гасырлардан автограф —
Кабер ташы — серле сагыш...

Калган безгә яман мирас —
Туры килә сөзешергә,
Мөгезләрне сындырырга;
Безне дә үлән чемченеп
    күзәтәме мәрхәмәтсез
    берәр сылу?..
Мәгънәсезгә һәлак булып,
Без
мәхәббәтне раслыйбызмы шулай?
Батырлыкны күрсәтәбезме?
    Матурлыкнымы?
Горурлыкны —
    тармак мөгезләрне җәеп,
Парлап, янәшә,
Янә бер кат
Кереп китә алырбызмы бер
    тормышка?
Яшәешкә хокук, имеш...
Көчлеләрчә җиңү, имеш...
Ә без — кешеләр.
Һәм безгә бер Сөю язган,
Һәм безгә бер Яшәү язган —
    көчлегә дә,
    көчсезгә дә...

❋

Авыр миңа.
Яшермим, дөресен язам.
Бу дөньяда яшәвемә
Бәлкем шушы минем җәзам.
Иңне баскан горурлыкны
Этеп төшерергә телим.
Тик нигәдер, коткар, диеп,
Әйтә алмый минем телем.

Каршы йөгереп килүчегә
Җитәр ялварулы күзем.
Минем бәйрәм — шул минутта
Баш бирмичә, калсам түзем.
Алда — гомер. Авырлыктан
Иелмичә торырлыкмы?
Тик нишләтим үзем белән
Бергә туган горурлыкны?!

❋

Көннәр тигезләшкән чак!
Сине эзләп кайчак
Күзләр илендә адашам.
Я үз-үземне алдыйм,
    я алдашам.
«Таптым!» диеп юанам да...
«Югалган»... дим,
Кайтмас бүтән.
Аның ярты җаны белән
    минем җанымнан торган бөтен —
        төтен...
Янган, пыскыган күмернең хисе...
Башкача нәрсә дисең...
Күк капусы ачылганда теләгән уй —
Серле абага чәчәген
    иреннәргә китергән чак!
...Сине югалтканнан бирле
    мәхәббәттә я угры мин,
        я гел качак...

БАТЫРЛЫК ДӘВАМ ИТӘ

## Фоат Садриев

# АВЫШ БАСУ ИКМӘГЕ

хикәя



Күптән түгел мин дустым Мәхмүт белән очраштым. Хәл-әхвәл сораштык, үткәннәрне искә төшердек. Күпме генә сөйләшсәк тә сугыш җиле кагылган балачак хатирәләре һәммәсеннән тирәрәк һәм өстенрәк булып чыкты. Эшме, гаиләме, халыкара хәлләрме — боларның кайсына гына кагылсак та, ирексездән балачакка әйләнеп кайттык. Шактый гәпләшеп утыргач, Мәхмүт кинәт болай диде:

— Нигә син сугыш елларына багышлап берәр нәрсә язмыйсың?

Мин сорауга сорау белән җавап бирдем:

— Ул чорлар турында ни әйтә алам соң?

Дөресе шулай иде, тик кыенсыну димме, үземне гаепле санау димме — ниндидер бер авыр тойгы күңелнең иң тирән җирен тырнап куйды.

— Без бит әйтергә тиеш.— Мәхмүтнең соры күзләре бер генә секундка миндә туктап алдылар да читкә төбәлделәр. Мин аның керфекләренең еш-еш сикерүен, күзләренең дымлануын күрдем. Бу халәтен яшерергә теләп булса кирәк, ул тәрәзә каршына барып, миңа аркасы белән басты. Аның тонык, калтыранган тавышы мине сискәндереп җибәрде:

— Без мәңге түләп бетерә алмаслык бурычлы...

Мәхмүт сервантны ачып, аннан бер төргәк алды һәм миңа сузды:

— Әти хатлары. Укыгач кайтарырсың.

Сәләхетдин абыйның районда танылган механизатор булганлыгын 1944 елның көзендә сугышка киткәнлеген ишетеп белә идем мин. Ул чакта Мәхмүт туарга ике айдан күбрәк вакыт калган булган.

Сәләхетдин абыйның хатларын кабат-кабат, аерыла алмыйча укыдым. Укый торгач, хат юллары минем колагымда яңгырый ук башладылар, музыка кебек бөтен рухымны биләделәр. Бу — безнең әтиләрнең уртак тавышы иде.

Берничә көн үтүгә Мәхмүт турында хикәя язарга керештем. Ләкин хатлар минем колагымда көн-төн яңгырауларын дәвам иттеләр, кулыма каләм алсам, язасы сүзләремне оныттырдылар, фикеремне чуалттылар. Шулай газаплана торгач, аларның кайбер юлларын, өзекләрен мин, үзем дә сизмәстән, хикәям битләренә төшерергә керештем. Һәм, ни хикмәттер, фикерләрем яктырып китте, каләмем туктаусыз йөгерә башлады. Әсәремне ничек язылган — шул хәлендә укучылар хөкеменә тапшырам.

* *

«...Әйтерсең, авылдан чыгып киткәнгә атналар түгел, еллар үткән. Барабыз да барабыз. Һәммәсе җимерелгән, яндырылган. Авылдан ераклашкан саен сезгә якыная гына төшәм кебек. Бөтенесе күз алдында. Таң алдыннан һаман да Галимәләрнең кызыл кикрикле әтәче беренче булып тамагын киерәме? Кояш Фәтхетдин абзыйларның читәне өстенә күтәрелүгә эшкә китәсездер. Шәрифәттәй керәме, мур кыргыры кәҗәсен өй борынча каргап йөриме?

Сәрбиҗамал, син миңа рәнҗебрәк калдың бугай. Фронтка җибәрүләрен сорап кабат-кабат гариза язмасаң да булыр иде, диден. Әнисенә үлем килгәндә аңа ярдәм кулы сузмаган баланы кеше дип буламы? Сугышка китү дә шулай бит. Син кайгырма, хәзер язмыш сине миңа, мине сиңа бәйләгән инде. Бәхетебез дә, бәхетсезлегебез дә уртак. Безне берни дә аера алмаячак. Саубуллашканда әйткән сүзләремне онытма: үзеңне дә, туачак бәләкәчебезне дә сакла». (1944 елның сентябрендә язылган хаттан.)

Балчык катнаш борчак сабагы тагын уракка килеп тыгылды. Мәхмүт кабаланып хедерны күтәртте. Юк, урын булмый иде. Ул тирсәкләрен штурвалга терәде, тирле маңгаен учларына салды. Онытыласы, бу комбайннан, бу борчак басуыннан әллә кая, күз күрмәс җиргә качасы килә иде. Ул башын күтәрде, төкереген йотты, йомылып баручы күз какларын сыпырды. Әвернә бер көйгә әйләнә, аңа уралып тырпаешкан борчак сабаклары Мәхмүткә йөзен тырнап-сыдырып ала кебек тоелды. Ул артына каерылып карады, торып басты, яңадан утырды, тартмадагы ачкычларга үрелде, кабат торып басты — җанын куяр урын юк иде. Йөз гектарлы басуда өч көн ят инде! Әле бит аның яртысы гына урылды. Председатель дә килгән саен исе китеп карап тора, агроном да матае белән көнгә биш-алты урап китә, бригадир да, башкасы да юлны суытмый. Барысы да аптырыйлар, баш чайкыйлар ә борчак аксыл-сары киез сыланган хәлдә ята бирә. Комбайннар аның эченә үтәргә телиләр, буыла-буыла моторлар үкерә, бер сажень алга барсалар, икене артка чигәргә мәҗбүрләр. Берсе урса, өчесе туктый, алар башлаганчы монысы да тыгыла. Басуы нинди бит: үзе кызгылт туфрак, үзе бер якка авыш, үзен буйдан-буйга урталай ярып торган чокыр үтә, тигез диган җире дә дулкын төсле сырлы-сырлы, чокыр-чакыр. Монда юньләп кар да ятмый, булган кадәресе дә иртә яздан эреп бетә һәм гомер-гомергә беренче булып шушы басуга тырмага төшәләр. Җәйге җилле көннәрдә биредән, күңелгә шом салып, өермә күтәрелә, аждаһа койрыгы төсле уйнаклый-уйнаклый авыл өстеннән үтеп китә...

Звеноны хурлыкка калдырды бу басу. Район газетасы, борчакка беренче булып төштеләр дип, чабата кадәр хәрефләр белән язып чыкты, Казан радиосы сөйләде. Инде борчакны бетерүче бригадалар бар, күпләр унар-уникешәр гектар чабалар, ә алар моның яртысын да үти алмыйлар.

Мәхмүт тырнаклы тимер таягын алып, уракны сабактан чистарту өчен җиргә сикерде. Озын көн буе шулай. Ашыга-ашыга менеп утыруга, тагын төшәргә кирәк була. Кичкә бөтен гәүдә кыйнап ташлагандай сызлый, уракны күтәрә-төшерә торган гидросистема рычагын өзлексез күчерүдән уч төпләре кызарып-кабарып чыкты. Мәхмүт ялгызы эшли, үзенең ярдәмчесе Рәдифне Рамилгә биргән иде. Шулай итми җае юк: Рамил армиядән кайтты гына, беренче мәртәбә комбайнчы булып уракка чыга. Моның нәрсә икәнлеген үзе шуны кичергән кеше генә белә. Һәм, үч иткәндәй, уракка менә-менә төшәбез дип торганда, егетнең ярдәмче-

се авыртты. Артта кеше юк иде. Мәхмүт үзенең ярдәмчесен ана бирде.

Беренче көнне ярты сәгать эшләүгә Рамилнең урагы җиргә кадалды, люфтерлар каерылган, икесе сынып ук чыккан иде. Шунда ук Мәхмүт килеп житте. Рамил бертуктаусыз кул сырты белән маңгай тирен сөртте, нишләгәнен белмәде, ачкыч урынына чүкечкә, чүкеч урынына отверткага үрелде. Аны шундый хәлдә күргәч, Мәхмүт үзе дә сәерсенеп китте. Чөнки Рамилне ул елмаеп кына йөрүче, салмак хәрәкәтле юаш егет дип белә һәм шуның өчен ошата да иде. Хәзер исә аны таныурлык түгел. Рамил өчен Мәхмүт үзе көенә башлады.

— Син борчылма, — диде Мәхмүт акрын гына.— Басуның тигез булмавыннан ул. Калкып торган җирләрдән уракны сикертебрәк үтәргә тырыш.

Техник хезмәт күрсәтү звеносы тиз килде, люфтерларны рәтләделәр. Рамил инде ашыкмаска тырышты, тизлекне шактый киметте. Бераз эшләгәч, тагын нидер булды: борчак чабылмый, әвернәгә генә урала башлады. Мәхмүт тагын йөгереп килеп житте.

Әвернәне бер сәгатькә якын чистарттылар. Рамилнең сулышы ешайды, күзендә ачулы очкыннар биеште. Ул ярсып рульгә утырды, кочле газ бирде, кузгалып ун-унбиш адым китүгә, туфракка кадалып пычак чалшайды. Рамил оятыннан җир тишегенә кереп киткәндәй булды! Мәхмүт егетнең рухын күтәрердәй сүзләр эзләде.

Кичкырын Рамил, чокыр буенда рулен кисәк борып, ава язды, тормоз дип муфтага басты, чак кына чокырга тәгәрәмәделәр. Аның тез буыннары дерелдәргә тотынды, куллары тыңламас, руль тота алмас булды.

Чүп өстенә чүмәлә дигәндәй, бүген җанны үртәүче тагын бер нәрсә өстәлде. Иртән Рамил комбайнчыларны басуга илтүче автобус янына килгәндә, алар звеносыннан Гата белән Сәлим шунда иде инде. Гата күрешкәндә аның кулын шытырдатып кысты да һәркөн әйтә торган сүзен әйтте:

— Нихәл, егет кеше?

— Әйбәт әле,— диде Рамил.

Тик үзе аптырашта калды. Ник шулай ди икән ул? Түбәнсетүеме, әллә син дә кеше булдың, безнең арага кердең бит диюеме? Һәм моны берничек тә белеп булмый. Чөнки Гатаның йөзендә елмаю да, ачу да юк, кырыслык кына бар. Яшерен-батырын түгел, Рамил аңардан шүрли. Гатаның тышкы кыяфәте үк әллә нинди сәер, кешедән аерылып тора. Сеңер белән сөяктән торучы озын нечкә гәүдә, тимердәй куллар. Кара тутлы йөзендә сөягенә кадәр баткан тирән җыерчыклар: маңгайга икәү сызылган, кашлары арасында берсе ярылып ята, бит белән борын арасыннан икккә кадәр ике тирән эз төшә, иякта бер тирән чокыр. Капкара калын кашлар һәм алдан шул кашларга кадәр, ә арттан җилкәгә төшеп торучы ап-ак чәчләр. Гатаның чәче армиядән шулай чаларып кайткан. Иллегә якынлашучы кешенең авылда җилкәсенә кадәр чәч үстереп йөртүе үзе үк мәзәк иде. Авылда Гатаның арыганын да, авырганын да күргән кеше юк. Дөрес, моннан берничә ел элек ул, Казанга барып аяктагы кан тамырларына операция ясатты. Анда да наркоз алмаган, өшетелмәгән килеш аякларын телгәләгәндә бер мәртәбә дә ыңгырашмаган. Хирург исе-акылы китеп бу турыда аның хатынына сөйләгән диләр. Шулай да ул авылның иң түземсез кешесе санала иде. Җыелыш мазар булмасын, үзара гәп куерткан да булмасын, Гата атылып-бәрелеп бәхәскә ташлана, беркайчан да сүзен бирми, үзенә каршы килүчене гөмбердәп торган тавышы һәм тупас сүзләре белән он-талкан китереп ташлый. Аның кушаматы да сәер — Җен. Бу — яшерен кушамат, аны әйтергә куркалар.

Гата кысып авырттырган бармакларын кесәсе эчендә яза-яза, Ра-

мил шушыларны уйлады. Менә Мәхмүт үзенең «Иж-Юпитер» мотоциклы белән автобусны узып китте. Гата Сәлимгә борылды да:

— Үз басуы булгач, ничек ашыга,— диде.

Сәлим бер сүз дә әйтмәде, мыегын сыпырып утыра бирде. Ялгыш ычкындырылган сүзнең үз башына күсәк булып төшү ихтималын ул белә иде. Гата аңа кабат борылмады, алга караган хәлдә, болай гына, үз-үзенә генә әйткәндәй әйтеп куйды:

— Онытып торам икән: безнең борчак белән хурлыкка калуда синең гаеп бар бит әле.

Күрәсең, дәшмичә генә котылып булмаячак иде. Сәлим акрын гына болай диде:

— Мин — кушканны үтәүче генә бит, Гата абый.

— Үтәүче...— Гатаның яңаклары ачу белән кысылды, йөзендәге җыерчыклары тирәнәйде. Ул күзенең чите белән генә Сәлимгә карап алды.— Бала-чага...

Аннары шундый кискен итеп артка борылды, чәчләре ат ялы кебек җилфердәп куйды.

— Әй Мәхмүт?! Ул томана түгел лә! Мин ул бүтәкәгә баштук әйттем — тыңламады.

Гата Мәхмүтне юл буе сүкте:

— Хәзер барыбызның да бер алдына, биш артына төшә дә — сон шул. Борчакны бүген башка басуга күчереп булмый.

Рамил аның әйткәннәренә төшенергә күпме генә тырышса да берни аңлый алмады. Алар арасында ул белмәгән нидер бар иде, ахрысы. Рамил аларның икесен бергә күз алдына бастырып карый. Мәхмүт төптән юан чыккан булса да бигрәкләр дә күзгә күренми шул. Буй дисәң бүе юк, соры кысык күзләре артык тыныч, тавышы нечкә, сүзен дә, исерек кеше кебек, төртелеп-төртелеп кенә сөйли. Битләренең гел алланып торуы аны ничектер артык яшь итеп күрсәтә. Рамилнең уйлавынча, звено җитәкчесе Гата кебек гәүдәлерәк тә, ике сөйләргә ирек куймый торганрак та кеше булырга тиеш иде. Бәлкем, Гата шуңа ачулыдыр да? Бәлкем, чыннан да Мәхмүт гаеплედер? Гата бит дөрес сөйли — Мәхмүтнең өчесе каршында да өтәләнүе хак. Ә ник? Димәк, гаебе бар. Ни өчен Рамилне үз звеносына кодалады икән ул? Бәлкем, монда да берәр сер яшеренгәндер?

Рамил, баш ватып барды, барды да, икесеннән берьюлы сорап куйды:

— Гаебе нәрсәдә соң аның?

Гата гүя аның сүзен ишетмәде — борылып та карамады. Сәлим генә серле итеп:

— Вакыты җиткәч белерсең әле,— дип куйды.

Рамил тәмам буталды, барысы да күңеленә авыр таш булып ятты...

Мәхмүт исә бүген иртән автобуста булган әлеге сөйләшүне, әлбәттә, белми, әмма күңеле барыбер тыныч түгел иде. Уйлана-уйлана ул уракны сабактан арындырып бетерде, билен бераз язгач, күперчеккә менде. Үзендәге арыганлыкка, сүлпәнлеккә һәм дәртсезлеккә ул инде менә ничә мәртәбә хәйран кала. Ләкин бу да озак бармый, ниндидер тыелгысыз ярсу белән алышына. Кулга тимер күсәк алып, комбайнны, җирне кыйныйсы килә... Ичмасам норма да үти алмыйлар бит: техника көчсез, алар көчсез. Беркемне күрәсе килми, берсе дә сөйләшми. Барысының да иреннәре кысылган, йөзләрдә әллә нинди рәнҗешле ачу. Ялгышып берәрсе дәшә күрмәсен, яхшы ният белән әйтелгән сүз дә тупас булып яңгырый, теге мескенгә әлләниләр әйтеп ташлана. Иң кыены Мәхмүткә Звенодагыларның үзенә булган нәфрәтен ул кайнар һава дулкыныннан тойган кебек тоя. Мәхмүт үзенең яз көнге олы хатасын аңлап, әмма бе-

ренче ялгышы мәшәкатьле звеноны житәкләргә ризалык бирүдә булгандыр. Гатаны куйсалар, бәлкем, мондый хәл килеп тә чыкмас иде. Ләкин бит аңа партком исеменнән мөрәҗәгать иттеләр. Син коммунист, яңалыкны кертергә беренче булып син алынырга тиешсең, диделәр. Ул чакта бригада подрядының ни икәнен беркем дә юньләп белми иде әле. Мәхмүттә бу яңалыкны сынап карау теләге инде әллә кайчан туган иде. Теләге барлыгын әйтмәсә дә, берсүзсез ризалык бирде.

Яз житкән иде инде. Звенога механизаторлар сайлап алуны аның үзенә тапшырдылар. Мәхмүт ике дә уйламыйча иң элек Гатага тукталды. Ул теләсә нинди техникада эшли ала, аның белән тауны да күчереп була. Гатаны ризалаткач, Мәхмүт әнисе ягыннан ерак туган тиешле Сәлимгә барды. Ул аңа балачактан ук колдан килгәнчә ярдәм итәргә тырышты. Сәлим кызлар төсле йомшак, кыюсыз һәм үтә дә моңлы-сагышлы булып үсте, армиядән соң берничә ел читтә йөрде. Ул кайтуга авылдагы кызларның кайсы кияүгә, кайсы шәһәргә китеп беткән иде. Өйләнә алмыйча озак йөрде ул. Былтыр күрше авылдан килен төшерделәр. Инде хәзер яңа өй дә салырга, абзар-кураны да яңартырга, мотоцикл да алып җибәрергә кирәк. Ә барысына да каян акча житкерәсең? Сәлим бригада подряды турында ишеткән-укыган иде. Шуңа Мәхмүтнең тәкъдименә шатланып риза булды, звенога зур өметләр баглады. Рамил дә карышмады. Звено оешты, договоры да төзелде, шартлары да аңлатылды. Хәер, аңлатып та торасы юк, биредә бик гади арифметика: планда билгеләнгәннән артык уңыш алсаң — отасың, киметсәң — оттырасың. Эшкә керештеләр. Ләкин Мәхмүт үзеннән ун яшь чамасы өлкән Гата каршында да, туганы Сәлим тирәсендә дә житәкче булып йөрүдән кыенсынды, бригадир, инженер, агроном халкы алдында да әйтер сүзен әйтә алмады, кыенсынды, чигенде. Кыскасы, эш тәртибе һаман элеккечә диярлек барды, ә хезмәткә договор нигезендә процентлап кына түләделәр. Озын җәй буе Мәхмүт шушы хакта уйланды, нинди генә килеп житмәгән як, нинди генә кыенлык булса да, һәммәсе өчен үзен гаепле санады. Бүген шуны төзәтергә кирәк. Әмма өчесе дә аңа каршы торганда ничек төзәтәсең? Ничек элекке дуслык-татулыкны терелтергә?

Звенодагыларның аңа йон тырпайтуы борчакка чыккан көнне ук сизелде. Иң элек Рамил жебеп төште. Мәхмүтнең «бажай» дип эндәшүенә башка чакта эреп китә торган Рамил аңа ачу белән карап куйды. Быел көзгә Хәлимә белән өйләнешәселәр иде кебек. Язын да, жәен дә гел аларга кайнар аш китереп йөргән Хәлимә дә бу араларда, нишләптер, күренми башлады. Егет кешенең кәефен кырырга ул да житә.

Комбайннар тыгылып туктау белән Гата очып килеп күперчеккә менде һәм мотор тавышын басарлык итеп кычкырды:

— Рәхәтме?! Сиңа төс ул! Кеше сүзенә колак салмыйча, үзеңне белдеклегә санап йөрсәң, шулай була ул. Бу басуга борчак чәчәргә ярамый дип әйтмәдемме мин сиңа?!

Йодрыгын Мәхмүтнең борын төбендә селкеде дә сүгенә-сүгенә төшеп китте. Хәзер инде бөтенләй дәшми. Ичмасам, сүгенсен иде. Ул гел сүгенә. Гатаны моның өчен авылда гаепләмиләр, ул аны бисмилла урынына гына кулланә диләр. Инде Гата булып Гата дәшми икән, эш уеннан узган дигән сүз.

Сәлим берни дә сиздермәскә тырыша. Ләкин Мәхмүт күреп тора, ике арадагы элекке табигыйлек бетте, янына килсәң, читкә карый, зәңгәр күзләрен яшерергә өлгермәсә, Мәхмүт эсселе-суыклы булып китә. Аның күзләрендә ачыну, үкенү генә калган, башка берни юк.

Менә шундый хәлләр. Ичмасам, хатыны Айзирәк янында юк, ул булса, рәхәтләнеп эчен бушатыр, киңәшер иде Мәхмүт. Тагын Айзирәк! Тагын барып чыкмады! Бүген бит ул Айзирәк хакында уйламаска, басуда чакта аны онытып торырга сүз биргән иде. Ах, Айзирәк, Айзирәк,

кайчан китererлэр синнэн шомлы хэбэр?! Әле син янда чакта гел ару булган икән. Ә хәзер эчендә бер генә исән урын да юктыр кебек — һәммәсе тоташ ут. Карачы, бу борчак басуы да Айзирәкнең чәчләре төсле аксыл сары икән лэбаса! Әллә шуңа гел хәтердән китмиме соң ул? Сары басу, сары сагыш... Юкка гына бу басуны авыл халкы җырга кертмәгәнндер:

Авыш басуның икмәге
Сары булыр, чуалыр
Сарылыгы — хәсрәт күле
Эчкә тулып туңадыр...

«...Менә Карпат тауларына килеп җиттек. Өченче көн беренче мәртәбә сугышка кердем. Кинодагы сугыш — сугыш түгел икән ул. Тыныч кына ашап утыра идек, бер минут эчендә җирнең асты өскә килде. Колак тондыргыч шартлап, тау-туфрак күккә оча, снаряд-пулялар сызгыра, дөньясы гөтен дә ут. Күк тә, кояш та юкка чыкты. Бөтенесе мине үтерү өчен бит. Син кеше түгел, кайда җилли шунда барып орылучы тузан бөртеге. Куркудан йөрәк таштай катты, башым берни уйламас булды. Колак төбендә «А ну, вперед!» дигән ачулы тавыш ишетүгә сикереп торып алга ташландым. Кемнәрдер егыла, җан ачысы белән кычкыра. Мин үзем йөгерәм, үзем тере дә түгел, үле дә түгел: авыз ачылмый да, йомылмый да. Соңыннан шуны белдем: бу сугышта автоматымнан бер генә пуля да атмаганмын, немецка мишень булып кына йөгергәнмен икән. Куркаклыгым өчен үземне битәрләдем, башкаларның йөзенә күтәрелеп карарга оялдым. Шулай уйланып, төне буе керфек какмадым. Куян кебек калтыранып яшәргәме? Юк инде! Алай яшәгәнче үлем артык. Мин шуны сайладым.

Кичә без һөҗүмгә күчтек. Мин «ура» кычкырып иң алдан йөгердем, күңелемнән сезнең белән бәхилләштем. Бөтен тәнем кызышты, йөрәгем дөп-дөп типте, үзем туктаусыз аттым, «ура» кычкырдым. Сәер хәл, миндә курку юк иде инде. Һөҗүм сәгатьтән артык дәвам итте, немецларны чигендердек. Мин тузан бөртеге түгел идем хәзер. Бу җиңүдә мин дә катнаштым бит. Аңлыйсыңмы — мин дә! Юк, Сәләхетдин, дидем мин үзүземә, син әле кирәк, син җиңгәнче сугышырга тиеш. Үлмибез әле, Сәрбиҗамалым!»

(1944 елның октябрь аенда язылган хаттан.)

Мәхмүт ялт борылды һәм, Рамилнең ярдәмчесе Рәдифне күреп, шундук комбайнын сүндерде. Аның миендә «мөгаен, чокырга төшкәндер» дигән уй талпынып алды.

— Ни булды?

— Рамил абый кайтып китте...

— Нишләп?

— Белмим... Инде әллә кайчаннан бирле пычаклар кистерми...

Мәхмүт Рамил комбайнының чайкала-чайкала авыл юлына таба баруын шәйләп алды. Ул, Рәдиф күзен ачып-йомганчы, җиргә сикерде һәм, басу почмагын кисеп, комбайнга каршы төшәргә йөгерде. Аннары, куып җитеп булмаслыгын күреп, җир башындагы вагонга борылды. Күләгәдән чыгарып бер тибүгә, «Иж-Юпитер»ы тырылдарга тотынды һәм җирдә зәңгәр төтен генә сузылып калды. Һәрвакыт кереләнә торган мотоциклның шулай кабынуы могҗиза иде.

Менә ул комбайнны куып җитте. Юл тар, узарлык түгел. Мәхмүт күперчеккә күтәрелә торган баскычка терәлеп диярлек бара башлады һәм берничә мәртәбә сигнал бирде. Рамил әллә ишетеп, әллә болай гына борылып карады, Мәхмүт астан йодрык күрсәтте. Ләкин егетен туктарга уйламады, киресенчә, тизлекне арттыра гына төште. Мәхмүт

мотоциклын юлда калдырды, комбайнны өч сикерүдә куып җитте һәм күперчеккә күтәрелде.
— Борыл!

Рамилнең чәче дә селкенмәде, ул штурвалны кысып тоткан килеш бара бирде. Мәхмүт үрелеп комбайнны сүндерде, тып-тын булып калды. Рамилнең уң кашы туктаусыз сикерә, кара озын чәчләре тир белән маңгаена ябышкан иде. Мәхмүткә ул күзенең агы белән карады:

— Ник кирәк мин сиңа?! Ник бәйләндең миңа?!— дип кычкырды ул елак тавыш белән.— Башкаларны интектергәнең дә җитәр!..

Мәхмүт аның куәтле беләкләренә күз ташлады һәм җилкәсенә кулын салды. Рамилнең зәңгәрсу күлмәге лычма тир, тәне ут кебек кайнар иде.

— Ә син егет бул, буеңа сеңдер.

— Көнгә өч гектар борчак чабып кеше көлдергәнче авылдан чыгып качам мин!

Рамил утыргычтан сикереп торды, үз-үзен кая куярга белмәде.

«Елак! Җебегән! Армиядә ничек хезмәт иттең син?! Мәмкә!»— Мәхмүтнең шулай дип кычкырасы килде, әмма чигә тамырларының кыршау белән кыскандай авырттырып тибүенә карамастан, ул тыныч күренергә тырышты.

— Син булдырасың, Рамил. Ышанмасам, сине алыр идеммени?

— Юк! Барыбер китәм, шәһәргә чыгып китәм. Барысына да син гаепле...

Мәхмүт егетнең тәмам сынганлыгын хәзер генә аңлады. Кичә Рамил ватылмыйча диярлек урып маташса да, кара көеп, бөтенләй сөйләшмичә йөрде, дүрт гектарга якын борчак урды. Бүген исә килеп бер әйләнүгә полотно планкаларын кырдырып чыгарды. Техник хезмәт күрсәтү звеносы рәтләгәндә якын да килеп карамады, читкә китте дә утырды. Звено җитәкчесе Әхәткә бу ошамады. Ул эш беткәч:

— Син чын капитан кебек әзер корабка гына утырасың,— диде һәм чеметтереп алды:— Тик корабың бик акрын йөзә. Әллә гел синең янга гына якорь ташлыйсы инде? Барыбер «SOS» килә...

Рамил бала башы кадәр йодрыгын күтәреп Әхәткә ташланды, тик Мәхмүт араларына кереп өлгерде...

Иртүк шулай башланган иде эш көне. Мәхмүт бераз уйланып торды, егеткә ачуы да килмәде, аны ниндидер үкенү генә борчыды. Димәк, берни дә барып чыкмады. Ә бит аның өчен күпме көч түкте ул.

— Тырышма да, үгетләмә дә: барыбер китәм!

— Ярый, Рамил, китәрсең,— диде Мәхмүт ныклы итеп.— Тик бүген түгел. Борчак бетү белән китәрсең.

Бусы соңгы чара иде. Ул аның җавабын юри көтмәде, тизрәк җиргә сикерде. Чөнки кызган чакта әлләниләр әйтелә дә, суынгач кире кайту кыен була. Ул комбайнның алдына чыгып кисү аппаратын карады: пычаклар йөри торган бармакларга үлән мае каткан иде.

— Әллә ни юк, балчык кына сыланган. Пычакка май агызып бераз эшләт — бер дигән кистерәчәк.

Мәхмүт мотоциклына ашыкты.

Звеноның тарала башлавы шушы, күрәсең. Гата белән Сәлимнең дә уе шуңа таба бара. Ләкин моны туктатырга кирәк, ничек тә булса туктатырга! Борчакны гына җиңсеннәр, аннары егетләрнең кәеф күтәреләчәк. Әле бит аларның утыз биш-кырык центнер уңыш вәгъдә итүче бодай басулары бар. Аңа аз көч салмадылар алар. Юлга үрелеп утыручы бодай башакларына бәрелә-бәрелә мотоцикл белән эшкә килгәндә дә, эштән кайтканда да Мәхмүтнең йөрәге дәртләнеп тибә, дулкынланып торучы шушы икмәк диңгезен ул күзе белән иркәли, иреннәре белән үбә, бала сөйгәндәге кебек татлы, рәхәт хис кичерә...

Мәхмүт артына күз ташлады. Рамилнең комбайны борылып болайга таба килә иде...

«...Кичә Көнбатыш Украинаның Ужгород шәһәрен азат иттек. Сынатырга исәп юк, командованиенең ике рәхмәтен алдым инде. Вакыт юк, бу хатымны котелок төбенә куеп, бик ашыгыч яздым...»

(1944 елның 28 октябрендә язылган хаттан.)

Мәхмүт вагонга якынлашканда, комбайнчыларга аш китерүче фургон күренде. Аның өчен аш булырмы, таш булырмы ул? Юлда нәрсә күренсә дә, Мәхмүтнең уйлары Айзирәккә йөгерә, аңардан хәбәр китерәләрдер дип көтә. Ул инде алдан ук сизеп тора: баланы саклап кала алмаячаклар. Күңеле шуны сизсә дә, әлеге шомлы хәбәрне һаман кичектерергә, ерагайтырга тели. Ләкин чиксез сузып булмаячак бит.— Мәхмүт бусын да яхшы аңлый. Кеше ничек кенә бәхетле булмасын, язмыш барыбер кайгы-хәсрәт бирә күрәсең. Сигез ел бергә яшәп, аларның бер генә авыр сүз әйтешкәннәре дә булмады. Тик... айлар, еллар, үтте, бала дигән шатлык килмәде. Больница юлын да аз таптамадылар. Көтегез, булыр, диделәр. Ниһаять, Айзирәк балага узды — Мәхмүтнең башы күккә тиде. Ул бүрекне кыңгыр салып, елмаеп кына йөри башлады, теленнән шаян сүз төшмәде. Бөтенләй икенче кешегә әйләнден, ни булды сиңа, дип гаҗәпләнделәр иптәшләре. Алар Мәхмүтнең шатлыгын аңлый алмадылар, чөнки бик җиңел генә ата булганнар, баласыз тормышның китеклеген белмиләр иде. Әмма куаныч озакка бармады. Дүрт ай дигәндә бала төште. Врачлар кистереп кенә сәбәбен әйтә алмадылар. Икенчесендә дә шул ук хәл кабатланды. Сәбәбен авыр күтәргәннән түгел микән диделәр. Айзирәк сыер савучы булып эшли иде. Мәхмүт аны көнкүреш комбинатының колхоз филиалына күчерде. Айзирәкнең өченче баласын алты ай күтәргәч саклап кала алмадылар... Инде бусында врачлар аны алдан ук больницага салдылар. Нәрсә булыр? Шатлык килерме аларның йортына, әллә кайгымы?

Ашны бүген дә Миңнур китергән иде. Әгәр Хәлимә булса, хәбәрне аның йөзеннән үк сизәр иде Мәхмүт. Миңнур берни дә әйтмәде. Бәлкем онытып торадыр? Юк, мондый хәбәрне онытып була димени!

Гата белән Сәлим бергә килделәр, Миңнурга баш кагып кына сәлам бирделәр. Гатаның күлмәге тар озын аркасына ябышкан. Кила-килешкә ул туфлиларын салып бәрде. Сәлимнең һәрвакыт елтырап торган нәфис мыегы керпе кебек тырпайган, болай да төшенке иңнәре бөтенләй юкка чыккан.

Өчесе дә сүзсез генә ашарга керештеләр.

— Рамил ник килми?— дип сорады Миңнур.

Аңа берсе дә җавап бирмәде. Шактый тынлыктан соң Гата гына сүзләрен авызындагы гокмачы белән бергә әвәли-әвәли:

— Сине Хәлимә дип белгәндер ул,— дип куйды.

— Алай уйласа, бигрәк тә килергә тиеш.

— Килде ди. Чәкәләшкәннәр бит. Сәлим шулай ди.— Гата моның белән генә канәгатьләнмәде:— Миңа нәрсә, әнә баҗасы беләдер...

Мәхмүт сизенә: Гата, гадәттәгечә, бәйләнергә сылтау эзли. Бер генә җайсыз сүз ычкындырсаң да, кабынып китәчәк. Ә хәзер бу һич тә кирәк түгел, һәр минут, йөрәкнең һәр тибеше кадерле. Бер кешедәй эшләгәндә генә борчакны җиңеп булачак. Шуңа күрә Мәхмүт инде өч көн буе үзен балтага каршы мендәр тотып саклаunion хәлендә хис итә.

— Рамил белән баҗа булганчы әле ун пот тоз ашарга туры килер,— диде Мәхмүт шаярткандай итеп.

— Булырсыз, әгәр быел ачтан үлмәсә.

— Нишләп?

— Атна буе уч төбе кадәр борчак басуында ятып тамак туйдырып булмый ул. Ясадың син безгә подрядны.

— Урмыйча да калдырып булмый бит инде аны, Гата абый.

Гата ашлы кашыгын авызына китереп житкергәндә генә кисәк шартлатып калай савытка бәрде. Тирә-юньгә аш чәчрәде.

— Чәчмәскә кирәк иде аны! Иллегә якынлашам, ә Авыш басуга борчак чәчкәнне белмим мин.

Болай дигәч, Сәлим кыбырсып куйды, бер Гатага, бер Мәхмүткә карады.

— Чәчү әйләнеше дигән нәрсә бар бит...

Мәхмүт бу сүзләрне иланудан түгел, болай гына әйтте. Гата бармак янады.

— Беләм, Әмирхан белән бер сүздә сез. А как же! Хатыныңның абыйсы бит, серләр уртак.

Гата катлы-катлы итеп сүгенде. Ул хаклы: Айзирәкнең абыйсы Әмирхан агроном булып эшли, бу басуга борчакны ул чәчтерде.

— Мин әйтмәдем түгел, әйттем бит...

Гата сикереп үк торды.

— Мин әйттем — үтмәде, син әйттең — үтмәде. Шулай булгач, ник ул подряд? Бүген үк таратырга — бетте-китте вәссәлам!

Мәхмүт бөтен тәненнән ток үткәндәй дерелдәү тойды. Сәлим күзен тутырып аның җавабын көтә. Ул, тынычланып булмасмы дип, алдындагы чәйгә үрелде, әмма кулы шулкадәр көчле калтырый иде, кружканы шундук урынына куйды. Мондый хәлдә икәнен күрсәтергә ярамый иде. Мәхмүт бөтен ихтыярын туплап акрын гына аягына басты, кулларын кесәсенә тыгып, Гатаның каршына ук килде.

— Әгәр сиңа үз тиребез белән сугарган бодайларыбыз кызганыч түгел икән, таралыгыз.

Шулай диде дә Мәхмүт эре-эре адымнар белән комбайнына таба атлады. Гатаның звенодан китмәсенә аның иманы камил. Комбайнына житәрәк Мәхмүтне мотоцикл белән Әмирхан куып житте. Мәхмүтнең котырып ачуы чыкты, шуның белән бергә эчтән теге ут көйдерә башлады һәм ул курку катыш ачуга әверелде. «Мөгаен, Айзирәктән хәбәр китерә...» Әйтмәсен генә, әйтмәсен иде Әмирхан ул хәбәрне. Әйтсә, Мәхмүт аңа ташланачак. Аның бөтен гәүдәсе корыч кыл кебек тартылды, куллары чытырдатып йодрыкланды. Ул Әмирханның кирпеч төсле кызыл чыраен күрмәскә тырышып аяк астына карады. Шулай да Мәхмүт аның борчулы икәнен абайлап алды. Менә хәзер... Әйтә дә, эчтәге өмет җебе мәңге ялганмаслык булып өзелә.

— Уңайга үзгәреш юкмы? — диде Әмирхан.

Мәхмүт тирән итеп сулыш алды, басып кила торган ниндидер көч чигенгән кебек булды. Ул җавап бирмәде, күперчеккә менеп китте. Әмирхан җилкәсен сикертте, күзен челт-челт йомып калды.

Мәхмүт җир башына кадәр урып баргач, тынычлангандай булды. Рамилнең кишәрлегенә күз ташлады: ул урып азаплана иде. Сәлим дә хәрәкәтләнә. Гата гына тәртәдәй озын кулларын бутый-бутый Әмирханга нидер исбатлый, ә тегесе озынча башын чөбен куган ат төсле берөзлексез селки...

Бүген ничек тә кичке унга кадәр эшләргә иде. Егетләр генә чыдасын, алар чыдаса, Мәхмүт чыдар. Аңа рәнҗесеннәр, аны каргасыннар, аның йөзенә кара яксыннар — ул түзәр, тик урсыннар гына.

Әмма кичкырын урман артыннан кара-кучкыл болыт күтәрелде, көмеш ут сызыгы аны урталай ярды һәм елан теле кебек сузылып-сузылып алды. Болыт дөбер-шатыр килеп тә житте, коеп яварга да тотынды. Барысы да йөгерешеп вагонга керделәр.

— Болай булгач гел булды инде бу,— диде Гата.

Мәхмүт үз-үзенә сөйләнгәндәй әйтеп куйды:

— Мин борчакка яңгыр яумаган елны хәтерләмим...

Ләкин бу су астында кычкыру гына иде. Әлеге сүзләр берсенең дә күңелен тынычландыра алмады. Мәхмүт үзендә дә моңарчы булмаганча күңел төшенкелеге тойды. Бөтен гәүдәдә хәлсезлек, бернигә дә теләк юк иде. Күпме тырышты, күпме өметләнде ул бүген норма үтәргә. Норма үтәлсә, эш бөтенләй башкача китәчәк иде. Булмады. Яңгыр тиз үтте, ялтырап кояш та чыкты, ләкин барыбер бүген эшләрлек түгел иде.

«Сәрбиҗамалым! Малай алып кайткан өчен нинди генә рәхмәтләр әйтим соң үзеңә?! Ни төсле микән ул минем җаным, минем каным? Йөзенә бер генә мәртәбә күз төшерсәм, үлсәм дә үкенмәс идем. Борыны гел минеке дигәнсең. Аныкына да каһәр төшкән үрдәк баскан микән, ә? Хатыңны егетләрне җыеп укыдым. Котладылар, һавага чөйделәр. Егорушка гына елады. Аның ике баласы белән хатынын немецлар Германиягә куып алып киткәннәр. Хат язганда берүк аңа аерым сәлам әйтергә онытма».

(1944 елның декабрендә язылган хаттан.)

Мәхмүт кайтканда беркайда да туктап тормады, бригада йорты янындагылар белән дә, урамда очраганнар белән дә баш кагып кына исәнләшеп китте. Әнисе Сәрбиҗамал апа аңа балачактан яраткан ризыгын — кыстыбый пешергән иде. Мәхмүт теләмичә генә капкалады, бер чынаяк чәй эчте дә кузгалды. Әнисе аптырады:

— Улым, тагын бер кисәк булса да аша инде,— диде ул борчылып.— Бу араларда бәләкәй генә булып калдың бит...

— Бәләкәй булганга мин гаепле түгел инде, әнкәй,— диде Мәхмүт коры гына һәм ишегалдына чыгып китте.

Ник кирәк булды инде бу сүз, ник?! Кереп гафу үтенмәкче булды — көче җитмәде. Ул печәнлеккә менеп чалкан ятты. Җаны таш кебек каткан, дөньясын күрәсе килми иде. Мәхмүт күзләрен йомды һәм баштан ук барысын да хәтереннән үткәрергә кереште.

...Язгы чәчүгә төшкән чак. Гата бер көнне кич Мәхмүтләргә килде. Салып та алган.

— Әмирхан иртәгә Авыш басуга борчак чәчтерергә йөри. Мин әйттем, колагына да элмәде,— диде ул зарланып.— Син барып сөйләш.

Мәхмүт Айзирәк белән аларга китте. Теге хакта сүз кузгатуга, Әмирхан елмаеп җибәрде һәм:

— Авыш басу договор нигезендә кемгә беркетелгән соң?— диде.

— Безнең звенога.

— Йөз гектар борчак шулай ук договар белән, план белән беркетелгән. Аны кайда чәчәсең?

— Арпа чәчәсе җиргә. Ә арпаны Авыш басуга.

Әмирхан дөртләп кабынды:

— Акыллы башлар! Агрономиядә әлифне таяк дип белмәгән Гата сүзе белән йөрисеңме? Чәчү әйләнешен бозарга ярамаганын сез бит аңлыйсыз! Фәнгә каршы барып буламы?!

— Авыш басуда арыш-бодай да егыла. Борчакны җыеп алып булмаячак.

— Җыярбыз! Хәзерге техника әллә ниләр эшли. Сез җыя алмасагыз, күрше бригададан буксир чакырырбыз...

Көтү дә кайткан икән инде. Әнисенең иркәләп-сыйпап сыерны печәнлек астына алып кергәне ишетелде. Бераздан борынга җылы сөт исе керде... Менә әнисе савудан туктады. Сак адымнар белән баскычтан күтәрелгәне ишетелде һәм чуар яулыклы башы күренде. Кулында литрлы банка белән сөт иде.

— Улым, җылы сөт эчмисеңме?

Мәхмүтнең бугазына кайнар төен килеп утырды, күзен нәрсәдер ачыттырып алды...

Ул сөтне эчте дә банканы әнисенә сузды.

— Рәхмәт, әнкәй... Булдыра алсаң, кичерә күр...

— Мин бит барысын да аңлыйм, улым...

Әнисе акрын гына төшеп китте, тагын сыер саварга кереште.

Капка шыгырдады, веранда ишеге ачылып ябылды, абзарга таба аяк тавышлары якынайды.

— Кодагый, син биредәме?

Эндәшүче Хәлимә иде. Мәхмүт сикереп торып утырды.

— Әллә берәр хәл бармы? — дип сорады әнисе.

— Бүген телефоннан апа белән сөйләштем.— Хәлимә туктап калды. Мәхмүтнең йөрәге дөп-дөп типте.— Хәле яхшы болай...

Бу вакытта тиккә йөрмәс балдызы. Басудан кайтышлый Мәхмүт больницага шалтыратмакчы булып ферма йортына сугылган иде бит. Линия эшләми диделәр. Күрәләтә алдаша...

— Җизни кайттымы соң әле?

— Чиңнектә.

Мәхмүт җәһәт кенә аска төште. Әнисе сөтле чиләген күтәреп өйгә кереп бара иде инде. Үземә генә әйтергә тели, әнине борчыйсы килми, дип уйлады ул.

— Сиңа ападан бер чуман сәлам,— диде Хәлимә елмаеп.

Мәхмүтнең бөтен гәүдәсеннән җылы дулкын йөгереп үтте.

— Хәле ничек?

— Яхшы.

— Телефон эшләми бит.

— Аш пешерергә әйбер алырга баргач, колхоз идарәсеннән шалтыраттым.

Мәхмүт аңа сынап карады. Шуңадырмы, Хәлимә кып-кызыл булды.

Алар бер тын сүзсез тордылар. Хәлимә чәчләрен рәтләп куйды.

— Ярый, мин кодагый янына керим әле...

— Сабыр,— Мәхмүтнең тавышы тамак төбеннән калын булып чыкты.— Рамил белән ни булды?

Хәлимәнең битенә ут капты.

— Булмады...

Ул аяк астыннан бер сарут сабагы алып кулында бөтерергә тотынды, астан сизелер-сизелмәс кенә җизнәсенә карап куйгалады. Хәлимәнең бармаклары җиңелчә генә калтырый иде.

— Булмаса бик яхшы,— Мәхмүт сарутны кискен тартып алды да читкә ташлады.— Иртәгедән башлап безгә ашны үзең китерәсең. Килештекме, балдыз?

Хәлимәнең күзендә әллә нинди аңлаешсыз очкыннар уйнап алды, күкрәге еш-еш күтәрелде. Ул бер сүз дә әйтмәде, кырт борылып өйгә кереп китте. Үзенең төс-кыяфәте, бөтен кыланышлары белән гел Айзирәк ул. Әнә шундый очкынлы карашы, җиңел-җиңел атлап кереп китүләре — һәммәсе дә апасыныкы. Айзирәкне күрмәгәнгә хәзер ай гына түгел, елдыр кебек тоела. Тагын ике ай ятарга кирәк диделәр. Баланы чыннан да саклап калсалар? Менә шушы бәпкә үләннәре өстеннән синең малаең ялан тәпиләре белән сиңа таба кулларын сузып йөгерсә, чыркылдап кәлә-кәлә муеныңа килеп сарылса, колагыңа җылы тыны бәрелсә, тагын ни кирәк дөньяда?! Ничә еллар шул хакта хыяллана Мәхмүт. Ул инде аны уе белән ничекләр генә иркәләмәде. Ничәмә ничә мәртәбә ул аны мотоциклы белән басуга алып барды, җитәкләп бодай башаклары арасыннан йөгертте, салам өеменнән мәтәлчек аттырып уйнатты, тезләренә утыртып комбайн штурвалын тоттырды, аның сигналын кычкырттырды, бункердан машина кузовына аккан җылы борчак, арыш, бодай бөртекләренә коендырды. Инде аңа күлмәк-ыштан да,

башлык та, бүтәне дә алынган. Ул инде аның исен, җылысын тоя, сакау тәтелдәүләрен ишетә, кәкре тәпиләрен, йомшак кулларын, бәләкәч бармакларын үбә...

«...Бу хатны госпитальдән язам. Уң аякның балтыры яраланды. Сөяккә тимәгән — борчылырлык нәрсә юк. Биредә вакыт күп, уйландыра. Мин бер нәрсәгә гаҗәпләнәм: кешене юк итү өчен кечкенә генә кургаш кисәге дә җитә. Ә үзе нинди батырлыклар эшли ала. Моны ник язаммы? Син үзеңне сакла дигәнсең. Үлем бит агач башыннан йөрми. Кайту насыйп булмаса, безнең өчен җиңү кайтыр. Ә шулай да мин исән калырмын дип уйлыйм. Бәләкәч Мәхмүтем, син, авыл, басу-кырлар гел күз алдымда. Әгәр сагыш-сагынуларымны конвертка салып җибәрә торган булса, кулыңны пешерер иде...»

(1945 елның февралендә язылган хаттан.)

Мәхмүт верандага кереп ятты. Ләкин никадәр арыган булса да, күзенә йокы кермәде. Ниһаять, ул моның сәбәбенә төшенде кебек. Күңел түрендә нindидер томанлы сизенү булып бер сорау ята икән бит. Моңа кадәр Мәхмүт аны ачык итеп тоймады да бугай, ул кымшанып-кымшанып куйгалады да онытыла килде. Әмирхан белә торып, күрә торып Авыш басуга ник борчак чәчтерде соң? Менә шушы сорау караңгы төндә бер ноктага юнәлтелгән ут көлтәсе кебек күп нәрсәләрне яктыртып җибәрде. Иң элек былтыр көз үткән бер партия җыелышы хәтергә төште. Мәхмүтләр бригадасы елның-елына яхшы уңыш үстерә. Былтыр исә, борчак, корылык булса да, гектардан унҗидешәр центнер чыкты. Бу — районда иң югары күрсәткеч иде. Әмирхан, бригада агрономы буларак, әлеге җыелышта бу хакта бик вәземләп сөйләде. Анда райком секретаре Гыйммранов та бар иде. Ул үзенең чыгышында:

— Тынычланырга, мактанырга иртәрәк,— диде.— Сезнең җирләрегез уңдырышлы — төп хикмәт шунда. Булган мөмкинлекләрегез начар файдаланыла...

Гыйммранов моның шулай икәнлеген туфракка һәм агротехник чараларны үтәүдәге кимчелекләргә нигезләп аңлатты. Әмирхан шунда сүз кыстырды:

— Ә без начар җирдә дә әйбәт уңыш үстерүебезне күрсәтә алабыз!

Секретарь аңа таба борылды:

— Шулаймы? Бик яхшы. Бу сүзләрне мин һич югы дүрт-биш ел хәтеремдә тотарга тырышырмын,— диде ул, саран гына елмаеп.

Моны ничек башта ук хәтеренә төшерә алмаган соң Мәхмүт? Ә бит, барлый башлагач, һәммәсе бер җепкә тезелә дә куя икән.

...Авыш басуга көздән күпләп черемә дә, компост та чыгардылар. Бригаданың бөтен черемәсен Авыш басуга ташып бетерделәр инде, дип сөйләнде кайберәүләр. Икенчеләре моны хупладылар, иң ерак басу, туфрагы начар, рәхәтләнсен, диделәр. Яз көне бу басуга минераль ашлама да аз кертелмәде. Ләкин уракка төшәр алдыннан егетләр янына баш экономист килгәч, шул ачыкланды: бирелгән отчетларда Авыш басудагы черемәнең яртысы, ә минераль ашламалар бөтенләе белән бодай, арпа җирләренә кертелгән булып күренә икән. Бу да Әмирхан кушуы буенча шулай эшләнгән. Яз көне Авыш басуны кат-кат эшкәртүләрен дә, анда борчак чәчкән өчен Әмирханны авыл кешеләренең тиргәвен дә белә Мәхмүт. Ул моңарчы аны гаепләсә дә тискәрелектә гаепләп йөрде, явым-төшемен, башкасын уйлап җиткермәгәндер дип, үзенчә акларга да теләде. Баксаң, Әмирхан барысын да аңлы рәвештә эшләгән икән. Моның нигезендә коры тискәрелек ятса үз сүзен сүз итәргә азаплану гына ятмый лабаса! Соңгы вакытларда председатель Зәкиевнең Әмирханнар белән йөрешүен, теге яки бу мәсьәләдә гел аның белән киңәшүен

колхозда һәркем белә. Былтыр туган-тумача белән өстәл артында утырганда Әмирхан:

— Мин ничек телим — колхозда бөтенесе шулай була! — дип ычкындыргач, Мәхмүт моны артык рюмка «кыткылдавына» гына санаган иде. Алай булмаган икән! Райком секретаре белән бер дәрәҗәдә торып сөйләшү, хәтта үз сүзен анықыннан өстенгә чыгару Әмирханны Зәкиев каршында әллә ничә башка югары күтәрә түгелме? Шул исәптән райком каршында да. Ә Мәхмүт иптәшләре алдында юри булса да аны яклап, Әмирхан күкрәк суксын, колхозда теләсә ни кылансын өчен аларны әйдәгән булып чыга. Гата хаклы: кем чәчтергән — шул гаепле һәм шул җәзасын алырга тиеш. Алар җитәрлек иза чиктеләр. Люфтер белән җир сөреп техниканы тәмам эштән чыгардылар, үзләре йончып беттеләр, оятка калдылар. Әмирхан исә астыртын елмаеп йөри бирә.

Иртән бераз томан төшкән иде. Ул күтәрелүгә басу өстеннән талгын җил йөгерә башлады. Иң элек барысы да озаклап комбайннарын карадылар, майладылар. Берсенең дә йөзендә елмаю әсәре күренмәде. Ниһаять, кузгалырга әзерләнделәр.

— Бүген борчактан котылырга кирәк,— диде Мәхмүт.

Гата мыскыллап көлде.

— Синең башкаруда Әмирхан сүзләреме бу? Чумарасы күп керәме сон?

— Тамашачы санына карап инде.

— Тамашачыларның кесәсендә җил уйный шул, сумнарын борчак басуында югалтканнар.

Моңа кадәр сүзсез торган Сәлим Гатага төртеп җибәргәндәй итте:

— Җитәр инде, Гата абый! Нишләсәң дә сум да тиен. Туйдырды, валлаһи!

— Кәҗә матаең бар — сиңа ике дөнья — бер моржа. Тиен, акча... Акча — чүп ул. Ә менә мин биш ел машинага чират торам. Быел районда иң күп эшләгән комбайнчыга «Москвич» машинасы алырга талон бирәчәкләр. Бәлки мин шуңа өметләнәмдер?

— Бик әйбәт, өметлән! Нигә соң аны сүз саен чәйнәргә?

— Сиңа әле абыеңны өйрәтергә иртәрәк, энекәем!

Гата теш арасыннан черт итеп төкерде дә комбайны янына китте. Башкалар да кузгалдылар.

Басу җиллән бетмәгәнлектән, бүген уруы элекке көннәргә карагандa күпкә кыен иде. Комбайннар бик акрын хәрәкәтләнәләр. Әмирхан иртүк килгән иде, карап торды-торды да авылга ычкынды...

Уйлардан аның башы тубал булды. Яз көне Әмирханга юл куясы булмаган. Ни өчен Мәхмүт парткомга кермәде? Әмирхан райком секретаре каршында мактанган партия җыелышында да кыжрап кына калды. Шулкадәр торып әйтмәкче булды:

— Тәнкыйть дөрес, кәпрәер чамабыз юк! — димәкче булды.

Әйтә алмады, эчендә калды. Вакыт яңгыры барысын да юды, оныттырды кебек. Әмма әле бер, әле икенче чакта Мәхмүтнең Әмирханга нишләптер ачуы килде дә торды. Алар ашка да чакырыштылар, болай да йөрештеләр, тик аралар сиздерми генә салкыная барды... Мәхмүт шушы уй йомгагын берләр сүтте, берләр урады, берләр таратты, берләр төйнәде...

«...Мин тагын алгы сызыкта. Аяк таш кебек, башкалардан калышкан юк. Теге ел Авыш басуда бодай урганны хәтерлисеңме? Мин сиңа беренче мәртәбә шунда сүз каткан идем. Уйлап йөргәнгәдерме, бүген шул басуны төшемдә күрдем. Күк зәп-зәңгәр, бодай шундый биек, башаклары эре, сап-сары. Син Мәхмүтне кулыңа тоткансың. Ул яланбаш, ак күлмәктән. Шул чак күбәләк-күбәләк кар ява башлады. Балага салкын тияр бир үземә, костюмым белән төрим, дим. Ә син көлә-көлә читкә ки-

тәсең. Мин кулларымны сузып синең арттан йөгерәм, инде Мәхмүтне алам гына дигәндә, уянып китәм...

Таллар песи чыгардымы инде? Каз оясы үрүче бармы? Чормада мин ясаган яңа сыерчык оясы бар. Колга тапсаң, өй кыегының бу башына куйдыр. Фәтхетдин абзый кадаклап бирер әле. Мин кушкан диген. Өйнең ике башында ике оя булсын. Мәхмүтне сыерчык сайраганны тыңларга алып чык. Бомбага тота башладылар, тревога! Хушыгыз!..»

(1945 елның мартында язган хаттан.)

Бүген төшке ашны Хәлимә үзе китерде. Ул ап-ак халат кигән, күзләренә сөрмә тарткан. Ашны беренче булып Гата алды. Сәлим юына иде. Мәхмүт Рамилгә сизелер-сизелмәс кенә баш какты: син ал, янәсе. Рамил ышанычсыз адымнар белән генә Хәлимә каршына барып басты, тегесенең дә хәрәкәтләре акрынайды. Ул ашын болгата да болгата, әйтерсең лә, термос эченә бик кирәкле әйберен төшереп җибәргән. Мәхмүт юри авыл ягына караган булып утырды, ә үзе колагын торгызды, күзенең чите белән генә аларны күзәтте.

— Үпкәче,— диде Рамил, ишетелер-ишетелмәс кенә итеп.

— Үзең дә,— диде тегесе, савытка аш салып.

Рамил ашын алып бирегә атлады. Юк, бу Рамил түгел, бөтенләй икенче кеше иде. Ничек кенә яшерергә тырышмасын, аның йөзендә мең кояшның яктысы һәм җылысы бар иде.

— Бер очтан миңа да алып кил инде,— диде Мәхмүт, аңа күз кысып.

Бу сүзгә Рамилнең болай да көч-хәл белән генә җыелып торган авызы борчак басуы кадәр булып җәелеп китте, ул аны Хәлимә янына барышлый, бинһая көч куйса да, барлап-җыеп бетерә алмады, тигез ак тешләре чирек ай кебек балкыды. Табигатьтәге нинди генә серле көчләрнең ярдәмнәре булгандыр, егет, кайнар шулпа белән беркемне дә коендырмыйча, ашны Мәхмүт каршына китереп куя алды.

— Сәлимгә дә алып кил инде, тагын бер өстәмә рәхмәт ишетерсең,— диде Мәхмүт.

Рамил күзләреннән якын туганлык хисләре чәчте дә тагын Хәлимәгә таба очты. Тегесе тагын термосны шалтырата-шалтырата ашны озаклап болгатты. Рамил аның ак һәм матур колак яфрагына иреннәрен тигезә язып пышылдады:

— Бүген тегендә чык...

Егетнең сулышы Хәлимәнең колагын пешерде, кайнар аш буы бу сулыш көйдерүе белән чагыштырганда бик зәгыйфь тоелды. Балдызының җавабын ишетергә теләп, Мәхмүт авызына капкан кайнар шулпаны йотмыйча торды... Ләкин ул дәшмәде, ашны салды да салды, Рамилнең куллары савытны авышрак тотканлыктан, аның шулпасы термоска акты да акты. Монда, әлбәттә, иң откан кеше Сәлим иде. Аның савыты макарон токмачы белән бәрәңгедән түбәләмә булды. Бу кадәр макарон Сәлимнең авыз эченә кереп югалырга да, мыегы арасына кереп уралырга да җитәрлек иде.

— Чыгасыңмы? — диде Рамил.

Тегесе дәшмәде, керт-керт басып ипигә киткән булды... Менә шулай көйдерә дә инде алар нәселе, шулай көйдергән саен сөйдерә. Хатын-кыз кирәк кадәр яндырсын, кирәк чакта ялындырсын. Шулай булган саен көчлерәк яратасың ул каһәр төшкән затларны...

Эшкә керешергә генә торганда Әмирхан килеп төште.

— Егетләр, комбайннарны бодайга көйлибез,— диде ул.

Мәхмүт сагаеп калды.

— Ә борчак?

— Күпме генә борчак бар монда? Кулдан чаптырам.

Аның сүзләре барысына да яшен суккандай тәэсир итте.

Мәхмүт берәм-берәм егетләргә карады.

— Әнкәйләргә чалгы тоттыру оят булмасмы соң?

Ана Рамил өстәп куйды:

— Чалгы белән борчак чабуны онытканга йөз ел бит инде. Без шуны кабат кайтарып дан алабызмыни, Әмирхан абый?

Әмирханның кызыл чырае каралып китте, яшел күзләре сикерештеләр.

— Интегегез алайса,— диде ул.— Мин әле сезне жәлләп кенә...

— Ике комбайн борчакта калсын, икесе бодайга керсен,— Гата, әйттемме мин сезгә, дигән төсле карап тора башлады. Әмирхан, шуны гына көткәндәй, тизрәк сүз кыстырды:

— Мин килешәм. Кемнәр кала?

— Әнә бит комсомоллар,— диде Гата, йөзенә елмаю чыгарып. Рамил аңа таба талпынып куйды.

— Ә нигә? Кирәк икән — мин калам.

Сәлимгә дә сүзгә кушылырга чират җитте:

— Хәлимә аш китерсә, син бу басуда ай буе да ятарга риза.

Мәхмүт катгый карарга килде.

— Ярый, бөтенегез дә бодайга китәсез. Үзем калам,— диде ул.

— Мин дә.

Монысын Рамил әйтте.

— Менә мәсьәлә хәл ителде,— Әмирхан кузгалды.

— Киттек, Сәлим,— диде Гата.

— Син кит. Ә мин... калам.

— Җыен тел бистәсе!— Гатаның тавышында чын-чынлап үкенү яңгырады.— Сезнең белән ләчтит сатып вакыт үткәргән мин юләр!

Әмирхан аның җилкәсенә кулын салды.

— Әйдә, Гата, булмаса үзең төш бодайга.

— Кем синең белән бер сүздә — шул төшсен!

Гата беренче булып комбайнына юнәлде.

— Яхшылыкның кадерен белмәгәч, үзегезгә үпкәлисез инде,— Әмирхан китмәкче булды, аннары ниндидер көч тарткандай туктап калды һәм, Мәхмүткә туп-туры карап, болай диде:

— Әгәр борчак уңышы кимесә, район җитәкчелеге алдында син җавап бирерсең!

Егетләр төнге унга кадәр баш күтәрмичә урдылар.

«...Гитлерның бугазыннан алыр көннәр дә җитте. Берлинга якынлашабыз. Сугыш озак бармас диләр. Сагынуны әйтеп бетерерлек түгел, үзем генә беләм дә эчемә йотам. Барыбыз да шулай. Инде сыерчыклар килгәндер. Ыкта бозлар киткәндер, яр буйларын тутырып боз киткәнне карагансыздыр. Минем бу хатым барып җиткәндә чәчүгә дә төшәрсез. Пар күтәрелеп торган басуларыбызны күрәм, борынымда туфрак исе. Әгәр бер кайтып әлгәшсәм, авылдан мәңге чыкмас идем, чәчү чәчүләрне, печән чабуларны, урак уруларны дөньяда бернигә алыштырмас идем. Оҗмах шул икән ул. Сабан туйларына кайтып җитеп, печәннәр чабарга, бергәләп уракларга төшәргә насыйп булсын иде.

Сәрбиҗамал! Сагыну күңелемне дә йомшартты бугай инде, Мәхмүтнең кулын кәгазьгә төшереп җибәр әле. Хәзер берни турында да уйлый алмыйм, каршымда сез икегез торасыз да авыл тора...»

(1945 елның апрелендә язган хаттан.)

Бүген дә көн чалт аяз булды, ярты көн тукталусыз, ватылуларсыз эшләделәр. Төшке аштан соң Мәхмүтнең эше кирегә китте. Җай гына урып барганда комбайнның вариаторы кырылып чыкты. Техник хезмәт күрсәтү звеносы килде, ләкин запас вариатор юк иде. Искесен ремонтлау хәтсез вакытны алды. Шул арада егетләр борчакны бетерә яздылар. Күп булса, ярты сәгатьлек эш калгандыр. Шушындый чакта сына-

туына Мәхмүтнең кәефе кырылды. Ул ашыга-кабалана комбайнын куз гатты, ләкин бер мәртәбә дә әйләнергә өлгермәде, авыл юлыннан тузан болыты күтәреп бирегә элдерүче фургон күренде. Кичке ашка әле иртә иде. Нәрсә булыр? Менә автомашина туп-туры монда таба борылды. Кабинада ак халатлы Хәлимәне күрү белән Мәхмүтнең йөрәге жу итте. Димәк, теге шомлы хәбәрнең сәгате сукты. Ул комбайнын туктатты, штурвалга ике куллап тотынган килеш башын түбән иде... Машина килеп җитте, Хәлимә тып-тын басып күтәрелде... Тукта, ни булды? Балдызы кинәт кенә аның башын борды да тузанлы иреннәреннән үбеп алды.

— Кызың бар, җизни, кызың!

Мәхмүтнең башы әйләнеп китте, ул чак кына егылмыйча калды. Аннары Хәлимәнең ике җилкәсеннән чытырдатып тотып, берни күрмәс күзләре белән аңа төбәлде.

— Ничек?! Ничек алай?!— тамагыннан ниндидер хырылдау гына чыкты.

— Шулай, кызлар җиде айдан туа!— диде Хәлимә чыркылдап.

Мәхмүт кулларын алды — ап-ак халатның җилкәсендә бармак эзләре ярылып калды.

— Халатны бетердең, юләр!

Хәлимә ак күбәләк кебек очып төште дә Рамил кишәрлегенә йөгерде. Менә комбайннар барысы да туктап калды, өч кара, бер ак нәрсә Мәхмүткә таба якынлаша башлады. Ул томан эчендә җиргә төште.

— Котлыйм!— диде Гата, аның аркасына авырттырып сугып.— Синнән әрмән коньягы.

— Авылда кызлар җитмәүне искә алгансыңдыр, молодец!— диде Сәлим, кулын кысып.

Рамил бер сүз дә дәшмәде, кила-килешкә аны ничектер эләктереп алды һәм Мәхмүт үз аякларының борчак басуыннан аерылуын тойды... Аны дүрт мәртәбә һавага чөйделәр. Гатаның зарланганы ишетелде:

— Вот бүтәкә, күтәрмәле түгел, төеп тутыргынмыни!

Мәхмүт җиргә басарга өлгермәде, Әмирхан килеп туктады. Кулын кысты, ул арада ярты чыгарды.

— Әйдә, кияү, кызың белән!— диде ул, тулы рюмка сузып.

Мәхмүт болай да исерек иде, рюмканы ничек алганын сизми дә калды. Әмма шул секундта аңа нидер булды, рюмка утлы күмер кебек бармакларын пешерде, бөтен шатлыгы каядыр очты. Гаепле кешедәй ул әле Хәлимәгә, әле Гатага, әле Сәлимгә, әле Рамилгә карады, иреннәре нидер әйтергә, акланырга теләгәндәй селкенделәр, тик тавышы чыкмады.

— Әйдә, суфыйланма инде,— диде Әмирхан, аның аркасына җиңелчә генә төртеп.

Мәхмүт кинәт аңа борылды, рюмкасын бик авыр йөк күтәргәндәй дерелди-дерелди күтәрде дә аракыны Әмирханның йөзенә сипте. Әмирхан корт чаккан кебек сикереп куйды, ләкин үзен бик тиз кулга алды. Битен сөртмәде, тавышын күтәрмәде, сүзләрен сыгып чыгарды:

— Рәх-мәт, кияү...

Барысы да тынсыз калдылар. Күзләр Мәхмүттә иде. Ярым пышылдау булып аның карлыккан тавышы ишетелде:

— Борчак өчен,— диде ул, сулышын еш-еш алып.

Әмирхан нидер әйтмәкче булды, ләкин әйтә алмады, аңа һава җитми иде, күрәсең. Ул мотоциклына таба атлады, туктап артына борылды һәм шешәне җиргә бәрде. Бер минуттан аның мотоциклы дылык-дылык авылга таба элдерә иде инде.

Мәхмүт иптәшләренә күтәрелеп карамады, күперчеккә менмәкче булды. Гатаның сөякчел кулы аны беләгеннән эләктерде.

— Аз гына сабыр ит әле, әти кеше...

Ул комбайнына йөгерде, берничә минутта сумка тотып килде. Сүзсез генә бер ярты, рюмка чыгарды. Мәхмүтнең кулыннан буш рюмканы алды да мөлдерәмә тулысын тоттырды.

— Бәхетле кыз булсын!

Мәхмүтнең күзенә яшь тыгылды. Ул яшьләрне Хәлимә үзенең хуш исле йомшак бармаклары белән, йөрәкнең иң авырткан җирен иркәләп үткәндәй, сөртеп алды. Мәхмүт Сәлимнең шатлыктан кысылып солы кебек кенә калган күзләрен күрде, елмаюын яшерергә теләп иренен тешләгән Гатага сизелер-сизелмәс баш какты... Рамил көрәктәй учына берничә кузак салып алды, өреп җилгәрде һәм аңа сузды. Мәхмүт искиткеч җиңеләю тойды, ирен читләреннән агыза-агыза, җылы аракыны эчеп җибәрде. Аннары ашыкмыйча гына Рамилнең учыннан борчак алып капты, тыгыз шарчыкларны тешләре белән яньчеде, чәйни башлады һәм телендә туганнан бирле таныш тәм тойды. Бу тәм — дөньяда бернигә дә алыштыргысыз, дөньяда берни белән дә бутап булмый торган тәм, ачлы-туклы ятим балачакларны, җиләктәй яшьлек елларын, барлык үткәннәрне, кайгы-шатлыкларны искә төшерә торган тәм иде... Аңарга әниләр сөтенең тәме дә, тау буе чишмәләренең сафлыгы да, кырларда-тугайларда түгелгән маңгай тирләренең ачысы да сыйган иде... Борчак каты иде, аны ныграк кыскан саен тәме күбрәк чыга иде.

Ә янәшәдә хуш искә күмелгән бодай басуы тын гына ямансулап аларны көтә иде...

«Кадерле Соня! Ирегез Сәләхетдин минем дустым иде. Сезнең сәлам хатларыгызны бергәләп укып юана идек. Сәләхетдин Берлин өчен барган сугышларның берсендә каты яраланды, үз кулларымда җан бирде. Үлгәндә дә Мәхмүт белән Сезнең исемне кабатлады, соңгы сәламен язарга кушты. Ул кыю сугышчы, олы җанлы кеше иде. Мәхмүтне аңа лаек итеп үстерегез.

Хөрмәт-ихтирам белән гвардия рядовое Егор Николаев.

30 апрель 1945 ел».

Бу хат белән янәшә саргаеп беткән кәгазь кисәге, аның уртасында корым карасы белән сызылган нәни генә бала кулы...

# Әхәт Гаффар

# 1945 ЕЛГЫ ХАТ

хикәя

Аңыма килгәч, палатада икәнемә төшендем. Ак түшәмне күрдем дә, әһә, ятам икән, мәйтәм. Яткач, әлегә тере икән бит инде. Әйе, кабердә дә басып тормыйлар, яталардыр, тик аның түшәме ак булмас, мәйтәм.

Шулай итеп, ак түшәм астында ятам икән. Түшәмнең аклыгын күрү, күз исән дигән сүз ич инде, әйеме? Һич югы — берсе. Хәзер, мәйтәм, тикшерәбез аны. Тикшерүем шул: берсен чытырдатып йомам — түшәм юкка чыкмаса, дөнья яктысы минеке. Сул як кайда да, уң як кайда — әле аңышмаган. Хәер, дөнья яктысына карарга кайсы күз дә ярый, ә солдат өчен уңы кирәгрәк... Мушкадан фашист башын күрергә миңа уң күз кирәк. Ул бит индө күнегелгән: аткан саен сул күз йомыла. Бу юлы да күз элеккечә йомылгандыр. Бүтәнчә күнегелмәгән: разведкада аягүрә генә черем итәсеңме, окопта йокымсырыйсыңмы — фашист килгәнне сизелсә, башта уң бәбәк чәчрәп ачыла... Карыйм — түшәм яңа кар кебек ап-ак. Челт бүтән бәбәкне — ак!.. Шул рәвешчә бер кавым челт-мелт күз уйнатып яттым. Унсигез ел яшәп, кызларга да шул тиклем күз кысканым юк иде. Кызлар дигәннән, фронтта ул нәрсәгә вакыты да, җае да тимәде, ә аңарчы... Мин сугышка үз теләгем белән унҗидедә чыгып киттем, син озата да белмәдең. Хәер, унҗидедән алынгач, буй-сын кызларга каш сикертерлек булмагандыр анысы, ә берсеннән дә керфек кагулар тәтемәде, гөнаһысына кермим.

Ярый, түшәм ак, күзләр, үзең беләсең, кара инде минем, кызларга күз кыскалау качмас. Үземә керфек кага-кага кайберәүләрнең күз нурлары уңып бетәр әле. Кызларны әйтәм. Сабырлык кирәк. Безнең әти «ир башы үлемнән качарга җай таба, мәгәр ходай аңа хатын-кыздан котылып калырлык мәдәт бирмәгән» дия торган иде... Әйе, күз исән икән, кызлардан керфек кактырырбыз! Кызлар дигәч тә... Җиңеп кайткач, сайланып йөрер бу дип уйлама тагын...

Ә менә куллар ни хәлдә икән? Кара керфекләр кактырып та, зифа билләр кочарлык әмәлең булмаса — нишләрсең? Кызлар биле кочканчы, сугышны очлап кайтасы бар бит әле. Монда кулсыз — хәлләр мөшкел. Сугышта кулсыз — ике кулсыз инде ул. Автомат тәтесенә басарга бер генә бармаклы калганы да җитә. Штыковойда мин ул фашистның бугазын кулсыз-нисез дә чәйнәп өзәргә күп сорамыйм.

Башны күтәреп карарга чамаласам — кая ул: муен белән гәүдәне бер итеп урап куйганнар, селкетерлек тә түгел. Туң кәбестә кучәне күк шыкырдатып катырганнар.

Күзләрне кыскалап кайбер нәрсәне ачыкладым, хәзер иң әүвәл уң кулны башларга кирәк. Дөньяда ашар ризыгың бетмәсә (баш очында ак түшәм торгач, минем моңа законный өметем бар), әйе, дөньяда ашар ризыгың бетмәсә, котелок белән авыз арасында анысы сул кул да адашмас, ачтан үлмәм, шәт. Шуңа күрә бу мәлдә уңын барлау хәерлерәк, ансыз үлем белән бер. Берзаман уң кулны граната томыргандай айкап торып җибәрүем булды — берәүнең «чырр» итеп кычкыруы бөтен палатаны басып китте, минсиңайтим!.. Күзне кыегайтып карасам, ак халат кигән шәфкать туташының билдән түбән йомры бер җиренә шапылдатып сукканмын бит, гөнаһ шомлыгы! Оятымнан нишләргә белмичә күзләрне түшәмгә терәдем дә каттым. Шәфкать туташы: «Егет икәнсең, Сәләхетдинов! Ниһаять, аңга килдең, ут борчасы!» — дип, битемнән үбәргә иелде, шунда сул кулым да үз урынында икәнен белеп алдым. Куллар ул, малай, итек балтырыннан кашык чыгарып, итле ботка ашар өчен генә түгел, бүтән эшкә дә ярый икән ич әле.

Күз күрә, колак ишетә; куллар, ялгыш кына булса да, кайбер йомры җирләрнең хәл-әхвәлен белеште, хәзер чират аякка җитте. Миңа, көтүче Җиһангир абыйның өч тракторчы малае шикелле, танк иярләргә туры килмәде. Мин — пехота. Ә пехотаны үзең беләсең, аяк йөртә. Аяк шәрифләренә ул-бу була калса, миннән ниткән пехота? Пехотаның бөтен дәрәҗәсе аякта. Ә минә аякның уңы-сулы юк. Тикмәгә генә ике чабата бер кием дими торганнардыр инде аны. Аякның аның икесе дә кирәк. Каз гына ул сыңар аякта тора һәм чүгә белә.

Шунда яныма шәфкать туташы борылып килгәнен тоеп алдым. Янәшәмә килеп басты — тулган айдай елмая! Хәлем шул хәтле дә мөшкел микәнни соң? Шуны сиздермәскә тырышып, шул тиклем елмая инде бу дип йөрәк әрни. Метр да туксан ике сантиметрлы буем белән стройда барган чагымда кайда иде соң синең бу елмаюларың дип, аяк тибеп, үтерепләр кычкырасы килә бит, каһәр суккыры! Ни тавыш чыкмый, ни аяк типми. Ә бу исә артка яшергән кулларын сузып, минем аяк очына ике чүәк куймасынмы, чукынчык! Минә шунда ак түшәм эреп күздән югалды. Кулларның җегәре китте, аяк оеды.

Мышык-мышык борын тарткалаганмын да, балавыз сыга язганмын. Шәфкать туташы: «Ела, ела, иптәш Сәләхетдинов. Ындыр табагы хәтле аркаңнан ярты котелок снаряд ярчыгы чүпләгәндә бер тапкыр да ыңгырашмаган идең, хәзер инде рәхәтләнеп ела! — дигәч, язгы ташу шикелле җәелепләр торып елыйсым килеп китте. Елмайдым гына. Ә хәл еларлык ахрысы: аркам яраланса, ник корсакта ятмыйм соң мин? Шәфкать туташы: «Иң әйбәте, аңга килдең, Сәләхетдинов»,— дип юата да бит... Ярар, күз күрер тагын. Беренче генә яралануым түгел. Бусында савыкмыйча калырга һич тә ярамый, йөзе кара Берлинга җитеп киләбез ич.

Бу хатымдагы шәмәхә карандаш белән язылган юллар урыны-урыны белән чыланып җәелгән икән, аны минем шатлык яшьләре дип уйлый күрмә тагын. Мин әле хат язарлык хәлдә түгел, шәфкать туташына әйтеп торып кына яздырам. Шәмәхә карандаш юлларына аның күз яшьләре тама. Үзе яза, үзе елый, юләр. Ник елый торгандыр — белмим. Ачыкланганча, һәммә җирем бөтен, буем шул ук — бер карыш та кимемәгән килеш.

Ярый, сау булып тор. Сине сагынучы пехота Сәләхетдинов диеп белерсең».

Авыр яраланганнан соң кыска гына вакытка аңына килеп, күңелендә йөрткән кызга үз гомерендә беренче һәм соңгы хатын әйтеп яздырган гвардия рядовое Сәләхетдиновны шул кечие госпиталь урнашкан замок бакчасына күмделәр. Карт юкә төбендәге җепшек кар каплап өлгергән яңа кабер шәфкать туташы учындагы адрессыз хатны хәтерләтә иде.

Халык гомере — мәңгелек диләр,
Ә син, Тукай, халык куйнында.
Илең белән мәңге бергә син
Мәңгелекнең олы юлында.

Х. Туфан. «Без һаман бергә», 1959.




Казанның Татар зиратында Г. Тукай кабере.
Татьяна Зуева рәсеме.

Эльмира Якубова

# ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ҺӘМ ТАТАР МУЗЫКАСЫ

*«Кечкенәдән үк күңелемә урнашкан җырулар сөймәкемнән миндә туган телемезне сөю тугъды».*

Г. Тукай

Габдулла Тукайның иҗади шәхесе формалашкан беренче рус революциясе чоры социаль-экономик мөнәсәбәтләр өлкәсендә дә, рухи тормыш өлкәсендә дә киң халык массаларының инициативасын кузгатып җибәрде. Монархиягә һәм, аеруча, дингә каршы тойгыларның актив таралуы нәфис сәнгать өлкәсендәге кыйммәтләргә бәя бирүдә принципиаль әһәмияткә ия иде. Шәригать зынҗырлары шактый йомшады, ә милли сәнгатебез үсешен тоткарлап-йомып торуда ул беренче урыннарны тота иде. Башка сүзләр белән әйткәндә, Тукайның иҗади ныгуы гасыр башында татар җәмгыяте тормышының демократлаша баруы шартларына туры килде. Табигый ки, бу процесс иске белән яңаның, реакция белән прогрессның каты көрәше нәтиҗәсендә нык катлауланды. Замана мәйдан уртасына моңарчы күзгә күренмәгән көчкә, карашларга һәм дәрт-дәрманга ия булган, халык язмышын үз язмышы итеп карый алырлык дәрәҗәдә җаваплы буһган көрәшче каһарман килеп чыгуын таләп итте. Бу мактаулы, калку урынны Тукай алды. Мәдәният прогрессында бөек татар шагыйренең әһәмиятен билгеләп, Чыңгыз Айтматов: «Андый шәхесләр тарихның иң киеренке, иң кискен, иң кыен, иң ымсындыра торган чорында килеп чыгалар»,— дигән иде.

Тукай үз халкын гомумкешелек культурасының иң югары кыйммәтләреннән «авыз итәргә» өндәде. Максатының халыкны агартуда икәнлеген бәян иткәндә дә шагыйрь мәдәни яңарыш мөмкинлекләрен барыннан да элек халыкның үзендә күрде. «Халык зур ул, көчле ул, дәртле ул, моңлы ул, әдип ул, шагыйрь ул» дигән даһи сүзләре дә нәкъ әнә шул хакта иде аның.

Замана баласы буларак, шагыйрь шул чорның иң җитлеккән проблемаларын күтәрә. Алар арасында халыкның рухи үсеше белән бәйләнгән мәсьәләләр төп урынны алып торалар.

Тукай вакытындагы татар җәмгыяте тормышы чуар иде һәм бертөрле генә дә түгел иде. Прогрессив профессиональ сәнгать (әдәби-музыкаль кичәләр һәм публика өчен концертлар оештыру, милли театр труппасы, халык музыка кораллары оркестры оештыру, һ. б.) үрентеләре белән беррәттән, арзанлы әдәбият, музыка учаклары да яшәп килде. Культурадагы яңа күренешләр белән бергә реалистик художество тәнкыйте дә пайда булды. Аның иң күренекле, иң талантлы вәкиле Тукай иде. Шагыйрьнең татар вакытлы матбугатындагы чыгышлары аның иҗади сизгерлеге һәм заманының культура тормышындагы яңа күренешләрне тиз тотып ала белүе хакында сөйли. Ул сәнгать даирәсендәге азмы-күпме күзгә ташланырлыгы булган һәр вакыйгага үз мөнәсәбәтен белдерми калмый. Тукай мәгърифәт өлкәсендәге файдалы һәм прогрессив чараларны тәбрикләп каршылый. Үз фикерен публицистик мәкаләләрендә генә түгел, ә бәлки шигъриятендә дә актив чагылдыра. «Әдәбият ахшамы ясаучы яшьләремезгә» шигырендә ул рухланып, болай дип язды:

*Сөям мин сезне, сез — чын яшь егетләр;*
*Өмет бар сездә, сез — интеллигентлар.*
*Сез яңа пешкән, җитешкән батырлар;*
*Хәзер яшь батырлар — бәя биргесез.*
*Бу кичә — чиксез гүзәл кичә;*
*Иртән дә, кичен дә бу минем исемдә.*

Шул чорның бөтен культура тормышы белән кызыксынган Тукай игътибарыннан музыкаль үсеш проблемалары да читтә калмый, билгеле.

Татар профессиональ музыка иҗаты һәм башкару сәнгате егерменче гасыр башында ярәлгы хәлендә генә була әле. Куәтле иҗтимагый күтәрелеш (1905—1907 еллар революциясе) нәтиҗәсендә татар халкының югары сәнгатьчә иҗатка булган омтылышы йокыдан уянып дулкынлана башлый. Яңа, революцион җилләр, халыкара мөнәсәбәтләрнең интенсив үсеше, татар халкының бу көнгә кадәрге милли азатлык һәм революцион көрәш тәҗрибәсен шактый баеткан аң үсеше инде фольклорда гына түгел, ә профессиональ югарылыктагы үрнәкләр аша да үзен сәнгатьчә милли чагылдыру теләге уяталар.

Һәр милли профессиональ сәнгать кебек үк, татар музыкасы да халык иҗатыннан килеп туды һәм беренче татар композиторларының әсәрләре халык көйләре прототипларына органик рәвештә бәйләнгән булулары белән аерылып тордылар, ә кайвакыт халык көйләре темаларын эшкәртүдән гыйбарәт иделәр.

Егерменче йөз башы ярымпрофессиональ милли композиторларыбыз арасында Фәттах Латыйпов аерылып тора. Үзенчәлекле таланты һәм осталыгын үстерүе нәтиҗәсендә соңга таба ул үз вакыты татар музыкаль эстрадасында иң популяр фигуралардан була. Вокаль әсәрләрен ул, гәрчә алар формалары һәм сурәт төзелешләре белән халык җырларыннан аз аерылсалар да, романслар дип атый. Халык кораллары оркестры өчен дә көйләр язган Заһидулла Яруллин талантлы музыкант була. Әйтик, аның Тукайга багышланган маршы бүгенге көндә дә бик популяр (шагыйрь үлгәннән соң бу әсәр «Тукай маршы» дип йөртелә башлый). Бу марш татар музыкасы тормышына Европа жанрлары килеп керә башлагач барлыкка килгән жанр әсәрләренең беренчеләреннән иде. Бу чорда яңа ритмнар, яңа моң әйләнмәләре үзләштерелә. Алар милли үзенчәлекле музыкаль тасвирламалар белән бергә кушылалар.

Бу чорда башкару эшчәнлеген җәеп җибәргән һәм киң танылган җырчыларның берсе — Камил Мотыйгый. Концертларында ул татар җырларын гына түгел, ә гарәп, фарсы, төрек җырларын да башкара. Халык скрипкачысы Мөхәммәтша Мостафин, пианист һәм скрипкачы Гали Зайпин, композитор һәм халык көйләрен җыеп тикшерүче Солтан Габәши, музыкант Фәйзулла Туишевларның башкару сәнгате халыкның мәхәббәтен яулап ала.

Габдулла Тукай гасыр башы сәнгать интеллигенциясенең күренеклерәк һәр вәкиле белән иҗади бәйләнештә тора. Ул алар белән милли музыкаль культураның бик күп проблемалары хакында әңгәмәләр үткәрә, репертуар турында үз фикерләрен әйтә, милли культуралар казанышларына үз бәясен бирә. Шул чорда Казанда эшләгән сукыр музыкант И. А. Козлов, шагыйрь белән булган бер кызыклы очрашуны искә ала. Козловның бер концертыннан соң,— ә ул концертта төрек композиторлары әсәрләре яңгырый,— Тукай, башкаручы белән сөйләшкәндә, төрек авторларында милли үзенчәлек аз, чөнки аларның күпчелеге музыкаль белемне, туган туфрактан аерылып, Көнбатыш Европада алганнар, дигән фикерне әйтә. Тукайның бу сүзе аның профессиональ әсәрләрдә милли колоритны саклау кирәклеге белән кызыксынуы, музыкаль сәнгать күренешләренә мөстәкыйль һәм тәнкыйть күзлегеннән чыгып бәя бирүе хакында сөйли.

Тукай чорында музыкаль пропаганданың тагын бер формасы — «Шәрык музыкасы кичәләре» барлыкка килә. Бу кичәләрдә шагыйрь үзе дә бик теләп катнаша. Шәрык клубында үзенең шигырьләрен укый һәм татар халык иҗатына багышланган лекцияләрен сөйли. 1907 елның 26 октябрендә Сәгыйть Рәмиев тарафыннан Казанда беренче милли әдәби-музыкаль кичә оештырыла. Бу кичә халык университетлары Казан җәмгыятенең музыкаль секциясе тарафыннан алда үткәреләчәк күп Шәрык кичәләренең беренчесе була. Тукай бу кичәләр белән бик кызыксына һәм үзе дә аларда берничә тапкыр катнаша. Кичәләрдә даими катнашучылар И. Козлов һәм Гречанинов эшкәртүендә татар-башкорт көйләрен башкаручы җырчы Г. Трейтер була. Концертларда шулай ук Г. Зайпин да катнаша, ул вакыт-вакыт программасына Көнбатыш композиторлары әсәрләрен дә кертә (өлешчә, аның бер концертта Данкляның Бишенче вариациясен һәм Вердиның «Травиата»сыннан соло башкарганлыгы турында мәгълүматлар бар). Татар тыңлаучысын дөнья музыкаль классикасы белән таныштыру максатыннан Европа көйләрен татар тексты белән җырлаган Камил Мотыйгый чыгышлары

да оригиналь яңгырый. Аның вокаль репертуарында Глинканың «Руслан һәм Людмила» операсындагы фарсы хорының Тукай сүзләренә җырлануы игътибарга лаек.

Менә шушы бөтен музыкаль башкару эшчәнлеге киң татар аудиториясен дөнья профессиональ сәнгатенә якынайтуга хезмәт итә һәм яңа, тагын да югарырак дәрәҗәдәге иҗатка юл күрсәтә. Алдарак атап үтелгән башкаручылар репертуарындагы позитив момент дип аның интернациональ эчтәлеген күрсәтеп үтәргә кирәк. Социаль-культура процессында демократик тенденцияләр шуңа китерде. Әдәби-музыкаль кичәләрдә татар көйләре белән беррәттән рус һәм чит ил музыкасы, шулай ук Россиянең башка халыклары (мәсәлән, башкорт, әзербәйҗан, үзбәк) музыкасы да күп яңгырый. Татар аудиториясе өчен әле яңа форма булган инструменталь ансамбльләр оештыру да прогрессив әһәмияткә ия була. Халык оркестры белән И. Галиәкбәров җитәкчелек итә. Бу беренче музыкаль-башкару коллективы скрипкачылар белән мандолиначылардан гыйбарәт була.

Тукай, культура өлкәсендәге шушы яңарыш һавасын сулап яшәгән һәм эшләгән бер вакытта, татар халкы тормышындагы яңа рухи процессларга үз мөнәсәбәтен белдерми калмый. Әле Җаекта чакта ук ул беренче әдәби-музыкаль кичә үткәрүне котлап, татар җәмгыяте тормышына бу вакыйганың нык тәэсир итәчәген фараз кыла: «Әдәбият ахшамы карт аталарымызның чын йөрәгеннән чыккан «Тәфкилеф», «Әллүки», «Сакмар суы» көйләрен, үлгән җиреннән яңадан терелтеп, туган вә туачак балаларыбызның күңеленә яңга-яңга милләт хисләре, истикъбаль (якты киләчәк) дәртләре галырга хезмәт итеп, милләт балаларының үлгән күңеленә, саба җиле шикелле, рух өрәчәктер.

Әдәбият ахшамы үзебезнең көйләребез, үзебезнең моңлы мотивларымызны кабахәт фәхешханәләр почмагыннан түгел, үзебезнең яшь зыялыларыбыз авызыннан ишетерәчәктер».

Бу мәкаләдә егерме яшьлек тәнкыйтьченең өлгергәнлеге һәм фикер киңлекләре күз алдына килеп баса. Иҗатының башлангыч чорында ук Тукай халык җырлары яшәешенең позитив һәм негатив якларын тәгәл ачыклый, милли репертуарның сафлыгы, чүпләнмәве ягында тора, татар җыр иҗатының иң яхшы үрнәкләрен башкарырга һәм популярлаштырырга өнди. Шул ук мәкаләсендә ул: «Зинага чакыра торган музыка хәрам булса да, алга китәргә, тәрәккыйга чакыра торган музыка мөстәхәб (эшләнүе гүзәл эш), хәтта ваҗиб (эшләнүе мәҗбүри эш) уктыр»,— ди.

Тукай музыканың тәрбияви, рухи әйдәүче көч икәнлеген ачык күрә. Бу мәкалә ачыктан-ачык антиклерикаль юнәлештә язылган. Мулла-ишаннарның икейөзлелеген фаш иткәндә, Тукай аяусыз. Иҗатының башлангыч чорында язылган «Хиссияте миллия» дигән икенче бер мәкаләсендә Тукай халыкны караңгылыктан яктылыкка, иреккә чыгарачак яңа кешеләр — баһадирлар хакында хыяллана: «Милләт образауный кешеләргә һәм халык файдасын һәртөрле үзенең шәхси мәнафигыннан вә корсак файдаларыннан өстә тота торган, милләт файдасын күз өстендәге кашы дәрәҗәсендә газиз тота торган милләт арысланнарына мохтаҗ. Милләт аталарга, аналарга, мөгаллимнәргә, мөгаллимәләргә, мөрәббиләргә вә мөрәббияләргә, чын мөхәррирлек табигатьләренә вә сәляхиятләренә мохтаҗ. Безнең милләт тә, башка милләтләрдәге кеби, хамисез (яклаучысы булмаган), мәлҗәэсез (сыеныр урыны булмаган), фәкыйрь вә эшче халыкның файдаларына тырышучы, биш фәкыйрь кешене бер бай этенә алыштырыр вакытлар үткәнлеген аңлаучы вә аңлатучы егетләргә мохтаҗ. Безнең милләт тә Пушкиннәргә, граф Лев Толстойларга, Лермонтовларга мохтаҗ. Кыскасы гына, безнең милләт тә башка милләтләрнең тәрәккыйларенә сәбәп булган чын мөхаррирләргә, рәссамнәргә, бардакханәдән чыкмаган яңа-яңа шигырьләргә, музыкаларгә вә гайреләргә мохтаҗ».

Халыкның үзендә сәнгать мөмкинлекләренең чиксезлеген аңлаган шагыйрь культура яңарышы уңае белән үзенең карашларын еш кына мәгърифәтчелек рухында яза. Аларда төп фикер булып халык аңына яңа уйлар һәм рухи омтылышлар кирәклеге куела. Бу хакта, мәсәлән, аның 1906 елга караган «Безнең милләт үлгәнме, әллә йоклаган гынамы?» дигән мәкаләсендәге түбәндәге юллар сөйли: «без ул милләткә әдәбият гөл-сулары сибик, газетә мәрвәхәләре (веерлары) илә йомшак җил истерик һәм авызына иттихад вә иттифак (берләшү, бергәләп эшләү) сулары салыйк; җан рәхәте

булган музыкалар илә дәртләндерик, хәтта рәсемнәр илә милләтнең үз сурәтен үзенә күрсәтик: тәмам күзе ачылсын, дүрт ягына карансын, гакылын җыйсын...»

Тукайның иҗади йөзен тасвирлаучы иң якты якларыннан берсе — аның халык авыз иҗаты белән тирәнтен кызыксынуы. Халкыбызның җыр хәзинәсе үрнәкләрен җыю һәм пропагандалауда аның хезмәте гаять зур. Тукай, күп җырлар җыеп, аларны формалары, характерлары, эчтәлекләре ягыннан анализлый. Шагыйрьнең халык җырларына булган керсез мәхәббәте, аларның гүзәллеген, сәнгатьчә байлыгын, этик һәм фәлсәфи тирәнлеген ачып салырга омтылуы, Тукайга «халык җырлары — халык тарихының иң кадерле хәзинәсе ул» дигән зур мәгънәле нәтиҗәгә килергә ярдәм итә. Үзенең «Халык әдәбияты» дигән лекциясендә шагыйрь халык җырларына бәя биреп болай дип язды:

«Халык җырлары — безнең бабаларымыз тарафыннан калдырылган иң кадерле вә иң бәһале бер мирастыр. Әйе, бу — кадерле мирас, кыйммәтле мирас! Мәгъмүр Болгар шәһәрләре, Болгар авыллары, бер дә булмаган төсле, кырылдылар да беттеләр, эзләре дә калмады.

Әммә менә бу кыйммәтле мирас дидекемез халык шигырьләрен туплар да ватмады, уклар да кадамады. Алар һаман да халык күңелендә һәртөрле бәлая вә казаядан, муллалар әйтмешли, мәсун вә мәхфуз[1] уларак калдылар, алар сәламәт әле, алар яңгырый әле».

Халык җырларының сулмас гүзәллеге һәм бөек эчтәлеге хакында Тукай үзенең «Милли моңнар» дигән шигырендә гаять нәфис һәм күркәм итеп язды:

*Ишеттем мин кичә: бераү җырлый,*
*Чын безнеңчә матур, милли көй;*
*Башка килә уйлар төрле-төрле,—*
*Әллә нинди зарлы, моңлы көй.*

Татар халык җырларын туплау һәм өйрәнү Тукай заманында система рәвешендә булмый. Бу эш ара-тирә этнографик максатларда гына башкарыла.

Фольклористика өлкәсендә Тукай эшчәнлеге асылда халык поэтик текстларын анализлау юнәлешендә барды. Шагыйрьнең халык җырларындагы сәнгатьчәлек, эчтәлек-фикер үзенчәлекләрен алга куеп тикшерүе табигый һәм логик яктан аңлашыла да. Талантлы һәм илһамлы художник буларак, Тукай татар халык иҗатындагы энҗеләр — сүз-гыйбарәләр диңгезенә «башы белән чума». Хәлбуки, бу әле Тукай җырларның көенә әһәмият бирмәгән дигән сүз түгел. Киресенчә, халык җырларын ул барыннан да элек көйләренең матур һәм күңелгә ятышлы булулары өчен ярата һәм аларга югары бәя бирә. Интуитив рәвештә җырдагы музыка һәм сүз бердәмлеген тойган хәлдә, Тукай шулай да үзенә яхшы таныш булган кадерле әдәби сфера хакында фикерләрен күбрәк белдереп калган. Шунлыктан аның игътибары еш кына эчтәлектәге сурәт-тасвир якларына, җыр текстындагы шигъри персонажлар табигатенең тирәнлегенә һәм төгәллегенә җәлеп була.

Халык җырының көенә характеристика биргәндә Тукай, кагыйдә буларак, көйдәге мәгълүм бер халәтне, эмоциональ климатны билгеләү белән чикләнә. Шул ук вакытта ул көйдәге психологик настройның гаять нечкә нюансларын да күрсәтеп күя.

Тукай җырдагы көйле-шигырьдә образ үсешенә сизгер. Шагыйрь буларак, ул җырлардагы мелодиканың бөтен эмоциональ төсмерләре тексттагы мәгънә сыйфатларыннан килеп чыга һәм киресенчә, дип күрсәтте. Мелодиканың күркәмлеге, Тукай аңлавынча, җыр сүзе астына яшерелгән фикерне дә тирәнәйтә һәм үткенрәк итә. «Тәфтиләү» җырының килеп чыгышын тикшергәндә, мәсәлән, Тукай бу җыр сурәтен болай тасвирлый:

«Аннан соң җегет белән кыз арасында нинди маҗаралар булгандыр, миңа мәгълүм түгел. Ләкин Тәвкилев көенең моңлылыгына караганда, җегет белән кыз арасында мотлак бер фаҗига булгандыр, дип фикергә килә».

Җыр текстларын тикшергәндә шагыйрьне, беренче чиратта вакыйгалы, фабулалы моментлар кызыксындыра. Тукай җырларның конкрет тарихи килеп чыгышларын күз алдына китерергә тырыша, халыкның мондый әсәрләре туардай тормыш-көнкүреш хәлләрен фараз кыла.

---

[1] Мәсун вә мәхфуз — сакланып.

Тукай күрсәтеп үткән фактларның күбесе тарих хатирәсе генә, һәм алар хәтта шагыйрьнең хәтерендә бик томанлы төстә генә ишарәләнәләр, әмма җырлар тарихы турындагы аның хикәятләрендәге ымнарның әһәмияте барыбер зур, чөнки алар халыкта көйле-шигырьле әсәрләр туу процессы чоңгылына күз ташларга булышалар.

Аның фольклор буенча чыгышларында мәгърифәтче пропагандистлык мотивларын күрүе кыен түгел. Халык иҗатына бик якты һәм ышандырырлык билгеләмәләр биргән «Халык әдәбияты» дигән әлеге популяр лекциясе дә нәкъ шул юнәлештә язылган. «Халык әдәбияты, халык шигырьләре дип, инша итүче шагыйре беленмәгән яки уйлап чыгаручысы вә әүвәл кем тарафыннан сөйләнгәнлеге мәгълүм булмаган хикәя вә мисалларга әйтеләдер,— дип язды Тукай.— Халык әдәбияты бер дә кәгазьгә язылмаса да, буыннан буынга ишетелеп, халык күңелендә бер дә онытылмый торадыр».

1907 елда шагыйрь «Җырларымыз» дигән мәкаләсен яза. Анда ул татар халык шигырьләренең структурасын һәм эчтәлек-фикер ягын анализлый. Шул мәкалә һәм «Халык әдәбияты» дигән лекциясе буенча шагыйрьнең эстетик һәм конкрет иҗат карашлары эволюциясен күз алдыннан кичерү кызыклы. Беренчесендә Тукай бернигә җыр нигезе булган шигырь текстларының образлар даирәсен тасвирлый. Шагыйрь халык шигыренең универсальлеген, аның теләсә нинди халык көе мелодикасына җиңел генә яраклаша алу сәләтен күрсәтергә һәм исбатларга омтыла.

1907 елгы мәкаләсендә Тукай күп проблемалар күтәрә, әмма игътибар үзәгендә шигъри тексттагы фразаларның мәгънәви мөнәсәбәте мәсьәләсе. Ул күрсәтеп узганча, татар халык шигырендә җырның беренче яртысының икенче өлеше белән мәгънәдәш булмавы табигый күренеш. Татар җыр текстларының бу үзенчәлеген шагыйрь ул елларда кимчелек дип саный. Ләкин аның дөньяга караш принципларының формалашуы зур тизлектә бара. Соңрак, бик интенсив төстә җитлеккән шагыйрь, эстетик критерийлар иясе булып өлгергәч, ул «Халык әдәбияты» лекциясендә татар җыры шигыренең хис-сурәт һәм мәгънә төзелешенә булган карашын бөтенләй башкача билгели. Тукай дүртьюллыкта карап торышка үзара мәгънә бәйләнеше булмаган юлларның чиратлашуы халыкның сурәтле фикерләвендә оригиналь үзенчәлек ул, бу кызыклы алым тыңлаучының игътибарын җәлеп итү, ә соңыннан кискен борылышта төп фикерне әйтеп салу өчен кулланыла дигән нәтиҗәгә килә.

Бу күзәтүе белән Тукай татар халкының сәнгатьчә фикерләвендәге милли үзенчәлекнең гаять әһәмиятле һәм катлаулы проблемасын күтәрә. Шагыйрьнең тирән фикере хәзерге заман галимнәренең эстетик концепцияләре үсеше өчен юл башы булып тора. Профессор Й. Г. Нигъмәтуллина, мәсәлән, болай яза: «Татар халык җырларында татарларның сәнгатьчә фикерләвендәге милли үзенчәлек ачык чагыла... Күпчелек очракларда куплет ике кисәктән тора. Бу кисәкләрнең тематикасы бөтенләй төрлечә, төрле булырга мөмкин, еш кына үзара бәйләнешләрен тотып алуы да кыен. Хәлбуки, куплетның беренче һәм икенче кисәкләре үзара сизелер-сизелмәс халәт һәм фикер нюанслары белән бәйләнгән булалар. Шул нюанста җырның мәгънәсе ачыла да. Татар җырларының күрсәтеп үтелгән үзенчәлегендә эмоция белән фикер үзенчә яраклаша: эмоциональ киеренкелек җыр куплетының беренче һәм икенче кисәкләрендәге тематика һәм сурәтләр төрлелеге һәм аларның күтелмәгән булып тоелган бәйләнеше аркасында килеп туа» [1].

Халык җырларын анализлап, Габдулла Тукай аз сүз белән, бик төгәл итеп, аларда халык милли психологиясе чагылуын дәлилли. Халыкның сәнгатькә сәләтен Тукай аның теге яки бу вакыйгага шул көне-сәгате белән үз мөнәсәбәтен белдерүендә дә күрә һәм, шактый нигезләп, «Иске, күчмә заманнардан калган гадәтме, нидәндер, безнең халык — шигырь вә җыр-бәетләр чыгарырга бик майл халык»,— ди.

Революция белән бәйләнешле прогрессив иҗтимагый күңел күтәренкелеге җыр культурасының югары сәнгатьчә үрнәкләре белән кызыксынуны нык көчәйтә:

«Әйе, хөррият булды, яшьләр чыкты,— дип язды Тукай «Халык әдәбияты»нда.— Алар халык арасына чумды. Алар шушы онытылып яки һичкем тарафыннан әһәмият бирелми башлаган милли моңнарымызны терелдерделәр».

Тукай өчен җырлар, әлбәттә, өйрәнү объекты гына түгел иде. Көйле моң асылда аның шигъри фикерләвенең табигый үзенчәлеге иде. Аның хисле-сурәтле шигърияте

[1] Нигъмәтуллина Ю. Своеобразие художественного мышления Тукая.— Китап: Габдулла Тукай. Казан, 1979, 76 бит.

дөньясының чыганагы, персонажлары табигатенең логик үсеше тамырлары нәкъ менә җырларга һәм халык шигырьләренә барып тоташа.

Тирә-юньне һәм дөньяны шигъри тою һәм танып белүнең халык җыр стихиясе белән органик бәйләнештә булуы Тукай шигъриятендә татар халык җырларының төрле жанрларын тирәнтен һәм күп яктан килеп трактовкалавында да чагыла (озын көйләр, такмаклар, бәетләр, мөнәҗәтләр һ. б.). Шагыйрь аңында сурәтләр, ритмнар, рифмаларның формалашуы төрле фольклор жанрлары традицияләре: авыл көйләре, шәһәр җырлары, ярымдини җырлар традицияләре һ. б. белән аерылгысыз бәйләнгән.

Шиксез, Тукай бик нечкә музыкаль аһәңгә ия булган. Аның иҗатында, башка беркемдә дә булмаганча, үзенең музыкаль халкы белән тыгыз бәйләнештә торудан туган һәм кеше, һәм художник буларак, рухи үсеше үткән «интонацион даирә»дән алган гаять бай моң тәҗрибәсе сизелеп тора.

Тукайның музыкаль сәләтләре үсешендә аның уку чоры да зур әһәмияткә ия. Ул укыган китаплар арасында, әлбәттә, «Бәдәвам», «Бакырган» һ. б. кебек көйләп укый торганнары да булган. Төрки телдәге борынгы язмалар белән танышу, мәдрәсә системасы шартларында гарәп, фарсы әдәбиятларының кул астында булуы, төрек шагыйре Габделвәли һәм Каһирә университетын тәмамлаган Камил Мотыйгый белән аралашу Тукайның мөселман Шәркы культурасына якынаюында зур роль уйный. Камил Мотыйгый Тукайның, бик бирелеп, аның башкаруында төрек, гарәп һәм фарсы җырларын тыңлавын искә ала. Уку барышында Тукай үзләштерергә тиешле материал да күптелле булуы белән аерылып тора. Нәкъ менә мәдрәсәдә уку чорында шагыйрь гарәп шигырь төзелеше системасы арузны камил үзләштерә. Ә татар халык җыр жанрлары булган бәет, мөнәҗәт, озын көй, кыска көй һ. б. структурасын һәм метроритмикасын күп очракта аруз һәм халык силлабикасы билгели. Мөнәҗәттәге стилистик үзенчәлек булган көйлелекне без Тукайның да күп кенә шигырьләрендә очратабыз. Шунысы кызыклы, Тукай үзенең дин әһелләренә каршы юнәлдерелгән шигырьләренең шактыен нәкъ менә мөнәҗәтләргә хас булган, канунлашкан мөселман культ ритмнарында яза. Бу уңайдан, «(музыкаль) ритмиканы Якын һәм Урта Көнчыгыш галимнәренең шигырь төзелешенең метрик нигезләре тәгълиматы белән бергә караулары»[1] очраклы түгел икәнлеген дә әйтеп үтәргә кирәк.

Кайбер шигырьләренә Тукай теге яки бу көйгә башкарыла дигән искәрмә бирә. Әйтик, «Милли моңнар» («Әллүки» көенә), «Эштән чыгарылган татар кызына» («Зиләйлүк» көенә), «Мөхәммәдия» көенә», «Сакмар суы» көенә һ. б.

Тукай халыкның җыр иҗатын бик яхшы белгән генә түгел, ә замандашларының бердәм фикере буенча, сәләтле башкаручы да булган. Апасы истәлекләренә караганда, шагыйрь аңа ул белмәгән җыр юктыр, дип әйткән булган. Тукай биографиясендә аның халык алдындагы чыгышлары турында сәхифәләр бик кызыклы һәм игътибарга лаеклы. Ул чорда бу шактый кыюлык таләп итә торган эш була. Тукайның сәхнәгә чыгуы хакында хәтта газеталар да язалар. Мәсәлән, 1907 елның 18 мартында «Фикер» газетасында рус-татар концерты турында хәбәр басыла. Андагы түбәндәге юллар кызыклы: «6 нчы пәрдәдә янә Г. Тукаев чыгып, үзенә кушылырга музыка булмаганлыктан, иң әүвәл халыкка хитабән: «Я сам балалайка, сам гитара»,— дип кычкырып, «Турецкий марш»ны җырлады».

Габдулла Кариев һәм Галиәсгар Камалның истәлекләрендә Тукай сәләтләренең тагын берсе турында мәгълүмат бар — шагыйрь вакыт-вакыт халык өчен концертларда... хор дирижеры буларак та чыга. Әлбәттә бу очракта профессионализм турында сөйләп торып булмый. Монда башкасы әһәмиятле — халык җырларын башкаручы һәм интерпретатор буларак, Тукайның абруе шундый югары булган ки, калганнар барысы да аңа җырда җитәкче һәм остаз итеп караганнар.

Әйе, Габдулла Тукайның эшчәнлеге һәм иҗаты музыка, халык җыры белән аерылгысыз бәйләнгән иде. Татар халкы Тукай шигърияте аһәңенең үз рухи дөньясына авазлаш икәнлеген тирәнтен аңлады. Шагыйрьнең күп шигырьләрен халык җыр итеп җырлый.

---

[1] Музыкальная эстетика стран Востока.— М., Музыка, 1967, 250 бит.

# Шәмсия Җиһангирова

⊛

Кечкенә чагымда
Әнигә охшарга тырыштым:
Елауда, көлүдә, ашауда,
Йоклауда...
Халкымны, илемне сөюдә...
Чәчемне үрүдә,
Ак кием, пакь кием киюдә,
Хәтта төш күрүдә
Әнигә охшарга тырыштым.

Мәктәптә — охшарга тырыштым
Фаягөл апага
«Параллель турылар кисешми» дигәндә.
Шигырьне тырыштым
Фәния апача сөйләргә.
Кислород тапканда,
Картада диңгезләр гизгәндә
Гел Лена[1] апага охшарга тырыштым...
Кемгәдер охшарга тырышып
Эзләдем үземне...

Ә хәзер
Һәр адым атлаган чагымда
Дусларым һәм ятлар янында,
Елауда, көлүдә,
Халкымны, илемне сөюдә,
Пакь кием киюдә,
Хәтта төш күрүдә
Үземчә булырга тырышам...

## Авылларда каз өмәсе

Авылларда каз өмәсе гөрли:
Юл буена канат сипкәннәр.
Канат өсләренә баса-баса
Кызлар каз юарга киткәннәр...

Әллә нинди генә сәер чак бу:
Үзе моңсу, үзе күңелле.
Каз гомере, кире кайтмый торган
Яшьлек кебек, кыска гомерле...

Җырлый-җырлый кызлар каз юалар,
Кызлары да моңсу, җыры да:
Гөлҗамал, Зиләйлүк, Хәмдиякәй,
Олы юл тузаны турында...

Нинди чак бу — каз өмәсе вакыты?
Юл буена канат сипкәннәр.
Димәк, туйлар өмет итә-итә,
Кызлар каз юарга киткәннәр...

[1] Укытучыларым Фаягөл Шәйгәрданова, Фәния Хафизова, Лена Ханнанова

## Әни буласым килә

Кызым инде зур үсте:
Матур күлмәкләр сорый.
Көне буе караса да,
Көзгедән бер дә туймый.

Чәчләрен әле тегеләй,
Әле болайга тарый.
Әле зәңгәр, әле кызыл
Күлмәген киеп карый.

Аның инде тиз-тиз генә
Әни буласы килә.
Мин кызыгып карап торам:
Бәби буласым килә.

## Йөрәгем

Йөрәгемне телем-телем
Кисеп алалармыни,
Телемнәрен дөрләп торган
Утка салалармыни!?

Тибүләре дөрес түгел:
Әллә инде чире бар,
Әллә инде үзе генә
Белә торган сере бар?

Ярсу аттай тыпырчына —
Йөгән салдырып кебек,
Борылышка җиткәч кенә
Егып калдырыр кебек.

Әйтәм инде, тынычлан, дим,—
Үз кадереңне белмисең.
— Әле бу,— ди,— башы гына...
Язга чыккач... күрерсең!

⊛

Биек тауга басып бер кычкырдым:
— Синсез яши алмыйм, сөйгән яр!
— Башкада,— дип,— аның күңелләре,—
Җавап бирде миңа чал таулар.

...Биек тауга кабат менмәдем мин —
Янәшәмдә генә булса да.
Еллар үткән саен сөюләрем
Ялкынлырак дөрли торса да.

...Бүген менә, очраттым да сине,
Күзләреңдә сагыш-моң күрдем.
Аңлатырга теләп серләремне,
Биек тауга каршы йөгердем.

— Күңелләрем минем башкада! — дип,
Аваз салдым сиңа яңадан,
— Синсез яши алмыйм, сөйгән яр! — дип,
Җавап килде миңа таулардан...

## Тимәгез сез миңа

Тимәгез сез миңа. Гел үземчә
Булыйм әле бүген аз гына...
Кырыслыкка күнеп барам ласа,
Җанда булса да тик наз гына.

Тимәгез сез миңа. Хисләремне
Шәрран-яра ачып җибәрим...

Язылмаган кануннарга табынып
Күп яшәдем инде җирдә мин.
Тимәгез сез миңа. Бүгенгедәй
Мин иртәгә, бәлки, булалмам...
Юк! Ышанмыйм! Җаным бар
чагында
Үзем булалмыйча түзалмам!

Тимәгез сез миңа... Тимәгез!

## Әле мин сине гафу итмәдем

Әле мин сине гафу итмәдем.
Иңемә килеп сарыла күрмә.
Күз яшьләреңне күрсәтмә миңа.—
Ялына күрмә, ялына күрмә.

Әле мин сине гафу итмәдем.
Өметләр баглап чәчәк китермә.
Йомшак ла аның күңеле диеп
Гафу үтенмә, гафу үтенмә.

Әле мин сине гафу итмәдем.
Каршыма килеп, башыңны имә.
Яратуымны белеп торасың...
— Кире кайт!— димә.
— Кире кайт!— димә...

Әхсән Баянов

# ВАТАН ТОЙГЫСЫ

Минемчә, кеше вакытның өч үлчәвендә берьюлы яши: ул — үткәннең дәвамы, ул — бүгенге чынбарлык, ул — киләчәккә юл башы. Аны бу бәйләнештән башка күз алдына китерү мөмкин түгел.

Кешенең дөньядагы урыны халкы һәм Ватаны язмышы белән бәйле. Мин дә, шәхес буларак, дәрәҗәмне, үз урынымны ачыкларга теләсәм, беренче чиратта, туган халкым турында, аның тарихы, бүгенгесе, киләчәге хакында уйларга тиеш булам. Уйлый төшкәч, тиз үк шуны күз алдына китерәм: минем дә, халкымның да, бөтен илнең, хәтта бөтен кешелекнең дә язмышы үзара аерылгысыз бәйләнгән.

Үткәнгә күз салсак, анда — авыр, катлаулы фаҗигаләр, сугышлар. Сугышлар тарихыбызга шәфкать күрсәтмәгән — шәһәрләрне һәм авылларны, фәнне һәм культураны, әдәбият һәм архитектура һәйкәлләрен вата, җимерә килгән. Вакыт бүгенге көнгә шулар аша гына уза алган.

Тарих, мәйданнар тутырып, китаплар янганын да яшерми. Хәтта кеше хәтере дә янарга мөмкин. Калалары һәм авыллары белән бергә, татар халкының тарихи аңы да янып бетәргә хөкем ителгән булган. Әмма хөкем җиренә җиткерелә алмады. Халык үзенең тарихы белән Октябрь революциясе көннәрендә яңадан кавышты. Ерак кала һәм авылларның күп өлеше җир һәм туфрак астында күмелсә дә, хәзер ул акыртын-акыртын дөнья өстенә барыбер калка тора. Калка алмаганнарын безгә риваятьләр җиткерә. Риваятьләр исә акрынлап чынга әйләнә, тормышка күчә.

Күз алдына китерәм: урам буйлап, зирәк сәфәрче атлый. Ул күрә: бераү, эшләпәсен җиргә куйган да хәер сорап утыра. Аңа карап, сәфәрче кычкырып көлә һәм ары китә. Күпмедер узгач,— урамнармы, юллар ашамы,— юлчы бер кибеткә керә. Анда, башмаклары тузып беткән таныш хәерче, үзенә әйбәт аяк киеме сайлый. Сатучы аңа арзанга гына менә дигән итекләр бирә. Шушы хәлне күргән сәфәрче елап җибәрә. Кешеләр гаҗәпләнеп:

— И хөрмәтле акыл иясе, аңлатып бирче: теге чакта фәкыйрь кешенең хәер соравыннан ник көлгән идең?— дип сорыйлар.

— Көлмичә ничек түзәсең,— дип җавап бирә юлчы.— Кеше искиткеч зур хәзинә өстендә утырып тора иде, ә үзе хәер сораша.

— Аның әйбәт итек алганын күргәч, ник еладың?

— Шуңа күрә еладым, чөнки ул тиздән үләчәк...

Бу риваять байтак халыкларга билгеле. Ләкин ул, беренче булып, безнең җирдә барлыкка килгәндер, диясе килә. Ничәмә гасырлар буе шушы җиребездә нинди олы хәзинәләр өстендә утырганбыз бит. Һәм белгенлек кичергәнбез. Шуларны таптап йөргәнбез. Аяк асларыбызда салават күперенең барлык төсләренчә асыл маллар яткан, ә кеше фәкыйрьлектән үләргә тиеш булган — риваятьтә түгел, монысы чынлап. Егерменче гасырга ул итексез генә кергән. Бөек шагыйрь шуңа күрә:

— Татар халкы, син бетәргә мәхкүм инде,— дип сызланган.

Сызланган күп акыл ияләре ялгышты. Халкыбыз яңа көннәр яктылыгында үзенә тиешле хәзинәләрне ачты. Халык үзен, үз тормышын, үз исемен, үзенең республикасын тапты.

Әгәр беренче бишьеллыкларда ул автономияле Татарстан республикасында дистәләрчә зур предприятиеләр корылган икән, Казан химия һәм машина төзү промышленносте һәм эре масштаблы җиңел промышленность үзәге булып әверелгән икән, авыл хуҗалыгында ирешелгән уңышлары өчен республика 1934 елда ук Ленин ордены белән бүләкләнгән икән, бу җиңүләрнең материаль нигезе гасырлар буе билгесез яткан хәзинәләрнең хәрәкаткә, дөньяга килүе хакында сөйлидер.

Хәзинәләрнең зур өлеше нефтькә, газга туры килгәндер — кара алтын, зәңгәр алтыннарга. Шулар куәте белән борынгы җиребез өстендә өр-яңа шәһәрләр барлыкка килде.

Татарстан нефте бөтен дөнья өчен күрелмәгән хәл булды. 1981 елда җиребездә чыгарылган нефть күләме ике миллиард тоннадан ашты. Дөньяда бер генә чыганактан да шул вакыт эчендә бу кадәр нефть алынганы юк иде.

Төзелеш — халыкның яшәү, үсү чарасы гына түгел, аның мәңгелек күңел таләбе дә. Төзүгә хокук шулай ук җиңел генә бирелмәгән. Татарстан җирендә дә патшалар-ханнар каршылыгын җиңә-җиңә генә, шәһәрләр, сарайлар салынган. Бу көрәш шулай ук үзенең риваятьләрен калдырган.

Шуларның берсен искә төшерик. Падишаһ үз бөеклеген, үлмәс рухын чагылдырган сарай алырга боерык бирә. Осталарны көнчыгыштан, көнбатыштан чакырып, төзәтеп карыйлар. Берсен дә ошатмый падишаһ. Аптырагач, берсен — Нижнийдан, икенчесен Казаннан табып, үзебезнең осталардан салдыралар. Сарай, туган җирнең барлык матурлыкларын җыйнаган чәчәк бәйләме сыман калкып чыга. Патша анда үз бөеклеген, үз данын күрә. Һәм осталардан сокланып:

— Моннан да матуррак итеп төзи алыр идегезме?— дип сорый.

Осталар, алдын-артын уйламыйча, дөресен әйтәләр:

— Ихтыяҗы чыкса, моннан да матур итеп салыр идек,— диләр.

— Ләкин минем бу сарайдан матуры салынмас!— дип падишаһ кызган тимер китертә, осталарның күзен сукырайта.

Әмма осталар нәселенең исән калганлыгын егерменче гасыр яңадан исбат итте. Безнең дәвердә халык даһие яңа могҗизалар тудырды: Әлмәт, Лениногорск, Җәлил, Түбән Кама, Брежнев шәһәре һәм Идел, Кама буйларындагы яңа төзелешләр — Татарстан атом электр станциясе. КамАЗ автомобильләре бөтен дөнья юллары буйлап чаба китте. Ихтимал, бу төзелешләр дә риваятьләргә әверелеп, килер заманнарга барыр.

Шәм, керосин лампасы, аннары вак-вак электр станцияләре яктырткан еллар аша узып, республика югары вольтлы электр агымының куе челтәре белән бизәкләнде.

Әле күптән түгел генә Кама елгасында Түбән Кама гидростанциясе корылды. Кама суыннан алынган энергия бөтен ил челтәренә, аның аша Европага тоташты. Үзенең бөтен куәте белән ул өч Днепрогэс хәтле электр энергиясе озата.

Һәр кеше исәбенә бүлеп караганда, Татарстан электр энергиясе эшләп чыгаруда бик күп алдынгы капиталистик илләрне узып китте.

Үз башы, үз акылы, үзенең күзләре булган республика менә ярты гасырдан артык инде, дус һәм тугандаш халыклар белән берлектә, уртак ватанны тагын да куәтлерәк итү өчен, дөньяның матурлыгын арттыру өчен көрәшә. Киләчәккә үзенең якты күзләре белән карап елмая. Олы тарихы, нык тормышлы бүгенгесе, ышанычлы киләчәге булган ил яңа легендалар иҗат итә — игеп үстерә, калалар, авыллар төзи, кара һәм зәңгәр алтыннар чыгара, табигатьнең яңа серләрен, хәзинәләрен эзли, китап яза. Яңа бурычлар, яңа проблемалар хәл итә.

Алда торган бурычларны гомумиләштереп әйткәндә, вакыт куйган иң зур җаваплылык Бөек Октябрь социалистик революциясе казанышларын саклап калудан һәм дәвам иттерүдән гыйбарәт. Максатларның иң изгеләре — халыклар дуслыгы, тынычлык.

Атом сугышы һәлакәте соңгы вакытта аеруча реаль яный башлады. Дәһшәт кешеләрнең көндәлек тормышын, каефен агулый, бәхетен кимetә. Шуңа күрә җирне, тынычлыкны саклау барлык халыкларның уртак максатына, һәр кешенең намус эшенә әйләнде. Тынычлыкны саклау илебезнең экономик куәтен ныгытуга да тоташкан. Тынычлык сугышны җиңәргә тиеш һәм җиңәчәк. Бу җиңүдә дә совет кешесенең иҗади хезмәте нигез булып тора. Радио-телевидение, газеталар аша илебезнең төрле

якларыннан көн саен килә торган хезмәт рапортларының олы мәгънәсе дә әнә шунда. Хезмәт җитештерүчәнлеген туктаусыз күтәрә бару — экономик максат кына түгел, политик максат ул. Кешенең әхлак сафлыгы да илне ныгытуга керткән өлешенә, хезмәт нәтиҗәсенә бәйле. Кемдер үзенең файдасызлыгын сүз уйнатып кына капларга тырышса да шуңа ирешсә, бу хәл, башкаларның кәефен бозып, гомум эшкә зыян китерсә, икенчедән, ул экономикага да тәэсир итә. Бу күренешкә халыкта сизгерлек, кискен мөнәсәбәт тәрбияләү көн тәртибендә тора.

Республика үзенең бүгенгесен һәм киләчәген авыр көрәшләр аша, фидакарь хезмәтләре белән яулады. Илнең йөзе гадел яу каһарманнарының, эш батырларының яңадан-яңа казанышлары белән бизәлә.

• • •

Чишмәләргә ятып су эчәргә һәм мәгънәви кыйтгамның беренче утравында калган яланаяк эзләремне эзләргә мин туган авылыма кайтам. Кайткан саен тиз генә онытыла алмаслык хатирәләргә байыйм.

Кайтуларымның берсендә ерак Сүрия республикасыннан килгән кунаклар белән очраштым. Кунаклар авыл хезмәтен, тормышын һәм культурасын оештыру формалары һәм методлары белән танышырга теләгәннәр. Алар тәҗрибә җыйнау, аннары үз илләрендә файдалану максаты белән минем туган җиремне карап йөрделәр.

Алар төзелешнең яңа үрнәкләре нигезендә салынган һәм җиһазландырылган район китапханәсен, культура йортларын, терлек фермаларын карадылар, дәресләр ике телдә — татар һәм рус телләрендә алып барылган урта мәктәптә булдылар, төрле профессия әһелләренең үз эшләре хакындагы фикерләре белән кызыксындылар. Һәр очрашу-әңгәмәләрдән соң күргәннәреннән зур канәгатьлек алуларын әйттеләр һәм күрелгән тәҗрибәләрнең яңа тормыш төзегәндә файда итәчәген белдерделәр.

Минем өчен әлбәттә, үземнең туган авылымда булган әңгәмә аеруча мәгънәле тоелды. Очрашу мәҗлесендә, гадәти гыйбарә белән әйткәндә, өстәлләр сыйдан сыгылып тора иде: чәк-чәк, тутырган тавык, грузиядән килгән шифалы су, әрмәнчә әзерләнгән шашлык — барысын исәпләп бетерү дә җиңел түгел иде.

Нинди генә сыйлар өстәлне
Бизәмәгән дисең ул көнне!
Елмаюга — җор сүз шикелле
Кымыз белән шәрап өстәлде.

Табыныбыздан ерак та түгел, гап-гади су — чишмә чылтырап ага. Кунаклар шул чишмә чылтыравына да колак салганнар икән. Арадан берсе, тартынып кына шул суны эчеп булмасмы икән дип сорады.

Янда гына аккан чишмәләр
Тылсымлырак икән шәраптан.
Кунакларны күр дә гаҗәплән:
Шул суларны өстен куйдылар,
Сөенделәр чөмереп, көлделәр,
Мең тылсымны садә сүз җинде:
«Су — тормыш бит, су бит ул — изге!»

Кунаклар безнең гомер буе эчкән суны изге дип атадылар.

— Су — тормыш ул!

— Бу — изге су!— диештеләр.

Бу минутларда (бәлки һәрвакыт, бәлки гомер буе шулай тиеш булгандыр), мин үземнең туган табигатемне, халык телендә, оҗмах дип йөртелгән рәхәт җирнең бер почмагы дип кабул иттем. Бу ачышым шулкадәр нык аңлашылды миңа, һәм моңарчы шушыны аңламыйча яшәү хәтта гаҗәп тоелды.

Кешеләр үз илләреннән ерак-ерак юлларга чыкканнар.

Кешеләр, үз җирләрендәге изгелекне күрмичә, танымыйча, туган йортларын, ата-

аналарын, хатыннарын, балаларын калдырып, ерак сәфәргә йөргәннәр. Җәяүләп, Африкага — Мәккәгә, Мәдинәгә. Табыну, гыйбадәт кылу өчен — кыйбла дигән җиргә. Аллага баш орып, изге саналган суыннан тамчылар гына булса да татып, өскә, киемнәргә чәчрәтеп, үзләрен һәм нәсел-ыруларын изгеләр рәтенә кертү өчен барганнар алар.

Күп очракта шул юлда үлемнәрен тапканнар. Байлар гына туган илгә кайтып җитә алган. Хаҗи дигән изге дәрәҗәгә ирешкәч, алар халыкка, чынын-ялганын бергә кушып, беркатлы хикәятләр сөйләгәннәр. Кыйбладан алып кайткан суны тамчылап дусискә, бик якын туганнарына гына авыз иттергәннәр. Бу тамчы тигән кеше үзен шулай ук изгедән исәпли башлаган. Кайбер хаҗилар, юл чыгымнарын каплау максаты белән бик үк изге булмаган ысулга да тотынгалаган: изге су дип, үз чишмәләреннән алган суны сатказаучылар да булган икән.

Вакытлар үзгәрә тора. Кешеләр ул якларга, әлбәттә, бу заманда да сәфәр чыга. Дөнья белән танышу ниятеннән кешеләр күп илләргә сәяхәткә дә йөри. Хәзер безгә дә чит илләрдән кунаклар еш килә. Безнең районга Германия Демократик Республикасыннан, Польшадан һәм бүтән илләрдән иген үстерү серләрена өйрәнергә килделәр. Инде менә Африка ягыннан үзләре әйткәнчә, совет кешеләреннән хөр яшәргә өйрәнү өчен килгәннәр. Якташларым аларны ипи-тоз белән каршылыйлар. Чишмәбезнең саф суы белән сыйлыйлар. «Изге су» дип атадылар аны. Изгелек төшенчәсе күзгә күренеп, үзенең яңа реаль мәгънәсен табып үзгәрә. Безнең бабайлар өчен кыйбла кайдадыр комлы, чүлле киңлекләрдә булса, яңага, үсешкә омтылган халыклар өчен инде менә бераз урынын алмаштыра төште: безнең якка, сан-исәпсез чишмәләре һәм елгалары чылтырап ага биргән яшел җиргә, без туган җиргә күчте түгелме!.. Суларыбыз да ялгансыз, саф, ялгансыз изге.

Һаман кирәк ләкин кыйблалар
...Кем өчендер бәлки юк алар,

Безнең заман кыйбласы — халыклар дуслыгы, алдаусыз, чын дуслык. Халыклар туганлыгы, метафора гына булудан туктап, көндәлек яшәү рәвешенә әйләнә бара. Интернационализм — һәр халыкның бөтенлеген саклаган кирәксез мөнәсәбәт — безнең яшәеш законы. Бүтәнчә булуы мөмкин түгел, бүтәнчә без яши дә белмәс идек.

Кешегә тулы бәхет өчен нәрсәләр кирәк? Гадәти бу сорау кунаклар белән сөйләшкәндә кырыс мәгънәләре белән ачылып китте. Гарәп илләренең Израил сионистлары белән булган каршылыгы бер гаепсез кешеләрнең канын коюга барып җиткән чак иде бу. Илләрнең бәйсезлеге көн тәртибенә куелган чак. Тәгаен кеше бәхете дигәндә дә нәкъ әнә шул дуслык дигән көч зарурлыгы аерымачык сизелде.

Әйе, нәрсәләр кирәк кешегә тулы бәхет өчен? Бәхет тулы булсын өчен күп кирәк. Аның иң беренче компоненты — Ватан куәте. Иң беренче чиратта кешегә үз гражданнарын тыныч, гадел тормыш белән тәэмин итә алган, ятлар ихтирам иткән яки санашырга мәҗбүр булган, аңа кем дә кул күтәрә, киңәнә алмаслык куәтле Ватан кирәк.

Безнең шундый Ватаныбыз бар! Бердәм Ватаныбыз бар! Кунаклар, мөгаен, шул бердәмлеккә төшенергә килгәннәрдер.

Безнең тормышка, тәнгә, канга күчкән хакыйкатьләр шундый. Кешеләрнең милләтләре төрле, әмма фикерләре һәм ышанычлары, хәтта гадәтләре белән алар инде бербөтен. Без үз җиребездәге яңарышларны бөтенсоюз бишьеллык программаларыннан тыш итеп күз алдына китерә алмыйбыз. Әгәр дә без күптән түгел: «КамАЗны бөтен ил төзи!» — дип кабатлаган булсак һәм хәзер бу автомобильләрнең бөек Союз киңлекләрендә гөрләп чапканын күрсәк, моңа тик барча уңышларыбызның, халыкның уртак куәте икәнен дә истә тотабыз.

Миңа, язучы буларак, сәнгатьнең бөек коралы булган сүзгә, телгә кагылышлы күренешләр аеруча якын һәм кадерле. Һәр халык теле — безнең уртак байлыгыбыз. Миллләтләрнең Конституция белән ныгытылган һәр тел үсешкә хаклы, саклануга лаек. Миллләтләрнең Конституция белән ныгытылган тигез хокуклылыгы телләрнең дә тигез хокуклы булуы үз эченә ала. Коммунист, нинди телдә сөйләшсә дә, коммунист булып кала.

Миңа башка республикаларда булырга, бүтән ил кешеләре белән аралашырга туры килгәләде. Беркайчан да сүзләремнең аңлашылмый калганын сизмәдем.

Азербайҗан халык шагыйре Әләскәрнең тууына 100 ел тулуга багышланган зур җыелышта илебезнең бөтен милләт вәкилләре катнашты, дисәм, хата булмас. Бүтәннәр рәтендә мин дә үз сүземне әйттем һәм гүяки бүгенге көннән дә дусларыма шул сүзләрне кабатлый алам.

«Азербайҗанның исемнәре бөтен дөньяга танылган шагыйрьләргә, фикер иясенә бай икәнлеге безгә күптән мәгълүм,— дидем мин.— Сүз даһилыгымның мондый муллыгына һәр халык, шул исәптән, гәрчә үзенең дә бөек исемнәре булуга карамастан, татар халкы да көнләшә алыр иде. Ләкин бөтен катгыйлыгы белән белдерә алам: безнең халыкка мондый хис ят. Чөнки безнең халык азербайҗан шагыйрьләрен үзенеке итеп таный. Дөнья поэзиясенең Физули, Низами, Сабир, Вагиф һәм халык җырчысы Әләскәр кебек олы фигуралары күптәннән бирле безнең уртак горурлыгыбыз булып килә һәм бу хакта, миннән бигрәк, тарих сөйли.

Безнең халыклар — игезәк туганнар. Туганнарга исә үзара ярдәм итешү һәм яратышу хас. Тарихта бу фикерне раслый торган фактлар бик күп, һәм аларны санап торуның мәҗбүрияте дә юктыр. Шуны гына искә төшерәм: ерак заманнарда, Идел буйларын корылык йончыткан елларда, безнең яктан бик күп кешеләр, бәхет эзләп, Азербайҗанга килгәннәр. Шуларның берсе — татар әдәбияты классигы Шәриф Камал. Ул, Каспий балык промыселларында йөргән һәм... тапкан — үзенең атаклы «Акчарлаклар» повестена материал алып киткән.

Икенче зур язучы Кави Нәҗми Баку пролетариаты тормышыннан шулай ук мул материал тапкан һәм үзенең «Язгы җилләр» романында файдаланган.

Революционер язучы Нариман Наримановның «Надершаһ» исемле әсәре буенча татар сәхнәсендә иҗат ителгән спектакль безнең сәнгатьтә тарихи факт буларак саклана. Җаббар Җаббарлы — безнең «штатта торучы» драматург. Сезнең «Моллa Насретдин» исемле сатирик журналыгызның бездә хәтта Азербайҗанның үзендәгедән дә күбрәк таралганлыгын искә төшермичә кала алмыйм. Бөек Тукай аны даим яздырып алучыларның берсе булган.

Бер-береңә игелек кылу — безнең ата-бабадан килгән гадәт. Әгәр дә без, Татарстан җиреннән миллиардларча тонна нефть алына, дип горурланабыз икән, без бу байлыкта Азербайҗанның безне шул эшкә өйрәткән нефтьчеләре өлеше барлыгын да истә тотабыз.

Берничә ел элек, Казанга кунакка килгәч, Азербайҗан шагыйрьләре Идел буендагы бер бакчага, ядкарь булсын дип, аккаен утыртканнар иде. Бакуга сөенечле хәбәр җиткерәм: татар җирендә Азербайҗан каены бик әйбәт тамыр җибәрде. Ямьле җәй көннәрендә ул яшелләнеп мәгърур басып тора. Ул сезнең җырларыгызны көйли һәм шаулый бугай. Без ул каен мәңге яшелләнеп, мәңге шаулар, халыкларның чын туганлыгы хакында мәңге сөйләр дип ышанабыз. Чөнки аның тамырлары күп елларга, гасырларга тоташкан дип уйлыйбыз».

* * *

...Бакуда тоеп йөргәнемчә, хәзер дә нык хәтерләвемчә, анда мине аңладылар. 1976 елның маенда Төрекмәнстан язучылар съездыннан да шундыйрак хисләр белән кайттым. Мин андагы чыгышымны:

— Әгәр дә әйтеп җибәргән йомышларын үтәмәсәм, безнең татар язучылары миннән, ник кайттың, дип сораулары ихтимал,— дип башладым.— Мин Ашхабадта үземне өемдә итеп тойсам да, күреп торасыздыр, миңа, Идел табигатенә күнеккән кешегә, монда шактый эссе. Шуңа күрә иптәшләрем теләгенә каршы килә алмыйм.

Бу сүзләрне әйткәндә, үземә тәбәлгән күзләрнең елмаюын, җөпләвен күреп, йомышымны тантаналы тавыш белән җиткердем: Съездда катнашучыларга һәм Төрекмәнстанның барлык язучыларына Татарстанның барча язучыларыннан ялкынлы туганлык сәламе тапшырдым.

Туганлык безнең өчен — тарихи чынлык. Безнең халыкларыбызның культурасы, объектив рәвештә, бер буын тарафыннан икенчесенә кыйммәтле мирас буларак тапшырыла килгән. Хәзер исә бу уртаклык безнең яшәеш законына, халыкларның бөек бердәмлеге законына әверелде. Әгәр дә бөек Мәхтүмколый әсәрләре хәзергә хәтле безнең телдә басыла килә икән һәм рухи кыйммәтләребезнең бер өлеше булып тора икән, яки безнең Кол Гали төрекмән халкы тарафыннан үз шагыйре итеп исәпләнә икән, ихтимал, халыкларның дуслыгын моннан да яхшырак раслаучы мисаллар эзләүнең кирәге калмыйдыр.

Төрекмән совет әдәбияты классигы Берды Кербабаев безнең Габдулла Тукай әсәрләрен тәрҗемә иткән һәм аның үз иҗатына игелекле йогынтысы хакында яки Муса Җәлилнең поэтик батырлыгын зурлап язган икән, безнең халык та аңа шундый ук затлылык белән җавап кайтара, төрекмән дустыбызның гүзәл сүзләрен һәм эшләрен хәтердә саклый, рәхмәт хисләре белән искә ала. Халыкларның шушындый дуслыгыннан мөһимрәк һәм гаделрәк тагы нәрсә бар?..

Минем бу чыгышым, андагы изге теләкләр һәм фикерләр төрекмән язучыларының әдәби газетасында басылып чыкты.

Тагын берсендә, Чехословакия—СССР дуслыгы җәмгыяте оештырган бер җыелышта катнашырга туры килде. Форсаттан файдаланып, күңелдәге фикерләрне әйттем. Алар моннан гыйбарәт иде: «Без барыбыз да бик яхшы аңлаганча, дуслык хисләре сүзләр белән генә түгел, ә кылган эшләр аша билгеләнә. Безнең гаять зур шатлыгыбыз һәм бәхетебез шунда, безнең халыкларыбыз дуслыгы карусыз, әйбәт эшләр белән дә беркетелгән. Безнең дуслык фашизмга каршы көрәштә бик күп кешеләрнең каны һәм гомере белән беркетелгән. Дуслык шул ысул белән ахыр чиккәчә ачык итеп билгеләнгән. Дуслык договоры рәвешендә ул шундый ук ачыклык белән дәвам итә.

Язучының эше — аның әсәрләре. Мин язучыларыбызның дуслык хисләренең дә эш белән ныгытылуын зур канәгатьлек тоеп билгелим. Чехословакия җирен данлый торган һәм аның гүзәл хезмәт халкын зурлый торган күп кенә илһамлы шигъри һәм чәчмә юллар барлыгын беләм һәм андый сәнгатьле әсәрләр күбәя барыр дип уйлыйм. Бу мәгънәдә чех һәм словак кешеләренең тәгаен дуслары исәбенә мин үземне дә кертергә кыюлык итәм.

Чехословакия әдәбияты миңе күптән кызыксындыра. Укучы буларак, чех һәм словак язучыларының байтак әсәрләрен хәтердә тотам. Алардан беренче итеп Мария Пуйманованың «Кешеләргә юл өзелгәндә», «Ут белән шаяру», «Үлемгә каршы яшәү» һәм, табигыйдер ки, Ярослав Гашекның «Житез солдат Швейк мажараларыннан» атый алам. Укучы буларак кызыксыну эшлекле мөнәсәбәткә әйләнде һәм Чехословакия авторлары әсәрләрен туган телемә тәрҗемә итә башладым. Шул рәвешле, Ярослав Гашекның «Бөгелмә шәһәре коменданты» исемле китабыннан хикәяләр газета битләрендә басылды. Алтмышынчы еллар башында, Чехословакия авторларының шигъри әсәрләреннән газетада берничә махсус бит оештырдым. Бу әдәби сәхифәләр турында «Руде Право» газетасы да язып чыкты.

Ярослав Гашекның иҗатын һәм биографиясен өйрәнүче әдәбият белгече Станислав Антонов Гашек биографиясеннән алып, повесть язган иде. Мин, ул әсәрне шулай ук тәрҗемә итеп, «Казан утлары» журналында бастырып чыгардым.

Соңгы вакытта Витезслав Незвал әсәрләрен укыдым һәм кайберләрен тәрҗемә иттем. Аның шигырьләре миңа күпкырлы булулары белән — Назим Хикмәт күрсәткән төп сыйфатлар аркылы килеп җиттеләр. Аның мирасында сагыш һәм оптимизм янәшә тыныч яшиләр: моң — пессимизмсыз, ә оптимизм — яраклашучысыз.

Мин Чехословакия әдәбияты белгече түгел һәм аны нинди дә булса система буенча өйрәнмим. Тәрҗемә белән мин бөтенләй шөгыльләнмим диярлек. Үземә ошаганны, тәрҗемә итмәскә мөмкин булмаганны гына тәрҗемә итәм, ягъни шәхси зәвыкка таянганмын. Ләкин кешедәге зәвык шулай ук нинди дә шартлар белән бәйлыкка киләләр. Гомуми төстә шуны әйтә алам: әлеге минем зәвык, мөгаен, барыннан да бигрәк совет халкының словак халкына, чех халкына булган туганнарча ихлас мөнәсәбәте нигезендә туа һәм тәрбияләнә алгандыр...»

* * *

...Фикерләреңне һәм тойгыларыңны башка халыкларга җиткерү җае чыккан вакытта күңел нечкәләр җиңеләеп, иркенәеп киткәндәй тоела. Шул рәвешле, әйтерсең, дөнья киңәя килә.

Очрашулар дәвам итә. Җәлил юбилейлары уңаеннан күрешкән дусларны хәтерлим. Аларның берсендә рус совет шагыйре В. Федоров: «Җәлилне укыган чакта, үзң миңа рус кешесе булып тоела»,—дигән иде. Рус шагыйренә таныш тойгыны мин дә яхшы беләм. Мин шулай ук үз шигъри дөньямны Блоктан һәм Есениннан, Маяковскийдан һәм Твардовскийдан башка күз алдына китерә алмыйм.

Халыкларның үзара якынлашуы, уртак экономик, социаль мәнфәгатьләр. Бу изге омтылышларның тормышка ашуы өчен тигез тырышлык һәм вакыт таләп ителә. Әдәбият һәм сәнгать өчен төрле телләрнең булуы, минемчә, чикләнмәгән киңлекләр ача. Барча телләр уртак кешелек культурасы хакына хезмәт итәләр. Теләсә нинди милләт кешесенең күп тарафлы үсеше өчен уңдырышы бетми-төкәнми торган бөек кырны әнә шулар ясый.

Мин, мәсәлән, Һади Такташ язган «Киләчәккә хатлар» үз адресатларына барып җитәчәк, дип, һәм ерак чорларда да теләсә нинди кешегә дә тулысынча аңлашылыр, дип ышанам.

Безнең суларыбыз изгелеген мин әнә шундый мәгънәләрдә аңлыйм. Чишмәләребезнең сафлыгын саклау — безнең гарантияләнгән хокукыбыз һәм шул ук вакытта— бурычыбыз.

Аккан сулар белән бергә тарих та киләчәккә таба үсә, байый, зурая бара.

**Газим Салихов**

# ИДЕЛ ЕГЕТЕ



Буг елгасы. Ул бер үк вакытта Польша белән Советлар Союзының чикләрен билгеләү вазифасын да үтәп, тын гына ага да ага. 1939 елның декабрь аенда елганың каршы ягындагы Польша гаскәре урынын Германия фашистлары алмаштырды. Аларның саны арта бара.

Елганың сул як ярында — безнең чик сакчылары. 98 нче отряд. Ул Любомоль шәһәреннән бары тик 15—20 чакрымлык арада, табигатьнең бик матур җиренә урнашып, бик җаваплы эшен башкара.

Елганың киңлеге 100 метрдан да артмый. Немец солдатларының һәр хәрәкәте безнең яктан бик ачык күренеп тора. Аларның байтагы чик сакчыларына әллә кайчаннан таныш кебек тоела, әмма күп төрле шөбһәле хәрби объектлар төзеп маташулары, сугыш уеннары, безнең якка төзәп куйган яңадан-яңа пушкалары, танклары, барысы да күңелләрдә борчылу, шик тудыра, һәр чак зирәк, уяу булуны таләп итә. Штаб Любомольда урнашкан. Әле беренче генә елын хезмәт итүче рядовой Гаяз Рамаевка еш кына штабка барырга туры килә. Бу юлны ул мотоциклда үтә. Сәфәр чыгарга ярата егет. Шәһәргә барып кайту гел бер төрле дәвам итүчән хәрби тормышны яңа тәэсирләргә баета. Шәһәрчекнең урамнарыннан үткәндә аның гади, ягымлы кешеләрен күрәсең: май заводы эшчеләре, тимер юлчылар, мәктәп балалары, базарга килгән колхозчылар... Аларның тыныч, хәвефсез, бәхетле тормышта яшәүләрен тою Гаязны шатландыра, күңелен күтәрә иде.

Биредән тимер юл буйлап та, шосседан да Брест, Львов шәһәрләренә барып кайтырга була. Базарларында, җаның ни тели, шул бар, җиләк-җимеш, чикләвек... Боларын хәтта солдат акчасына да бирәләр.

Бу якның табигате бай. Матур урманнар, күлләр, серле сазлыклар. Һавасы йомшак. Кышы да, җәе дә кешеләрне назлап, иркәләп кенә тора, каты салкыннар юк. Март аенда ук 18—20 градус җылы була, алма, чия агачлары чәчәккә күмелә.

Гаяз монда, армиягә алынгач та, 1940 елның ноябрь аенда килеп төште. Хәрби хезмәткә, яңа шартларда көн итүгә тиз күнекте. Дежурда яки постта торырга туры килгәндә, ялгыз калган чакларда гына күңелне сагыну баса... Башка вакытта уйга бирелеп торыр ара юк. Отряд комсомоллары бик шаулы тормыш алып баралар. Әле җыелыш, әле политуку, корал өйрәнү, төз атарга остару, төнге тревогалар, походлар — өлгер генә дә чыдап кына тор! Үз-үзеңне чыныктырырга телисең икән, буш вакытыңда спорт белән шөгыльләнә аласың. Шулардан соң да берничә сәгатең калса, уку бүлмәсендә газета-журналлар укып утырырга мөмкин. Егетләр туган якларга җибәрә торган хатларын да шул чакта язалар.

Елганың аргы ягындагы хәлләр исә җанны талкый. Ул тарафтагы гаскәрләрнең шөгылен дә һич яхшылыкка юрап булмый.

Ара-тирә елганы кичеп безнең якка чыгучылар очраштыргалый. Андый качаклар гитлерчыларның сугышка хәзерләнүләрен хәбәр итәләр, шактый ышандыргыч дәлилләр китереп сөйлиләр.

Нәкъ менә шундый хәбәрчеләрнең өчесен Гаяз да коралсызландырган иде, тотып отрядка тапшырды. Аларның берсе, кырык яшьләрдәге ефрейтор, кулга эләккәч тә: «Их бин коммунист» дип сөйләнергә тотынды. Ләкин сораулар алу нәтиҗәсендә аның ялганчы икәнлеге фаш ителгән...

Таң атып килә. Табигать бу вакытта кешене тәмам исертә. Ул кояш нурларының балкышы, ул урмандагы сафлык, ул кош сайраулары — җаның бөтенләе белән матурлык дөньясына күчә кебек. Мәһабәт чыршыларда тиеннәр биешә, ботактан-ботакка күчкәндә аларның оста сикерүләренә хәйран калып карап торасың.

Гаязлар төркеме — сакта. Алар да бу гүзәллектән әсәрләнгән. Адымнарындагы саклык, сабырлык та тирә-юньдәге гаҗәеп матурлыкка соклanудан, аны борчымаска тырышудан килә кебек.

Чик сакчылары төркеме «Салкын» күл буена җитте. Шул чак Гаяз кинәт туктап, гаҗәпләнеп кала. Ни сәбәптән моңарчы су эчендәге казыкка бәйләнгән килеш тын гына чайкалып утыручы хуҗасыз иске каек, яр читенә чыгарылып, беркетеп куелган. Ишкәкләр дә әзер тора. Элек алары бөтенләй юк иде. Кемгә кирәк булган бу ташландык көймә?

Чик сакчылары, бер нәрсәгә дә кагылмыйча, яңадан постларына юнәлделәр.

Көн кичкә авышты. Төн карасы төште. Ай калыкты. Елгада аргы яктан килүче көймә шәүләсе күренеп алды. Оста ишкәкченең суда бер тавышсыз йөзүе гаҗәп иде. Су тамчылары да чапылдамый, көймә юлында кечкенә генә дулкынчык та күренми. Берничә минуттан ике кешелек җиңел көймә, талларга күмелгән безнең ярга чыгып туктала.

Гаязлар яшерен телефон аша отряд дежурныена хәбәр итәләр дә, тавышсызтынсыз, кайбер урыннарда шуышып, чик бозучылар янына юнәләләр. Шул чак, көймә яңадан су өстендә күренә, ләкин ул ишкәкчесе белән генә китеп бара иде инде. Бу якта калганы якында гына посып ята, мөгаен. Хәзер үк, аргы якка сиздермичә генә, кулга алырга кирәк анысын!

Гаяз кушуы буенча, рядовой Комаров үз урынында күзәтергә кала, ә Гаяз, яшеренеп, дошманның юлына аркылы төшәргә ашыга.

Менә таллар арасыннан як-ягына карана-карана зур гәүдәле, авылча киенгән, аркасына капчык аскан берәү килеп чыга. Ул куе куаклык ягына ашыга. Тагын бер ун адым үтүгә, аның алдына кинәт Комаров чыгып: «Тукта, күтәр кулларыңны!»— дип боера.

Чик бозучылар мондый очракларда үз язмышларын үзләре, алдан өйрәнеп куйганча, хәл итәләр. Бу адәм дә, каушаганын сиздермәскә тырышып: «Здоровенки були, браток!»— дип, теләр-теләмәс кенә кулларын күтәрә, үзе Комаровка якынлаша һәм, җиң эчендәге пычагын чыгарып, Комаровка ташлана. Шул чак Гаяз килеп җитеп, аның кулына ябыша, пычагын ташларга мәҗбүр итә.

Дошман зат, күз ачып йомганчы, коралсызландырыла. Аркасындагы капчыкка кагылмыйлар. Аның документлары Дивиденко фамилиясенә тутырылган булып чыга. Күл буеннан үткәндә Дивиденко иске көймәгә карап ала. Гаязның: «Нәрсә, шул көймәгә ышанган идегезме?— диюенә ул, сискәнеп, каушап төште. Хәзер инде безнекеләргә, каекны хәзерләп куючыны, көнбатыш шпионын каршы алучының эзенә төшәсе бар икән, дип уйлады Гаяз. Соңыннан Дивиденконың 1939 елга кадәр кулак булганлыгы, ә көнбатыш Украина безнең илгә кушылгач, сатлык җанга әверелүе ачыкланган.

10 мартта Гаяз Рамаев белән, Олег Комаровка, чик саклауда аеруча сизгерлек күрсәткәннәре өчен, ун көнлек ял бирелә.

12 мартта Гаяз үз өенә, Саратовка кайтып төшә. Өйдән чыгып киткәнгә дүрт айдан артык вакыт узган. Менә вокзал мәйданы, Дзержинский һәйкәле, таныш өйләр, урамнар.

Биредә кар әле һаман эреп бетмәгән. Ә Любомольда инде тирә-юнь шау чәчәктә иде.

Кайтуы турында алдан хәбәр ителмәгәнгә күрә, кавышу минутлары бигрәк тә шатлыклы килеп чыкты.

80 яшьлек дәү әтисе, кадерле дәү әнисе Гаязны күрү куанычыннан еларга ук тотындылар.— Әй балам әниеңә генә бу бәхетне күрергә насыйп булмаган. Исән-сау күрешүең үзе зур шатлык-бәйрәм инде безгә, диештеләр.

Гаяз картларның хәлен белеп, алар янында чәй эчеп алгач, шинелен, яшел фуражкасын кия дә, төзелештә прораб булып эшләүче, иң кадерле кешесе, абыйсы янына ашыга.

Юлы Идел ярына килеп чыккач, Гаяз Урал, Чаган елгаларын исенә төшерә. Алар, Уральскида яшәгән чакта, әнисе белән бергә ташу карарга, боз киткәнне күрергә йөрүләр иде.

Тукай яшәгән өй, ул укыган мәдрәсә бинасы исендә нык сакланган. Фрунзе, Чапаев штаблары урнашкан йортлар да Гаязга нык тәэсир итә торган иде.

1933 нче елны Гаязның әнисе Заһидә апа кинәт авырый башлады. Егет хәтерендә әнисенең: «Улым, минем белән берәр хәл була калса... аптырап-югалып калма, нык бул. Саратовка китәрсең. Анда минем әтием, әнием, абыең бар. Алар бик миһербанлылар... Әтиеңнең дә үпкә авыруы көчәйгәннән-көчәя бара...»,— дигән сүзләре ачык саклана. Иртәгесен әнисе дөнья куйды. Ун көннән әтисе күрше хатын — Мәликәгә өйләнеп, аның кечкенә генә кетәклектәй өенә дә күчтеләр. Гаязның тормышы әнисе әйтеп калдырган юлга төште: Саратовтагы абыйсы кайтып, малайны үзләренә алып китте. Бер елдан соң әтисенең үлү хәбәрен ишеттеләр.

Шуннан башлап, әби-бабасы һәм әле өйләнергә дә өлгермәгән абыйсына сыенып яшәде Гаяз. Укыды, комсомолга керде, тырыш, намуслы егет булып өлгерде...

Дүрт катлы мәктәп төзелеше ерактан ук күренеп тора. Иң өстә, кулындагы сызымнарга карап, эшчеләргә нәрсәдер өйрәтеп торучы абыйсы, Гаязны күргәч, траплар буйлап аска йөгерә башлады, Гаяз да аңа каршы ашыкты. Кочаклашканда, хәтта Гаязның фуражкасы җиргә төште. Төзүче хатыннарның берсе, фуражканы алып алъяпкыч белән сөрткәләп иясенә тапшырды.

19 март көнне алар үзешчән артистлар хәзерләгән «Сүнгән йолдызлар» спектакленә бардылар. Бу Саратов кешеләре өчен бәйрәм төсе ала торган бер вакыйга иде. Спектакльдә Гаязның абыйсы да катнашты. Армиягә киткәнче, Гаяз үзе дә бу түгәрәктә: «Галиябану», «Зәңгәр шәл» спектакльләрен куйганда берничә роль уйнаган иде. Мәктәптә укыган чагында Гаяз шигырьләр дә, ике пьеса да язды. Беренчесе бер пәрдәлек —«Батырлар», икенчесе дүрт пәрдәлек «Коммунарлар» пьесасы. Шунысы кызык: катнашучылар арасында пограничник һәм шпион образлары бар иде. Хәзер менә Гаяз үзе — чик сакчысы. Кунактагы көннәр бик тиз үтүчән. Күрешеп-сөйләшеп тә туймыйлар — Гаязга китәр чак җитте. Туганнары истәлеккә төшкән фоторәсемнәрен алып кайтканда, егет инде үз постында иде.

1941 елның май аенда язган хатларының берсендә Гаяз: «...Тормышымда аерым яңалыклар юк... Уку, өйрәнүләр белән көннәр сизелмичә генә үтәләр. Бүген өйдән киткәнгә 60 көн вакыт узган. Яңадан сезнең белән күрешү өчен күпме 60 көннәр уздырасы бар әле...»— дип язган ул.

Бу хат язылып, тагын бер ай үткәч, 22 июньдә, фашистлар Германиясе безгә каршы сугыш башлады. Чик саклаучыларыбызга сугышның беренче минутларыннан ук коточкыч авырлыклар, кичерергә туры килгәне табигый. Бер атналык кискен бәрелешләрдән соң бу отрядның йөзләп чик сакчысыннан нибары дүрт кеше исән кала. Шуларның берсе Гаяз Галиәскарович Рамаев иде.

1941 нче елның 30 нчы июнендә язган хатында:

«Бу хатны үземнең исән-саулыгымны белдерү өчен язам. Сәламәтлегем әйбәт, күңелсезлекләргә бирелергә исәп юк. Фашистларны бик шәпләп дөмбәсләп киләбез. Хәзер яңадан фронтның беренче сафында юл тотам. Минем өчен күп кайгыртмагыз»,— дигән юллар бар.

Сугыш кызганнан-кыза бара. Дошман, көтелмәгән каршылыкка дучар булып, «Тиз арада җиңү» яулый алмаячагына ышанырга мәҗбүр ителә. Ләкин ул зур көчкә, техникага ия, шунлыктан һаман алга бара, безнең илнең үзәгенә якынлаша.

Гаяз хезмәт итә торган частьтагы өченче рота чигенеп өлгерми кала. Бу хәл полк командиры капитан Рубанны бөтенләй чыгырдан чыгарды. Кич, Гаяз үз теләге

белән разведкага, дошман тылына китә. Ул чолганышта калганнарга ярдәм күрсәтергә дә тиеш була.

Гаязга иптәш итеп, Саратов егете Владимиров билгеләнә. Бу аларның беренче разведкалары түгел. Шактый тәҗрибә туплаган, кыю, куркусыз, ышанычлы разведчиклар булып саналалар инде алар.

Фронт сызыгы өзгәләнгән чылбыр төсле. Гаязлар, өч чакрымлап араны узгач, Семеновка авылы тирәсендәге алма бакчаларындагы снаряд шартлаган чокырга урнашалар. Күзәтәләр. Олы юлдан фашист гаскәрләре һаман алга узып торалар. Ә авыл артында сугыш туктамаган әле. Мөгаен, чолганышта калганнар, үз частьларына кушылу өчен, тигезсез сугыш алып баралардыр. Хәзер инде, һичшиксез, Гаязларның да кайту юллары киселгән булырга тиеш.

Якында гына бер төркем кыр үрдәкләре очып үткәне күренә. Димәк, якында гына күлләр, сазлыклар бар. Ә немецлар сазлыктан куркалар.

Әнә әсир төшкән, коралсызландырылган солдатларыбызны алып китеп баралар. Күбесе яраланган. Араларында авыл кешеләре дә бар. Барысы да көч-хәл белән генә сөйрәлә. Авылга якынлашалар. Йөзгә якын әсирне унлап солдат, бер офицер озата бара.

5 июльдә Гаяз: «...ул гади генә разведка булып чыкмады. Без кагыйдәдән читләшеп, якыннан гына узучы әсирләрне коткарырга карар кылдык. Конвойга җайлы гына итеп ут ачтык. Бу барысы өчен дә көтелмәгән хәл булды. Әсирләр арасындагы кыюрак кешеләр, эшне аңлап, исән калган конвоирларга ташландылар, кораллandылар. Шатлыкларыбызның чиге булмады.

Колхозчыларның берсе, сай күлләр, сазлыклар аша юл күрсәтте. Өч көннән полкыбызга килеп кушылдык. Азат ителүчеләр арасында өченче ротабызның да исән калган ундүрт кешесе бар иде...» — дип яза.

Шул хәлдән соң Гаяз разведка группасы командиры итеп билгеләнә. Бик күп хәтәр разведкаларда була, бик кирәкле «телләр» кулга төшерелә. Июль аенда Гаяз «Батырлык өчен» медале белән бүләкләнә.

1942 елның февраль башында сугышлы разведкада Рамаев яралана. Ә инде 1942 елның 12 мартында язган хатында: «Сугышчан бурычыңны үтәп частеңа кайту — зур бәхет ул. Иртәгә минем 20 яшьлек гомеремнең иң олы, иң бәхетле көне. Иртәгә мине даны коммунистлар партиясенә кабул итәчәкләр. Шатлыгымның чиге юк...» — дип хәбәр итә.

Тиздән аны ике айлык хәрби курсларга укырга җибәрәләр. Майның 12 сендә лейтенант Гаяз Рамаев разведка взводының командиры итеп билгеләнә.

15 майда ул болай яза: «Бездә инде җәй. Кырлар, урманнар күптән яшәрде. Сандугачлар сайрый. Тик алар хәзер бәхет, мәхәббәт турында түгел, сугышта безнең җиңәчәгебез турында сайрыйлар кебек. Хәзер инде хатлар сирәк язылыр, бик катлаулы, җаваплы бурычлар үтим. Кайнар вакытлар җитте. Фронт аша операциягә ашыгам. Хушыгыз. Гаязыгыз».

Шул ук 1942 елның июнь аенда, батырлыкларын билгеләп, аңа «Кызыл Йолдыз» ордены бирәләр. 20 нче октябрьдан Гаяз Сталинград фронтында 7 нче гвардия армиясенең 72 нче дивизиясе, 128 нче укчылар полкы составында һөҗүмдә катнаша башлый.

Ул 23 октябрьда язылган кош теле кадәр генә хатны фәкать 6 ноябрьда гына салып җибәрә алган: «Бу хат кисәген җибәрә алмый тору сәбәбен аңлыйсыздыр, гафу үтенәм. Сезне Бөек Октябрь революциясенең 25 еллыгы белән тәбрик итеп, иң яхшы теләкләремне теләп — Гаязыгыз».

Яшь-яшь Гаязның олы җанлы булганлыгын, коммунистик омтылышын аңлатыр өчен, тагын бер хатына мөрәҗәгать итү кирәктер. Хатның түбәндәге юллары аеруча гыйбрәтле: «...безгә алмаш булып үсеп килүче туганнан туган кардәшләремә: Ирекка, Илдарга, Әлмирага, Илзарга ирештерегез, изге җиребезне соңгы тамчы каныбыз калганчы саклаганда, без һәлак булсак, безнең эшне алар дәвам итсен, җирдә коммунизм төзү эшенә турылыклы хезмәт итсеннәр!..

1942 елның 20 ноябреннан 7 нче армия Сталинградның көнбатыш ягында хәлиткеч һөҗүмгә күчә. Тиздән Паулюс армиясе камап алына, чолганышта кала.

Разведка ротасының замполиты Харитонов Николай Егорович, Гаязның абыйсына 24 декабрьда хат җибәрә. Бу рәхмәт хатында «лейтенант Рамаевның батырлыгы, кыюлыгы, барлык бурычларын бик оста үтәве, башкаларга үрнәк булуы» телгә алынган. «...Ватаныбызның, партиябезнең ышанычлы, гайрәтле сугышчысы ул. Без аның белән горурланабыз...» диелгән.

Гаять дәһшәтле бу көннәрдә Гаяз үзенең разведка взводы белән Сталинградның Советский районында каты сугышта катнаша. Взвод полкка уңышлы һөҗүм тәэмин итәр өчен юл ача.

Тын. Разведка ротасының командиры өлкән лейтенант Ценин, Гаязның сугышта уздырылган 556 көнлек хезмәтенең нәтиҗәсен исәпкә алып, оператив сводка яза. «1943 елның 15, 16 январенда гына да лейтенант Рамаев, үзенең взводы белән һөҗүм иткән вакытында, беренче булып, Германия фашистлары блиндажларын алды. Нәтиҗәдә взвод 51 гитлерчыны юк итә. Шулар арасында — 6 офицер. Дошманның 60 солдатын пленга алдылар,— дип язып куя. Шул кыска гына тынлыктан файдаланып Гаяз яр буена сыенып хат язып утыра. Хатының ахырында, Уралын сагынуының чиге юклыктан:

*...Уралкаем, ана илем,*
*Йөзең күрәм Идел ярында,*
*Исән калсам, гүзәл Җаеккаем,*
*Кайтачакмын илем таңында.*

*18/1. 43 Гаяз.*

— дип язып куя.

26 январь өлкән лейтенант Ценин ротаның көндәлек сводкасына:

«Бүген лейтенант Рамаев взводы Печеника авылы белән Верх. Елшанкага барел кереп, дошманның биш блиндажына һөҗүм итеп, 18 гитлерчыны юк итә, 28 солдатны һәм 3 офицерны әсирлеккә ала. Шул хисаптан 9 сугышчысы белән 4 орудиене кулга төшерә». Бу көн Гаязның гадәти сугыш көннәренең 566 нчысы иде инде.

Аяз төн. Суык 33 градуска җитә. 23 сәгать 15 минутта Гаяз взводы армиягә яңа гына алынган тәҗрибәсез солдатлар белән тулыландырыла. Һөҗүмгә хәзерлек башлыйлар. «Рабоче-крестьянская» урамы. Почмактагы өй подвалына нык коралланган гитлерчылар урнашкан. Командованиегә монда Паулюс армиясенең байраклары, яшерен оператив документлар, безнең ил буйлап талап җыелган байлыклар тупланганлыгы да билгеле була.

45 минут буена артиллериябез әлеге подвалны ут астында тота. Рота өч яктан һөҗүм башлый. 70—80 метр ара калды дигәндә, подвалдан шундый көчле ут ачыла ки, Гаяз взводына бозлы асфальтка сыенып ятудан башка чара калмый.

Югалтулар артканнан-арта бара. Бу килеш, хәрәкәтсез ятсак, кырылып бетәчәкбез икән дип, Гаяз һөҗүмгә күчәргә карар кыла һәм: «Гранаталарыгызны хәзерләгез! Әйдәгез минем арттан, ур-ра!»— дип, взводны күтәреп, алга ташлана.

Ләкин 10—15 метрлап үткәч, яшен суккандагыдай кискен бер көч Гаязны икенче якка алып ыргыта. Бераздан әле ул, яңадан кузгала... «Алга!»— дип кычкырмакчы да була, әмма тавышын үзе дә ишетми. Аяк-куллар да аны тыңламыйлар иде...

Һәркемнең гомерендә ул гына башкарган эшләр, ул гына кичергән хисләр бар. Көрәшле адымнар аны башкалардан кай ягы белән аерылып торуын бигрәк тә ачык тасвирлыйлар.

Сынауларда үзен ничек тотуына карап, кешегә мәгълүм бер бәя бирелә.

Гаяз һәлак булганнан соң, өченче көндә, 1943 елның 2 февралендә Германия фашистларының 330 меңлек удар группасы коралсызландырылып, фельдмаршал Паулюс Кызыл Армиягә әсир төшәргә мәҗбүр ителде.

1944 елның 12 январенда СССР Верховный Советының Президиумы Указы белән лейтенант, взвод командиры Рамаев Гаяз Галиәскаровичка Советлар Союзы Герое исеме бирелә.

1983 елның 29 апрелендә халык депутатларының Саратов шәһәр советы башкарма комитеты шәһәрнең бер урамын Рамаев Гаяз исеме белән атарга карар чыгара. Волгоград, Уральск шәһәрләрендә дә Рамаев һәйкәл-бюстын булдырырга һәм аны батырлык аллеясына урнаштырырга диган фикерләр бар икән. Бөек җиңүнең 40 еллыгы уңаеннан, мөгаен, алар да тормышка ашырылыр.

## Нонна Орешина

# ВАТАНЫМНЫҢ КӨЧЛЕ КАНАТЛАРЫ

Кыю очучыларыбызның хезмәтен, тормыш-көнкүрешләрен өйрәнгәндә миңа Татарстаннан шактый еракларда йөрергә туры килде: Кырым, Тын океан ярлары, Урал киңлекләре, Белоруссия урманнары — барысы да күз алдымда тора. Байкал буенда күргәннәрем исә күңелгә аеруча тирән уелганнар. Җансыз кебек тоелган таш кыялар, кайчандыр гөрләп аккан-аккан да суы мәңгегә туктап калган коры ермаклар, үзәккә үтеп исүчән тузанлы җил, карсыз суык, җелегеңне киптерердәй эсселек... Бу якларда хезмәт итүче, тормыш алып баручы кешеләр башка токымнандыр кебек. Алар кырыс та, гади дә, гайрәтле дә, шәфкатьле дә. Байкал арты табигате аларны үзе шулай чыныктыргандыр шикелле. Хәер, башкача була да алмый, кеше мондагы шартларны үзенә ничек буйсындырыр иде?! Юк, мин бу кешеләрнең җан асрар өчен алып барган гадәти көрәшләре турында сөйләргә җыенмыйм.

Язмам хәрби очучылар турында. Димәк, алар табигатьнең алда сурәтләнгән шартларында самолетларын карап-көйләп торырга, аэродромны тәртиптә тотарга һәм тәүлекнең теләсә кайсы мизгелендә күккә күтәрелергә әзер булырга тиешләр. Алар — хәрби очучылар!

## Ант биеклегендә

Махсус прибор безнең әле ун чакрымга гына күтәрелгәнлегебезне күрсәтеп торса да, ак атластан сырылган йомшак юрган кебек болытларның чалт аяз зәңгәрлек төбендә, шактый тирәндә калганлыгын чамалап, үзеңне инде галәмнең иң биек ноктасында хис итә башлыйсың. Без каурый болытларның сөттәй аклыгында, тар гына бер аралыкта тузан бөртеге кадәр генә күренеп узачак «дошман» самолетын «тотып» калырга тиешбез.

— Курс... Биеклек...— Командалык пунктынан безнең истребительгә күрсәтмәләр килеп тора.

Подполковник В. В. Шишков үз самолетын, алдан сузып куйган эздән алып баргандай, бик төгәл очырта, хәтта кискен борылышларны да җиңел уздырып җибәрәсең.

Эфирда очучыларның һәм «дошман»ның күмәк ябырылу юлын кисәргә тиешле хәрби идарә офицерларының үзара сөйләшүе яңгырап тора.

— Биеккә күчер!..

— Аңладым. Күзәтәм...

— Максатны күрәм.

— Дөрес күрәсең, максат — сезнеке. Әйдә, эшләгез!

«Юл кисү» вакытында самолет мең төрле хәлгә дучар була. Бик түбәндә дә күзләп йөри ул, «дошман»ны яшел басулар, чуар урманнар, көзгедәй ялтыравыклы күл-су җирлекләреннән яки калкулык араларыннан эзли. Бу очракта самолетның һава алмаштыру «органы»на кош-корт керү куркынычы бар. Шунда ук очу-

чылар, эзәрлекләүне дәвам иттереп, тавыш тизлегенә якын тизлектә биеклеккә атылалар. Таулар, урманнар күздән югала, стратосферага җитәсең. Мондагы күк зәңгәр төстәге шомлы тирәлек галәм киңлеге, аның бинһая мөмкинлекләре турында уйлата башлый, бу зурлык каршында хәтта самолет та кечсезләнебрәк кала кебек.

Тарихка күз салсаң, һава сугышы вакытында «юл кисү» ысулыннан файдаланучыларның беренчесе итеп штабс-капитан П. Н. Нестеровны күрсәтергә була. Ул беренче тапкыр Австриянең разведчик самолетын, эзәрлекләп барып, таран алымын кулланып, кисеп төшерә. Испаниядә дә бу ысулдан файдаланалар. Бөек Ватан сугышында дошман самолетын эзәрлекләү, юлына аркылы төшү һәм тармар итү аеруча киң тарала.

1941 елны Ленинград фронтында, соңрак Мәскәү янындагы сугышларда һава пиратларын эзәрлекләү буенча радиолокацион тәҗрибә постлары эшли башлады. Сугыш тәмам кызып җиткәндә, һавада тар-мар итәргә тиешле ноктаны билгеләүдә, радиолаштырылган постлар ярдәмгә килде. Әмма истребительләр, дошманны эзәрлекләп, аның юлын кисүдә, самолет бортына дошманны уннарча чакрым арадан, төнлә дә, көндез дә «күреп» ала торган радиолокацион прицел куелгач кына, чын мәгънәсендә «юл кисүче»ләргә әйләнделәр.

Һәр самолетның зыян-зәрәтсез күккә күтәрелүен һәм исән-имин җиргә төшүен тәэмин итүче бу аэродромны кеше организмына кан бүлеп торучы йөрәк белән чагыштырырга яраса, аның командалык пунктын, мөгаен, баш миенә тиңләү кирәктер. Локатор экраннары пунктының бик үткен күзләре вазифасын үти сыман, аның «ишетү сәләте» дә ифрат көчле, үз тавышы да әллә кайларга барып ирешә. Хәрби идарә үзәгендә, самолетлар хәрәкәте турындагы һәр мәгълүмат туплана бара. Үз самолетларыныкы да, ятларныкы да. Моннан дошманның юлын кисүче истребительләргә, максатка ирешү өчен, кирәкле күрсәтмәләр дә бирелә.

Мин беләм: менә хәзер без утырган самолет та өлкән лейтенант Вовк карамагындагы экранда якты бер нокта булып хәрәкәтләнә. Тактик очу күнекмәләре башланыр алдыннан, әле моннан ике сәгать элек кенә мин аның янында идем. Гаҗәпләнүемә чик-чама булмады: экранда өзлексез дәвам итүче үзгәрешләрне Вовк шулкадәр тиз аңлап өлгерә, нинди күрсәтмәләр бирергә икәнен кай арада хәл итүенә сокланмый мөмкин түгел. Ул микрофоннарның әле сорысына, әле карасына, әле коңгыртына борыла, кайсыдыр самолетны башка берәү карамагына тапшыра, очышларны җитәкләүче часть командиры белән дә элемтәгә кереп ала, үзенең һәр сүзе ап-ачык яңгырый. «Дошман» истребительләре арткан саен, аларның юлын кисәргә тиешле парлы самолетлар да күбрәк озатыла, экран чуарланганнан чуарлана, командалар кискенрәк яңгырый, өлкән лейтенантның хәрәкәтләре тагын да ышанычлырак, тәвәккәлрәк була бара, аның осталыгы күзгә күренеп арта шикелле.

— Менә ул — безнең максат! — Гел шуны гына көтеп торсам да, подполковник Шишковның бу сүзләре мине сискәндереп җибәрде.— Уң яклап артына төшәбез.

«Дошман» самолеты болытның үзеннән яралган кебек: боз кыйпылчыгыдай болыт койрыгына ябышкан да, күз ачып-йомганчы әреп юкка чыгар сыман. Берничә секундтан без тиешле дәрәҗәдә аңа якын килдек. Тагын бераз... Ә дошманны тәгаен юкка чыгару өчен кирәкле араны ничек чамаларга соң? Монда инструкцияләр генә җитми, беренче шарт — очучының тоемлау сәләте, тәҗрибәсе, осталыгы.

Тәвәккәлләү! Бер мизгел! «Дошман» самолеты, кыя түбәсеннән ычкынган түмгәктәй, аска атылды, без, кисәк борылып, бу урыннан китү ягын карыйбыз. Һәр секундта һөҗүмгә әзер тору һәм самолетыңны куркынычсызлыкта тоту. Бу төшенчәләр берсен-берсе юкка чыгаралар кебек. Әйтик, түбәннән очу үзе үк самолетка куркыныч ясый түгелме соң? Һава һөҗүме вакытында да, максатыңа ирешү тәгаен булсын өчен, кеше сәләте һәм машина мөмкинлекләре соң тамчысына кадәр сарыф ителмиме? Бер-береңнең чыныкканлыгына, ныклыгына, фидакарьлегенә ышанмасаң, төркемеңдәге очышның бер сулудай агышына ирешер идеңме? Очучы осталыгына теорияне шап белү, башкалар тәҗрибәсен өйрәнү юлы

белән генә ирешеп булмасын күреп-тоеп торганда, яшьләрне бу эшкә ничек ияләндермәк кирәк? Һәртөрле рангтагы һәм дәрәҗәдәге очучылар һава киңлеген буйсындыручыларга иң кирәкле сыйфатларның беренчесе итеп акыллы тәвәккәллекне саныйлар. Подполковник Шишков командалык пунктына:

— Өч йөз дә биш! Без эшне бетердек,— дип хәбәр итте. Тавышы барыбер кырыс, чөнки эш түгәрәкләнсә дә, алда әле һәр секунды бик җаваплы булган ун минутлык очыш бар. Шул арада аэродром зонасына чыгарга, болытлар юрганын кичәргә, исән-имин җиргә «аяк басарга» кирәк. Болытлар исә шактый түбәннән йөзә, аэродромның бетон идәне соң чиктә генә күзгә күренәчәк.

Мин командалык пунктында хәйраннарга калып күзәтәм. Истребительләр солдат шинеле кебек соры бетон тар бу юлга гаҗәеп төгәллек белән килеп төшәләр! Эфирда:

— Юлга «аяк бастым!» — дигән хәбәр яңгырый. Яшь кенә тавыш. Киеренкелектән хәбәре дә яңгыравыклы төсмер белән өртелгән. План таблицасыннан карап беләм: өлкән лейтенант Жердецкий төшкән икән.

— Эзең туп-туры булды, килеп төшүең дә төгәл, отлично! — Очучыларның җитәкчесе подполковник Ю. М. Трубчаников, микрофоннан миңа борылды.— Бу егетем мондый көйсез көндә беренче очты әле. Сәләтле. Әйбәт командир чыгачак үзеннән. Мактаудан гына бозылмаса...

Һавалану — яшьлеккә хас сыйфат. Тик очучыларга аның нык кына комачаулавы да ихтимал. Шуңа күрә подполковникның яшь очучыны мактаудан тыелып торуы яхшы аңлашыла. Төнге очышлардан соң ул әлеге өлкән лейтенантка шактый кырыс кисәтү ясады:

— Фараны нинди биеклектә чыгарырга икәнен белмисеңмени, өлкән лейтенант?!

Күз иярмәс тизлеккә, колак ишетмәгән куәткә ия булган бүгенге заман техникасы очучыдан гаять зур физик көч тә, белем дә, сабырлык та таләп итә. Шунлыктан авиациягә коры, хискә саран кешеләр киләдер кебек. Чынбарлык исә моның киресен раслый.

Мин, подполковник Шишковның: «Очучылар училищесына керә алмасам, чит телләр өйрәнеп, дипломат булу ягын караган булыр идем»,— дигәнен ишеткәч, аптырап калдым. Бераздан гаҗәпләнүем арта гына төште: подполковникның музыкаль белеме дә бар икән, өч чит телне су кебек эчә, рәсем ясый. Ник очучы булганын аңлап кара син аның! Үзе миңа өр-яңа Указ суза. Укыйм. Яңа хәрби техниканы яхшы үзләштергәне өчен, подполковник Шишков Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкләнгән.

Ничек кенә катлаулы булмасын, кешедән нинди генә зур тәвәккәллек таләп итмәсен, барыбер, очыш — машина буйсындыру, үз осталыгыңны сынау гына түгел. Очу — сокланып туя алмаслык матурлык та әле ул. Күз алдында күк киңлеге офыктан алып гөмбәз түбәсенә кадәр тоташы белән җәйрәп ята. Чиксезлек һәм кабинаның кул сузымына гына чамаланган кысынкылыгы серле бер килешүчәнлек кичерәләр.

...Төн аэродромны әллә ничә төстәге ут нокталары белән бизи: борылыш тыкрыкларын өзек-өзек зәңгәр нур тасмасы чикләгән, менү-төшү юлларында — саргылт утлар яна. Хәрби самолетларны карап-әзерләп йөрүче техниклар кулында — кесә фонарьлары. Алары теләсә кайчан, теләсә кайда яктыртып-яктыртып алалар. Кешеләр сөйләшкәне дә, самолетларга ягулык ташып йөрүче машинаның гүләве дә, хәтта җил дә басынкыланып калган сыман. Самолет двигательләре дә көндезгедәй ыжгырмый, көчле сызгыруга охшаш тавыш чыгара кебек. Яшелле-кызыллы утларын җемелдәтеп, менү юлына борылган истребительләр дә посып, җиргә елышып бара кебек.

— Миңа төнлә очу ошый! — Подполковник Антонец кисәктән ачылып китте. Бөтен торышыннан кырыслык кына сизелүчән командирның хискә бирелүе шулкадәр сәер тоелды, мин ихтыярсыздан, адымнарымны салмаклатып, аңа борылдым. Без инде самолет янына килеп җиткән идек.— Менә туйганчы карагыз! — диде Владимир Михайлович.— Без утырып очачак истребительләр болар. Парлап очачакбыз.

Биш басмалы тимер баскыч буйлап өскә күтәреләм. Баш өстендә генә — кабинаның капкачы. Катапультлы утыргыч нык иттереп һәм шул ук вакытта сак кына үзенә сеңдерә. Каршыдагы таблода язулар, саннар җемелди. Командир, миңа карап, көлә:

— Гали бабай мәгарәсендәге кебекме? — Ул, алдагы кабинаның баскычында килеш, минем яндагы техникка күрсәтмәләр бирә.— Булыш, булыш! Парашют элмәкләре ялгыш киелмәсен. Кабинагыздагы яктылыкны чамалап куегыз, күзегезгә төшәрлек булмасын!

Күтәрелеп китүебезнең беренче мизгелендә бөтен тирә-юнь дөм-караңгы булып тоелды. Кабинаның үтә күренмәле капкачына дегет сылап куйганнар диярсең! Бераз вакыт үткәч, төньяктан яшькелт яктылык сизелә башлады, ул да түгел, көнбатышның кызгылт-сары нурлары күренде, көнчыгыш исә һаман кап-кара иде.

— Күрәсезме; нинди генә нурлар юк монда!? — Кабиналар арасында үзара сөйләшү өчен көйләнгән бик катлаулы җайланма да командир тавышыннан сизелеп торган соклану галәмәтен яшерә алмый.

Бу подполковник белән беренче очрашканда мин аның шикләнеп сынаучан карашыннан коелып төшкән идем. Очышларны тикшерүен тыңлаганда, командир миңа бик кырыс, таләпчән тоелды. Командалык итү пунктында ул бик җитез, төгәл һәм тәвәккәл иде. Көндезге очышта мин аның бөтен торышындагы камиллегенә сокландым. Ул чакта ук: «Бу очучы — лирик бит»,— дигән уйга килгән идем.

Димәк, очучыда ир-егетләргә хас сугышчанлык белән иң нечкә хисләр берләшә. Димәк, матурлыкны тирәннән тою тәвәккәллек белән бер рәткә баса ала һәм тора-бара бу бердәмлек, очучының күзләренә — ял, җанына терәк буларак, аның беренче ихтыяҗына әйләнә. Шушындый кискенлекләрдә, беренче карашка, капма-каршы булып тоелган хисләр бердәмлегендә очучы шәхесе формалаша. Алар һөнәрне генә түгел, очу сәнгатен тирәннән белүчеләргә әйләнәләр. Очуы да нинди бит әле аның: хәрби өйрәнү бурычларын үти-үти очу, мәгълүм бер хәлләрдә сугыша-сугыша очу, җиңә-җиңә очу, кешегә бирелгән физик һәм психик мөмкинлекләрне соңгы тамчысына кадәр сарыф итеп очу...

Күккә бик азга гына күтәрелгән арада да очучыдан һәр хәрәкәткә иҗади мөнәсәбәт таләп ителә. Очу — җыр, шигырь, рәсем кебек үк, талантлы кешенең иҗат җимеше ул. Очуны иҗат итүче автор төгәлсезлек җибәрсә, аның бу хатасы җырдагы яман яңгыраучы аваз яки рәсемдәге күз карашын рәнҗетердәй ямьсезлек булып кына калмый, бу ялгышлык кешенең гомерен тартып ала. Аерма шунда.

## Ал чәчәкләр

Моннан берничә ел элек очучылар үз частьларына «гвардия» исеме бирелүгә кырык ел тулуны билгеләгәннәр. Өлкәннәр дә килгән. Декабрь ае булган бу. Тирә-якта — таш кыялы сопкалар, үзәккә үтәрдәй салкын җил исә, ә өстәлләрдә вак кына алсу таҗлы сазанак чәчәкләре елмаеп утыра. Менә сиңа — декабрь! Байкал тирәсендә үсә торган, беренче карашка, тәбәнәк кенә, корыган тал-тирәкне хәтерләтүче бу куакчыкның сокландыргыч сыйфаты бар: кыш уртасында кыска ботакларын сындырып, җылы бүлмәгә алып кереп, суга утыртсаң, берничә көннән ал чәчәк атып җибәрәләр. Аларга карап: «Менә бит, барына да чыдап, сабырлык түгел!» дип уйлыйм. Гүзәллеген табигатьнең һәртөрле кырыслыгыннан саклап яшәргә өйрәнгән сазанак чәчәкләре хәтердә хәрби очучыларның ныклы таянычлары, ышанычлы киңәшчеләре булган хатыннары турындагы истәлекләрне яңарта. Алар да һәр очышның бөтен җаваплылыгын үз иңнәрендә тоталар, тик, ирләре һавага күтәрелгәндә, алар җирдә кала. Көтәргә. Ягымлы сүз, якты йөз, кайнар аш белән каршы алырга...

Очучы хатыны... Арадан берсе — Лидия Васильевна Гандера. Йөзендә елмаю нуры балкый, карашында — сабырлык.

— Без монда тугыз ел яшибез инде,— дип сөйләп китә ул.— Бу кадәр үк озак яшәүчеләр әллә ни күп түгел: Кленинннар, Кудрявцевлар, Падалкилар... Балаларыбыз да шушында үстеләр. Хәзер ияләндек инде. Баштарак кыен булды. Мин — шау чәчәкле бакчаларда, теләсә нинди җимешне агачыннан өзеп алып ашарга өйрәнгән кыз. Иремнең очучы булачагын мәктәптә укыганда ук белдем...— Лидия Васильевна көлеп җибәрде, сазанак чәчәгенең таҗлары ачылды диярсең! — Без кечкенәдән бергә үстек, бер мәктәптә укыдык. Ул авиамодель ясап үҗәтләнә иде. Аннары очучылар училищесына китте, мин — мединститутка. Башта биткә операция ясаучы хирург булдым. Җирдәге бөтен кешеләрне матур итәсем килде. Аннары теш дәваларга да өйрәндем. Шулай кирәк иде. Нишлисең бит! Язмышымнан һич тә зарланмыйм, бәхетле мин.

Любовь Николаевна Черненконың җырчы булуын ышанып көткәннәр.

— Консерваториядә укый башлаган идем инде.— Люба да елмая.— Мондагы һәвәскәрләр арасында минем җырлавым, мөгаен, кирәгрәктер дә әле.— Любаның гадәти сөйләшүендә үк украиннар тавышына хас музыкальлек сизелеп тора...

Валентина Григорьевна Коненко очучы гаиләләренең серен ачып җибәрә:

— Кайберәүләр, гарнизонда күңелсез, дигән булалар. Имеш, якында гына зур шәһәрләр дә юк, фәлән дә фәсмәтән.— Валя гарнизон тормышын яман яктан сурәтләүче сүзләрне әйтеп тормый.— Минемчә, кешенең нинди тормыш алып баруы шәһәрнең зурлыгына бәйләнмәгән. Ун миллион халкы булган калада да коточкыч күңелсез яшәүчеләр очрый. Шулай түгелмени? Мин әле балалар бакчасына тәрбияче булып урнашырга йөрим. Белмим, эшли алырмынмы-юкмы, инглиз теле укытырга әзерләнгән идем бит мин...

Светлана Владимировна Козловага үз һөнәре буенча эшләү бәхете әләккән. Ул — радиоэлектрон җиһазлар механигы.

— Алайса, сез иregезнең хезмәтенә дә шактый якын? — дип сорыйм.

— Әйе шул, барын да белеп торам. Ул кадәр үк кирәкмәс тә иде. Уем гел аңа тоташкан, эштә дә, өйдә дә. Җайланмаларының төзелешен үк белмәсәм, бәлки, җан ул кадәр тынгысыз булмас иде. Икенче яктан карасаң, белеп торуның зыяны юк кебек. Мин очышларга турыдан-туры хезмәт күрсәтәм. Очучының исән-имин әйләнеп кайтуы миңа да бәйле. Әгәр игътибарлылыкны саный торган үлчәү булса, эштә, мөгаен, миннән дә зуррак игътибарлы кеше таба алмас идегез. Ирем очмаса, бәлки ул кадәр үк бирелеп эшләп булмас иде...

Бу якларда кояш баюны күзәтүе рәхәт. Ул, офык читенә эләгеп, шактый озак тора, аннары кинәт аска төшеп юк була. Тирә-юньне тирән караңгылык, сәер тынлык каплый, гүя тормыш тукталып кала. Аэродром гына гүли бирә, утлары да җемелди, моторлар үкерә—бары да хәрәкәттә. Командалык иту пунктыннан карaганда, бераз читтәрәк урнашкан өйләрнең якты тәрәзәләре дә күренә. Очучылар шәһәрчегендә җылы, рәхәт кебек. Анда очучының кайтып керүен көтәләр. Очучы өендәге хатыннар һавадагы һәр авазны тыңлап, күңел аша үткәреп, шомлы уйларга урын калдырмаска тырыша-тырыша, өзлексез көтеп яшиләр.

— Һаваны самолетларның гүләве яңгыратып торганда, минем җаным тыныч.— Галина Витальевна Диденко миңа үз кичерешләрен аңлата.— Дөнья тынтын калса, мин инде шикләнә башлыйм. Озак та үтми, тагын гүләү башлана. Шул чиратлашуны тыңлап ятасың да ятасың. Ниһаять, ул ишекне ача! Шунсыз йокыга киткәнем юк.

Яшь гаиләләрдә әлегә барын да белеп бетермиләр, бугай. Әнә Оля Турчина сөйли:

— Минем ирем гел әйтә: «Син мине көтеп торма, ят та йокла!» ди. Безнең бала да яшь әле, шуңа күрә утны сүндермим, барыбер йокламыйм ич мин. Элек шактый тыныч йоклый идем әле. Күптән түгел политбүлек очучыларның хатыннарын аэродромга чакырды. Бик дөрес иттеләр. Барын да күрсәттеләр. Очу хикмәтләре турында сөйләделәр. Ирләребез гади генә иттереп аңлаталар. Бер уйласаң, бу эштә баш җитмәслек кыюлык кирәк бит!

Оля сөйләргә оста. Галя Ольшевская кичерешләрен тиз генә чишә торганнардан түгел. Тыңлап кына утыра.

Очучы хатыннарының самолетлар төшә торган юл янына килеп тезелүен күз алдында тотам. Коточкыч көчле җил чыккан көн иде. Самолетлар очыштан әйләнеп кайталар. Мондый шартларда, табигатьнең холыксызлыгы белән күзгә-күз килгәндә, юлга төгәл төшү бик кыен. Җиңелчә генә янтаюлар, җиргә «аяк тидерү» вакытының бераз үзгәрүе ихтимал. Хатыннар бу нечкәлекләрдән хәбәрдар да түгелләр, тик аларның җаннары барын да тоя иде. Барлык самолетлар да төшеп беткәч кенә, берәве шаяртып куйды: «Болай булгач, ярый инде, әллә ни ачуланырлык түгел!»

Очучы балалары барын да гадәти кабул итә. Алар бу шартларга кечкенәдән иләнеп үсәләр. Балалар бакчасы мөдире Людмила Михайловна Еременконы да мин өлкән группа балаларын аэродромга алып килгән көнне очраттым. Сизеп торам: балаларның монда беренче генә килүе түгел. Берсе:

— Менә бу самолетта микем әти оча,— ди.

Шунда ук аңа каршы төшәләр:

— Юк, ул — минем әтиң самолеты.

— Түгел, безнең самолет ул!..

Людмила Михайловна сүзне башка якка бора.

— Әйдәгез, балалар, Дима Чуринның әнисе эшли торган җиргә барыйк!

Надежда Чурина барлык параметрларны теркәп баручы приборның эшен тикшерә икән.

— Минем хезмәтнең ниндилеген аңлатырлык сүзләр каян табарга соң?

Ул куе чәчләрен кысып торган кыекчасын рәтләгәндәй итә. Комбинезонын төзәткәли, кызарып чыга. Әйтерсең лә балалар алдында имтихан тота. Надежданың сөйләгәннәрен тыңлап бетергәч, балалар Света Кирейцеваның әнисе эшли торган якка юнәләләр...

Яңгыр сибәли. Эссе һава, тәмам кайнарланып җиткән җир һәр тамчыны суызлып-суызлып алалар да йотып ук җибәрәләр шикелле. Бу тирәләр яшеллеккә бик саран булганга, ахры, һәр өйдә гел үстерәләр. Үрмәлеләре дә, аска салынып үсә торганнары да, тәрәзә төбендәгеләре дә күп.

Хатын-кызлар советы председателе Галина Алексеевна Першина балконнарда да гөлләр үстерүне оештырып йөри.

— Тиздән өйдәге чәчәк шытымнарын балконнардагы әрҗәләргә күчерер чак җитә,— дип сөйли ул.— Безнең якның җәе кыска. Чәчәк атып өлгерсеннәр дисәң, башта бүлмәдә үстерәсең. Балконнарны гөлләр белән бизәү буенча ярышлар үткәрәбез, конкурслар игълан итәбез.

— Кышын шәһәрчекнең үзәк мәйданына чыршы куябыз. Кыш бабай балаларга бүләк өләшеп чыга. Шушы коңгырт җирдә су туңдырып шугалак ясыйбыз. Тимер аякта фигуралап шуучы осталарыбыз да бар. Чаңгычылар сопкаларга бара. Рәхәт! Иртән торасың да, чаңгыңны күтәреп, сопка ягына йөгерәсең.— Таня Завражнова куллары белән чаңгыда баргандагы кебек хәрәкәтләр ясый.— Мин кызымны да чаңгыда шуарга өйрәттем инде.

Таня сүзен Валентина Перегуда куәтли:

— Әле безнең балыкка йөргәнне күрсәгез! Балыклы күлләр күп монда. Кайсында нинди балык эләксә, шул исемне бирәбез: Чуртан-күл, Тәрәч-күл... Ял көннәрендә гаиләләребез белән чыгабыз. Балыгыннан бигрәк матурлыгын яратам мин ул күлләрнең. Монда бит безнең су да юк, урман да юк, яшел алланнар да юк, бөтен дөньяны коңгырт чуер таш каплаган кебек. Читкәрәк китсәң, рәхәтләнеп ял итәрлек урыннар барын күреп шатланасың. Күк җиләк, кара җиләк, гөмбә җыябыз — бары да бар.

Бу якларда, кырыс табигать һәм бинһая җаваплы хезмәт шартларында барлык нәрсәләргә икенче бәя бирелә. Дусларның, иптәшләренең үзара мөнәсәбәте дә башка. Монда китап, музыка күп тапкырга кадерлерәк. Хәтта яшелчәләр, җиләк-җимешләр дә монда тәмлерәк кебек.

Әгәр инде берәр театр коллективы яки филармония артистлары килеп чыкса, очучылар шәһәрчеге тантана кичерә. Кечкенә зал шыгрым тула. Сәхнәдән яңгыраган һәр авазны йотып алырдай булып тыңлыйлар, кул чабалар, ихлас күңел-

дән рәхмәт сүзләре яудыралар. Бу хәлләрне күргәч, мондый шәһәрчекләргә актерларның, музыкантларның, язучыларның килеп йөрүе ни кадәр мөһим икәнен аңлыйсың. Тиздән Офицерлар йортының яңа бинасы салыначак. Кирәк, бик кирәк. Якты, иркен заллар, ял бүлмәләре, төрледән-төрле түгәрәкләр эше нәкъ менә монда кирәк! Бу якта хезмәт итүче очучыларның хатыннары зәмһәрир салкын кичләрдә, үзләренең иң матур күлмәкләрен киеп, ял итәргә, биергә, җырларга йөри алсыннар өчен кирәк ул!

Сазанак сабаклары, беренче карашка, шыксыз, корыган, сынып бетәргә йөз тоткан агачны хәтерләтә. Әмма язның беренче нурлары гына күренсен, бөреләре ачылып китә дә, бөтен тирә-юнь ал нурга күмелә — сазанак чәчәк аткан! Ерак гарнизонда фидакарь хәрби очучыларның җаннарын җылытып яшәүче хатыннар да хәтердә шул нәфис чәчәкләр кебек саклана лар.

## «Оча торган танк»лар

Минем моңа кадәр бу төр вертолетка утырганым булмаганны ишеткәч, очучы И. Сергеев кыска гына аңлатты: «Маневр өчен ясалган вертолетлар болар, тизлекләре бик зур, искиткеч камил приборлар белән җиһазланганнар. Без аларны «оча торган танк» дип кенә йөртәбез».

Майор В. Константинович мине кабинага алып керде: «Сез истребительләрне өйрәндегез инде, карагыз әле, безнең вертолет та истребитель кебек бит әйеме?!»

Күккә күтәрелә башладык. Вертолетлар парлап-парлап төркемнәргә бүленгән. Аста — сопка түбәләре, агачлар шуышып үтте. Вертолет канатларының күләгәләре аларны сыйпап уза кебек. Колакка киертелгән җайланмадан И. Сергеевның:

— Тиешле урынга җиттем, эшкә тотынам,— дигән хәбәре яңгырады.— Дүртенче квадратта бик күп олы танклар җыелган. Караңгы җирлеккә сыенганнар.

Бу сүзләрне ишетмәсәм, мин тау-таш арасына поскан танкларны һич абайламас идем. Сопкалар арасында калын кар катламы ята. Аклыгы күзне камаштырырлык. Соры палаткалар, пулемет оялары да тирә-яктан кар белән томаланган. Баррикадалар белән уратылган кебек. Сопкалар ягыннан сузылган юлдан килсәң, аларны һичничек күрә алмас идең. Безнең биеклектән соры шинель кигән кешеләр дә аерым ачык танылалар.

Сопканың түбәсендә локатор тәлинкәсе әйләнә. Астарак, тау итәгендә, үзйөрешле ракеталар җайланмасы күренеп кала. Хәрби хәлдә булсак, безнең өскә әллә кайчан ут өермәсе ябырылыр иде инде.

Кисәктән янга борылгач, без берсеннән-берсе көчлерәк тавышлар дулкынына килеп кердек. «Максатыгыз — сулдарак!», «Күрдем, таптым, маневр ясыйм», «Син алдан баручысын ал! Мин уң яктан бәрәм». Вертолетларның төп төркеме килеп җитте. Парлап та, звенолап та очалар. Тирә-юньне гел алар тутырды. Шома маңгайларына карасаң, сөзешергә әзерләнгән үгезләр искә төшә.

— Син миңа карап оч! — Сергеев арттагы вертолетка эндәшә.— Бик еракта калма!

— Була ул! — Константинович миңа да хәбәр итә.— Хәзер сугышып алабыз...

Кеше үзен кайчан очучы дип хис итә икән: самолетка беренче утыруындамы, беренче тапкыр, очышын түгәрәкләп, җиргә исән-имин килеп төшкәчме — әйтүе авыр. Һәркайсы үзенчәдер инде. Хәрби очучылар исә үзләренең очучы икәнлекләрен бөтен тирәнлеге белән беренче уңышлы һөҗүмнән соң тоялардыр, мөгаен. Сүз, әлбәттә, хәрби өйрәнүләрдәге һөҗүм турында гына бара. Менә ул — пулемет көпшәсенең зәңгәрләнеп торган «күзе». Учларың — тоткада, монда бармакларга җайлы. Хәзер хәбәр итәргә кирәк: «Эзләгәнне таптым, эшкә тотынырга әзермен!» «Атака!» — дигән сүз яңгырый. Бөтен барлыгың: «Ут ачарга!» дигән боерык көтә.

Күк йөзенең караш җитәрлек арасын эреле-ваклы вертолетлар тутырган. Сопка аралары чуп-чуар. Берәүләре әле күтәрелеп кенә килә, икенче төркем инде төшеп бара, кайсыларыдыр һавада эленеп тора кебек. Йөк ташучы вертолетлар

сабыр гына, әйтерсең лә җирне капшап карый-карый, төшеп утыралар. Кар өстенә тран сузыла, тирә-якны орудиеләр, аларны тартып йөрүче машиналар, пехотаны төягән бронетранспортерлар тутыра. Хәрби вертолетлар һавага эленеп тик торалар, пәрдә корып куйганнар диярсең. Шул рәвешле десантчыларга мөмкинлек тудырыла. Десантчылар исә юк ителергә тиешле объектларга якынлашалар. Мин аларның мотор тавышыннан гүләп торган фюзеляжда автоматларын җайлабрак куюларын күрәм кебек. Ишек ачылып киткәч, алар җир белән ике араның ераклыгын чамалагандай, күзләрен кыса төшәләр дә аска сикерәләр. Вертолетның бер ноктада эленеп торуын тәэмин итү өчен нинди осталык кирәген очучы үзе генә белә!

Десантчыларны озатып бетерүгә, вертолетлар читкә ашыгалар. Җиргә сибелгән автоматчыларның бер төркеме юл буенда ныгып кала, башкалары ракетачы дивизион урнашкан сопкага менә башлый. Күктән карагында, җирдәге солдатларның хәрәкәте бик акрын кебек. Вертолеттагыларга тирән кар ерып баруның да, солдат иңендәге коралларның авырлыгы да сизелми шул. Күктә — зурлыклар башка: тизлек тә, көч түгү дә, ара ераклыгы да. Монда җирнең тарту көче генә һәрчак истә. Җирдәге хәлләр дә күктәгеләрнең җентекле күзәтүе астына алынган. Кыскасы, җир — игътибар үзәгендә, барысы да аның зурлыгы белән үлчәнә.

Майор Константинович миңа бурычларын аңлатып бирде:

— Без җирдәге техниканың ничек яшеренүен дә, өстән карагында, әйберләрнең ничек күренүен дә тикшерәбез. Вертолетның үзенең кайчан ничек күренүен дә, аны истребительләр һөҗүменнән ничек саклап калырга мөмкин икәнлеген дә ачыклыйбыз...

Капитан В. Козенков, ачылып киткән чагында:

— Миңа вертолетта ясала торган маневрларның мөстәкыйльлеге ошый,— дип сөйләгән иде.— Зенитчыларның яки ракеталы җайланмаларның утыннан котылыр өчен, самолетлар я бик биеккә, стратосферага чаклы күтәрелергә тиеш булалар яки җиргә елышып ук очалар. Хәрби вертолетларның тизлеге һәм төрле маневрларга осталыгы тиз генә җиргә кунакларга да, тау араларына кереп посарга да мөмкинлек бирә...

Без түбән генә очабыз. Мондый хәрәкәт очучыдан зур осталык сорый. Сопкаларның сыртлары арасыннан очканда, көтелмәгән тарафтан килеп бәрелгән җил, вертолетның очу юнәлешен үзгәртә. Шуңа күрә бу очракта төгәллек кенә дә җитми, астагы һәр «тыкрык»ны, ермакларны-фәләннәрне бик яхшы белү кирәк. Байкал арты климатының үзгәрүчәнлеге очучылардан үзләре яши торган урынга өзлексез игътибар таләп итә. Тирәннән өйрәнмисең икән, белгәннәреңне гел тулыландырмыйсың икән, сине коткарырга һәрвакыт әзер торучан җирнең кисәктән һәлакәтенә сәбәпче булуы ихтимал.

...Гаҗәеп зур гәүдәле кошлар көтүе кебек вертолетлар эскадрильясы «юлга» чыга. Теземнең башындагылары инде күздән дә югалды, соңгылары күтәрелеп кенә килә. Подполковник Марк Семенович Биль үзе, барын да озатып бетергәч кенә, иң азактан очачак. Ул миңа:

— Ну, киттекме? — диде.

Биль шактый йончыган инде: җирдә дә аңа зур җаваплылык йөкләнгән, очарга да кирәк. Сынап карап торуымны һич сизмичә, ул эшен дәвам итә, хәбәрләрне тыңлый, төркем башында очучы белән сөйләшә. Бары да тәртиптә икәненә ышангач кына: «Хуҗалык зур шул безнең,— дип шаярткан була.— Барына да өлгерергә кирәк, ә ашыгырга ярамый. Ашыкмыйча гына йөгер! Хәлне шуннан аңлагыз инде!..»

Двигательләр ни бар көчләренә гүлиләр, вертолетлар, сәәгәк үгезләрдәй, кыска гына араны йөгерәләр дә кисәктән биеклеккә, йомшак холыклыларны кичермәүчән күк киңлегенә ашыгалар...

# Җәүдәт Дәрзаман

## КҮҢЕЛ ҖЫЛЫСЫ

Нургаян Мөхәммәтшин кабинетында авыл табигатенең иң күркәм бер өлеше саклана сыман. Монда һәр нәрсәдән үзгә бер җылылык сирпелеп тора. Түрдә — түшәмгә кадәр бөдрәләнеп үскән купшы гөл. Стена буена тезелгән Кызыл байраклар, вымпеллар, пыяла шкаф эчендәге дипломнар хуҗалыкның озак еллар дәвамында намуслы хезмәт итеп яшәве хакында сөйли. Моннан ике ел элек Бөтенсоюз социалистик ярышында ирешкән казанышлары өчен XXII партсъезд исемендәге колхоз КПСС Үзәк Комитеты, СССР Министрлар Советы, ВЦСПС һәм ВЛКСМ Үзәк Комитетының күчмә Кызыл байрагына лаек булды... Бу кадерле бүләкләрнең һәркайсы — колхозчыларның күпьеллык тырышлыгы нәтиҗәсе, әлбәттә.

Коридорда аяк тавышлары ишетелде. Аны адымнарыннан ук таныды председатель. Халык контролерларының баш группасы председателе Әюп Вәлиуллин иде бу.

— Нургаян абый,— диде ул, ишектән керешли ук,— Кызыл Мишә фермасында сөт кимеп киткән. Баш зоотехник белән шунда барышлый керүем.

«Тынгысыз җан,— дип уйлап алды аның турында председатель.— Кырыкка бүленсә бүленер, әмма үз дигәнен эшләми калмас».

Экономист китүгә, ишектә ике егет күренде. Берсе эшкә бик батыр булса да, кыюсызрак. Анысының кабинет бусагасын беренче генә атлавы, бугай әле. Ә икенчесе эшен дә булдыра, сүз артыннан да кеше кесәсенә керми. Дөрес юнәлеш биргәндә, әйбәт кенә урта звено җитәкчесе чыгачак үзеннән. Бу юлы да үгезне мөгезеннән алды егетебез.

— Иртәнге сигезгә военкоматка чакырганнарые, Нургаян абый, машина менгермәс микән?

— Кичә, кичке нәрәт вакытында ни уйладыгыз соң?

— Эш күп булды бит, Нургаян абый. Мавыгып киткәнбез.

— Җиде-сигез чакрым җәяү тәпиләсәгез, исегезгә тиз төшәр иде төшүен... Хәзер «Сельхозтехника»га машина китә, шуның белән барып кайтырсыз...

Ул да булмый, телефон шалтырады. «Сельхозтехника»дан икән. Хәл-әхвәл сорашкан арада гына да әллә никадәр мәсьәлә хәл итте председатель.

— Рәхмәт, бик рәхмәт,— диде ул соңыннан.— Машина хәзер кузгалырга тора. Ургычны шуңа салып менгерербез. Әзер двигательне ала төшәрләр. Нәрсә? «Волга»ны әйтәсезме? Бер пешкәгенең рәте китте. Җибәрербез, дисезме? Менә рәхмәт! Сау булыгыз!

Аңа һәркөнне, хезмәт иртәсе башлануга, хуҗалыктагы күп төрле мәсьәләләрне хәл итәргә туры килә. Барысы да бердәй әһәмиятле аларның, берсен дә онытып торырга ярамый.

Кабинет бушап, тынып калды. Инде машина-трактор утарына, фермаларга барып килергә дә була. Председатель сәгатенә күз төшерде. Радиодан иртәнге концерт башланган иде инде. Нургаян Вәлишович радиоалгыч төймәсенә басты. Эфирда ул яраткан җыр яңгырый иде.

Туган авылым минем, кырларыңда синең
Шаулап үтте яшьлек елларым...

Туган авыл... Ул юкка гына җырларга күчмәгән ич. Мәңге җуелмаслык булып күңелне биләп ала икән авыл дигәнең! Әтисе яшьли дөнья куйганлыктан, Нургаян аны бөтенләй хәтерләми диярлек. Ә менә авыл халкы бик яхшы хәтерли Вәлишаны, бүген дә бары тик яхшы яктан гына телгә ала. Күмәк хуҗалык оештыруда башлап йөрүчеләрдән, колхозның беренче төзелеш бригадирларыннан булган ул. Олыларны — олылый, кечеләрне хөрмәт итә белгән. «Аның таләпчәнлегенә, гаделлегенә сокланмаган кеше юк иде»,— дип искә ала озак еллар дәвамында шушы колхозда председатель булып эшләгән Билал ага Гайнетдинов.

Бөек Ватан сугышы башлангач, тормышның бөтен авырлыгы хатын-кызлар, Нургаян кебек үсмер малайлар җилкәсенә төште. 1942 елның язгы чәчүен Нургаян кебек унбиш яше дә тулмаган авыл малайларының күбесе кырларда каршылады. Атлар йончыган, кешеләр талчыккан. Ә эш тукталмаска тиеш. Фронтка икмәк кирәк. «Тырышып эшли күрегез, авылдашлар! Сез үстергән икмәкнең һәр бөртеге ядрә булып дошман йөрәгенә кадалачак!» — дип язалар әнә өлкән абыйлар фронттан. Димәк, эшләргә, көчеңнән килгән кадәр тырышырга кирәк. Атлар булып, атлар түзмәде, ә кешеләр чыдады, өлкәннәргә карап, үсмерләр тырышты. Атлар ялга туктаган чагында сабаннарны үзләре тарттылар. Кирәк чакта, муеннарына тубал асып, орлыкны үзләре чәчтеләр. Үз куллары белән чәчкән игеннең тигез келәм булып шытуын күрүдән дә зуррак шатлык булмагандыр Нургаян өчен ул вакытта. Барысы да бер йодрык булып тупланган хәлдә, авыл кешеләре, көннәр, айлар, еллар дәвамында фашизмга һәлакәт әзерләделәр.

Җиңү килде. Исән калган ирләр авылга кайта башладылар. Эшне дүрт ел буена ирләрчә ныклык белән алып барган Асия Тимерханова, ире кайтуга, колхоз идарәсенә килде.

— Дөрес аңлый күрегез,— диде ул,— эшлисем килмәгәннән түгел, сугышлардан йөреп кайткан ирләргә эш кушып йөрергә йөрәгем кушмый. Әнә Вәлиша абзый малаен куегыз минем урынга! Егет, кеше ир-ат белән уртак телне дә тизрәк табар...

Менә шулай итеп, Нургаян кырчылык бригадиры булды. Ике ел йөрде ул бригадир булып, эшен дә әйбәт кенә башкарды кебек. Тик күңеленә кереп оялаган бер уй, җыр булып, әйләнде дә әйләнде тел очында.

Китә казлар, китә казлар,
Китә казлар Донбасска,
Мин дә уйлап торам әле
Шул казлардан калмаска.

Һәм Донбасска китте Нургаян. Күмер чапты. Арып кайта иде дә, күзләрен йомды исә, кара ташкүмер фонында алтын дулкыннар булып уйнаган иген басуларын күрә иде. Авылны сагынуына артык түзә алмады, янәдән әйләнеп кайтты Нургаян. Икеләтә дәрт белән керешге ул эшкә. Күмер чабып ныгыган куллар бригадир дилбегәсен дә, кирәк җирдә, нык итеп тота белде. Тагын берничә елдан аны «Ирек» колхозына председатель итеп сайладылар. Авыр хәлдә иде колхоз, аны «Ирек» колхозына председатель итеп сайладылар. Авыр хәлдә иде колхоз, авыл кешеләренең иң булдыклыларына кадәр халыкка таратып бетергәннәр иде. Авыл кешеләренең иң булдыклы дигәннәрен үз тирәсенә туплап, әрттәлык белән, биш ел эчендә председатель. Һәм басты колхоз аякка, җиңел сулап куйды халык!

Илле алтынчы елларда — Нургаян Вәлишович утызмеңчеләр сафында. Тагын ике елдан аны «Кызыл Таң» колхозына күчерәләр. Тора-бара хуҗалыкка «Маяк» һәм Пушкин исемендәге хуҗалыкларны да кушып, аңа XXII партсъезд исемен бирәләр.

Үткәннәрне бүгенге белән чагыштырып карасаң, ышанасы да килми хәтта — никадәр үсеш, никадәр үзгәреш, никадәр алга китеш!

Кайчандыр колхозның булган бөтен техникасы бер тракторы да бер «Коммунар» комбайны белән исәпләнә иде. 283 баш мөгезле эре терлек, 210 баш сарык, 400 тавык — барлык кош-корты, терлек-туары шушы иде хуҗалыкның. Бүген исә колхозның 70 кә якын тракторы, 40 тан артык автомашинасы, кирәк кадәр комбайннары бар. Мөгезле эре терлекләрнең саны 3000 нән артып китте. Мөхтәрәм кешеләре никадәр аның! Механизаторлардан — сигез, терлекчеләрдән тугыз кеше Ватаныбызның төрле орденнары белән бүләкләнгән. Унөч колхозчы Бөтенсоюз Халык хуҗалыгы Казанышлары күргәзмәсенең медальләренә лаек булды. Менә ничек үсте кешеләр, менә ничек үсте авыл! Моңа горурланмый мөмкинмени?

Нургаян Вәлишович, уйларыннан арынып, үзалдына елмаеп куйды. Менә бит, җыр дигәнең ничек чайкалдырып түкте күңелдәге хисләрне. Радиодан яңгыраучы концерт әле тәмамланып кына килә үзе, ә күз алдыннан тулы бер гомерне үткәрде.

Нургаян Вәлишович фермага килеп кергәндә, экономист белән баш зоотехник Яхъя Нуриев кайтырга җыеналар иде.

— Ничек, ачыкладыгызмы?

— Азыкны вакытында китереп өлгермәгәннәр. Иртәгә-берсекөнгә эшләр җайланыр, Нургаян Вәлишович!

— Ярый, әйбәт,— диде председатель,— безнең эштә дилбегәне бушатырга ярамый шул!

Әле кайчан гына көнлек савым сыер башына җиде килограммнан да артмый иде. Март ае. Кызыл Мишә фермасындагы 400 баш сыерны машина белән сава башларга кирәк. Ферма мөдире дә икеләнә, сыер савучыларның да шикләнүе көчле. Терлекчеләрнең гомуми җыелышында «ду» килделәр.

— Булмаганны! Гомер бакый кул белән саудык, артмадык та, кимемәдек тә. Киләчәктә дәген шулай булыр!

— Әле рәтле генә урында барабыз, машинага күчсәк...

— Машина белән сава башласакмы? Сыер койрыгынаябышкан салам шикелле, районның иң арттагылары арасында сөйрәләчәкбез.

— Ашыкмыйк, каш төзәтәм дип күз чыгармыйк!

Шулай да, берничә савымчы яңалыкка каршы килмәде. Саву җайланмасы эшли башлауга ук, яңалыкның өстенлеген исбатларга керешә алар. Белгечләр дә, колхоз председателе белән партком секретаре да алар янында еш булдылар, булыштылар. Терлекләр акрынлап аппаратка күнегә башлады. Савымчыларның хезмәте күпкә җиңеләйде: эшләре тиз бетә, куллары талмый. Шуңа күрә аппарат белән савучылар арта торды. Атна-ун көн дигәндә, сыерларның барысы да аппарат белән савуга күнегеп җиткәннәр иде инде. Ферма күләмендә сөтнең әле һаман да сизелерлек артып китмәвен терлекчеләр яңалыктан күрмәсен өчен, колхоз җитәкчеләре кулдан килгәннең барын да эшләргә тырышты: азыкны тәмләтергә, күләмен дә арттырырга карар кылынды. Ниһаять, сыерлар сөт бирүдә ныклы эзгә төштеләр, терлекчеләрнең дә күңелләре үсеп китте. Аеруча сөтле сыерларны махсус рацион белән ашатырга керештеләр. Ай ярым да вакыт узмагандыр, көнлек савым ун ярым килограммга җитә язды. Яңалыкның җиңүе, дәресрәге, терлекчеләрнең үз-үзләрен җиңүләре иде бу. Куанычлы нәтиҗә шунын беренче җимеше булды.

Әммә фермада ирешелгәннәр уңышның башы гына иде әле. Кимчелекләрнең иң үзәккә үткәне — эшкә сүлпән караучылар. Председатель Нургаян Мөхәммәтшин болай фикер йөртә:

Терлекчелектә безнең уңышлар болай гына булмаска тиеш,— ди ул.— Әйтик, Рәшидә Латыйпова сыерларыннан ел саен дүрт мең килограммга якын сөт савып ала. Ә аның белән бер үк шартларда эшләүче Клара Хәсәнова — 2600 килограмм гына. Кларанын күбрәк вакыты сөйләшеп, бәхәсләшеп үтә. Яки булмаса, шулай ук Зәйтүнә Шаһиева да бар. Гөлнур Баева да бар. Гөлҗиһан Шәрәфиева яки Камәрия Сабировалар дүрт мең килограммга якын сөт алган вакытта, болар бары

тик ике мең килограммнан артыграк савалар. Сәбәп нәрсәдә соң? Сыерларын яхшылап тәрбияләмиләр. Фермага соң килсәләр дә, кеше рәтендә кайтып китәргә ашыгалар. Андыйлары сыерларны савып бетермәскә дә күп сорамый. Кайберсе көненә бер генә тапкыр сава. Тикшерү нәтиҗәләре моны ачыклады, бу кешеләргә карата чара күрелде. Әгәр киләчәктә дә мондый хәл кабатланса, эшләреннән алу мәсьәләсен кузгатачакбыз. Башкача мөмкин түгел...

Берсендә председательнең бу кискен фикерләре республика радиосы аша яңгырады. Әй үпкәләделәр, әй ачуландылар кайберәүләр. Тик, дөрес сүзгә җавап юк, дигәндәй, кемне гаепли аласың? Җиң сызганып эшләүдән башка чара калмады. Җиңнәрең сызганулы булса, күңелең сызланулы булмас... Әнә бит, терлекчеләрнең эшләре уң булсын өчен көнен дә, төнен дә кызганмый баш зоотехник. Ниләр генә кыландырып бетерми ул рационны! Әзерләнгән азыкны һәркөнне үзе тикшереп тора: азыклар яхшылап эшкәртелгән, әллә нинди тәмләткечләр белән туклыландырылган. Хәтта шикәр калдыгы да кушалар.

Шикәр дигәннән, бу хакта баш зоотехник хафага да төшә язды. Көннәрдән бер көнне колхозга республика авыл хуҗалыгы министрлыгыннан хат килеп төште. Берәү, малларга шикәр ашатуны кискен гаепләп, «Чаян» журналына тозлы-борычлы язма юллаган икән. Язучысын кем диген әле, кайчандыр зоотехник белеме булып та, хәзер шәһәрдә яшәп ятучы бер адәм. Бар көчен сарыф иткән бу «белгеч» үзенең хаклыгын раслау өчен. Мәгәр гаять мөһим ике нәрсәне истән чыгарган: беренчедән, савым сыерларына билгеле микъдарда шикәр комы бирү фән тарафыннан аклана. Икенчедән, маллар өчен бу кыйммәтле продуктның бары тик калдыклары гына файдаланыла. Аларны чүплеккә түккәнче, терлекләргә ашату файдалырак икәнне аңларга тиеш иде бу иптәш, югыйсә. Ә ул исә әнә ни кадәр кирәкмәгән мәшәкать тудырды...

Ел ярымга җитәрлек терлек азыгы да үзеннән-үзе генә әзерләнмәгән иде, билгеле. Моның өчен күп көч түгәргә, мөмкин булганын да, булмаганын да эшләргә туры килде. Чабылган печәннең кипкәнен күзәтеп кенә тордылар. Тиешенчә кипкән һәр пакус — чүмәләләргә, чүмәләләре эскерткә өелә барды. Сенаж салганда да тизрәк чокыр тутырып калыйм дип ашыкмадылар, суы саркып торган үләнне урдыруга ук машина-тракторларга төяп озатмадылар: череп әрәм булуы ихтимал. Ике-өч көн җилләгәнен көттеләр. Сенаж салуда бераз соңгарак калсалар калдылар, әмма максатларына ирештеләр. Кыш уртасында да аның бер генә мыскалы да бозылмаган иде.

Көзге чәчү вакытында кукуруз, көнбагыш басулары мәшәкать тудырды. Аларны ике-өч көндә җыеп алырга кирәк иде. Кызу эш өстендә чәчүлек җирләр әзерләүдә механизаторлар гаҗәеп фидакарьлек күрсәттеләр. Алар янына председатель киңәш-табыш итәргә килде:

— Җир әзерләүчеләргә ачылган мәйдан бетеп китте бит әле, егетләр. Бүген төнгә көнбагыш кырын бушатырга иде. Бар ышаныч сездә генә. Әгәренки төнге уникегә кадәр эшләүне оештырсак, моның өчен яхшы иттереп өстәмә хезмәт хакы түләсәк... Үзегезгә дә әйбәт, сөрүчеләргә дә яхшы булыр иде.

Аңлый механизаторлар — олы башын кече итеп, үтенеп килгән икән, димәк эшләргә кирәк. Үзе өчен түгел, колхоз өчен тырышып йөрүе бит. Бердәм тырышлыкның нәтиҗәсе дә куанычлы булып чыкты. Көзге кыр эшләре тирә-күрше хуҗалыкларныкына караганда берничә көнгә алдан тәмамланды. Бу исә киләсе ел уңышына ышанычлы җирлек иде. Терлек азыгы да мул һәм туклыклы иттереп әзерләнде.

Хуҗалыкның һәрьяклап ныгуы колхозның авылларын да үзгәртте, матурайтты. Үзәк авыл Тимыршыкның урамнары аеруча күркәм. Аңарда берсеннән-берсе әйбәтрәк йортлар калка, культура-көнкүреш биналары ишәя, каралты-куралар төзекләнә. Бу яңарышка ирешү өчен никадәр вакыт, иҗади фикер һәм көч, тырышлык, матди байлык сарыф ителә — димәк, зур социаль мәсьәлә тормышка ашырыла. Колхоз соңгы елларда 46 квартира салды. Колхозчылар сала торган йортларда да колхозның ярдәме зур.

Председательнең карашы яңа йортларның берсенә тукталды, ә хәтеренә Нурмиев Мәсгутләрнең аңа ничек күченү вакыйгасы килде.

Шулай бер көнне иртән председательнең сөтчелек фермасына барышы иде. Караса, каршына бишекле мотоцикл җилдерә. Тракторчы Мәсгут ич бу! Хатыны белән ике баласы да янында. Кая барышлары соң әле боларның? Нигә Мәсгут тракторы янында түгел дә, хатыны нигә сыерлары янында түгел?

Председательне күргәч, Нурмиев туктарга мәҗбүр булды.

— Кая җыендыгыз әле болай?

Председательнең күзләренә туры карап, дөресен ярды да салды Нурмиев:

— Олыязга менәбез, Нургаян абый. Анда балаларны калдырасыбыз бар. Аннан соң икебез дә газовикларга эшкә урнашабыз. Белешеп кайттык инде.

— Болай эшләргә сезне нәрсә мәҗбүр итте соң?

— Төп йортка энекәш кайта. Хаты килде. Кысангарак китәр, дибез.

— Әгәр дә без сезгә квартира бирсәк?

Көтелмәгән бу сүздән тракторчы югалып калды:

— Ничек?

— Колхозның әзер квартирасы бар: пар белән җылытыла. Зал ягы алты метрга алты метрлы, икенче бүлмәсе биш метрга алты мертлы. Сарае да, терлек абзарлары да бар...

Нургаян Вәлишович гаилә башлыгын идарәгә алып керде.

— Менә сезгә ачкыч. Урнашыгыз, рәхәт яшәгез. Әйберләрегезне күчерергә бер көн вакыт бирәм. Ә иртәгедән — икегез дә эшкә!

Мәсгутләрнең квартирага урнашулары булды, Казаннан энеләре Исмәгыйль кайтып төште.

— Нургаян абый, миңа да бирәр эш табылыр микән?

Менә шулай итеп, бер атуда ике, юк, хәтта өч куян алган иде председатель ул чакта: тракторчы белән сыер савучысын да югалтмады, тагын бер механизаторлы да булды. Туганнар үзара да тату-дус калдылар, гөрләшеп яшиләр хәзер.

Авыл халкы азык-төлек кибетенең кечкенәлегеннән, аның ярлылыгыннан зарлана иде. Хәзер исә яңа сәүдә үзәге кешеләрнең бу ихтыяҗын да канәгатьләндерде. Амбулатор типта төзелгән медицина профилакториенда сигез кабинет бар. Алар кирәкле җиһазлар белән тәэмин ителгән. Хәзер инде колхозчыларга сызлаган билен яисә авырткан тамагын дәвалау өчен дә Сабага барып, көн уздырып йөрисе юк. Айга ике мәртәбә район үзәк больницасыннан белгечләр килеп, авыл халкының сәламәтлеген тикшереп китәләр. Монысы — үзе бер куаныч.

Менә шулай һәр нәрсәгә күңел җылыңны кызганмыйча тырышсаң, колхозчылар да хезмәткә бөтен ихласларын сала. Шуның матур нәтиҗәсе буларак, ничә еллар инде хуҗалыкның кадрларга мохтаҗлык кичергәне юк.

...Авыл өстенә караңгы төште. Председатель бүлмәсендә тагын ут кабынды. Җылы яктылык авылның киң урамына бөркелде.

Ринат Мөхәммәдиев

# ИЛЕМ КОЯШ ЧЫГЫШЫНДА

*Хәзерге татар әдәбиятында халык әхлагының чагылышы*

Мәгълүм булганча, әдәп һәм әхлак төшенчәләренең мәгънәви җегәре
әдәбият сүзенең килеп чыгышы һәм тамырында ук чагылыш тапкан. Шу-
ңадыр дөнья халыкларының рухи культурасы һәм әдәбиятында халык-
ларның әхлак һәм әдәп нормалары эволюциясе күзгә дә гедәй ачык чагы-
лып, гәүдәләнеп килгән. Гасырлардан гасырларга, чордан чорларга күчеп, киләчәккә
үткән әдәби җәүһәрләрнең үлемсезлеге, идея-эстетик кыйммәте һәм актуальлеге дә
хәлиткеч дәрәҗәдә халык әхлагының тарихи бөтенлегенә, тирәнлегенә бәйле.

Әйтик, хәтергә килгән беренче дүртьюллыкка игътибар итик:

*Чәчкә идем илләрдә,*
*Чәчелдем чит җирләргә;*
*Яңадан чәчкә булыр идем*
*Кайтсам туган илләргә.*

Бу җырны беренче кат кем һәм кайсы якларга нинди язмыш дулкыннары илтеп
ташлаган ир-егет җырлады икән, әйтү кыен. Әмма бер нәрсә бәхәссез: ул җыр ту-
ган-үскән якларынннан үз ихтыярыннан тыш аерылган сагышлы йөрәктән саркып чык-
кан. Анда шәхси язмыш кына түгел, халык язмышы өчен борчылу да ассоциатив ра-
вештә чагылыш таба кебек. Шул ук вакытта җыр юлларында өметсез сагыш түгел,
өмет һәм ышаныч өстенлек итә, үз-үзеңә, матур киләчәккә ышану әлегә югалмаган.
Бу ышанычның нигезендә туган-үскән якка, туган илгә, халыкка чиксез мәхәббәт ту-
лышып тора. Ә бу исә — кешене кеше итүче, аның гүзәллеген, рухи һәм физик гар-
монияен күрсәтүче критерий! Шуңа да көчле рухлы әлеге ир-атның тагы бер ка-
вымнан, мисал өчен, әйтик, болай дип җырлап җибәрүенә дә шик калмый:

*Кошларым, кая очасыз,*
*Әллә безнең илләргә?*
*Очсагыз безнең илләргә,*
*Сәлам — нечкә билләргә.*

Монда инде «нечкә бил» дип әйтелгән, шаяру катыш үз иткән сүз югарыда күзал-
ланган гүзәл рухи һәм әхлакый сыйфатларга яңа нур өсти, аларны тагы да реаль-
ләштерә, гадиләштерә төшә.
һәм, шул рәвешле, әлеге җырларны күздә тотып кына да тагы әллә нинди дөнья-
ви нәтиҗәләр ясарга мөмкин булыр иде. Чөнки ул җырларда тыпырчынып торган җан
һәм язмыш бар, әхлакый җегәр тулып тора. «Халык җырлары — безнең бабаларыбыз
тарафыннан калдырылган иң кадерле вә иң бәһале бер мирастыр. Әйе, бу — кадер-
ли мирас, кыйммәтле мирас! Мәгъмүр Болгар шәһәрләре, Болгар авыллары, бер дә
булмаган төсле, кырылдылар да беттеләр, эзләре дә калмады.
Әмма менә бу кыйммәтле мирас дидекемез халык шигырьләрен туплар да ват-

мады, уклар да кадамады. Алар һаман да халык күңелендә һәртөрле бәлая вә казаядан сакланып калдылар, алар сәламәт әле, алар яңгырый әле»,— дип бер дә очраклы рәвештә генә язмагандыр Габдулла Тукай да. Халык иҗаты әсәрләренең халкыбыз күңеленең һич тә тутыкмас вә күгәрмәс саф вә рәүшән көзгесенә тиңләнүе дә очраклылык түгелдер. Чөнки ул әсәрләрдә халыкның яшәү рәвеше, дөньяга һәм җәмгыятькә карата мөнәсәбәт нормалары, иҗтимагый һәм идея-эстетик аңы, гүзәллекне фәлсәфи категория буларак тану үзенчәлекләре чагылыш тапкан һәм сакланып калган. Ә тагы да төгәлрәк итеп әйтсәк, халык иҗаты әсәрләрендә — халкыбызның күңел сафлыгы һәм әхлагы.

Халык рухын, аның яшәү рәвешен һәм тормыштагы идеалын чагылдыруда, мөгаен, бик борынгы йола җырлары аерым игътибарга лаектыр. Чөнки алар конкрет бер халәт һәм кәефтән чыгып кына җырланмаган, ә гасырлар дәвамында формалашып кристаллашкан, канун буларак кабул ителгән әхлакый нормаларны чагылдырып килә. Әйтик, иске календарь буенча Яңа ел килгәндә авыл яшьләренең өйдән-өйгә йөреп, изге теләкләр юллар йөрүе максатында туган «Нәүрүз» җыры шуның характерлы мисалы булса кирәк.

*Нәүрүз әйттек без сезгә,*
*Хакын бирегез безгә;*
*Яшегез җитсен йөзгә,*
*Малыгыз артсын көзгә,*
*Нәүрүз мөбарәкбад.*

Әнә шул рәвешле халык ничәмә-ничә гасырлар дәвамында бер-беренә игелекле имин тормыш теләгән. Басуларда икмәк уңсын дип, еллар тыныч торсын дип, кеше озын гомерле булсын дип җырлаган ул. Һәм бу иң игелекле гуманистик җырларның күбрәк яшь буын тарафыннан җырлануы да очраклы булмагандыр, шул рәвешле, халык үзенең иң матур идеалларын, яшәү үрнәге буларак, килер буыннарга юллаган.

Еллар, гасырлар уза торган. «Нәүрүз» онытыла төшеп, аның урынына яңасы — «Нардуган» дип аталган бәйрәм килгән. Бусы да яңа көн, Яңа ел килгәндә туганлашу, бер-береңә игелекләр юллау традициясен дәвам иткән йола булып туган. Гыйбрәтле факт: тарих кешеләрне, буыннарны алыштырган, буыннар белән бергә йолалар үзгәргән, әмма кайчандыр халык күңелендә туган игелекле әхлак нормалары онытылмаган, дәвамлы булган, өзлексез рухи хәзинә буларак яшәвендә дәвам иткән.

***Нардуган, Нардуган,***
*Нардуган, хуҗалар*
*Котлы мөбәрәк булсын,*
*Тормыш түгәрәк булсын;*
*Мал туарыгыз артсын,*
*Колыннарыгыз чапсын,*
*Игеннәрегез уңсын,—*
*Кукәй кебек тук булсын,*
*Нардуган, Нардуган.*

Әлегедәй җырларны искә төшергәндә, яңадан кайтып-кайтып, үз вакытында Г. Тукайның халык иҗатына мөнәсәбәтле әйтелгән сүзләре ни дәрәҗәдә урынлы һәм хаклы булуына сокланасың. Чынлап та, халыкның күңел бишегендә, бәгырендә туган рухи байлык, һәм шуның бер өлеше булган җырлардан да көчлерәк, озын гомерлерәк ни бар икән тагы... «Туплар да ватмады, уклар да кадамады...» дигән сүзләрнең хакыйкать булуы бәхәссез. Шуңа күрә дә бүген гасырлар дәвамында, күпме ут һәм суларга да бирешмичә безгә килеп җиткән халык иҗаты җәүһәрләренең мәртәбәсе ифрат зур, идея-эстетик кыйммәте әйтеп, бәяләп бетергесез әһәмияткә ия. Заманыбызның прогрессив көчләре сафында бүген дә алар килер буыннарга аяз күк, иминлек һәм бәхетле сәламәт тормыш юллау хокукын даулап көрәшәләр.

Әдәбиятның һәммә жанрларында сизелгән һәм соңгы елларда аеруча активлаша барган бер тенденция — халык иҗаты әсәрләренә торган саен тирәнрәк керә бару күренеше һич очраклы түгел. Борынгы әдәби җәүһәрләрнең ихтыяҗын торган саен тирәнрәк аңлый барып, аларны агымдагы әдәби һәм рухи хәрәкәткә чыгару юнәлешендәге активлык та закончалыклы күренеш. Әбугалисина, Фирдәүси, Ш. Руставели

һәм Нәваи иҗатларына рухи ихтыяҗ күтәрелә баруы тикмәгә түгел. Рус халкының мәшһүр әдәби җәүһәр «Слово о полку Игореве»га булган игътибары да рухи ихтыяҗ нигезендә туып, берөзлексез арта бара. Без моның шулай икәнлеген болгар-татар җирлегендә туган «Кыйссаи Йосыф»ка бүгенге татар укучысының ташкын сыман омтылышыннан да ачык күрәбез. Кол Галинең мәшһүр әсәре басылып чыккач, без тагы бер тапкыр үзебезнең үткәндәге мираска мөнәсәбәтебезне тәнкыйди күзлектән бәяләргә тиешлегебезне аңладык. Әдәби җәүһәрләр музейлар өчен сакланып калган истәлек кенә түгел икән бит, алар соң дәрәҗәдә актуаль, һәм, кирәксә, кешелеклелек һәм иминлек өчен актив көрәшкә күтәрелерлек җегәргә ия икән. Алай гына да түгел, алар бүгенге әдәби процессны үзләре артыннан әйдәргә сәләтле!

Моннан җиде гасыр ярым вакытлар элек иҗат ителгән «Кыйссаи Йосыф» язмышы чынлап та гыйбрәтле булып чыкты. Юк, сүз аның сигезенче гасыр дәвамында халык күңелендә сакланып килүе турында гына түгел. Сер түгел ич, әле санаулы еллар гына элек тә бу әсәр белән рухи элемтә чагыштырмача түбән иде. «Хикмәт нәрсәдә соң?» дигән урынлы сорау туа. Һәм бер карашка бу сорауга җавап та гади генә кебек: чөнки узган 1983 елда Татарстан китап нәшриятында бу гүзәл шигъри әсәрнең фәнни, текстологик һәм полиграфия ягыннан моңарчы күрелмәгән югарылыктагы заманча яңа басмасы дөнья күрде. Бу кадәресе дөрес һәм бәхәссез. Әмма хикмәт китапның яңа басмасында гынамы икән... Миңа калса, монда бүгенге көннең рухи һәм әхлакый таләпләрен, бүгенге чынбарлык һәм халыкара хәлләрнең соң дәрәҗәдә киеренкеләшү факторларын да истән чыгару ярамас.

Дөрес, кешелекнең сугыш дигән афәттән әлегәчә һичкайчан арына алганы юк. Гомер-гомергә аның бәгырен әзәрлекләп һәм телгәләп килгән ул. Аның ямьсез кара шәүләсе әле булса җир шарының урта бер җирендә эленеп тора. Материклар һәм илләрнең әле бер, әле икенче почмагында шартлау авазлары гөрселдәп, аннан кан, күз яшьләре саркылып чыга. Кызганычка каршы, алай гына да түгел: кешелек һәм зәңгәр бишегебез алдында яшәргәме, әллә... юкка чыгаргамы дигән сорау куелган. Америка империализмының котырынып кораллануы, кан исенә исергән ерткыч сыман яңадан-яңа корбаннар эзләп кабалануы, Җир шары, Кешелек һәм Яшәү дигән иң изге төшенчәләр белән дә хисаплашмыйча, коточкыч финалга ашкынуы бөтен прогрессив дөньяны тетрәнергә мәҗбүр итте.

Агымдагы елның 11 августында Америка радиосына язылыр алдыннан президент Р. Рейганның авызыннан чыккан сүзләр бу киеренкелекнең ни дәрәҗәдә җитди булуын кабат ачыклап килә: «Хөрмәтле америкалылар,— дип дәшә ул, имеш, микрофоннарның ничек эшләвен тикшергән булып.— Сезнең белән үземнең шатлыгымны бүлешергә телим, әле яңа гына Россияне законнан тыш ил дип игълан итүче законга кул куйдым. Биш минуттан бомбага тоту башлана». Янәсе, президент шаярган гына, дип аңлатырга тырыштылар соңыннан бу фактны. Ләкин гигант дәүләт җитәкчесе авызыннан чыгып очкан бу сүзләр очраклымы икән?..

Кол Галинең сигез гасырлык түгәрәк бәйрәме һәм аның мәшһүр «Кыйссаи Йосыф» әсәре язылуга җиде йөз илле ел тулу әлеге киеренке һәм җаваплы көннәргә туры килде. Һәм нәкъ шул көннәрдә, югарыда искә алынганча, ул аерым китап булып басылып чыкты. Шушы очраклылыклар киеренкелеккә инде тәмам күнегеп килгән күңелләрне кинәт тагы бер кат тетрәндереп куйды. Җирдә яшәү шул дәрәҗәдә гүзәл икән ич, кеше дигән олы исемне йөртү — бәхет, дөнья — матур, бер-береңә игелек һәм изгелекләр кылып кына яшәүгә ни җиткән... «Кыйссаи Йосыф»ны укыганда күңелгә килгән уй, тойгы һәм хисләр, иң элек, шулардан гыйбарәт ич. Иминлекнең кадерен белгән, дус-тату яшәүне бар нәрсәдән югарырак бәяләгән, рухы таза һәм чиста булган халкыбыз өчен (бу очракта мин бөтен совет халкын да күздә тотам) бу олы мәгънәле бүләк булды.

Тынычлык, туганлык һәм мәхәббәт төшенчәләренең халык күңелендә береләнгән ерак тамырларына барып тоташкан әдәби җәүһәр безне тагы бер кабат халык әхлагының сәламәтлеге һәм ни дәрәҗәдә гармонияле булуы турындагы уйлануларга этәрә. «Кыйссаи Йосыф» һәм халык авыз иҗаты әсәрләре арасындагы идея-эстетик вамлылык һәм рухи уртаклыкларга игътибар ителә. Халык авыз иҗаты белән үрелеп үскән әдәбият тарихын кыскача күз алдыннан кичерәсең, Котби, Мөхәммәдъяр,

Мәүлә Колый, Утыз Имәни, Кандалый һәм Акмуллаларның күңелгә сеңгән шигъри моңнарына янә кайтып колак саласың. Шундук бөек Тукай, Такташ, Җәлил, Туфан... Күз алдына гаҗәп бер картина килеп баса: болар һәммәсе нечкә зәвык белән тезелгән дисбенең аерым буыннары икән ләбаса. Һәммәсе бер җеп белән теркәлгән, бер үк кешелекле һәм игелекле идея, рухи матурлыклар белән өртелгән. Бергә укмаштырып, гасырларны гасырларга, җырны җырга тоташтырып торган ул җеп — халык әхлагы, халкыбызның рухи гармониягә омтылышы икән ләбаса.

Дөрес, әдәби тәнкыйтьтә «мифлармы, әллә чынбарлыкмы?..» дигән сорау куеп, табигый рәвештә, бәхәсне чынбарлык файдасына хәл итүләр әле булса кабатланып тора, дәвам итә. Ләкин нәкъ шул бәхәс барган көннәрдә Ч. Айтматовның «Гасырдан да озаккарак сузылган көн» романы басылып, айнытып җибәрә. Найман-Ана турындагы бәет, хәтерсез калган Манкрот фаҗигасе һәм космик фантазия, кешелек язмышын бер колачка сыйдырып, җирдә яшәүнең рухи һәм әхлакый асылы турында тетрәнеп уйланырга мәҗбүр итә. Астафьевның «Балык-патша»сы, Распутинның «Бәхилләшү» әсәре, Абрамов романнары халык әхлагының күләгәдә калып, онытыла башлаган нечкә кылларына кагылып сискәндереп куя, игелекле уйлануларга этәрә. Нодар Думбадзеның «Мәңгелек законы», Грант Матевосянның «Ана буйвол» әсәрләре, татар прозаигы Әмирхан Еникиның «Әйтелмәгән васыять» һәм «Туган туфрак» хикәяләре иҗат ителеп, күңелләргә заман өчен, халык һәм кешеләр язмышы өчен тынгысызлык иңдерә...

Мифлармы, әллә чынбарлыкмы дигән сорауга, әлбәттә, «чынбарлык!» дип җавап бирәсе килә, һәм һич икеләнмичә. Ләкин шунда ук бу төшенчәләрне капма-каршы куюы, гомумән, урынлымы икән дигән сорау туа. Мифлар, әкиятләр һәм бәетләр чынбарлыкка нисбәттә туып, кешеләрнең тормыш турындагы татлы һәм авыр хыял, кичерешләре булып яшәгән ич. Алар һәммәсе баштан ахыргача халык әхлагының иң гүзәл үрнәкләре белән сугарылган. Һәм бүген дә заманыбызның талантлы каләмияләренең әсәрләрендә урын алып, кеше булып яшәүнең, тыныч һәм имин гомер итүнең мәңгелек кануннарын яклап актив көрәшкә юнәлтеләләр.

Әлбәттә, зур булмаган хезмәттә халык әхлагының әдәбиятта чагылышын тулаем күз алдына китереп бастыру мөмкин түгел. Шуны аңлаган хәлдә, киңлеге һәм тирәнлеге белән дә иксез-чиксез булган әлеге рухи академиянең бары тик бер аспектына, ул да булса тынычлык өчен көрәштәге ролена игътибар итүне кирәк санадым. Ватаныбыз иминлек һәм азатлык сагына басып, планетаны, кешелекне һәлакәттән саклау өчен җаваплылыкны үз иңнәренә алган көннәрдә бу хакта уйлану, фикер йөртү һич урынсыз булмас.

Заманы шундый, заман көн тәртибенә куйган масштаблы проблемалар шундый. Йөрәкләр кысылган, нервларның тартылган җәядәй киеренке чагы. Кешелеклелек һәм гүзәллек сагында булган әдәбият битараф була аламы шундый чорда? Юк, әлбәттә! Бүгенге иҗат кына түгел, үткәндәге мирасның да заман эчтәлеге белән баеп, гуманизм һәм җирдә яшәү матурлыгын раслап актив көрәшкә күтәрелүе законлы күренеш.

«Кыйссаи Йосыф» — болгар бабаларыбызның тыныч, имин тормышка йөз тотып, көч, батырлык һәм матурлык сыйфатларын кемгә дә булса каршы көрәштә түгел, халык бәхете өчен янып хезмәт итүдә сынарга өйрәнгән булуын ачык раслап килгән әдәби әсәр. Җирдә яшәүнең матурлыгына соклану һәм дөньяви гүзәллеккә табынуның классик үрнәкләрен мәңге гашыйк Г. Кандалый иҗаты да калку чагылдырды. Бу таза рух Акмулла һәм Дәрдмәнд шигъриятендә янә бер кат, инде бермә-бер катлаулы һәм каршылыклы чор һәм шартларда сынала.

*Бишенче кыйммәт нәрсә әдәб дигән,*
*Әдәб дигән — мәхәббәткә сәбәп дигән...*

Шагыйрь Акмулланың рухи һәм әхлакый йөзен чагылдырган принципиаль әсәрләренең берендә юкка гына күңел, әдәп, гакыл һәм сабырлык төшенчәләренә махсус игътибар юнәлтелми. Игътибар итик, кешенең рухи матурлыгы, иминлеге өчен алшартлар булып торган сыйфатларга дан җырлый ул, һич кенә дә физик көчне олылап, кемнән дә булса өстен булу, кемне дә булса рәнҗетү, буйсындыру хакында түгел.

Дәрдмәнднең туган ил һәм Ватан төшенчәсен ничек кабул итүенә игътибар юнәлтеп китү дә гыйбрәтле булыр:

*Әйтеләр, кем, бер бәхетсез*
*Илгә гашыйксың, фәкыйрь.*
*Бер кызардым, бер бүзардым...*
*Ни таныйм — таналмадым.*
*Ни таныйм!.. Таналмадым!*

Ә нигез, әлеге дә баягыча, бер. Әдәп тә, әхлак та бер!

Дөрес, халык иҗатында һәм әдәбиятта явыз көч алдында тез чүгү кебек мескенлекнең дә мәртәбә саналганы юк. Бу җәһәттән агымдагы гасыр поэзиясе аеруча игътибарга лаек. Кимсетелү, сырхау һәм гаделсезлекләр белән тигезсез көрәштә горурлыгын җуймый өстен чыккан һәм янып яшәгән Г. Тукай образы бу күзлектән тоташ гыйбрәт чыганагы. «Сорыкортларга», «Китмибез» кебек шигырьләрнең тугры Тукай иҗатында программ яңгыраш алуы һич очраклы күренеш түгел. Бу тугрылык, намус һәм ватандарлык һ. Такташ һәм Х. Туфан җырларының асылын тәшкил итә. Такташ һәм Туфан поэзиясенең халык авыз иҗатына рухи һәм әхлакый бәйләнеше турында махсус хезмәт язарга да мөмкин. Бөтендөнья батырлык поэзиясенең иң гүзәл үрнәкләреннән булган М. Җәлил иҗаты да әдәбият күгендә очраклы күренеш түгел, ул гасырлар дәвамында эзлекле рәвештә үрелеп килгән әхлакый һәм рухи байлыкның гадәттән тыш шартлардагы табигый чагылышы булды.

*Җыр өйрәтте миңе хөр яшәргә*
*Һәм үләргә кыю ир булып...*

кебек юллар артында, шагыйрьнең каһарманлыгы, рухи гармониясе һәм ныклыгын аңлауга гыйбрәтле ачкыч ята. «Җыр» дигәндә Җәлил һич тә үз иҗатыннан алынган гыйбрәтне генә күздә тотмый, ә киңрәк карый, тирәнрәк тоемлый һәм күрә. Халык җырын, изге Ватан-ана җырын тыңлап үскән шагыйрь сүзләре ич бу.

Нәкъ шул ук зур сынау елларында икенче бер татар шагыйре Европаның икенче бер төбәгендә шигъри ант кабул итә:

*Үлем турында уйлама,*
*Илең турында уйла;*
*Илең турында уйласаң —*
*Гомерең озын була.*

Юк, гадәти канатлы сүзләр генә түгел болар, ил өчен көрәшкә барыр алдыннан кабул ителгән ант, яшәү принциплары һәм шәхси язмыш белән исбат ителгән хакыйкать.

Төрле фронтларда, Европа кырларында ирләр, көрәшчеләр сынала, рух сынала, әхлак сынала. Шулар белән бергә җыр сынала, әдәбият сынала. Әмма берәве дә сынатмыйлар. А. Алиш һәм Н. Баян, Г. Кутуй һәм Х. Мөҗәй, Ш. Мөдәррис һәм Г. Хуҗи — һәммәсе бер үк дисбенең төймәләре, бер үк рухи бишектә тибрәнеп үскән, сеңер ныгыткан шәхесләр.

Ватан өчен көрәш кырларында сыналган әлеге бай рухи җәгәр, әхлакый тәҗрибә әле бүген дә С. Хәким һәм Н. Арсланов, Н. Дәүли һәм З. Нури, Х. Камалов кебек әдипләр иҗатында дәвам иттерелеп, яңа буын шагыйрьләренә мирас буларак тапшырыла. Әйтик, С. Хәкимнең «Эзлиләр Европа буйлап» һәм «Күгин» поэмалары белән бер үк чорда язылган әсәрләр — Т. Миңнуллинның «Әлдермештән Әлмәндәр», «Моңлы бер җыр» драмалары, М. Мәһдиевның «Кеше китә — җыры кала», М. Юныс-ның «Биектә калу» повестьлары югарыда кат-кат искә алынган тоташ чылбырны дәвам иттерәләр. Әдәбиятыбыз барышында соңгы елларда сәнгатьчә югарылыкта торган күп кенә башка әсәрләр дә иҗат ителде, билгеле; әмма боларын аерып куюның үз сәбәпләре бар. Чөнки аларда замандашыбызның күңелен борчып, уйга салып торган проблемалар халкыбыз әхлагының иң тотрыклы һәм дәвамлы принципларына нигезләнеп хәл ителгән.

Татар халык авыз иҗаты әсәрләрен, борынгы әдип, шагыйрь һәм фикер иялә-

ренең күпме генә хезмәтләрен актарып та, кулга корал алып, башка халыкларның азатлыгына кул сузуны яклап янсә хуплап язылган бер генә юлны да очратмассың. Авыз иҗатында гына түгел, аның телендә дә иң еш кулланыла торган сүзләр «иминлек», «игелек» һәм «хәвеф-хәтәрсез көн күрү» булган ич. Дусларына да, күршеләренә дә шундый теләктә булган халкыбыз, юлга чыккан һәммә кешегә дә иң элек шул теләктә калган.

Бүгенге әдәбият, халык тормышының әнә шул принципларына тугры калган хәлдә, замандашларыбызны рухи тәрбияләүдә үз алымнарын эзли.

Мисал өчен, Т. Миңнуллинның «Моңлы бер җыр» әсәренә мөрәҗәгать итик. Ул — Җәлил һәм аның көрәштәшләре батырлыгының фәлсәфи һәм рухи нигезе, Ватан һәм халкы намусы өчен гомерләрен дә кызганмаган каһарманнарның изге антларына тугрылыгын олылаган әсәр. Әлеге тиңдәшсез батырлыкны автор очраклы рәвештә генә халык күңелендә туган җыр һәм моңга нигезләнеп ачмаган. Әсәрнең идея-эстетик бөтенлегенә ирешүдә халык җыры «Сибелә чәчәк»кә гаять әһәмиятле роль йөкләтелгән. Драманың буеннан буена әледән-әле яңгырап торган, һаман саен көчәя барып, ташкынны хәтерләткән тоташ моңга әверелүче җыр көчле рухлыларның җан тавышы булып ишетелә. Иксез-чиксез дәрьядан көч туплагандай, әлеге җыр һәм моң автор күңелендә туган ниятне укучы һәм тамашачының рухи-әхлакый тәҗрибәсенә тоташтыра һәм яңадан-яңа төсмерләр белән баетылып заманча актуаль яңгыраш таба. Халык әхлагына нигезләнгән моңны автор шул рәвешле тиңдәшсез зур тәэсир итү чыганагына ия һәм идея, һәм эстетик чарага әверелдерә.

Т. Миңнуллин әлеге алымнан «Әниләр һәм бәбиләр» драмасында да файдалана. Онытылып барган бишек җыры әсәрнең лейтмотивына әверелеп гаять җитди һәм актуаль проблемаларның сәнгатьчә үтемле хәл ителүен тәэмин итә. Бишек җыры — мөгаен, җир йөзендә иң киң таралышта булып, кешелеклелек һәм гуманизм җәһәтеннән тиңдәше булмаган рухи хәзинәдер. Әнә шул хәзинәне драматург заман һәм замандашлары язмышы өчен борчылуда юлдаш итеп, кеше өчен, ана һәм бала дигән изге төшенчәләрнең сафлыгын яклап көрәштә янә яңартып җибәрә. Җирдә яшәүнең бар нәрсәдән дә гүзәлрәк икәнлеген күңелләргә илткән, халык әхлагының нигезендә торган «иминлек», «игелек» һәм «хәвеф-хәтәрсез көн күрү» төшенчәләренә заманча яңгыраш биргән сәнгать әсәре туа нәтиҗәдә.

Бишек җырын юксыну һәм аңарга ихтыяҗ, күрәмсең, шул дәрәҗәдә актуаль булгандыр, халык әхлагының нигезендә бөреләнгән әлеге җыр, Т. Миңнуллин белән нәкъ бер чорда, шагыйрь Гәрәй Рәхим иҗатында да үзенчәлекле чагылыш таба.

*Әлли-бәлли бәү итә,*
*Балалар йоклап китә.*
*Балалар йоклап киткәч,*
*Баштан күпме уй үтә...*

Нинди уй, нинди борчулар тибрәнә соң шагыйрь күңелендә? Сабыр гына ерагая барган бишек җырын көйләп нәрсә әйтергә тели ул? Җир бишегендә мәңгелек йокыга талган ватандаш ир-егетләр, киләчәк хакына гомерләрен кызганмаган каһарманнар тибрәлә икән ул көйгә. «Легендалар, мифлар йоклый, Алыплар черем итә... Әлли-бәлли бәү итә». Ләкин алар гына түгел, шагыйрьнең күңелен тынгысызлаганы тагы да әһәмиятлерәк икән — җир өстендә бишек сыман атынып торган ракеталар борчый аның җанын. Һәм шагыйрьнең соңгы юлһары җир шарының барлык почмакларында яшәгән аек акыллыларга, прогрессив кешелеккә чакыру булып яңгырый: «Әлли-бәлли бәү итмә, Җирем, син йоклап китмә...»

Гомумән, бишек җыры мисалында чагылыш тапкан әлеге җитди борчылу әдәбиятыбызда төрле формада һәм халык әхлагының күп кенә тирәнлекләрен үзенә сеңдергән башка деталь, күренеш һәм төшенчәләр аша да киң чагылып килә. Г. Бәшировның «Туган ягым — яшел бишек» повесте бу җәһәттән аерым игътибарга лаек. Ул беренче сәхифәләреннән соңгысынача халык әхлагының байлыгын, тирәнлеген ачуга турыдан-туры багышланган әсәр. Рус совет язучысы Василий Белов та соңгы елларда «Лад» әсәрен язып, бу юнәлешнең әдәбиятта зур перспективага ия булуын күрсәтте. Тик шунысы кызганыч, «Лад» тәнкыйть тарафыннан шундук бертавыштан хуплап каршы алынды, ә «Туган ягым — яшел бишек»кә исә — сәнгатьлелек һәм

тормышчан дөреслек җәһәтләреннән аз гына да кайтыш булмаган әсәргә — бездә битарафлык күрсәтеп, шик ташларга җөрьәт итүчеләргә кадәр табылды. Миңа калса, бу безнең кайбер әдипләребезнең һәм тәнкыйтьнең принципиаль хатасы иде.

«Туган ягым — яшел бишек» Г. Бәширов иҗатында гына түгел, әдәбиятыбыз барышында да аерым урын алып торган әсәр. Зур социаль үзгәреш һәм кискен борылышлар алып килгән XX гасыр башы илебез халыклары тарихында, аерым алганда, аларның рухи культуралары тарихында, махсус игътибар сорый торган чор. Г. Бәширов әсәрендә исә, татар халкының, аерым бер авыл мисалында, Бөек Октябрьга килү юлы күрсәтелгән. Монда масштаблы геройлар, революция каһарманнарын тасвирлау максаты куелмаса да, үзәктә рухы белән принципиаль яңа җәмгыятьтә яшәргә омтылган һәм шул яңача яшәү үрнәгенә лаек булган халык бар.

Гомумән, тарихи темага караган әсәрләр язмышын, кагыйдә буларак, халык рухына тугрылык һәм аның әхлакый дөньясын тасвирлауда ирешелгән уңышлар билгели булса кирәк. Әйтик, Н. Фәттахның «Әтил суы ака торур» һәм «Сызгыра торган уклар» романнары, «Кол Гали» драмасы шул хакыйкатьне кабат раслап киләләр. Соңгы еллар әдәбиятыбызда мәртәбәле урын алып торган бу әсәрләр замандашка тарихи мәгълүмат бирүдән дә бигрәк, чиста, сәламәт яшәү үрнәге, җирдәге тормышның мәңгелек кануннарын тасвирлавы белән гыйбрәтлерәк. Юкса, тарих китапларын укый торгач, бу кеше дигәнең гомер-гомергә җир йөзенә бары тик сугышып, кан коешып яшәү өчен генә килгән икән дип тә уйларга урын кала. Тарих сәхифәләрен яхшыга омтылып, гүзәллеккә сокланып яшәгән буыннар мисалында тасвирлаган нәфис әдәбият исә җирне һәм тормышны яратырга рухландыра, тагы да матуррак итеп яшисен китерә. Шул рәвешле тарих бүгенге иминлек хакына көрәшкә тартыла. Н. Фәттахның «Сызгыра торган уклар» романыннан Тәгин углан һәм М. Хәбибуллинның әле яңа дөнья күргән «Кубрат хан» романыннан Илбарыс образларының заманча яңгыраш алулары, аларның рухында нәкъ менә кешелеклелек сыйфатлары өстенлек итү, җиргә, тормышка һәм гүзәл кызларга чиксез мәхәббәт саклану белән аңлатыла.

Халык әхлагының иминлек һәм татулыкны бар нәрсәдән югары кую үзенчәлеге соңгы елларда иҗат ителгән кайбер башка проза әсәрләрендә һәм, аерым алганда, хикәяләрдә дә чагылыш тапмады түгел. Олы сүз остасы Ә. Еникинең «Тынычлану» хикәясен күңелләргә нинди игелекле тынгысызлык алып килүе хакында мин махсус язып та чыккан идем. Әле дә, хикәяләребезне барларга керештекме, иң элек күңелгә классик осталык белән башкарылган шул ук гүзәл әсәр килә. Мәгаен, тагы А. Шамовның соңгы ике ел эчендә дөнья күргән үтә җылы һәм кешелекле хикәяләр циклын, Г. Бәшировның «Бибек нигә елый», Гариф Галиевның «Карлыгач оя кора» хикәяләрен искә алмый үтү ярамас. Халык рухын тирән тоеп, гасырлар дәвамында ныгып кристаллашкан әхлак нормаларын заманча фокуска җыеп күрсәтә алган остазларыбыздан әле безгә күп өйрәнәсе бар

Р. Ишморат драматургиясендә, А. Расих, А. Гыйләҗев, Г. Ахунов, М. Мәһдиев, Р. Төхфәтуллин прозасында, Ш. Галиев, И. Юзеев, Н. Дәүли, М. Шабаев кебек дистәләгән шагыйрьләр иҗатында да халык әхлагына йөз белән борылуның яңа һәм гыйбрәтле яңгыраш алган мисалларын күпләп китерергә мөмкин булыр иде.

Әйтик, халкыбызның иң гүзәл бәйрәмнәреннән Сабантуй турындагы күренешләр, ил агасы буларак тасвирланган картлар, игелек чыганагы буларак сурәтләнгән ана һәм хатын-кыз образлары, туган як табигате, чишмәләр — болар һәммәсе тынычлык сөю, туганлык һәм интернациональ дуслык идеяләрен тудыруда традицион чара булып торалар. Шул уңайдан, Ренат Харисның «Ак сөлге» дип исемләнгән шигырен генә искә алыйк. Шагыйрь ак сөлгене халыкның намус һәм гаделлеге, күңеле төсе буларак кабул итеп, аның аша Ватан өчен хезмәт һәм көрәштә үткән олы юлның рухи гүзәллегенә дан җырлый.

*Ихтирамымны белгертим*
*Хак сүз белән:*
*Кунак килсә, каршыладың*
*Ак йөз белән,—*

дип башланган шигырьнең һәр яңа строфасы халык әхлагының бик борынгылардан бүгенгәчә дәвам итеп, яңадан-яңа төсмерләр белән баый, үсә килгән нечкәлекләрен

чагылдыра. Уңышлы бер деталь буларак кына китерелгән ак сөлге, укучы күңелендәге истәлек, вакыйга һәм тәэсирләр белән ассоциацияләшеп, идея һәм эстетик җегәргә ия эчтәлек һәм сыйфат җәһәтеннән яңа образ тудыра.

*Син бит үзең дә халкымның*
*Күңеле төсле —*
*Сөттән сеңгән зур пакьлекнең*
*Бер көзгесе*
*Һәрбер эшнең, һәр ниятнең*
*Өмете — уңыш.*
*Кешеләрнең нияте зур,*
*Сөлге, булыш!*

Әсәрнең шул рәвешле, ак сөлгене ярдәмгә чакыру белән тәмамлануы, уй һәм фикерләүгә җитди нигез бирә. Рухи сафлык, гаделлек һәм игелеклелеккә чакыру булып яңгырый бу. Ә безгә — XX гасыр ахыры кешеләренә исә, борынгыдан әбиләр һәм аналар үз күңел аклыкларын кушып суккан ул ак сөлгеләргә салынган әхлакый җегәргә лаек булырга кирәк.

Соңгы елларда халык иҗатын игелекле илһам чыганагы һәм бай тәҗрибә буларак файдалануның активлаша баруы әдәби әсәрләрнең — роман, повесть һәм пьесаларның исемнәрендә үк аермачык чагылып килә. Әйтик, «Агымсуларга карап», «Ай булмаса, йолдыз бар», «Аккан су юлын табар», «Сулар үргә акса да», «Шикәрем син, балым син», «Ефәк баулы былбыл кош» һәм башкалар, һәм башкалар. Әлбәттә, бу матур факт. Ә инде халык җырларыннан алынган ул сүзтезмәләргә салынган рухи җегәр әдәби әсәрнең үзендәге идея һәм эстетик тирәнлекләр белән дә кушылып китсә, халык үзе үк әйтмешли, нур өстенә нур гына. Тик, кызганычка каршы, аерым бер очракларда халык җырларыннан алынган юллар әдәби әсәргә ятышып тормый, яисә ул исемнәр урынсыз ябыштырылган ялтыравыклы этикеткаларны гына хәтерләтәләр. Шуңа күрә дә рухи хәзинәбезгә булган җитди игътибар вакытлы мавыгуга әверелмәсен, әсәрдәге бушлыкны яшерү максатында файдаланылмасын иде.

Халык иҗаты һәм халык әхлагына булган игътибар һәм ихтирам бүгенге татар әдәбиятында өлкән буыннардан башлап яшьләргәчә күчеп дәвам итә, яңадан-яңа мәгънәви төсмерләр ала. Жанр һәм тема, вакыт һәм пространство чикләре белән дә хисаплашмыйча хәрәкәт итә бу бетмәс-төкәнмәс кыйммәтләргә ия булган бай хәзинә. Мисал өчен, әкиятләребезне генә алыйк — иҗади фикергә канат бирерге сәләтле бетмәс-төкәнмәс рухи һәм әхлакый җегәр бар ич аларда. Халык әкиятләре М. Хәбибуллинның әле яңа дөнья күргән «Кубрат хан» романы өчен сюжет төзү һәм кешелекле эчтәлек өчен этәргеч нигез булып торса, шагыйрь Зөлфәт әкиятнең үз язмышы өчен хафаланып, аның үзен яклап чыга.

*Әкияти хисең саумы, кешем, җанда?*
*Җуймадыңмы Жирдән күчкән тылсым көчең?*
*Әкиятне җую — кешелекне җую.*
*Әфсен-төфсен!*
*Җаннан-җанга күчсен серле әкиятләр!*
*Яз җилләре булып, Жирне назлап иссен!*
*Котсыз яшәп Жирнең котын алучыга*
*Ачы каргыш төшсен!—*
*Әфсен-төфсен!*

Бөтен кешелекне борчып торган җитди проблемага күпер сала шагыйрь халык рухында туган әкият аша. Дөнья һәм бөтен җир шары «Сугышмы, тынычлыкмы?» дип, тынгысызланып көрәшкә күтәрелергә тиешле бер чорда халык әкиятләренә мәдхия җырлый Зөлфәт. Кешелекне әкияткә йөз борырга чакыра.

Һәм, уйлап карасаң, бер дә юкка түгел икән, чөнки әкияттә кешенең иң гүзәл омтылышлары һәм хыяллары чагылыш тапкан. Әкияттә — гуманизм, әкияттә — яшәү матурлыгына соклану, әкияттә — дуслык һәм туганлык хисләренең иң олысы. Әкияттә — югары әхлак, рухи сафлык һәм гүзәллек. Әкияттән бигрәк, шул әхлакый нормаларны яклый икән ич шагыйрь.

Халык күңелендә туган рухи матурлык символы булган әкият Зәлфатнең «Йөрәкләрдә — үлмәс дастан» поэмасының башыннан ахырынача җирдә яшәүгә, якты хыял һәм зур омтылышлар белән яшәүгә дан җырлаган сәнгатьле чара буларак кабул ителә. Шагыйрь замандашларына оран сала:

*...Канатлы ат чаба җир буйлатып —*
*Азат җан ул — Хыял һәм Өмет!*
*Йөрәгендә — үлмәс дастан: Бәхет!*
*Ул булырга тиеш мәңгелек...*

Чынлап та, дөньяда һәм җанда әкияткә урын калмаса, яшәү кызык булыр идеме икән?.. Әллә әкият белән бергә хыял һәм өметен, матур киләчәккә ышанычын югалтып, үз-үзен соңгы чиккә китереп җиткерер идеме икән кеше... Бәхеткә каршы, әле бүген күпме малай, канатлы ат турындагы әкиятләр тыңлап, ерак планеталарга очу турындагы татлы хыял белән үсә, бәхеткә каршы, әле «Таң батыр»ны укып буй җиткергән егетләр Ватаныбыз чикләрендә, хәрби хезмәттә һәм зур төзелешләрдә яңадан-яңа батырлык үрнәкләре күрсәтәләр. Димәк, әкият яши, әкият яшәргә тиешле һәм әкият яшәячәк — халык рухында туган әхлакый нормалар югалмый, дәвам итә. Әдәбиятыбыз әлеге әхлакый нормаларны пропагандалап һәм иҗади үзләштереп кенә калмый, халык хыялында бөреләнгән иминлек һәм кешелеклелек принципларын дәвам итеп, чорыбызга лаек яңаны тудыру юнында ышанычлы адымнар белән алга атлый. Халкыбыз әхлагын һәм шул әхлак киң чагылыш тапкан фольклорны әле безгә өйрәнергә дә өйрәнергә.

*Биек тауга менгән чакта*
*Борылып киткән юл булыр,*
*Асыл ирләр, туган җирләр —*
*Безнең туган ил булыр,—*

дип җырлаган халкыбызга тугрылыклы булып, Ватанга бирелгәнлек һәм патриотизм идеяләрен пропагандалауда әле яңа биеклекләр яулыйсы бар.

*Сандугачлар басып сайрый*
*Гармун каешларына;*
*Илем кояш чыгышында,*
*Үзем баешларында,—*

дип җырлаган асыл ир-атларның күңелендәге рухи гармониянең чыганаклары, тамырларын тагы да тирәнрәк итеп ачып саласы бар әле. Юкка гына шулай үз итеп җырламаган халык «Кояш чыгышы» — ул яңа көн, димәк, якты, матур тормыш, имин яшәү һәм сүнмәс мәхәббәт дигән сүз... Туган илебез бүген дә бөтен прогрессив кешелек алдында кояш чыгышын гәүдәләндереп, туасы көннәрнең иминлеген саклап җаваплы вахтада тора. Безнең җырлар да шул бөек җаваплылыкка, «Илем кояш чыгышында...» дип күкрәк тутырып җырлаган халкыбыз җырларына лаек булса икән.

библиография

# ТЫНГЫСЫЗ ХИСЛӘР ҖЫРЧЫСЫ

Шагыйрь Галимҗан Латыйп әдәбият сөючеләрнең берничә буынына яхшы таныш. Аның күп санлы лирик әсәрләре һәм шул исәптән җырлары, юмористик шигырьләре һәм балаларга атап язылган шигъри парчалары бай традицияле шигъриятебез үсешенә сизелерлек өлеш керттеләр. Татар совет шигъриятенең олы традицияләрен үстерүдә шактый зур хезмәт куйган өлкән буын шагыйрьләре арасында, әйе, Галимҗан Латыйпның үз урыны, йөзе бар. Әйтик, Сибгат Хәкимнең беренче карашка гадәти кебек тоелган шигырь юллары безгә тыгыз фикер, тирән хис һәм нәфислектән торган зур шигъри дөнья белән очрашу куанычы бирә. Нури Арсланов шигъри традициябезгә Көнчыгыш поэзиясенең шифалы сулышын алып килде. Әхмәт Исхак белән Зәки Нури шигъриятебезне үткен сатира белән бизәделәр. Галимҗан Латыйп, Шәрәф Әхмәдуллин әйткәнчә: «Барыннан да элек, ул — реалист шагыйрь. Аның шигырьләрендә тормыш сурәте күп очракларда иң гади көнкүреш детальләреннән тукыла».

Әлеге фикер күпмедер дәрәҗәдә Галимҗан Латыйпның иҗат кредосын да чагылдыра. Моның шулай икәнлегенә дәлилләр нигезендә ышану өчен, шагыйрьнең сайланма әсәрләре тупланган җыентыгына [1] күз салыйк. Ул безгә әдипнең иҗади үсеш баскычларын һәм шигъри дөньясын күзалларга ярдәм итә. Беренче карашка гади генә кебек тоелган шигырьләр, тирәндә яткан эчке җегәре белән, зур шигърият эченә бөтереп алып кереп китә һәм нәфис аһәңе, лирик куәте белән күңелне әсир итә. Гадәти тормыш күренешләре, вакыйгалар артында олы тормышның кайнар сулышын сизәсең. Шагыйрьнең үзе кебек үк самими һәм ихлас геройлары белән очрашкач, ләззәтле куаныч кичерәсең. Бу геройлар, әйтерсең лә, күңел зарыгып көткән ниндидер бер рухи байлыкны, хәзинәне үзләре белән алып килгәннәр дә сабыр гына безгә өләшәләр...

Ни турында гына язмасын — туган җиребезнең матурлыгына сокланамы, бәхетлеме, азат хезмәткә мәдхия укыймы, сугышны үз җилкәсендә күтәргән батыр солдат яки «таң нурында уянып чайкалган иркә иген кырлары»ның гүзәллеге алдында таң калып, илһамланып җырлыймы — аның иҗатының үзәгендә — һәрчак Гади Кеше, Хезмәт иясе. Шушы сыйфат ул иҗат иткән әсәрләрнең нигезен билгели. Гади хезмәт кешесенең бай күңеле, мактаулы эше — Галимҗан Латыйп өчен бетмәс-төкәнмәс илһам чыганагы. «Тегермәндә», «Урманчы», «Чишмә тазартучы картлар», «Бабаларым минем», «Мусалар булсалар» һәм башка шундый әсәрләрендә шагыйрь ил-көнебезнең тәрәге булган ир-егетләрнең Ватан һәм халык алдындагы изге бурычлары хакында сүз алып бара. Гомерләре бәйсезлек һәм азатлык өчен янган Мусалар, Фучиклар кебек каһарманнарга карап тигезләнергә чакыра:

*Ак төсләр каралмас,*
*Каралар агармас,*
*Дөньяда Мусалар*
*Күбрәк булсалар.*

Галимҗан Латыйп заман сулышын нечкә тоеп иҗат итә. Фикеребезгә дәлил рәвешендә, «Иминлеге өчен дөньяның» дигән әсәргә тукталыйк. Биредә автор зур югалтулар һәм әрнүләр бәрабәренә яуланган тынычлыкны сакларга, сугыш дәһшәтен булдырмаска өнди:

*Мәңгелек ут яна!*
*Ә исәннәр*
*Сакка куйды җанын —*
*Иманын,*
*Кукләрнең саф зәңгәрлеге өчен,*
*Иминлеге өчен дөньяның.*

Бөтен прогрессив кешелек дөньясы, бар намуслы халык тереклек, яшәеш язмышын кайгыртып, аны ничек кенә итеп булса да саклап калырга омтылганда, заман рухы белән аваздаш әлеге хисләр безнең күңелләргә тагын да якыная.

[1] Галимҗан Латыйп. Җир җыры. Шигырьләр, җырлар, поэма. Татарстан китап нәшрияты, 1983.

Җир-анага, кешелеккә янаган зур афәткә кисәтү, тынычлыкны яклау пафосы шагыйрьнең «Футбол тубы түгел җир шары» шигырендә аеруча куәтле яңгырый. Җирне футбол тубы урынына тибеп йөртергә хыялланучы сугыш чукмарлары уңайлы форсат көтеп яшәгән бер вакытта, гражданлык рухы белән җылытылган бу патриотик шигырь, актуаль булу белән бергә, төрле телләрдә сөйләшүче җирдәшләрнең бердәм ниятен, протестын да чагылдыра:

*Җәберләмә җирне,*
*Типкәләмә,*
*Футбол тубы түгел*
*Җир шары!..*

Җирне футбол тубы белән тиңләү — әсәрнең тәэсир итү куәтен арттырып җибәрә. Гомумән, Галимҗан Латыйп әдәби детальләрдән уңышлы файдалана һәм аларга мәгънә-фикер йөге салып, көтелмәгән ассоциацияләр тудыруга ирешә.

Шулай ук Галимҗан Латыйп әсәрләренең төзелешенә һәм яңгырашына да нык игътибар итә. Җыентыкта традицион үлчәмдә язылган әсәрләр белән бергәттән, ирекле ритмнар да ишетелеп китә. Шулар белән янәшә үк диярлек хикмәтле сүзләр, канатлы гыйбарәләрдән торган дүрт, биш, алты, сигез юллы шигъри миниатюралар да очрый. Әнә шулай итеп, өлкән шагыйрь фикер-хисне сәнгатьчә белдерүнең яңа формалары өстендә туктаусыз эзләнә. Әлбәттә, кайвакыт хис-фикер уңышлы дип фәразланган калыпка сыеп та бетмәскә мөмкин. Һәм бу очракта әсәрнең җаны булган моңны коры риторика, «проза стиле» басып китә. Бәхеткә каршы, Галимҗан Латыйп җыентыгында мондый характердагы әсәрләр сирәк очрый, һәм алар шагыйрь иҗатының әдәби-эстетик кыйммәтенә әллә ни зыян китерә алмыйлар шикелле.

Галимҗан Латыйпның табигый таланты туган җиребезнең гүзәллегенә багышланган иҗат үрнәкләрендә аеруча тулы ачыла. Аның иң яхшы әсәрләренә туган як табигате җан өргән. «Олыяз», «Авылга кайта җырлар», «Килә көз олауларда» һ. б. шундый шигырьләрдә җир кешесенең шагыйранә җаны, якты хисләргә бай күңеле зур җылылык белән сурәтләнә.

Китаптагы күп кенә әсәрләр мәхәббәт темасына багышланган. «Учка салынган йөрәк турында җыр», «Сагындырып килми хатларың», «Оныт, диләр» кебек әсәрләрдә лирик герой нечкә күңелле, кайнар йөрәкле, саф мәхәббәт хакына үзен корбан итәргә дә әзер торучы кеше буларак күз алдына килә.

Шагыйрьнең җылы хисләр белән сугарылган якты әсәрләрен күздән кичергәндә, аның җырлары хакында фикер әйтмәү бик үк дөрес булып бетмәс. Галимҗан Латыйпның бер үзенчәлеге шунда: аның күп кенә әсәрләре үзе үк көй сорап торалар. Әйтерсең лә, ниндидер бер якты моңга, сихри аһәңгә тартылалар алар. Шул рәвешчә, шигырь кысаларыннан чыгып, сулышларын киңәйтергә, канатланырга омтылалар.

Әсәрләренең шушы хасиятен үз итеп, аның күп кенә җырларына композиторларыбыз матур-матур көйләр яздылар. Әйтик, «Арышларым», «Туган туфрак», «Чайкала иген кырлары», «Тегермәчләр» һәм башка шундый җырларны халык үзенеке итеп кабул итте, күңеленә якын алды. Композиторлар белән иҗади дуслык җирлегендә туган бу җырлар шагыйрь хисләрен халык күңеле белән тоташтырып торучы ышанычлы күпер булды.

Халыкчан җырлар авторы булудан кала, Галимҗан Латыйп юмор-сатира өлкәсендә дә эшли. «Ике күрше», «Белмәссең дөньяның хикмәтен», «Кешесенә карап», «Тирес корты» кебек шигырьләрендә ул рухи торгынлыкның һәм гамьсезлекнең тамырын фаш итә, җәмгыятебезнең рухи үсешенә киртә булып торган кайбер кимчелекләрне сатира уты белән рәхимсез рәвештә көйдерә, халык җилкәсен кимереп ятучы ялкаулар, эчкечеләр, әрәмтамакларның чын йөзләрен ачып сала.

Җыентыкта шагыйрьнең эпик колачлы әсәрләреннән «Җыр үткәндә» исемле поэмасы урын алган. Әлеге әсәр безне үткәнгә — яңа тормыш өчен кискен көрәш барган чорга алып кайта. Җир, Икмәк, Тынычлык, Азатлык һәм Бердәмлек өчен көрәшкә күтәрелгән каһарманнарның якты образын автор Хәтмулла бабай һәм аның онытгы язмышлары аша ышандырырлык итеп тасвирлый. Кызыл гаскәргә үзе теләп язылган Хәтмулла бабайның оныгы, революция байрагы күтәреп, ак бандаларны юк итү өчен көрәш кырына ыргыла. Поэма драматик эчтәлеге һәм якты образлары белән күңелгә тәэсир итә.

Тулаем алганда, Галимҗан Латыйпның «Җир җыры» дип исемләнгән күләмле генә җыентыгы шигърият сөючеләрне битараф калдырмас. Оптимистик рухы, лирик җылылыгы һәм гражданлык пафосы белән ул укучы күңеленә юл табар.

**Әхмәт СӘХАПОВ.**

**Марсель Сәлимҗанов,**

Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрының баш режиссеры, СССРның халык артисты, РСФСРның һәм ТАССРның Дәүләт премияләре лауреаты

# ТЕАТР КАЙДАН БАШЛАНА

Үзган елның җәендә, театрыбызның Мәскәүдәге иҗат отчеты вакытында, без күренекле рус совет язучысы Л. Леонов белән очрашкан идек. Кыенсынып торубызны күреп, ул шаярып алды һәм аннары эшлекле сөйләшүгә күчте: «Ягез сөйләгез, «Ябырылу»ны сәхнәләштергәндә, мөгаен, мине ачулангансыздыр. Пьеса сәхнәдә кую өчен бик авыр бит...»

Мин, режиссер буларак, әсәрне сәхнәләштерүнең авыр булганлыгын яшердем. Һәм аннары «Ябырылу»ның камаллылар тарафыннан инде сиксән мәртәбәдән артык уйналуын, спектакльнең зур уңыш белән баруын әйттем.

«Пьеса сәхнәдә кую өчен бик авыр бит...» Чыннан да, авыр булды. Җитмәсә, Леонид Максимович Леоновның алдынгы театрны ничек итеп күрергә теләве турында әйткән сүзләре хәтердә һәрвакыт яңарып торды: тирән анализ театры, югары хисләр, үткер сүз һәм күңелнең иң тирән төпкелләренә үтәрлек тормышчан сәхнә гәүдәләндерешенә ия булган театр... Билгеле инде, мондый олы бурыч өстә торганда, әсәрне җиңел генә сәхнәләштерә алмыйсың. Гомумән, минем сизүемчә, соңгы вакытта теләсә кайсы пьесаны сәхнәләштерү авырлаша бара. Кем әйтмешли, халык театрга яхшы спектакль карарга килә, ә югыйсә пьесаның үзен укып чыгарга да була бит.

Үз-үзеннән канәгать булган режиссер юктыр, мөгаен. Дөрес бүген театрыбызга халык яратып йөри. Бу — зур уңыш, әлбәттә. Әмма киләчәктә театрны нинди юлдан алып барырга? Бер елдан соң, өч елдан соң нәрсә куярга? Театрда зур талант ияләре бар. Ә талант — халык байлыгы, аны «тик яткырып» булмый. Әйтик, Биктимеров, Таҗетдинов, Шәрәфиев иртәгә нинди рольдә уйнарлар? Иҗат мөмкинлекләрен тагын да тулырак ачар өчен Камаловага нинди образ тәкъдим итәргә? Яки менә Гайнуллина, Зарипова, Мотыйгуллина кебекләрне ничек итеп иҗат үсешендә тотарга? Театр яшьләргә дә, урта буынга да, өлкәннәргә дә бердәй кызыклы булсын өчен нәрсә эшләргә? Гомумән, нәрсәне ничек уйнарга? Бер-берсе белән үзара бәйләнгән менә шундый сораулар режиссерга беркайчан да тынгылык бирми. Кайда гына булсам да (хәтта балык тотканда да), мин әнә шул хакта уйланам. Сорау артында сорау. Тулы җавап биреп кара син шуларга! Ә имтихан алучы заман мәсьәләләрне тагын да катлауландыра.

Театрга кемнәр йөри? Мин үзем тамаша залын туктаусыз өйрәнәм. Йөзләр сөйли. Сәхнәдә уйнаучы артистлар да залны бик нечкә һәм төгәл итеп тоялар. Кешеләр акылларын зирәкләндерергә, яшәргә өйрәнергә килгәннәрме, әллә күңел ачар, «ат кәмите» карар өчен генәме?

Чыннан да, тамаша залын өйрәнү зарур. Мондый кызыксыну кайвакыт гыйбрәтле нәтиҗәләргә китерә. Бер карасаң, тамашачыларның 75 процентын хатын-кызлар тәшкил итә. (Килүләре өчен аларга рәхмәт, әлбәттә). Ә ирләр кая? Югыйсә тормышта гомуми сан буенча башкачарак чагыштырма күзәтелә бит. Әллә соң сәхнәгә ирләрне җәлеп итәрлек проблемаларны тиешенчә күтәрә алмыйбызмы? Әлеге факт уйландыра. Тагын бер күзәтү: залның яртысында эшчеләр сыйныфы вәкилләре утыра. Бу, бер яктан, күңелле күренеш. Мәсәлән, Мәскәү театрларында алар шактый азрак була. Сүз

да юк, илебез театрлары алдында, гомумән, хезмәт ияләрен спектакльгә күбрәк тарту бурычы тора. Татар театрында бу юнәлештә икенче якка авышу сизелә шикелле. Монысы да — уйландыра торган мәсьәлә. Ни өчен безгә башка категория тамашачылар, әйтик, интеллигенция вәкилләре чагыштырмача азрак йөри башлады? Ә бит театр Казанның фән һәм культура учреждениеләре, уку йортлары күбрәк булган районында урнашкан. Без театрга укытучыларның да ешрак килүен телибез, чөнки бар эшебез, ахыр чиктә, тәрбия мәсьәләләренә барып тоташа. Ун-унбиш еллар чамасы элек медицина, авыл хуҗалыгы, ветеринария институтлары белән театр арасындагы элемтәләр дә әйбәтрәк иде шикелле. Билгеле, «ара бозылуда» без дә гаепледер. Әйдәгез, бергәләшеп шуның сәбәпләрен ачыклыйк.

Тамаша залын өйрәнгәндә, тагын шул күзгә ташлана: татар театрына башкалабыз кунаклары бик яратып һәм сагынып киләләр. Бу, гомумән, халкыбызга хас күренеш, күркәм гадәт. «Кунак итү программасы»ннан татар театры читтә калмый. Менә шуңа күрә, килгән кунакларга, билетлар сатылып беткән очракта, һич югы өстәмә урындыклар куярга тырышабыз. Һәм безгә авылдан бик күпләп киләләр. Шулай да араларында яшьләр азрак күренә.

Халык театрны тәрбия мәктәбе дип тә йөртә. Ә тәрбия сүзен әйтүгә, яшьләр искә төшә. Театр шундый сәнгать инде ул — сәхнәдә күп кенә проблемалар яшь буынны тәрбияләү максатыннан күтәрелә. Театрның үзендә дә яшьләр байтак. Һәм аларга бәйләнешле рәвештә дә проблемалар туа тора. Мәсәлән, драматургиядә яшь персонажлар өстенлек иткән пьесалар була. Ә менә безнең театр шартларында бу мәсьәләне ничек хәл итәргә, яшь буын артистларны ни рәвешле «тулы ставка»га эшләтергә? Бездә яшь тамашачы өчен махсус театр юк. Ә академия театрында спектакльләрне «яшь буенча бүлү» шактый четерекле. Шулай да кыенлыктан чыгу юллары табыла. Театрда яшьләрнең планнан тыш спектакльләр әзерләве күркәм гадәткә әверелде.

Гомумән алганда, яшь буынны тәрбияләү мәсьәләсе һәрвакыт игътибар үзәгендә тотыла. «Шәһәрдә җәй көннәре» спектаклен (Анар) гына алыйк. Күп кенә ата-аналар үз балаларының югары уку йортларында белем алуларын телиләр һәм бу хокукны төрле юллар белән алырга омтылалар. Бу табигый күренешме? Югарыда телгә алынган спектакльдә менә шушы сорауга җавап бирергә омтылыш ясала. Бу уңайдан шуны әйтеп үтү урынлы булыр: актуаль темаларның берсенә багышланган әлеге спектакль Бөтенсоюз фестивалендә 1 дәрәҗә дипломга һәм премиягә лаек булды. Кызганычка каршы, бу спектакльгә ата-аналар да, укытучылар да һәм яшьләр үзләре дә чагыштырмача азрак йөриләр.

Бервакыт Мәскәүдән «Әлдермештән Әлмәндәр» буенча фильмспектакль әзерләргә килгәннәр иде. Алар залны да төшерделәр. Мин тамашачының йөзен болай да күзәтергә яратам. Ә фильмспектакль төшергән чакта мондый күзәтү аеруча тәэсирле булды. Дөресен генә әйткәндә, без Туфан Миңнуллин белән үзебез өчен тагын бер сабак-гыйбрәт алдык. Нинди әсәр ничек сәхнәләштерелгән? Тамашачы йөзендә барысы да күренә!..

Тамашачы да төрле. Алар географик төбәкләре буенча гына түгел, театраль зәвык һәм ихтыяҗ дәрәҗәләре ягыннан да бер-берләреннән аерылып торалар. Әйтик, казанлылар белән уфалыларны берничек тә бутый алмыйсың. Спектакльләрне һәркайда үзләренчәрәк кабул итәләр. Бер генә мисал. «Әни килде» бездә бик яратып кабул ителде, һәм ул инде 400 мәртәбә уйналды. Ә анда күтәрелгән кайбер проблемалар, мәсәлән, Урта Азиядә яшәүчеләргә бик үк аңлашылып җитми. Сәбәбе шул: бу төбәктә мондый күренешләр сирәгрәк очрый. «Зифа»да уйнаучы Равил Шәрәфиевнең мишәр акцентыннан бездә, кем әйтмешли, егылып көләләр, ә менә Уфада аннан алла ни ләззәт алмадылар шикелле. Мәскәү тамашачысы да үзенчәлекле. Мин аларны инде 30 ел беләм. Һаман өйрәнәм. Монда да «Галиябану», «Зәңгәр шәл» кебек спектакльләрне яраталар. Ә хәзер исә тамашачының яңарак катламы үсеп чыкты. Әйткәнемчә, былтыргы җәйдә без Мәскәүдә иҗат отчеты тоттык. Күрәбез: безгә шул ук МХАТка йөри торган тамашачылар килә. Милли спектакльләр белән берраттан, «Бичәсез кызыны да алкышлап каршыладылар. «Ябырылу» да бик яратып кабул ителде. Пьеса авторы Л. Леонованы сәхнәгә чакырдылар. Иксез-чиксез рәхмәт хисләрен белдерделәр. Ә без, үз чиратыбызда, кунакханәгә йокларга кайткач та тамашачыга күңелебездән рәхмәтләр укыдык. Ә театр белән тамашачы арасындагы аңлашу бик күп нәрсә турында сөйли.

Тамашачыга — рәхмәтнең иң зурысы. Әмма, рәхмәт әйтүдән файдаланып, кечкенә генә бер үпкә сүзе дә белдереп үтәсе килә: ни өчен бездә тамашачыларның шактый өлеше, спектакль тәмамланып, пәрдә төшәр-төшмәстән, дәррәү кубып, киенү урынына чаба, яки кайберәүләр, сәхнәдәге вакыйгаларга үз мөнәсәбәтен белдереп, төрле репликалар ташлап утыралар? Ә бу исә җаны-тәне белән бирелеп уйнаган артистның күңелен төшерә, иҗат дәртен һәм стимулын үстерүгә күпмедер дәрәҗәдә зыян китерә.

Театр сөючеләрдән меңә бик күп хатлар килеп тора. Араларында үзләренең килешмәүләрен белдерүчеләр дә, үз зәвыклары җирлегендә туган тәкъдимнәрен көчләп тагарга тырышучылар да бар. Берсенә дә үпкәләмим. Кызыксынсыннар, әмма битараф булмасыннар. Бәхәсләшәбез. Кайберәүләр сорый: нигә «Таһир-Зөһрә»ләр куелмый? Һич сүзем юк, куярга кирәктер. Әмма һәр заманның үз «Таһир-Зөһрә»ләре бар. Без куябыз, әлегрәк язылган әсәрләрне бүгенге заман күзлегеннән укып куябыз, ә ул, әйтик, «Таһир-Зөһрә»нең үткән еллардагы куелышын карап үскән кайбер «көйсез» тамашачының күңеленә бик үк хуш килми. Артистлар да башка, сәхнә бизәлеше дә. Әйтик, Ермолова, Качалов, Кариев, Волжская, Тархановлар бүген башкачарак уйнарлар иде. Өлкән тамашачы чагыштырып карый, әмма аңа яшь вакыттагы беренче тәэсирләре белән бәйле спектакль якынрак кебек тоела. Ә театр, тере организм шикелле, туктаусыз камилләшә. Тормыш алга бара. Гореф-гадәтләр дә үзгәреш кичерә. Хәзерге яшьләр яратуны да, әйтик, испанча тәрәзә янында җырлап яки «тәрәзәдән тартып ал» дип түгел, башкачарак белдерәләр. Тамаша залында яңа заман кешеләре утыра. Аларны бит үткәннәрнең «экзотика»сы гына кызыксындырмый. Кабатлап әйтәм, кешеләр театрга тормыш сабагы алыр өчен киләләр. Син дөрес яшисеңме? Тукайча әйткәндә, «тормышың нинди: җитешме? Җитеш булмаса, кай җире җитешми?» Менә шуңа күрә, заманчалык алга чыга. Ә сәхнә әсәрләре заман күзлегеннән укуга бигрәк тә мохтаҗ. Гомумән, театр бүгенге заман кешесенең эстетик зәвыгыннан югарырак торырга, тамашачыны үз артыннан ияртергә бурычлы. Театрны туктаусыз хәрәкәт һәм эзләнү яшәтә. Товстоноговча әйткәндә, театр һәр биш ел эчендә яңадан коралланa да белергә тиеш. Труппаның да яңарып торуы зарури. Һәм, табигый ки, мондый яңарыш режиссер алымына да кагыла. Тормыш раслаганча, теге яки бу алым чиктән тыш «эксплуатацияләнсә» ул алдынгы алым булудан туктый.

Кайвакыт үз зәвыкларын гына алга сөрүчеләр дә очраштыргалый. Берәр җитди спектакль караганнан соң, андыйлар әйтеп куялар: нигә шунда җырлап-биеп алмаска?! «Бирнәсез кыз»да да тальян уйнатырга теләүчеләр булгалады. Алга барабыз-җырлап алабыз (яки биеп алабыз), дип әйтүләр, бәлки, концертларда гына килешәдер. Ә спектакль — концерт түгел. Спектакльне музыка белән генә яраттырып булмый. Музыка, бию, чәчәкле-чуклы декорация белән бизәлгән мәгънәсезлек, француз язучысы А. Ривароль әйтмешли, барыбер мәгънәсезлек булып кала.

Кайберәүләр фикеренчә, «Казан сөлгесе»нең яңа куелышы, янәсе, дөреслеккә бик туры килми. Муллаларның, мәзин кызларының үз-үзләрен тотышы, имеш, безнең халык өчен характерлы түгел. Шулаймы? Без милли типажларда артык дәрәҗәдәге талантлык күрергә теләмибезме? Безнең халык ачы итеп көлә дә белә. Гомумән, без яшәешнең аерым этапларын моңсуланып кына түгел, көлеп-елмаеп та озатабыз. «Казан сөлгесе»ндәге көлү — киңрәк мәгънәдәге көлү. Без бу әсәрдә К. Тинчуринның зур интернационалист икәнлеген тагын бер мәртәбә ачык күрәбез. Бу уңайдан «Американ»ны, «Җилкәнсезләр»не искә төшерик. Әлеге пьесаларда көлү угы вак милләтчеләргә, «түргә комган белән елкы мае куючылар»га каршы юнәлдерелгән. Көлик. Әйтик, грузиннар бу мәсьәләдә бер дә курыкмыйлар — ачы итеп, мәгънәле итеп үзләреннән көлә беләләр. Һәм шуны да әйтеп узасы килә: бер генә режиссер да классиканы бозып куярга теләми, киресенчә, аның һәр заман өчен дә актуаль булган идея-эстетик кыйммәтен тагын да тулырак ачарга омтыла. Бездән хәтта автор күреп-тоеп җиткермәгән кыйммәтләрне ачу сорала!..

«Нәрсә турында язарга?» Кайбер авторлар миңа әнә шундый сорау да биргәлиләр, актуаль тема, хәтта мин күрергә (ә ул язарга) теләгән әсәрнең конфликтын тәкъдим итүемне сорыйлар. Иҗат эшенә мондый карашны мин аңлый алмыйм. Язарга тема беткәнме? Халкыбыз биографиясенә генә күз салыйк. Казанда Совет власте урнаштыруга багышланган берәр яхшы пьеса бармы? Татар халкының тарихи шәхесләрен

сәхнәгә үзләренә лаеклы рәвештә күтәрдекме? Ә гражданнар сугышы геройларын, коллективлашу чоры фидакарьләрен?! Бүгенге авыл темасы да «вакансияле» булып кала бирә. Шулай ук нефть темасы буенча да «Монда тудык, монда үстек» кебек пьесаларны тагын да язарга буладыр. Ә тынычлык темасын онытырга хакыбыз бармы? Әхлак проблемасының актуальлеге хәзер арткannан-арта бара, һәм ул һәрбер әсәрдә дә күпмедер дәрәҗәдә күтәрелергә тиештер... Мин киләчәктә «Тормыш төбендә»не куярга уйлыйм һәм төп акцентны Лукага, аның яхшы һәм киң күңелле булуына юнәлтергә телим. Бездә нәкъ менә шундый сыйфат саега башлады шикелле. Ә мондый үзгәрешләр импульсын драматургка теге яки бу режиссер түгел, ә тормыш үзе генә бирә ала. Дөрес, без дә аңа бу юнәлештә төрлечә ярдәм күрсәтергә, аны театр коллективының бер әгъзасы итеп танырга бурычлы.

Мин үзем ачкан саен ачыла баручы, үзенең мәгънәви серлелеген беркайчан да җуймаучы драматургларны яратарак төшәм. Ничектер өч драматург, төгәлрәк әйткәндә, К. Тинчурин, Н. Исәнбәт, Т. Миңнуллин пьесаларын күбрәк куярга туры килде. Ни өчен? Бу хакта еш уйланам. Минемчә, әлеге драматургларны бер уртак сыйфат берләштерә: алар иҗатында чын мәгънәсендәге әдәбият чагылыш таба. Өчесе дә җирдә нык басып торалар. Чын реалистлар. Тел осталары, стилистлар, заман ритмын һәм музыкасын нечкәләп тоя белүчеләр. Әмма алар бер-берләреннән аерылып та торалар, үз-үзләрен дә кабатламыйлар. Әйтик, «Сүнгән йолдызлар», «Американ»га яки «Казан сөлгесе»нә охшамаган. Әмма шул ук вакытта аларның Тинчуринныкы икәнлеге кычкырып тора. Яки менә Н. Исәнбәтнең «Хуҗа Насретдин», «Һиҗрәт», «Зифа»сын үзара чагыштырып карыйк. Формалары да, язу алымнары да бер-берсен кабатламый. Шулай ук Т. Миңнуллинның «Диләфрүзгә дүрт кияү», «Бәхтияр Канкаев», «Әлдермештән Әлмәндәр», «Моңлы бер җыр» кебек пьесаларының форма төрлелеге сокландыра. Аларда тулы бер образлар галереясы бирелгән. Һәм шунысы әһәмиятле: санап үтелгән әлеге әсәрләрдә «урынчылык»ка хас мәсьәләләр түгел, ә гомумкешелек проблемалары күтәрелә. Менә шуңа күрә, мондый пьесаларны 10—15 елдан соң да рәхәтләнеп куярга була. Алар ачкан саен яңа яктан ачыла баралар.

Заман, театр, драматургия, режиссура, тамашачы... Бер-берсенә тыгыз бәйләнгән әлеге төшенчәләр турында вакыт үткән саен күбрәк уйланасың икән. Яңа пьесаны сәхнәләштерү, беренче репетициягә барулар, яңа сезон ачулар кыенлаша шикелле. Театр да бит, кабатлап әйтим, теләсә нинди зур художник кебек ук, бүгенге тормышның бәрәкәтле агымнарын алдан ук тоя белергә тиеш. Шундый тоем булмаган очракта, ул үле учреждениегә әверелә. Бу хакта еш уйланыла. Әмма уйлаган саен шуңа тирәнтен төшенәсең: заман театры дәрәҗәсендә тору өчен нык гражданлык позициясе, югары партиялелек, профессионал осталык таләп ителә.

# ДАГСТАНЛЫЛАР КАЗАНДА

Шәһәрләр дә кешеләр кебек. Кайберләрен бер күргәннән соң бер дә онытмыйсың, гомерең буена хәтереңдә кала. Кешеләре белән очрашуларыңны, урамнарын, һәйкәлләрен, музейларын, тагын әллә нәрсәләрен искә аласың. Күңелеңә якын булып киткән шәһәргә кабат-кабат әйләнеп килергә омтыласың.

Минем өчен Казан — ничә гасырлар дәвамында Көнчыгыш халыкларының культура һәм экономика үзәге булган шәһәр — шундыйга әйләнде. Беренче тапкыр Казанда моннан унбиш ел элек булган идем. Кремльдә булдым, мәгърур Сөембикә манарасына сокланып тордым, татар халкының сөйгән уллары һәйкәлләренә чәчәкләр салдым.

Казанның урамнарын, йортларын карап, күп санлы мемориаль такталар янында тукталып, мин борынгы шәһәрнең тарихын өйрәнеп йөрдем. Пугачев яуларының дәһшәтле авазларын, Казан аша Себергә озатылган декабристларның богаулары чыңын ишеткәндәй булдым. Шушында революцион көрәш юлына баскан яшь Володя Ульяновның кадерле образы күз алдыма басты.

Шактый көннәремне Татарстан АССР Дәүләт музеенда үткәрдем. Халык осталары агачтан һәм балчыктан, таштан һәм бронзадан, йоннан һәм ефәктән ясаган, иҗат иткән әйберләр каршында озак-озак басып тордым, талантлы халыкның сәнгатенә сокландым.

Үзем музейда йөрим, күңелем туган Дагстанымның авылларына һәм шәһәрләренә, якташларыма күчә: эш коралларында, бизәнү әйберләрендә, йорт кирәк-яракларында уртак сыйфатлар, охшаш бизәкләр күрәм. Татарларның һәм Дагстан халыкларының культурасында уртаклыклар никадәр күп икән. Башымда уй: «Ничек болай булган соң, нинди хәлләр, нинди вакыйгалар безнең халыкларны, культураларны якынайткан, алар ничек берсен-берсе баеткан?»

Җавап эзлим. Чыннан да, аралар бик якын түгел бит. Хәзерге заман могҗизасы «ТУ-134» тә ике республика арасын дүрт сәгатьтә үтә. Элекке заманнарны әйтеп тә торасы түгел.

Кешенең табигате шундый: үзенә таныш булмаган проблемалар, күренешләр очраганда ул аларга җавап табарга омтыла. Эзләнә башлый, сораша, укый, йокысын калдыра, бөртекләп мәгълүмат җыяр өчен архивларга, музейларга юнәлә. Нәтиҗәдә ачыклык килә, билгесез билгелегә әверелә... Иделдәге данлы шәһәргә беренче баруымнан соң минем белән дә шулайрак булды.

...Бәйләнешләрнең башы ерак тарихка барып тоташа. Мәсәлән, XIV йөзнең танылган укымышлысы Ибн Баттута (1377 елда үлгән) Алтын Урда территориясе буйлап сәяхәт иткәндә аның башкаласына кадәр барып җиткән һәм анда «хокук белгече имам Садретдин әл-Лекзине, иң лаеклы кешеләрнең берсен» очраткан (кара: В. Г. Тизенгаузен. Сборник материалов, относящихся к истории Золотой Орды. т. 1, СПб., 1894, 277 б.). Көньяк Дагстанда туган Садретдин Сөләйман галим-сәяхәтче була. Маҗаралар эзләү аны Идел буена китерә, шунда Ибн Баттута белән дә очраша.

XVIII гасырның икенче яртысында Дагстандагы Яксай (Аксай) авылында мәгълүм татар шагыйре, XIX йөз татар җәмгыятендә бик популяр әсәрләрдән саналган «Рисаләи Газизә» дигән хезмәтнең авторы Таҗетдин Ялчыгол (1768—1838) яши һәм белем ала. Ул бала чагында әтисе белән күп дөнья гизә. Астраханьда, Дагстанда, Мәскәү-

дә, Нижний Новгородта, Троицкида, Истамбулда була. Дагстанда башлангыч белем ала. Аннары ул беркадәр вакыт Аксай мәдрәсәсендә дәресләр бирә.

Татар халкының зур мәгърифәтче галиме Шиһабетдин Мәрҗани мәгълүматларына караганда, Дагстанның күп кенә укымышлылары, шул исәптән яшьләр дә, Казанда белем алганнар. Ш. Мәрҗани Шамилнең улы Абдуллатыйп хаҗи Аварлының иҗади эшчәнлеге формалашуга мәгълүм йогынты ясый. Абдуллатыйп Казанга кабат-кабат килә, Мәрҗанидә туктала торган була. Абдуллатыйп татар галиме исеменә язылган мактау хатында остазы Мәрҗанине «мөҗтәһид», ягъни үзеннән яңа хөкемнәр чыгара белүче, яңа фикерләр әйтә алучы галим дип атый.

СССР Фәннәр Академиясенең Дагстан филиалы галиме Мөхәммәт Сәит Сәидовның язуына караганда, Мәрҗани хезмәтләрендә (2 томда) белем алу өчен төрле елларда Казанга килгән җитмештән артык дагстанлы турында мәгълүматлар бар.

Казанда яшәгән Тау иле кешеләреннән мәшһүр галим, Россиядә «Көнчыгышны өйрәнү патриархы» Мирза Мөхәммәт-Али Касыймович Казембекның (1802—1870) эшчәнлеге бик зур вакыйга булып тора. Казембек үзе XIX гасыр башында Дагстанда иң нык үскән һәм куәтле феодаль үзәк булган Дербент шәһәреннән. Дагстан Россиягә кушылганнан соң Казембекның әтисе Фет-Али Хан сараенда финанс министры булып эшли.

Бу укымышлы гаилә була, шунлыктан Казембек кече яшьтән үк Көнбатыш Европа һәм Шәрык филологиясен үзләштерә. Төрек, фарсы, әзербайҗан телләрен һәм башка төрки телләрне белә. Казембек халыкка хезмәт итәргә карар кылгач, аларның гаиләсе патша указы белән Астраханьга җибәрелә. Монда алты ел яшәү чорында ул, чит ил сәүдәгәрләре белән аралашып, Көнбатыш Европа телләрен дә өйрәнә.

1826 елда Казембек Казанга килә, анда ул университетның танылган галимнәре Н. И. Лобачевский, И. И. Хәлфин, И. Н. Березин, Н. Ф. Катанов, О. М. Ковалевский һәм башкалар белән таныша, шулар булышлыгы белән университетка лектор итеп алына. Монда ул лектордан Көнчыгыш әдәбияты профессорына кадәр үсә. 1844 елдан 1849 елга кадәр философия факультетының деканы булып эшли. Шушы еллар эчендә Казембек күп дистәләрчә төрле милләт яшьләренә белем бирә,

Казан университетында студент булган вакытында рус әдәбиятының булачак даһие Л. Н. Толстой да Казембектан төрки телләр һәм әдәбият дәресләре ала. Бу белемнәре аңа 1851—1854 елларда, Кавказда вакытында, комык телен өйрәнергә ярдәм итә.

Казанда Казембек 1843 елның ноябренә кадәр, Петербург университетына күчеп киткәнче яши һәм эшли. Казанда аның «Төрек теле грамматикасы» дигән мәгълүм хезмәте, әдәбият, тарих, философия һ. б. буенча күп кенә оригиналь тикшеренүләре басылып чыга. Казембекның Казандагы күпкырлы фәнни һәм практик эшчәнлеге — татар-дагстан культура-тарихи бәйләнешләренең иң якты сәхифәләреннән берсе. «Казембек Казанда» дигән темага киләчәктә фәнни хезмәтләр язылыр әле.

Дагстанлыларның һәм Казан татарларының юллары киң илебезнең башка җирләрендә дә кисешә. Кайда гына очрашмасыннар, аларны якын дуслык, мораль һәм материаль ярдәмләшү берләштерә.

1866—1881 елларда дагстанлы шагыйрь һәм мәгърифәтче Мөхәммәт-әфәнде Османовның (1839—1904) Петербург университетында укытучы булып эшләгәнлеге мәгълүм. Ул төрки телләр лекторы була. Бу эшкә аны танылган татар галиме Хөсәен Фәезханов (1828—1866) үлгәннән соң аның урынына, М. Казембек һәм башкаларның юллап йөрүе нәтиҗәсендә чакыралар.

Россия империясенең башкаласына Османов 1861 елда күчеп килгән була. Шул вакыттан бирле ул Петербург университеты галимнәре һәм укытучылары белән белешеп яши. Ә Фәезханов белән алар арасында дуслык мөнәсәбәтләре урнаша. «Фәезхановның мәгърифәтчеләр арасыннан танышлары даирәсе Кавказ таулары ягына таба да киңәя,— дип яза Казан галиме Миркасыйм Госманов «Заветная мечта Хусаина Фаизханова» дигән китабында.— Мәсәлән, ул комык мәгърифәтчесе Мөхәммәт-әфәнде Османов белән дусларча мөнәсәбәттә була... Османов Хөсәен үлгәннән соң университетта төрек-татар телләре лекторы эстафетасын алып кына калмый, җитмешенче елларда да мәрхүмнең гаиләсе белән дуслык элемтәләре тота, кулыннан килгәнчә ярдәм күрсәтә».

Петербург университетында Фәезханов белән Казембек арасында бик җылы мөнәсәбәтләр урнаша. Казембек татар мәгърифәтчесенә төрлечә ярдәм күрсәтеп тора. Ул аны Петербург университетына үзе чакырта һәм талантлы хезмәт кешесенә эшләү өчен бөтен шартларны тудыра. Фәезханов үлгәннән соң, аның хатыны һәм кызларының тормыш итәр чыганагы калмагач, Казембек аларга материаль ярдәм күрсәтә. Көнчыгыш факультеты исеменнән ул, мәрхүмнең семьясына пособие билгеләүне үтенеп, югарыгы органнарга берничә тапкырлар мөрәҗәгать итә.

XIX йөз уртасында Идел буе татарлары царизмның колониаль политикасына каршы Кавказ халыкларының көрәшен игътибар белән күзәтеп торалар, имам Шамилнең язмышына да теләктәшлек белән карыйлар. Дөрес, әсирлеккә алынган Шамилгә һәм аның гаиләсенә илнең өч шәһәреннән берсендә урнашырга патшаның рәсми рөхсәтен мин беркайда да очратмадым. Әмма патшаның шундый әмере булган диләр. Император Шамилгә күчеп килергә рөхсәт иткән шәһәрләр арасында берсе Казан булган, һәм ул Казанны сайлаган да. Казанда бу хәбәрне шатланып каршы алганнар һәм үзәк урамнарның берсендә Шамил өчен йорт салганнар һәм ул хәзергә кадәр халык арасында «Шамил йорты» дип йөртелә.

Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты фольклорчыларының раславынча, Идел буенда, бигрәк тә Татарстанда Шамил һәм аның гаилә членнары турында мәкальләр, әйтемнәр, җырлар, риваятьләр киң таралган. Әдәбият белгече М. Гайнетдинов миңа 1979 елда талантлы татар шагыйрәсе Газизә Сәмитованың (1862—1929) сайланма әсәрләр җыентыгын бүләк итте. Анда оригиналь әсәрләр белән беррәттән «Шамил бәете» дә урын алган. Бу әсәрдә Кавказдагы азатлык хәрәкәте юлбашчысының эшчәнлеге югары художестволы итеп тасвирлана. Бәеттә чорның социаль каршылыклары, патша хөкүмәтенең халыкны изү политикасына каршы таулыларның көрәш алып бару сәбәпләре ачыла. Таулыларның батырлыгына, каһарманлыгына дан җырлана.

Бу гасырның беренче унъеллыгында илебездәге төрки халыклар арасында күренекле галим, тарих, философия һәм башка өлкәләрдә зур хезмәтләр куйган Риза Фәхретдиневнең хезмәтләре бик популяр була. Илебездә Көнчыгышны өйрәнүчеләрдән беренче булып, ул Шамилнең һәм аның тарафдарларының тормышына, эшчәнлегенә мөрәҗәгать итә.

1813 елда төзелгән Гөлстан килешүе буенча Дагстан Россия составына керә. Патша хөкүмәте шул вакыттан башлап тау халыклары арасында ирексезләп үз тәртипләрен кертә башлый. Дагстанлылар үз ирекләрен яклап көрәшкә күтәреләләр. Алар царизмның колонизаторлык политикасына каршы да, халыкны талаучы җирле феодалларга да каршы чыгалар.

Мәгълүм булганча, дагстанлыларның көрәшенә утыз елга якын Шамил җитәкчелек итә. Патшаның регуляр армиясе ахыр чиктә бу хәрәкәтне бастыра. 1859 елда генерал Барятинский 64 яшьлек Шамилне әсир итә һәм ул якыннары белән бергә Калуга губернасына сөргенгә озатыла. Шамил белән бергә уллары Казый-Мөхәммәт, Мөхәммәт-Шәффи дә була.

Бүген безне бигрәк тә кызыксындырганы — Шамилнең өченче улы Мөхәммәт-Шәффи. Р. Фәхретдинев аның боегуны белми торган, күрер күзгә матур гына кеше булуы хакында яза. Әтисе белән бергә Калугага килеп эләккәч, Мөхәммәт-Шәффи тиз арада үзенә дуслар таба, русчага өйрәнә. Калугада Мөхәммәт-Шәффи рус армиясенә кабул ителә. 1863 елда патша конвое составына кертелә, берничә тапкыр Кисловодскида, Владикавказда була. Шул ук Р. Фәхретдиневнең язуынча, ул югары хәрби мәктәп тәмамлый. 1877 елда Мөхәммәт-Шәффи полковник чинында Казанда хезмәт итә.

Мөхәммәт-Шәффи ике тапкыр өйләнә. Аның икенче хатыны Мәрьям-ханым Казан сәүдәгәре Ибраһим хаҗи Аппаковның кызы була. Мөхәммәт-Шәффинең бу хатыныннан өч баласы туа: улы Мөхәммәт-Заһит, кызлары Патимат-Заһират һәм Нәфисәт-ханым. Балалары Казанда тәрбияләнәләр, яхшы белем алалар. Мәсәлән, Мөхәммәт-Заһитка Казанда алган белеменең соңрак нәширлек эшендә бик файдасы тия. 1906 ел ахырында Мөхәммәт-Заһит Шамуил (Шамилов дигән мәгънәдә — С. А.) Мәскәүдә татар телендә «Тәрбиятел-әтфал» дигән журнал чыгара башлый. Ул гарәп язуы белән айга икешәр мәртәбә чыга.

Күптән түгел мин бу журналның 1907 елның 1 мартында чыккан бишенче санын таптым. Журнал Мәскәү һәм Петербургтагы архитектура истәлекләренең фоторәсемнәре белән матурлап иллюстрацияләнгән.

Югарыда әйтеп үтелгәнчә, Мөхәммәт-Шәффинең ике кызы да була. Ул алар белән берничә тапкыр Кисловодскига ял итәргә килә.

1905 ел ахырында— 1906 ел башында (ихтимал, кышкы каникул чорындадыр) Петербург тимер юл транспорты институты студенты, Дагстанда Совет власте өчен көрәшнең булачак җитәкчеләреннән берсе Махач Дахадаев та Кавказга кайта. Аны Петербургтагы революцион группа Төньяк Кавказга җирле халык арасында агитация-пропаганда эше алып барырга җибәрә. Дахадаев килгән чакта Мөхәммәт-Шәффи дә гаиләсе белән шунда була. Бу хакта ишеткәч, М. Дахадаев атаклы якташының улы белән очрашырга тели.

Дахадаев Мөхәммәт-Шәффи белән таныша, үзе турында, Петербургта укуы турында сөйли, әлбәттә, үзенең Кавказга ни өчен килүе турында әйтми. Ни дисәң дә, аның каршында, Шамил улы булса да патша генералы тора бит. Беренче очрашудан соң М. Дахадаев Мөхәммәт-Шәффи янына тагын берничә тапкырлар килә, тегесе аны кызлары белән таныштыра. Мөхәммәт-Шәффи белән дагстанлылар, аларның хокуксыз хәле турында сөйләшкәндә, М. Дахадаев аңа үзенең килү максаты турында берничә тапкыр әйтмәкче була. Мөхәммәт-Шәффи, болар белән кызыксынмаган булып кыланса да, халыкны җирле феодаллар һәм патша самодержавиесе изүеннән азат итү эшенә теләктәшлек белән карый.

М. Дахадаев Мөхәммәт-Шәффинең кызлары белән бик дуслашып китә. Генерал гаиләсе белән Казанга киткәч, бераздан Дахадаев та шунда килә, Мөхәммәт-Шәффи йортында кунак була һәм Петербургка китә. Шул рәвешчә, Дагстанның данлы улларыннан берсе Казанда — Ленин гвардиясе большевигы Мулланур Вахитов ватанында була. Ихтимал, алар Петербургта да очрашканнардыр. Язмышлары бик охшаш бит: бер үк елларда революцион Петербургта уку, башкаладагы революцион группалар эшендә катнашу, черегән стройга каршы көрәшү өчен яңадан үз якларына кайту.

Дахадаев та, Вахитов та Петербургта С. Габиевның «Дагстан таңы» газетасын һәм «Мөселман газетасы»н чыгаруда (1912—1914) актив катнашалар. Гадел эш өчен һәлак булулары да бер үк 1918 елда. Берсе туган Казан шәһәрен контрреволюция көчләреннән саклаганда һәлак була, икенчесен Гоцинский һәм Тарковский бандасы ерткычларча үтерә.

1906 елның җәендә Мөхәммәт-Шәффи каты авырып китә. Якыннары аны дәвалау өчен Кисловодскига алып киләләр. 10 августта ул шунда үлә. Кисловодскида аны күмгәндә М. Дахадаев та була.

Ире вафат булганнан соң Мәрьям-ханым кызлары белән Петербургка күчеп килә. Бераздан соң М. Дахадаев Нәфисәт-ханымга өйләнә һәм аның белән Дагстанга кайта, анда Тимер-Хан-Шура (Буйнакск) шәһәрендә яшиләр. Башка революционерлар белән берлектә ул демократик көчләрне патша строен бәреп төшерү өчен көрәшкә әзерләүдә актив катнаша.

Хезмәт ияләрен революцион вакыйгаларга әзерләү өчен аларга большевиклар партиясенең сугышчан сүзен җиткерергә кирәк була. 1917 елның язынннан Дагстан Агитация-пропаганда бюросына (ДАПБ) берләшкән прогрессив көчләр милли телләрдә газета-журналлар чыгаруны оештыралар. Мәсәлән, авар телендәге «Заман» газетасын Казанда туып үскән, шунда тәрбия алган Нәфисәт ханым Дахадаева редакцияли.

Ире һәлак булганнан соң Нәфисәт ханым әнисе янына Петроградка китә. Анда ул төрле культура учреждениеләре эшендә катнаша, Ленинград блокадасы вакытында үлә.

Танылган мәгърифәтче, Дагстанда рус һәм Көнчыгыш классикасын пропагандалаучы Абусуфьян Акаев та Казанга берничә тапкыр килә. Монда ул төрле уку йортларында укый, яңа ысул белән укытыла торган мәктәпләрнең тәҗрибәсен өйрәнә, дәреслекләр һәм уку ярдәмлекләре әзерләү методларын үзләштерә. Акаев һәр яклап та бик белемле кеше була, аны Казанда «Дагстан профессоры» дип йөртүләре юкка гына түгел. Ул практик эшчәнлеген туктаусыз уку белән бергә алып бара. «Вакыт» газетасының 1909 елгы 18 июнь санында бер фоторәсем урнаштырылган. Анда «Дәрел-мә-

галлим»нең (укытучылар институтының) җиде тыңлаучысы арасында биек папаха, Кавказ бишмәте кигән Акаевны да күрәбез.

Дагстанның күренекле мәгърифәтче демократы Нухай Батырмурзаевның (1865—1919) тормышында да Казан гаять зур роль уйный. Ул анда берничә ел яши, бертуган Кәримовлар типографиясендә эшли һәм «Казан мөхбире» газетасында хезмәттәшлек итә. Казандагы иҗади эшчәнлеге турында ул «Һарун һәм Зөбәйдә яки насыйпсыз Җанбикә» повестеның төп герое Һарун авызыннан сөйли.

Н. Батырмурзаев Казанда татар әдәбиятын бик әйбәт үзләштерә. Татар әдәбияты классигы Габдулла Тукай, бигрәк тә мәгърифәтче прозаиклар Муса Акъегет, Заһир Бигиев, Риза Фәхретдинев, Закир Һади иҗаты йогынтысы астында ул «Язык Хәбибәт», «Давыт белән Ләйлә» дигән һәм югарыда телгә алынган өч повесть яза, «Кавказның һәм бөтен Россиянең хәле» дигән поэма иҗат итә.

Тикшеренүчеләрнең мәгълүматларына караганда, Казанда Н. Батырмурзаевның улы, ялкынлы революционер, талантлы шагыйрь, язучы һәм публицист Зәйнәлабид та яши. 1915—1916 елларда ул, Астраханьда кулган алынудан качып, Казанга килә. Бирелә ул патша шымчыларыннан эз яздырырга уйлый, икенче яклап, әтисенә язган хатларыннан күренгәнчә, югары белем алырга дигән зур хыялы да була. Ләкин, Казанга килгәч, Астраханьдагы кебек үк җирле социал-демократлар белән якыная, «Халык» газетасында басылып чыккан мәкаләсе өчен яңадан качып йөрергә мәҗбүр була. Казаннан ул Бакуга китә, аннары Дагстанга кайта һәм алдынгы иҗат яшьләреннән театр труппасы оештыра. 1917 елда, Тимер-Хан-Шурага килгәч, ул ДАПБ члены, прогрессив «Таң-Чулпан» журналының (1917—1918) редакторларыннан берсе була. Хәрби-революцион комитет тапшыруы буенча большевистик «Эшче халык» газетасын редакцияли. Ә 1918 елның көзендә, Дагстанда контрреволюцион чит ил интервентлары ярдәмендә совет власте бәреп төшерелгәч, З. Батырмурзаев Хасавюрт округында партизаннар хәрәкәтендә җитәкчелек итә һәм акгвардиячеләргә каршы көрәштә һәлак була.

Дагстан хезмәт ияләренең контрреволюциягә каршы көрәшендә Астрахань, Казан хезмәт ияләре дә гаять зур ярдәм күрсәтә. Ярдәм Идел һәм Каспий аша килә. Казаннан Дагстанга милли типография өчен шрифтлар китерәләр.

Утызынчы елларда Дагстан интеллигенциясе вәкилләре партиянең өлкә комитеты һәм республика хөкүмәте тарафыннан культура һәм белем дәрәҗәсен күтәрү өчен Казанга җибәрелә. Бу елларда Татарстан башкаласында революционер, шагыйрь, драматург А. П. Салаватов, республика газетасы «Ленин елу»ның элекке редакторы Г. Керимов, өлкән педагоглар А. Гамзатов, Б. Сунгуров, галим, тарихчы А. Тамай һ. б. укый яки белемнәрен күтәрә.

Дагстанлыларның Казан, Татарстан белән күп яклы элемтәләре безнең көннәрдә тагын да тирәнәя. Дагстанлылар Казанга, аның вузларында белемнәрен күтәрергә, архивларда һәм китапханәләрдә эшләргә, фәнни-теоретик конференцияләрдә, киңәшмәләрдә катнашырга, фән, культура, производствоның төрле өлкәләрендә тәҗрибә алмашырга киләләр. Иделдәге зур фән һәм культура үзәгенә якташларыбыз В. И. Ленинның, аның көрәштәшләренең тормышы, революцион эшчәнлеге белән бәйле истәлекле тарихи урыннарга экскурсияләргә дә киләләр. Казан кунакларын һәрвакыт яратып каршы ала.

**Солтанморат АКБИЕВ,**
филология фәннәре кандидаты.
*Каспийск шәһәре.*

# ФИДАКАРЬ ГАЛИМ ОНЫТЫЛМЫЙ

Минем студент елларым борынгы рус шәһәре Воронежда узды. Шулай бер вакытны Воронеж университеты доценты Полина Андреевна Бороздина (ул СССР халыклары әдәбиятын яхшы белүче галим буларак танылган) үзендә диплом язучыларны өенә чакырды. Иркен квартирадагы бай китапханәне күреп таң калдык. Без бу китапханәнең хуҗаныкы — мәрхүм профессор, тарихчы Илья Николаевич Бороздинныкы (1883—1959) икәнен белә идек. Шулай ук безгә аның китап «җене» кагылган, фәнгә мөкиббән киткән кеше булганлыгы да мәгълүм иде.

Әңгәмәбез ахырында П. А. Бороздина безгә бик сирәк очрый торган китапларны күрсәтте. Без борынгы халыклар тормышы язылган калын-калын китапларны, А. Блок, В. Маяковский, С. Есенин, В. Брюсов, О. Мендельштамнарның Илья Николаевичка үзләре бүләк иткән җыентыкларын тотып карадык. Мин Бороздина җитәкчелегендә татар әдәбияты буенча диплом яза идем. Ул миңа мәрхәмәтле итеп болай диде: «Ә менә бу китаплар сиңа гына кызыклы булыр...» Минем кулыма ул Г. Ибраһимов, Г. Сәгъди, Г. Нигъмәти, Г. Рәхим исемнәре язылган китапларны тоттырды. Шуннан соң, профессор И. Н. Бороздинның Казан, Татарстан белән фәнни бәйләнешләренең тарихын күбрәк беләсем килеп, бу йортта озаграк утырырга булдым.

Тарихчы, этнограф, әдип И. Н. Бороздин — алдынгы рус культурасының соклангыч вәкиле. Һич шикләнми әйтергә мөмкин — татар совет әдәбияты тәүге адымнарын атлаган заманда ул татар культурасы һәм фәне әһелләренә гаять зур ярдәм күрсәткән. Аның бай эрудициясе рус һәм татар халкы арасында дуслыкны ныгытуга хезмәт итә.

И. Н. Бороздин Мәскәү университетының тарих-филология факультетын тәмамлый. Шул елларда яшь галим Россиядә яшәүче төрле халыкларның тарихын, культурасын өйрәнә башлый. Дөрес, ул яшь чагында ук «XIX гасырда Франциядә социаль хәрәкәт тарихыннан очерклар» (1906) исемле бик кызык китап авторы буларак танылып өлгерә. Галимнең беренче зур тикшеренүләре һәм археологик эзләнү нәтиҗәләре И. Н. Бороздинны илебезнең көньягын өйрәнүне шәп оештыручы итеп тә таныта. Аның шушы эзләнүләргә караган китабы да басылып чыга. Галимнең үз дигәненә ирешә торган кеше булуы, шәкертләренең дәрманын тарих фәнендәге «ак тапларны» өйрәнүгә юнәлтә белүе, аңа күпләрнең игътибарын җәлеп итә.

Аның хезмәтләре «Вестник Европы», «Русская старина», «Современный мир», «Гермес» кебек дәрәҗәле журналларда басыла. Антик чор һәм норманнар мәсьәләсе, борынгы, урта гасырлар тарихы һәм яңа тарих, Греция, Рим, Көнчыгыш — галимне бөтенесе дә кызыксындыра. 1914 елда ук рус галимен Франциягә, археологларның тугызынчы конгрессына чакыралар.

Галим Бөек Октябрьдан соң зур күтәренкелек кичерә. Кече Азиядә яшәгән хеттлар тарихын өйрәнә. Шәкертләре белән Кырымда казу эшләре алып бара. Гераклия ярымутравындагы кайбер корылмаларның хронологиясенә караган мөһим ачышлар ясый. Галим Төрекмәнстанны өйрәнүгә дә байтак көч түгә.

20—30 елларда И. Н. Бороздин татар культурасы тарихына мәрхәмәтле итә. Аның тарих, этнография, әдәбият, музыка өлкәсенә караган киң белемнәре без яшәгән төбәк белән кызыксынуын озак дәвам итү өчен җирлек була. Тарихчының фәнни хезмәтләре биш йөздән артып китә. Аларның бик күбесе татар халкы тарихына һәм культурасына багышланган. Моның сәбәбе шул: И. Н. Бороздин күп еллар дәвамында СССР Үзәк Башкарма Комитеты каршындагы Көнчыгышны өйрәнүчеләрнең гыйльми ассоциациясенең (НАВ) актив члены булып тора. Бу ассоциация каршында татар культурасын өйрәнү буенча махсус комиссия эшли. «Яңа Шәрык» дигән журнал чыгарыла, аның редколлегиясе эшендә Бороздин актив катнаша. И. Н. Бороздин чит илләр белән культура бәйләнешләре буенча Бөтенсоюз җәмгыятенең милләтләр бюросы председателе булып та тора. Монда эшләгәндә СССР халыкларының культура казанышларын киң пропагандалау өчен мөмкинлекләр була. Ул Бөтенсоюз олимпиадасын әзерләү комитеты председателе буларак, Беренче СССР халыклары

сәнгате смотрында (1930) татар культурасы тиешле югарылыкта күрсәтелсен өчен бөтен көчен бирә.

Казан тарихын археологик дәлилләүгә тарихчы галим берәгәйле өлеш кертә. Бороздинның «Татар культурасына карата» (1928 елның җәендә Татреспубликада фәнни-тикшеренү экспедициясе), «Иске Казанны эзләгәндә» (1929), «Казан Кремлендә археологик казу эшләре» (1929) исемле һәм башка хезмәтләрендәге кызыклы күзәтүләре, табышлары әле дә булса тикшеренүчеләрнең игътибарын җәлеп итә. НАВның тарих-этнология бүлеге утырышында ясаган докладында И. Н. Бороздин культура катламын табу һәм топографиянең кайбер бәхәсле мәсьәләләрен ачыклау максатында Казан Кремлендә алып барылган археологик казу эшләрендә үзе белән бергә Академүзәк вәкилләре В. В. Егерев, профессор А. С. Башкиров, фәнни хезмәткәрләр П. Е. Корнилов, Л. И. Вараксина, Н. Ф. Калинин, аспирантлар һәм студентлар катнашуын билгеләп үтә. Беренче археологик казып карау Спасс капкасыннан ерак түгел, Киприан чиркәве янындарак үткәрелә. Эшнең мөһим нәтиҗәсе Казан Кремленең чикләрен билгеләүдә була.

Ул чагында Арча кантонына кергән Князь Камаево шәһәрлегендә табылган археологик мәгълүматларның Иске Казан урынын билгеләүдә әһәмияте зур була. Бу археологик сәфәрдә Г. Рәхим, Башкиров, Вараксина, Осипова, Булич, Таһиров, Хөсәеновлар катнаша. И. Бороздин шундый нәтиҗә ясый: «Разведка нәтиҗәле булды. Биредә һичшиксез казу эшенә керешергә кирәк, бу — күп кенә риваятьләр һәм хикәятләр аша әлеге җир белән нык бәйләнә торган мәсьәләләрне бөтенләй башкача яктыртырга мөмкинлек бирәчәк»[1].

Республика җәмәгатьчелеге И. Н. Бороздинның бу юнәлештәге эшчәнлеген югары бәяли. Казан музееның Көнчыгыш сәнгате бүлеге фәнни хезмәткәре профессор Б. П. Денике үзенең бер хезмәтендә Көнчыгышны өйрәнүче рус галименең тикшеренүләре перспективалы булуын күрсәтеп үтә.

Бороздин татар халкының тарихы белән генә кызыксынып калмый. Ул яңа татар әдәбияты, театры, музыкасы турында кайгырта. Шунысы игътибарга лаек: үзенең күп кенә чыгышларында ул элекке культураның иң гүзәл казанышларын өлге итеп алырга кирәклеген искәртә. Халык мәгърифәте җәмгыяте съездында чыгыш ясаганда галим татар культурасын комплекслы өйрәнү идеясен күтәрә. «Жизнь национальностей» дигән үзәк журналда (1923, 5 нче китап) Казанда булу тәэсирен уртаклашып, Бороздин мондый тикшеренүчеләрнең беренче уңышлары турында сөйли. Шул ук вакытта ул игътибарны Идел-Кама краен өйрәнү буенча тарихчылар, археологлар алдында торган кичектергесез бурычларга юнәлтә.

И. Н. Бороздин Татарстан республикасының биш еллык юбилее алдыннан да шактый эш башкара. Күп төрле оештыру эшеннән тыш энтузиаст галим яшь республиканың экономика, политика, халык мәгарифе, культура өлкәсендәге казанышларын популярлаштыру белән дә мәшгуль. Аның «Бүгенге Татарстан» дигән зур очеркын (СССР Үзәк Башкарма Комитеты каршындагы Көнчыгышны өйрәнү гыйльми ассоциациясе нәшриятында 1926 елда аерым китап булып басылып чыга (укучылар бик җылы кабул итә. Бу очерк «Яңа Шәрык» журналында да басыла (1925 ел, 10—11 саннар). «Кызыл Татарстанда» дигән баш астында аны «Безнең юл» журналы да күчереп баса.

Гаять гыйбрәтле, мәгънәле саннар, Татарстанның экономик, политик һәм культура яңарышын раслаучы фактлар китереп, автор яшь республиканың авыр сынауларны уңышлы үтүен әйтә. Крайның промышленносте ныгый, куәт ала, авыл хуҗалыгында да уңай якка үзгәрешләр сизелә. Культура өлкәсендә казанышлар байтак. Биш елда гына да республика 29 яңа уку йорты ача. Галим Казан университетының искиткеч зур әһәмияте турында яза, 6 югары уку йорты, 23 техникумның, яңа рабфаклар, профтехучилищелар, уку-өйрәнү мастерскойларының эшенә уңай бәя бирә. Наданлыкны бетерү буенча актив эш алып барылуын күрсәтерлек саллы саннар китерә.

И. Н. Бороздин Казан нәшриятларының Башкортстан, Кыргызстан, Таҗикстан, Калмык АССР, Кырым халыкларына китап чыгаруда интернациональ ярдәм күрсәтүе турында сөйли. Алфавит, орфография, әдәби телне гадиләштерү турында кызыклы

[1] Бороздин И. Н. «Татар культурасына карата. «Яңа Шәрык», 1929, 25 китап, 200 бит.

фикерләр әйтә. Татарстандагы революцион хәрәкәтне өйрәнү проблемасын бик вакытлы күтәрә («СССР Көнчыгышының революцион хәрәкәтләре һәм халык тарихын күмәк көч белән язарга вакыт»).

Бороздин озак еллар дәвамында Татарстанның культура әһелләре — язучылар, журналистлар, музыкантлар, рәссамнар белән аралашып яши, алар белән хезмәттәшлек кыла. Бер факт игътибарга лаек. И. Н. Бороздин СССР язучылар союзына 1934 елда, беренчеләрдән булып алына. Лаеклы рәвештә алына.

Бороздин озак еллар Г. Ибраһимов белән дус була. «Галимҗан Ибраһимов белән очрашулар» дигән истәлекләрендә («Г. Ибраһимов турында истәлекләр». Казан, 1966) ул татар халкының талантлы язучысы белән Мәскәүдә, Ленинградта, Бакуда, Казанда булган очрашулары турында эчке бер җылылык белән сөйли. Г. Ибраһимовның бай эрудициясе рус галимен таң калдыра, әдипнең тәэсирле чыгышлары сокландыра («Бу җыелышларның барысында да Г. Ибраһимов иң әһәмиятле мәсьәләләрне оста күтәреп, тирән уйланган, реаль һәм урынлы тәкъдимнәр белән чыкты»). Әдипне әңгәмәдәш буларак та хөрмәт белән искә ала ул («Г. Ибраһимов акыллы, игътибарлы һәм кызык әңгәмәче, үзенең тоткан позициясен җиңел генә ташламый иде»). Г. Ибраһимов һәм И. Бороздин арасындагы хат язышу да бу дуслыкның ни дәрәҗәдә ихлас һәм «уңдырышлы» булуын күз алдына китерергә мөмкинлек биргәнгә күрә, заманында укучыларның игътибарын җәлеп иткән иде. Рус язучысы «Безнең көннәр», «Тирән тамырлар», «Казакъ кызы» кебек сокландыргыч әсәрләр иҗат иткән, үзенең роман һәм повестьларында халык тормышының кызыклы күренешләрен биргән авторның иҗатын киң пропагандаларга кирәклеге турында матбугатта кат-кат язып чыга.

Бороздин Г. Ибраһимовның «Тирән тамырлар»ын үз редакциясендә бастыра. Ш. Усманов хикәяләре дә аның редакциясендә нәшир ителә (кереш сүзне дә ул яза). Татар альманахы басылып чыккач (А. Фадеев һәм Э. Багрицкий редакциясендә, М., 1930), ул «Красная новь» журналында (1931, 3 сан) рецензия белән чыга.

«Милли әдәбият турында язмалар» дигән мәкаләсендә (1929) Бороздин СССР халыклары әдәбиятларындагы моңарчы күрелмәгән үсеш-күтәрелеш турында сөйли. «Революцион дәвер әдәбият дөньясын тибрәтеп җибәрде, аңа яңа сулыш, яңа темалар бирде»,— дип яза ул «Красная Татария» газетасының 1929 елгы 1 август санында басылган шушы мәкаләсендә. Татгосиздат алдына татар әдәбиятының иң матур үрнәкләрен планлы рәвештә, яхшы сыйфатлы итеп рус теленә тәрҗемә итү бурычы куела. Бөтенсоюз укучысы татар әдипләренең яңа буынын начар белә («яңа татар әдәбияты вәкилләре бөтенләй диярлек тәрҗемә ителмәгән») дигән сүзләр вакытлы әйтелгән шелтә иде. «Активрак, планлырак эшләргә, үзара танышлыкны көчәйтергә — шул чагында Көнчыгыш халыклары әдәбияты үзенә лаек урын алыр» дип тәгаллий ул мәкаләсен. Хәзер — татар әдипләренең китаплары дөнья мәйданына чыкканнан, алар дөнья һәм СССР халыклары теленә тәрҗемә ителгәннән соң — И. Н. Бороздин сүзләренең никадәр вакытында әйтелгәнен аңлыйсың.

Фәнни-тикшеренү, педагогик эшләре баштан ашкан булса да, Илья Николаевич Бороздин татар язучыларыннан Ш. Усманов, Х. Туфан, Н. Баян, М. Крымов, С. Батталлар белән бергә «Комсомольская правда» битләрендә чыгыш ясарга вакыт таба. (1930 ел, 4 январь саны.) Газета бер битен тулысы белән Совет Татарстаны әдәбиятына багышлый. И. Н. Бороздин шул чор татар әдәбиятына күзәтү рәвешендә язылган зур күләмле мәкалә белән катнаша. Әлеге хезмәте һәм «Казаннан алган тәэсирләр», «Татар театры», «Сания» операсы хакында» дигән h. б. мәкаләләре аның республикабызның культура тормышындагы һәр әһәмиятле вакыйганы игътибарга алып баруы хакында сөйли. Кагыйдә буларак, авторның һәр әйткән сүзе бөтенсоюз культура тормышына килеп ялгана. Ул татар культурасының илебездә яшәүче халыклар тормышы белән багланышлары хакында уйлана. Әйтик менә татар театрының уңышларына сокланып язган мәкаләсендә профессор Союзда яшәүче төрки халыклар тормышында татар сәхнә культурасының зур роль уйнавы турында яза. Мәкаләдә талантлы актерлар, драматурглар, С. Гыйззәтуллина-Волжская, Г. Кариев, К. Тинчурин, Ф. Бурнашлар СССР халыкларының байтак культура әһелләре өчен маяк булып тора дигән фикер әйтелә.

Беренчеләрдән булып И. Н. Бороздин рус матбугаты битләрендә беренче татар операсы «Сания» турында югары фикер белән язып чыга. Опера һәм башкорт хал-

кының яраткан көйләре тукымасында иҗат ителгәнлектән, бу көйләр белән системалы танышу мөмкинлеге ачыла. «Опера татар музыкасының опера композицияләре өлкәсендә шактый җитлегеп килүен күрсәтте»,— дип яза ул «Яңа Шәрык» журналында.

И. Н. Бороздинның һәр чыгышында аның Россия халыкларының экономикасы һәм культурасы чәчәк атуны чын күңелдән теләүче галим икәнлеге сизелеп тора. Үзе эшләгән бик күп рекомендацияләрне, киңәшләрен ул социализм төзү практикасы белән бәйләргә омтыла.

Аннары язмыш Бороздинны Төрекмәнстанга китерә. Ул анда кафедра җитәкли. Казу эшләре алып бара. Ә 1949 елдан алып гомеренең соңгы көннәренә кадәр ул Воронеж университетында эшли. 1959 елның ноябрендә сокландыргыч кеше һәм зур галим вафат була.

Шәкертләре һәм дуслары әйтеп бетергесез тыйнак, хезмәтчел профессор истәлеген күңелләрендә йөртәләр. Советлар Союзының барлык төбәкләреннән борынгы рус шәһәре Воронежга үзен И. Н. Бороздин шәкерте дип санаучылар килә. Тын һәм чиста урамдагы зур йортка, Бороздиннар квартирасына кешеләр җыела. Иданнан түшәмгә кадәр киштә-киштә китаплар тезелгән бүлмәләрдә яңадан-яңа бәхәсләр кыза, сүз көрәштерүләр барышында кыю идеяләр туа. Ә киштәләрдәге китапларның бик күбесе — хуҗаның татар әдәбияты, культурасы белән дуслыгының шаһитлары.

Николай **МОРАДЫМОВ**,
Кыргызстан ССР, Ош педагогия институты доценты.

# РУХИ МИРАСНЫ БАРЛАГАНДА

Бөек Октябрь социалистик революциясеннән соң халкыбызның кульязма мирасын җыю һәм өйрәнү өлкәсендә яңа юнәлешләр барлыкка килә. Совет архив органнары, музейлар һәм иң беренче чиратта Татарстанны өйрәнү буенча фәнни җәмгыятьләр бу өлкәдә мәгълүм күләмдә эш күрсәтеләр. Тарихка, әдәбият тарихына караган язма истәлекләрне, документларны җыю һәм өйрәнү мәсьәләсенә егерменче-утызынчы елларда Г. Ибраһимов, Г. Гобәйдуллин, Гали Рәхим, С. Вахидилар зур игътибар бирәләр. Шул чорларда бу өлкәдә җиң сызганып эшләгән кульязма «мәҗнүн»нәренең берсе Сабир Алимов [1].

Сабир Алимов 1872 елда элекке Пенза губернасы Саранск өязе Татар Таулысы авылында крестьян гаиләсендә туган. Башлангыч белемне туган авылында алгач, бераз вакыт күрше авылда укый. Соңыннан тирәнрәк белем алу максаты белән Бохарага китә. Ләкин Бохараның схоластик мәдрәсәләрендәге тәртипләр белән килешә алмаган егет биш айдан соң Ташкентка китеп бара. Бу шәһәрдә азрак укытучылык иткәч, гыйлем эзләүче егет язмышы аны Каһирәгә китерә. Монда ул мәдрәсәдә укуын дәвам иттерә, соңыннан бер гарәп газетасында корреспондент һәм тәрҗемәче булып эшли. Мәктәп-мәдрәсәләрдә уку елларында С. Алимов гарәп, фарсы, төрек телләрен бик яхшы үзләштерә.

1896 елларда ул туган якларына кайта һәм яңадан Ташкентка китеп укытучылык эше белән шөгыльләнә. 1909—1911 елларда без аны Оренбургтагы атаклы «Хөсәения» мәдрәсәсе укытучылары арасында күрәбез. 1912 елда ул Әстерханга килеп укыта башлый һәм гомеренең соңгы көннәренә кадәр шунда яши. 1912 елда Уфага барып Диния назаратында муллалыкка имтихан тотса да Сабир Алимов бу вазифаны бервакытта да үтәмәгән.

Бөек Октябрь революциясеннән соң С. Алимов Әстерханда татар совет мәктәп-

[1] С. Алимов турында документаль чыганаклар Казан дәүләт университетының Н. И. Лобачевский исемендәге фәнни китапханәсенең кульязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә (№ 2392 т.) һәм СССР Фәннәр академиясенең Көнчыгышны өйрәнү институтының Ленинград бүлеге Көнчыгышны өйрәнүчеләр архивында (152 фондта) саклана.

ләрендә укытуын дәвам итә. 1918 елда мөселман эшләре буенча Әстерхан край комиссариатының мәгариф бүлеге тарафыннан ачылган кыска вакытлы курсларда укып белемен күтәрә.

Кульъязмалар җыю эшенә С. Алимов 1935 елда катнашып китә. Бу эшкә аны шушы елда кульъязмалар һәм документаль истәлекләр җыю максаты белән Әстерханга килгән, Ленинградтагы тарих-археография һәм Көнчыгышны өйрәнү институтының фәнни хезмәткәре Вәли Зәбиров тарта. Соңыннан шушы археографик экспедиция эшендә актив катнашканы өчен Сабир Алимовка Көнчыгышны өйрәнү институты дирекциясе, академик А. Н. Самойлович йөзендә рәсми рәвештә рәхмәт белдерә. Шул ук елны ул Вәли Зәбиров булышлыгы белән Көнчыгышны өйрәнү институтының штаттан тыш корреспонденты итеп билгеләнә һәм гомеренең соңгы көннәренә кадәр халкыбызның кульъязма мирасын җыю, киләчәк буыннар өчен аны саклап калу эше белән шөгыльләнә. Өлкән яшьтә булуына карамастан (ул 1939 елның 14 ноябрендә, 68 нче яшендә вафат була) Әстерханда гына түгел, Волгоград өлкәсе авылларына да чыгып кульъязмалар җыя. 1935 елдан Сабир Алимов җыйган кульъязмаларын даими рәвештә Көнчыгышны өйрәнү институтына җибәреп тора. Ул җибәргән 460 лап кульъязма китаплар, документлар арасында нәрсәләр генә юк! Менә мәшһүр болгар-татар шагыйре Кол Галинең «Йосыф кыйссасы». Аның ике нөсхәсен С. Алимов саклап калган икән. XIX гасырның икенче яртысында иҗат иткән шигърияттебез былбылы Газизә Сәмитованың иҗади мирасы сакланып калуга да без С. Алимовка бурычлы икәнбез. Аның тарафыннан табылган һәм борынгы харәзем телен өйрәнү өчен кыйммәтле чыганак булган «Къонийәт-ел-мөнийәт» исемле борынгы бер бик сирәк очрый торган әсәрнең кульъязмасына белгечләр тарафыннан югары бәя бирелә [1], бу хакта үзәк матбугатта да хәбәр басыла [2]. XIII гасырда иҗат ителгән дип исәпләнә торган бу кульъязманың азагында, Урта Азиядә монгол яулары алдыннан юкка чыккан һәм хәзер фәндә үле теллэрдән саналучы харәзем телендәге сүзләргә гарәпчә аңлатма бирелгән, ягъни кечкенә генә харәзем—гарәп сүзлеге теркәлгән була. Академик И. Ю. Крачковский җитәкчелегендәге «Гарәпчеләр ассоциациясе» дә бу табыш өчен С. Алимовка махсус рәвештә рәхмәт белдерә һәм премия бирә.

Ул саклап калган әдәби ядкарьләр арасында күренекле татар шагыйре һәм галиме Габдерәхим Утыз-Имәнинең, төркмән әдәбияты классигы Мәхтүмколыйның һ. б. әдипгалимнәрнең әсәрләре дә бар. Күренекле татар тарихчысы һәм фикер иясе Ш. Мәрҗанинең бер хатын, дистәләрчә документларны, хосусый актларны да С. Алимов табып Ленинградка җибәргән. Боларга җыр, шигырь, бәет-мөнәҗәтләр белән тулган дистәләрчә шәкерт дәфтәрләрен, юриспруденция, халык медицинасы буенча язмаларны һ. б. истәлекләрне кушсаң аның фидакарь хезмәте никадәр бәрәкәтле булганын якынча күз алдына китерергә мөмкин.

Кыскасы, СССРда Көнчыгышны өйрәнү үзәкләреннән берсе булган Көнчыгышны өйрәнү институтының Ленинград бүлеге кульъязмалар фондын туплауда С. Алимов үзеннән зур өлеш кертә. Татар һәм гомумән шәрык кульъязмаларын, төрле документаль чыганакларны җыю һәм өйрәнү тарихында без һәвәскәр археограф С. Алимовның исемен хөрмәт һәм рәхмәт хисләре белән телгә алып үтәбез.

**Җәүдәт МИҢНУЛЛИН**

---

[1] Волин С. Л. Новый источник для изучения хорезмийского языка. — Записки Института востоковедения АН СССР. в. VII — М. — Л., 1939, 79—91 бб; Фрейман А. А. Хорезмийский язык. — Шунда ук, 306—319 бб.

[2] «Учительская газета», 1938, 5 февраль, № 18 (2323).

# БӘХЕТЛЕ ЯЗМЫШ

Мәшһүр гармунчы Фәйзулла Туишевны, мөгаен, үз вакытында сәхнәдә күрмәгән бер генә кеше дә калмагандыр. Илле елдан артып киткән иҗат гомерендә бу тынгысыз музыкант кайларда гына булмаган да кемнәр алдында гына чыгыш ясамагандыр. Илебезнең кайсы гына төбәгенә күз ташлама, һәркайда да бу сәхнә ветераны үткән юлларга, шәһәр һәм авылларга тап булырсың.

Әйе, туып-үскән җирләреннән таралышып, ерак-еракларга китеп көн күргән татарлар әлеге музыкантны һәрвакыт сагынып көтеп алганнар. Артист шулай шәһәрдән шәһәргә, авылдан авылга йөри-йөри, үз халкы күңелендә ватанны олылау кебек бөек, изге хисне тәрбияләүгә булышлык иткән. Ике зур чемоданга төялгән күп төрле гармуннарын күтәреп, күп еллар дәвамында халкына бик теләп хезмәт күрсәткән Фәйзулла ага Туишевны әле булса онытмыйбыз. Ә бит инде аның сәхнәдән китүенә дә утыз елдан артык вакыт узып бара икән ләбаса.

Кайларда, ничегрәк башланган соң бу мәшһүр артистның биографиясе? Моңының чишмә башы кайларда? Кайбер рәсми кәгазьләрдә теркәлгәнчә, Фәйзулла Кәбир улы Туишев ак калачлы Мәләкәс каласында түгел, чордашлары сөйләгәнчә Чирмешән елгасы буйлап барганда кырык-илле чакрым өстәрәк урнашкан Иске Тегәлбуга авылында беренче йотым суын эчкән, бәбкә үләне мул үскән җылы җиргә беренче тапкыр аяк баскан. Моны ул үзе дә раслый. «Яшь артист чагымда мин шәһәр кешесе буласы килгәнлектән генә Мәләкәстә тудым дип йөрдем»... Мәләкәстә ул чыннан да кабат туган дип әйтерлек. Физик яктан Иске Тегәлбуга авылында дөньяга килгән Фәйзулланы шушы тормышы сәхнә юлына алып чыкканлыгын һәммәбез дә беләбез бит.

Кечкенә Фәйзук туганда Иске Тегәлбуга авылы Самара губернасының Самара өязе, Кыр Шенталасы волостена карый. Бу төбәктәге татар, чуваш, мукшы авыллары арасында Иске Тегәлбуга иң зурларыннан дисәк тә ялгышмабыз. Элек анда биш мәчет, берничә мәктәп-мәдрәсә була. Кул буе һәм Зур урам асты мәдрәсәләрендә шәкертләр дога өйрәнү, дин китаплары уку белән генә чикләнмичә, дөньяви әһәмиятле кульязмаларны күчереп язу белән дә мавыгалар. Нәкый ага Исәнбәт хәтерләвенчә, бу авылның Гаделша, Гобәйдулла исемле кешеләре күчереп язган кульязма китаплар архив киштәләрендә хәзер дә очраштыргалый.

Әнә шул авылның Кәбир Туктаров йортында, Курай урамында яшәүче бик ярлы бер гаиләдә дөньяга килә Фәйзук. (Туишев фамилиясен әле ул артист булып таныла башлагач кына ала, авылдашлары әйтмешли, Казан якларында йөреп кайтканнан соң гына «Туиш» булып танылa.) Ярлы гаилә өлешенә тигән барлык кимсенүләр, ачлык-михнәтләр, балачакның үзенә генә хас бихисап күп юаныч һәм шатлыклар Фәйзук өлешенә дә төшә, билгеле. Шулай яшәп ятканда узган гасырның туксанынчы елларындагы рәхимсез корылык, ачлык башланып китә. Болай да җирсезлектән интеккән, җир-сулары төрле яклап кысрыкланган Иске Тегәлбуга халкы бу ачлыкны бик авыр кичерә. Мукшы алпавытларына ялланып эшләп, тормышларының очын очка көч-хәл белән ялгап килүче ярлырак катлам вәкилләре исә бу афәт вакытында бөтенләй җирсез, мал-мөлкәтсез калалар. Чөнки бу өлешләренә чыккан җир-иманаларын үз авылларының Шәкүр, Туктар ише байларына «сатып» җибәрми мөмкинлекләре калмый.

Кәбир абзый да әнә шундый ярлы-ябага арасында була. Тиздән ул да, «имана җирен ашап бетереп», күрше чуваш авылына көтүчелеккә барып ялланa. Шулай итеп алты-җиде яшьлек Фәйзүк, авылдаш малайларыннан аерылып, җиде чакрымдагы Иске Салаванга күченеп китә. Монда алар өч-дүрт ел яшиләр. Фәйзүк тә атасы белән бабасына ияреп көтүгә чыккалый.

Аннан алар Самара губернасының икенче бер өяз үзәге саналган Мәләкәс каласына юнәләләр. Мәләкәс хәзерге Димитровград шәһәре, Ульяновск өлкәсенә керә (ул вакытта шул тирәнең иген-ашлык сәүдәсен әйдәп баручы өч тегерманле шәһәрчек була. Анда ел саен сәүдә ярминкәләре оештырылып килә. Ярминкәгә килеп-китүчеләр өчен кунак йортлары әзерләнә. Шулар арасында Алексей Федоров «Постоялый двор»ы да була. Кәбир ага менә шунда килгән-киткән кунакларның арбасын карашырга, ишегалды тирәсен тәртипкә китерергә яллана. Инде буй җитеп килгән Фәйзүк тә эшсез калмый. Аңа кунакханә хуҗасының һәм килгән кунакларның төрле йомышларын йомышлау йөкләнә. Йөгереп торган күндәм авыл малае, бу каланың ак калачыннан чак кына авыз итеп, дәртләнеп алганның соңында «Постоялый двор»га төшүчеләр өчен самовар куючы, бүлмәләргә чәй-мәй ише нәрсәләр ташып торучы «малай»га әверелә. Күндәм, җитез, зирәк бу кәләпүшле малайны, мөгаен, бик күпләр үз иткән, яратканнар. Шул беренче кыш бетәр алдыннан ярминкә ачылуга җыела башлаган кайбер кунаклар белән инде ул ярыйсы ук танышып, аралашып та китә.

Ярминкә кунаклары арасында язгы кала тормышын тагын да бизәп, җанландырып җибәрергә дип Рәсәйнең төрле почмакларыннан җыелган һәвәскәр артистлар була. Әнә шул кәмитчеләр, төрле кәсеп ияләре, ул чорда бик модада булган карусель уеннары оештыручылар Фәйзүкне дә үз араларына тарталар. Кичә генә көтү көтеп йөргән Иске Төгәлбуга авылы малаеның күк капусы ачыла башлый, баш очында бәхет йолдызы шәүләсе шәйләнгәндәй була. Һәм акренләп ул «самоварчы малай»дан артист Фәйзүккә әверелә башлый. Баштагы бер-ике сезонда «чын артист»ларга булышкалап кына йөргән, сәхнәдә күренеп кенә киткәләгән Фәйзүкне тиздән ярминкәбәйрәмнәргә килгән халык оста итеп такмаклап биюче сыйфатында да, гадирәк акробатик номерлар башкаручы итеп тә күрергә күнегә. Билгеле, артист халкы «Постоялый двор» бүлмәләренә хәл алырга кайткач та тик кенә ятмый: берише биюнең яңа алымнарын үзләштереп азаплана, гармунчылары исә гармун шыңгырдаткан булалар. Кызыгып торган Фәйзүккә дә гармун теләренә басып карарга рөхсәт ителә. Һәм тиздән инде ул өйрәтүчеләреннән калышмыйча уйный алырлык дәрәҗәгә җитә. Өстәвенә, аның рус көйләрен генә түгел, җирле халык күңелен җилкендерерлек итеп татарча һәм чувашча да «көйли» алуы цирк, карусель оештыручыларга хуш килә. Озакламый аны Мәләкәстән читтә, Сембер, Казан, Макарҗа ярминкәләрендә күрсәтеләчәк тамашаларга да димли башлыйлар.

Оста гармунчы дигән дан әнә шулай туа. Мәләкәс «Постоялый двор»ында башланган иҗаты Иске Төгәлбугадан чыккан Кәбир улы Фәйзүкне олы дөньяга алып кереп китә. Очраклы бер хәл — Кәбир абзыйның, хәзерге заманча иттереп әйтсәк, гостиница хезмәткәре эшенә яллануы Фәйзүккә олы сәнгатькә чыгарга булыша. Бәхетле итә. Моны инде бәхетсезлеккә бәйле рәвештә туган бәхет дияргә дә буладыр. Армый-талмый эшләргә, хезмәт итәргә гадәтләнгән крестьян баласы, ташны ярып чыккан үлән кебек, барыбер яктыга омтыла һәм, ниһаять, үз дигәненә ирешә.

Шаулап, давыллап яңа чор — Октябрь революциясе тудырган дәвер килеп җитә. Кызылармеецлар белән бергә Петербургтан алып ерак Себер чикләренә чаклы йөреп, үзенең үтемле агитациясе — оста уены белән культура хезмәте күрсәткән артист, ниһаять, егерменче ел урталарында кабат Казанга әйләнеп кайта. Татарстанда милли сәнгатьне үстерү өчен янып йөрүчеләр Фәйзулла Туишевны таушалган гармуннары белән сөенеп каршы алалар, гармуннарын гына түгел, репертуарын да яңартырга булышлык итәләр. Һәм күп тә үтми, артистларыбыз арасында беренчеләрдән булып, аңа Татарстанның атказанган артисты дигән мактаулы исем бирелә. Ә тагын берничә елдан соң атаклы гармунчыбыз Татарстанның халык артисты дигән исемгә лаек була.

Шушы урында Фәйзулла ага Туишевның иҗатын азмы-күпме күз алдына китерер өчен замандашларының кайбер тасвирын күздән кичерик. Булачак театр артисты

Локман Аитов атаклы гармунчы белән беренче мәртәбә 1909 елның җәендә, Нижний Новгородта Макәрҗә ярминкәсе барган чагында очраша. «Шул көннәрдә Фәйзулла Туишев концертлары да барды, аның белән дә таныштым. Безнең халыктан да шундый гармунчы чыгар икән, дип тагын хәйран калдым... Фәйзулла Туишевның рус көйләреннән башка татар халык көйләрен дә кечкенә гармуннарда зур осталык белән уйнавы, шуның өстенә тагын үзе уйнап, үзе биеп җибәрүләре сокландыргыч иде»,— дип язды ул соңыннан.

«Кабатланмас якты талант, чын мәгънәсендә профессиональ музыкант иде Фәйзулла ага Туишев. Аның репертуары гаять бай иде. Менә ул... берара чит җирләрдә йөреп, ниһаять, сөекле, моңлы Казанына кайтты... Татар Дәүләт академия театрында аның беренче концерты. Миңа бу концертта аны тамашачылар белән таныштыру вазифасын үтәргә туры килде... «Сезнең алдыгызда Фәйзулла Туишев», дип белдергәч, залдагы алкышларны язып та, сөйләп тә аңлатуы кыен. Тамаша залы гөр килде. Бу очрашу миндә онытылмас тәэсир калдырды. Концерт ике бүлектән торды. Беренче бүлектә ул бик ыспай, мәһабәт буйлы егет кыяфәтендә кәләпүш, камзул, читек киеп чыгып, фәкать татар көйләрен уйнады. Бигрәк тә «Ончы Фәхри» белән «Әллүки»не тирән эчке бер хис белән башкарды... Аңа кадәр дә, аннан соң да мондый виртуоз башкаручыны очратканым булмады... Фәйзулла абзый гармунда уйнау белән генә чикләнми, бик оста итеп биеп тә җибәрә иде»,— дип искә алды Татарстанның халык артисты Хәким абый Сәлимҗанов бер истәлегендә.

Шундый ук мактау сүзләрен Гази ага Кашшаф та теркәп калдырган. Ул 1940 елда күренекле язучы Шәриф Камалның Мәскәүдә уздырылган иҗат кичәсен искә ала. «Бу кичәдә Шәриф абзыйның дусты һәм кордашы Фәйзулла Туишев та катнашты, һәм ул концертның җаны, йөрәге булды», ди әдип.

Егерменче һәм утызынчы елларда Ф. Туишев туган авылына еш кайта. Чөнки бу вакытта инде мәчетләр клубка әверелгән, гармун уйнаганны яратмаган булып кыланган мулла-мәзиннәр урынына анда Фәйзукнең үз ишләре — «избач Мөхәммәтша», «солдат Нәкетдин»нәр баш бит. Мәшһүр авылдашларын алар, диндар картлар кебек төкеренеп, бәддогалар кылып түгел, бик сөенеп каршы алалар, кат-кат чакырып торалар. Бу кайтуларында ул Кәбир абзыйның ата-баба нигезендә төпләнеп калган кече энесе Хөснетдин Туктаров йортына төшә. Хөснетдин агасы яу кырыннан кайтмаса да, Бәнат «тәчи»е (ягъни, җиңгәсе), Сәхаб белән Шәмси энеләре бар ич әле.

Шушы соңгы мәртәбә, сугыш башланыр алдыннан кайтуында Ф. Туишев туган авылында ике көн рәттән армый-талмый гармун уйный. Аның концертына тирә-як күрше авыллардан да бик күп кеше җыела. «Шуннан соң инде ул туган туфрагына аяк баса алмады. Әүвәл сугыш чыкты, аннары үзе бик каты сырхаулады»,— дип искә алды Иске Тегәлбуга авылының беренче коммунистларыннан булган Нәкый бабай Миңлебаев.

Артист авылдашларын менә шулай хәтерли, шулай исендә калдырган Иске Тегәлбуга халкы.

**Лирон ХӘМИДУЛЛИН.**

## ҺИБӘТУЛЛА САЛИХОВНЫҢ ТУУЫНА 190 ЕЛ

Салихов Һибәтулла Сәетбаттал улы — XIX йөз татар әдәбиятының күренекле вәкиле — 1794 елда Оренбург янындагы Чебенле авылында мулла гаиләсендә туган. Аның бабалары бу якларга элекке Казан губернасы, Чистай өязе, Такталы авылыннан күчеп килгән булалар. Башлангыч белемне туган авылында алган Һ. Салихов соңыннан шунда ук мулла була. Бу вазифаны ул Оренбург Каргалысында да (Сәгыйть бистәсендә) башкара һәм 1867 елда вафат була.

Аның «Төхфәтел-әүлат», «Мәҗмәгыль әдәб» исемнәрендә басылып чыккан китаплары һәм кулъязма рәвешендә укылып йөртелгән шигырьләре булган.

Һ. Салихов иҗатында суфичылык идеяләре төп юнәлешне тәшкил итә. «Тәндә җаным» исемле атаклы шигырь — моның ачык чагылышы. Бу әсәрдә дөньяның фанилыгы, дөнья эшләренең файдасызлыгы турында бәян ителә. Пессимистик рухта язылган бу шигырь иске мәдрәсә шәкертләре арасында бик популяр әсәр була. Әдипнең «Мәҗмәгыль әдәб» китабында да суфичылык карашлары үзенчәлек сиздерә. Шагыйрь, урыны туры килгән саен, фикерләрен раслауга мисал итеп, читләтеп әйтү юлы белән булса да җәмгыятьтәге кайбер күренешләрне тәнкыйть иткән хикәяләр дә китереп уза. Мондый иҗтимагый, әхлакый мотивлар аның «Хикаяте фит тәмсил», «Залимнәр турында» дигән баш астында бирелгән шигырьләрендә дә чагыла.

Һ. Салихов әсәрләрендә татар әдәбиятында гасырлар буе эшкәртелеп килгән әдәби формалар дәвам иттерелә. Мәсәлән, «Мәҗмәгыль әдәб» әсәрендә элек нинди дә булса әхлакый яки дини фикер әйтелә һәм шуны раслау өчен бер хикәя китерелә. Мондый форма XIV гасыр татар әдәбияты ядкарьләреннән «Нәһҗел-фәрадис», XVI гасыр әдәби җәүһәрләреннән «Нуры содур», «Төхфәи мәрдан»да да күзәтелә.

Һ. Салихов иҗатында үзәк урынны алып торучы суфичылык тәгълиматы, билгеле булганча, иҗтимагый каршылыклар хөкем сөргән җәмгыятьтә генә үзенә яшәеш җирлеге таба алган.

## МУСА АКЪЕГЕТНЕҢ ТУУЫНА 120 ЕЛ

Муса Акъегет XIX йөзнең соңгы чирегә татар әдәбиятында күренекле роль уйнаган язучыларның берсе. Ул 1864 елның 3 декабрендә элекке Пенза губернасының Чембар (хәзерге Белинск) шәһәрендә чиновник гаиләсендә дөньяга килгән. Башлангыч белемне атасының туган авылы Мачалида алган. Берничә елдан соң аны Чембарга кайтаралар һәм дүрт класслы рус мәктәбенә бирәләр. 1878 елда ул Пенза шәһәрендәге беренче гимназиядә укый башлый. Рус телен камил белүе өстенә, французча да өйрәнә, рус һәм Европа әдәбияты белән дә таныша. Шул ук вакытта татар культурасы һәм әдәбияты торышын да бик кызыксынып күзәтә. Төрле чикләүләр нәтиҗәсендә югары уку йортларына керә алмаган М. Акъегет Бакчасарай шәһәрендә чыга торган «Тәрҗеман» газетасында эшли. 1886 елда ул Төркиягә китә һәм Истамбул шәһәрендә югары мәктәпкә укырга керә. Соңыннан шунда ук рус теле укытучысы булып эшли. М. Акъегет соңгы көннәрдә Истамбул китапханәсендә эшләп, 1923 елның 24 сентябрендә вафат була.

М. Акъегет иҗатында иң әһәмиятле урын тоткан әсәр — 1886 елда Казан университеты типографиясендә басылып чыккан «Хисаметдин менла» романы. Бу роман татар әдәбияты тарихында мәгърифәтчелек реализмы методлары белән язылган беренче әсәрләрнең иң күренеклесе булды. Әсәрдә автор ул чордагы татар җәмгыяте өчен әһәмиятле булган проблемалар күтәрә: халыкка хезмәт итү, шәхес иреге өчен көрәш һәм шушы проблеманың состав өлеше булган хатын-кыз азатлыгы мәсьәләсе, уку-укыту һәм тәрбия өлкәсендә хөкем сөргән схоластиканы кире кагу һәм дөньяви белемнәр бирә торган уку йортлары ачу, рус телен укыту, һәртөрле хорафатларга, сорыкорт ишан һәм муллаларга каршы көрәш һ. б. Әсәрдә мәгърифәтчелек һәм ватанчылык идеяләре авторның кайбер буржуаз омтылышларына («милли һәм дини» теләкләрнең уртаклыгын идеаллаштыру, аларның сыйнфый мәнфәгатьләрдән өстен торуын дәгъва итү һ. б.) караганда шактый көчле бирелгән. Бу әсәргә характерлы каршылыклар — үсеп барган буржуаз тәртипләрне идеаллаштырып гәүдәләндерү — реалистик сәнгатьнең бер этабы булган мәгърифәтчелек реализмына хас сыйфат.

# ЯШӘҮ ҺӘМ ХЕЗМӘТ ҮРНӘГЕ

*Профессор Л. Җәләйнең тууына 90 ел тулу уңае белән*

Күренекле тел галиме, тәнкыйтьче, педагог һәм актив җәмәгать эшлеклесе, филология фәннәре докторы профессор Латыйф Җәләйнең тууына 90 ел тулды.

Өч революцияне башыннан кичергән ярлы крестьян баласы Латыйф Җәләйнең тормыш юлы төрле вакыйгаларга бай һәм фәнни-иҗади эше дә бик гыйбрәтле, башкаларга үрнәк булып тора.

Л. Җәләй 1894 елның ноябрендә хәзерге Ульяновск өлкәсе Майна районы Иске Кызыл Су авылында дөньяга килә. Тормышның авырлыгы Латыйфны 9 яшьтән үк ялланып эшләргә, йөкче булырга мәҗбүр итә. Яшьли әти-әнисе үлеп китсә дә, ул чигенми, бөтен читенлекләрне җиңеп чыгарга тырыша, мәдрәсәне тәмамлауга да ирешә. 1912 елда Л. Җәләй укытучы булып эшли башлый, ләкин бәхет эзләп йөрергә мәҗбүр була — Ташкентка китә, анда төрле эшләрдә була. Аннары солдат хезмәте. Л. Җәләй беренче империалистик сугышта катнаша, яралана. Февраль революциясе көннәрендә Румыниягә дә барып чыга.

Бөек Октябрь социалистик революциясе аңа культура-мәгариф өлкәсендә үсәргә, канат җәяргә ярдәм итә. Самара һәм Кузнецк педагогия техникумнарында укытучы булып эшли, өяз һәм өлкә мәгариф бүлеге инспекторы була, әдәби-фәнни эшчәнлеген башлап җибәрә. 1933-35 елларда Казан педагогия институты каршындагы аспирантураны тәгәлләгәч, шул ук институтта укытучы булып кала, тел тарихы, диалектология фәннәрен укыта, фәнни тикшеренү эшләре алып бара. 1939 елда Тел, әдәбият һәм тарих институтында тел секторы мөдире итеп билгеләнә, шул ук елны СССР Язучылар союзына кабул ителә.

1944 елда Казан дәүләт университетында татар теле һәм әдәбияты бүлеге ачылгач, Л. Җәләй студентларга диалектология һәм тел тарихы фәннәреннән лекцияләр укый. Бер үк вакытта ул тел белемендәге проблемаларны хәл итү өстендә эшли. Экспедицияләр оештырып, төрле урыннарда яшәгән татар халкының тел үзенчәлекләрен тикшерә, тел тарихын өйрәнү өчен күп материал туплый.

Тел белеме традицияләрен үстерүдә һәм татар тел белемен бер әзлеклелектә соңгы чорлар белән китереп тоташтыруда Л. Җәләйнең эшчәнлеге аеруча зур. Бу— аның моңа кадәр тиешенчә өйрәнелмәгән — диалектология, тел тарихы, этимология, орфоэпия, стилистика, язучылар теле, орфография кебек тармакларны эшкәртүе һәм шул өлкәләрдә фәнни тикшеренүләр алып баруы белән бәйләнгән.

1946 елның апрель ае. Дәһшәтле сугышның бетүенә бер ел булып килә. Авыр еллар... Сугыш яраларын төзәтергә, илне аякка бастырырга кирәк... Беренче чиратта

ашау һәм кием кайгысы... Шулай булуга карамастан, илебезнең башкаласы Мәскәү шәһәрендә СССР Фәннәр академиясенең тарих һәм философия бүлеге тарафыннан оештырылган Идел буе татарларының килеп чыгышына багышланган фәнни сессия ачыла. Бу абруйлы гыйльми җыелышны ачып җибәрүче академик Б. Д. Греков көн тәртибендә гаять катлаулы проблеманы — татар халкының этногенезын хәл итү бурычы торганлыгын белдерә һәм мәсьәләнең бик актуаль булганлыгын искәртеп үтә. Трибунага бер-бер артлы илебезнең могтәбәр галимнәре күтәрелә. Алар казан татарларының Идел-Кама буенда төзелгән борынгы Болгар дәүләтендәге культура һәм андагы халыклар белән тарихи-генетик якынлыгын төрле фәннәрдәге фактлар белән раслап күрсәтәләр. Төп докладчылар тарихчы-археолог профессор А. П. Смирнов, антрополог Т. А. Трофимова, Казан галимнәреннән этнограф Н. И. Воробьев, тел галиме Л. Җәләй булды. Өстәмә докладларда (Казан археологы Ф. И. Калинин, тарихчы Хәйри Гыймади) һәм фикер алышуларда катнашкан иптәшләрнең чыгышларында да (СССР Фәннәр академиясе член-корреспондентлары Н. К. Дмитриев, А. Ю. Якубовский, профессор С. П. Толстов, профессор В. В. Богданов һ. б.) бердәм фикер яклау тапты. Сессия зур мәсьәләне хәл итте: ул Татарстан АССРның тарихын язу өчен җирлек хәзерләде. Моңа кадәр аерым кешеләр тарафыннан гына күтәрелгән, татарларның чыгышы ягыннан болгарлар белән бәйләнештә булу теориясен рәсми рәвештә фәнни җирлеккә утыртты, шуны тарихи, археологик, этнографик, антропологик, лингвистик яктан дәлилләүдә зур эш башкарды. Казан татарларының тарихы монголлар чорыннан гына килә дигән карашны юкка чыгарды. «Казан татарлары,— диелә сессиянең резолюциясендә,— мәгълүм бер халык буларак, төрле этник төркемнәр һәм халыклар белән озак дәверләр аралашу һәм үзара бәйләнешләр нәтиҗәсендә барлыкка килгәннәр. Аларның формалашуында, бу крайга монгол басып алучылары килгәнче үк, үзләренең Кама болгарлары дәүләте булган җирле кабиләләр һәм төрки телдә сөйләшә торган халыклар (болгар һ. б.) хәлиткеч рольне уйнаганнар»[1]. Әлбәттә, сессиядә бөтен проблемаларны да берьюлы хәл итү мөмкин түгеллеге дә ачыкланды. Бу теория бүгенге көндә дә бик актуаль, аның көн тәртибеннән төшкәне юк. Ул вакыттан бирле инде татарларның этногенез мәсьәләләре яңа фәнни мәгълүматлар белән тулыландырылды.

Л. Җәләйнең сессиядә сөйләнгән, «Тел материаллары нигезендә казан татарларының килеп чыгышы» дигән эчтәлекле докладында[2] әле кайбер мәсьәләләр тезис хәлендә генә куелган була. Ул лингвистик яктан татарлар һәм болгарлар арасындагы генетик берлекне яңа фактлар белән ачыкларга кирәклекне ачык сизә. Л. Җәләй бу сессиядә үзенең сайлап алган фәнни юнәлешенең, эш алымнарының дөрес булуына ышана, ничек эшләргә кирәклеген ачык күз алдына китерә.

Татарларның болгар һәм Идел буендагы җирле кабиләләр белән бәйләнеше турындагы караш күптәннән килә. Бу мәсьәләгә үз вакытында Н. Г. Чернышевский, И. Н. Березин, В. В. Григорьев, Шиһап Мәрҗани, Каюм Насыйри кебек галимнәр зур игътибар бирделәр. Совет чорында болгар-татар теориясен үстерүгә Л. Җәләй лаеклы өлеш кертте.

Л. Җәләй хәзерге татар теленең бер төрле материалдан гына тормаганлыгын ачык күрә, аның нигезендә монголлар килгәнче үк, Идел буенда формалашып, лексик, фонетик, грамматик нормалары ягыннан аерылып торган төрки тел ятканлыгын, анда болгар-кыпчак үзенчәлекләренең иң зур урынны алып торганлыгын ачык күрә.

Л. Җәләй тикшеренүләренең характерлы ягы шунда: ул телнең тарихын ачканда язма истәлекләр белән генә чикләнмичә, тарихи тел фактларын халык сөйләменнән, хәзерге тел үзенчәлекләреннән чыгып билгеләүне дә төп максат итеп куя. Бу юнәлеш татар тел белемендә яңа тармакларның үсүенә китерде. Диалектология һәм тел тарихы — шуның нәтиҗәсе иде. Шулай итеп, тел тарихын өйрәнгәндә төрле чыганакларга таянырга була. Алар арасында бик борыннан килгән, халык телендә саклэнып калган җирле сөйләм һәм диалектлар, төрле истәлекләр-ядкарьләр, халык авыз иҗаты әсәрләрендәге тел үзенчәлекләре аеруча зур урын тота. Телнең тарихи үсешен билгеләгәндә ышанычлы чыганак булган диалектларны дөрес таба һәм бу юнәлештә объектив юлны сайлый белү аеруча әһәмиятле. Шуңа күрә җирле сөйләмгә

[1] Происхождение казанских татар. Материалы сессии отделения истории и философии Академии наук СССР.— Казань, Татгосиздат, 1948, 4 бит.
[2] Китапта: Происхождение казанских татар. 81—89 бит.

таяну, аңа фәнни анализ ясау зур осталык һәм киң эрудицияле булуны таләп итә. Л. Җәләйдә нәкъ шушы як бар иде. Ул халык тарихы белән тел тарихын бәйли торган әчке җепләрне табуга һәм шушы юнәлешне фәнни яктан эзлекле рәвештә үстерүгә зур игътибар бирде. Төрки телләр белеме тарихында беренче буларак Л. Җәләй татар телендә өч зур диалектның системалы яшәп килүен, аларның халык тарихы белән бәйләнешле рәвештә борынгы чорда, кабилә телләре заманында ук үскән үзенчәлекләр икәнлеген күрсәтә алды. Татар халкының этногенезын ачыклауда бу тикшеренүләрнең әһәмияте зур булды.

1947 елда Л. Җәләйнең югары уку йортлары һәм педагогия училищелары студентлары өчен «Татар диалектологиясе» дәреслеге дөнья күрә. Анда беренче мәртәбә диалектларның бүленешләрен билгеләү принциплары эшләнә, татар теленең төп диалектларына анализ ясала: Урта диалект (Казан арты, Бәрәңге, Нократ, Минзәлә, Тау ягы сөйләшләрен кертеп), Көнбатыш диалект, Көнчыгыш диалект. Җентекле рәвештә ул Урта диалектны өйрәнә, нәтиҗәдә ике томнан торган «Татар теленең Урта диалекты» дигән капиталь хезмәт языла. 1954 елда Л. Җәләй аны докторлык диссертациясе итеп яклый.

Тел тарихын өйрәнү белән бергә, Л. Җәләй орфография, орфоэпия, стилистика, пунктуация, тел культурасы мәсьәләләре буенча фәнни тикшеренү эшләре алып бара, сүзлекләр (диалектологик, лингвистик, фразеологик) төзүдә дә актив катнаша.

«Татар теленең орфоэпик нигезләре» хезмәтендә ул дөрес әйтелешнең принципларын, сузыклар, тартыклар, кушымчалар, ярдәмлек сүзләр орфоэпиясендәге төп тенденцияләрне, төрки телләр орфоэпиясендә сингармонизм законының тоткан ролен билгели.

Л. Җәләй үзенең хезмәтләрендә әдәби телнең үсеш юлларына, матур әдәбият стиле һәм язучылар теле мәсьәләләренә дә зур урын бирә.

Милли әдәби тел мәсьәләләренә караган мәкаләләрендә ул әдәби телнең халык сөйләме белән тыгыз мөнәсәбәттә үсүенә, андагы үзгәрешләргә һәм язучыларның роленә тукталып үтә.

«Башлап язучыларда тел» дигән мәкаләдә, тематика, идея юнәлеше, жанр үзенчәлекләре, типик сурәт мәсьәләләре белән беррәттән, тел-стиль проблемасы да беренче планда тора [1]. Тел ярлылыгы әсәрнең идея ягыннан камиллегенә дә зыян китерергә мөмкин,— дигән тезис ул чорларда бөтен катгыйлеге белән куела. Л. Җәләй башлап язучыларның телендә архаизм-диалектизмнарны, стиль кытыршылыкларын һәм башка кимчелекләрне лексик, морфологик һәм синтаксик яктан дөрес күрсәтә, күп кенә киңәшләр бирә һәм яшьләргә ярдәм итү кирәклегенә басым ясый.

Октябрьдан соң татар матур әдәбият телендәге үзгәрешләр һәм аңа куела торган таләпләр дә Л. Җәләй игътибарыннан читтә калмый. «Совет чоры татар матур әдәбияты теленә бер күзәтү» дигән күләмле мәкаләсендә [2] ул проза теленә анализ ясауны максат итеп куя. Совет чорында проза әсәрләрен гомумхалык теле хисабына баету, диалогик һәм монологик сөйләмнең үзенчәлекләрен ачу юнәлешендә аерым язучыларның стиленә туктала, аларның нинди алымнар белән язу юлларын ачыкларга тырыша.

Л. Җәләйнең язучылар телен тикшерүгә багышланган махсус мәкаләләре бар. Алар арасында халык шагыйре Г. Тукай [3], күренекле прозаик Ш. Камалга [4] багышланганнары үзләренең масштаблылыгы һәм төп индивидуаль сыйфатларны дөрес ачулары ягыннан аерылып торалар. Г. Тукай поэзиясендә фигыльләрнең мәгънәви һәм стилистик кулланылышы традицияләр белән дә һәм шагыйрьнең үзенә хас алымнары белән дә бәйле. Галим бу якны аеруча калку күрсәтә. Ул Тукай поэзиясендә боерык фигыльнең күп мәгънә төсмерләренә, хикәя һәм исем фигыльләрнең төрле функцияләр башкара алуына игътибар итә. Шагыйрьнең поэтик синтаксисында зур урын тоткан интонация, кабатлау, инверсия, тезем алымы, кереш сүзләр күп мисаллар белән җентекле рәвештә анализлана. Л. Җәләй Ш. Камал әсәрләрендә телдән файдалану алымнарына, бигрәк тә персонаж сөйләме һәм лирик кичерешләрне бирү чара-

[1] Л. Җәләй. Башлап язучыларда тел.— Совет әдәбияты, 1937, 6—7 сан, 74—80 бит.
[2] «Совет әдәбияты», 1951, 10 сан, 102—118 бит.
[3] Л. Җәләй. Тукай телендә фигыльләр.— Совет әдәбияты, 1938, 3, 4, 5 саннар; Г. Тукай поэзиясенең кайбер синтаксик үзенчәлекләре.— Совет әдәбияты, 1954, 5 сан.
[4] Л. Җәләй. Татар художество телен баетуда Ш. Камалның роле.— Совет әдәбияты, 1940, 1, 2 сан.

ларына, диалектизмнарга туктала. Гомумән, татар проза телен үстерүдә Ш. Камалның тоткан ролен ачыклый.

Җанлы сөйләм байлыгы Л. Җәләйнең аеруча игътибар үзәгендә торды. Ул халык теленең бик нечкә мәгънә төсмерләрен сиземли иде. Мисалга игеннең үсү дәверендә күзәтелә торган аерым баскычларын, аларның исемнәрен китереп үтәсе килә. Л. Җәләй аны 14 баскычтан тора дип күрсәтә: борнау, тишелү, икенче яфракка китү, өченче яфракка китү, көпшәләнү, буынга сикерү, баш кысу, баш чыгару, серкәгә утыру, серкә очыру, инә башлау (орлыклану), орлыкката башлау, сары керү (балавызлану), өлгерү.

Галимнең педагогика, методика, тәрбия өлкәсенә караган хезмәтләрен дә искә алып китмичә мөмкин түгел. Л. Җәләйнең дәреслек-хрестоматияләре укучыларга файдалану өчен бик ачык аңлаешлы һәм эчтәлекле төзелгән.

Л. Җәләй әдәбият тарихы, фольклор һәм әдәби-тәнкыйть мәсьәләләренә кагылышлы күп хезмәтләр яза. Әдәби-тәнкыйть мәкаләләрендә М. Әмир, Г. Баширов, Ә. Еники, С. Хәким, Ә. Ерикәй, А. Расих, М. Максуд, М. Ногман, Ә. Юныс һ. б. язучыларның әсәрләренә анализ ясый, алардагы уңай һәм кимчелекле якларга туктала.

Фәнни кадрлар әзерләүдә дә Л. Җәләйнең киң эш алып баруын күрсәтеп үтәргә кирәк. Аның җитәкчелегендә үскән тел белгечләре хәзер җаваплы урыннарда эшлиләр, мәктәпләрдә, югары уку йортларында укучыларга, студентларга белем бирәләр һәм киң педагогик-тәрбия эше алып баралар.

Фән һаман алга бара, үсә, яңа проблемалар туа. Шулай булуга карамастан, профессор Л. Җәләй хезмәтләре әле дә үзенең әһәмиятен югалтканы юк.

Галим Латыйф Җәләйнең тууына 90 ел тулу көнен киң җәмәгатьчелек чын күңелдән билгеләп үтә һәм аның халыкка, фәнгә багышланган гүзәл гомерен зур горурлык белән искә ала.

**Вахит ХАКОВ.**

# ҖАН ҖЫЛЫСЫ

*Скульптор Васил Маликовка 60 яшь*



Авыл малайларының бөтенесе кебек үк, Актаныш районында туып үскән Васил Маликов та урманнарда йөрергә, кошлар моңын тыңларга, болыннарда чәчәк җыярга, дөньясын онытып, чылтырап аккан чишмәләр тавышына колак салырга ярата иде. Агыйдел аңа дөньяның иң гүзәл агымсуы булып тоела. Әмма чордаш малайларының күбесеннән аермалы хәлдә, Васил яфрак һәм чәчәкләрнең формасын, агымсу бормаларының үзләренә юл салу рәвешенә, кошларның, җәнлек-җанварларның гәүдә төзелешенә һәм агач ботакларының бизәксез сурәтләренә кереп үсүенә озак-озак карап торучан, шуларны күңеленә сеңдерүчән иде. Малайларның байтагы төсле, Васил Маликов та күргән-күзәткәнен кәгазьгә рәсем итеп төшереп карый иде. Ләкин, яшьтәшләреннән үзгәрәк буларак, Васил агачтан, балчыктан, тимер-томырдан сыннар да ясый белә иде. Аның кулындагы гап-гади балчык кисәге кошка әверелә, гап-гади тимер-чыбык агач тамыры көтмәгәндә Тукайның Шүрәлесе кыяфәтен ала, хәйран калып торырлык формага керә. Күңелендә сәнгать тылсымы булган кешенең җан җылысы әнә шулай һәр ташны да җанландыра, кешеләр сокланырлык итә ала.

Болар һәммәсе дә булачак скульпторда сәнгать бөреләренең уянуы булгандыр, күрәсең. Тик Васил Маликов үзендәге бу һәвәслеккә әллә ни игътибар да итмәде шикелле. Һәрхәлдә, профессиональ сәнгать остасы булуны күз алдына китермәде. Скульптор булганчы әле аңа гади эшче булырга, аннары кулына корал алып, камалуда калган Ленинградны немец фашистларыннан саклашырга туры килде. Шуңа күрә аның сәнгать юлындагы чишмә башы да Октябрь революциясенең бишеге — геройшәһәр Ленинград белән аерылгысыз бәйләнгән. Бирегә ул В. И. Мухина исемендәге югары художество училищесында белем алды, тарихи шәһәрнең музейларындагы, сәнгать сарайларындагы, парк һәм бульварлардагы, проспект һәм каберлекләрдәге искиткеч сыннарны, бизәкләрне өйрәнде, бик күп укыды, узган гомер сынчыларының тормыш һәм иҗат юллары белән җентекләп танышты. Һәм аннары бер-бер артлы иҗат әсәрләре туа башлады. Менә «Суык һәм ачлык» скульптурасы. Әлеге сын сугыш чоры истәлекләренә нигезләнгән. Фашистик Германияне җиңүнең 30 еллыгына эшләнгән мәһабәт статуя «Соңгысы» дип атала. Анда соңгы снарядына кадәр илбасарларга каршы аяусыз көрәшкән совет артиллеристы гәүдәләндерелгән. Сугышта үзе дә артиллерист-тупчы булган Васил Маликов бу хезмәтен фронтташ дусларына багышлаган.

Хезмәт темасы — бөек тема. Художество училищесын бик яхшы билгеләренә генә тәмамлагач, яшь скульптор республикабыз нефтьчеләре — Социалистик Хезмәт Геройларының портретлар сериясен ясый. «Бораулаучы», «КамАЗны башлап төзүчеләр» дигән скульптураларын иҗат итә.

Сәнгать ВУЗында диплом яклаган елны ук Васил Маликов «Мулланур Вахитов» скульптурасын ясый һәм моның өчен РСФСР Культура министрлыгы дипломына лаек була. Шуннан соң ул иҗат иткән хезмәтләр арасында без Муса Җәлил, чекист Н. Голубятников, Шамил Усманов, Хөсәен Ямашев, Габдулла Тукай, Һади Такташ образларының карап туйгысыз сыннарда гәүдәләнүен күрәбез.

Татарстанда Совет власте урнаштырылуның 50 еллыгы уңае белән Казанда монументаль комплекс ачылды. Андагы «Чакыру» скульптурасы өчен Васил Маликовка Татарстан комсомолының Муса Җәлил исемендәге премиясе бирелде.

Югарыда телгә алынган хезмәтләреннән тыш та, Васил Маликов бик күп һәйкәлләр авторы булды. Аның таланты тудырган скульптураларны без Раифа поселогында да, Актаныш һәм Чистай районнарында да, Минзәләдә дә күрәбез, музейларда карыйбыз.

Татарстанның халык, РСФСРның атказанган художнигы, ТАССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Васил Маликов үз иҗатының чәчәк ату чорын кичерә. Аның әле бик күп яңа үрләр яулаячагына ышаныч чиксез зур.

Барлас **КАМАЛОВ.**

## Эшләпәнең Дәүлигә үпкәләве

Бер елны Нәби Дәүли эшләпә сатып ала. Яңа эшләпәсен киеп урамнан барганда бер дусты очрап аңа әйтә:

— Нәби, салып ташла моны, сиңа эшләпә килешми! — ди.

Өенә кайткач, Дәүли көзге каршына килеп карый: чыннан да эшләпә аңа бик үк килешми төсле.

— Ярар,— ди Н. Дәүли.— Иртәгә көньякка, Минеральные Водыга китәсе, мин аны поездда онытып калдырырмын!..

Һәм поездан төшкәндә Н. Дәүли эшләпәсен алмый. Перронга чыккач, аны проводница куып җитеп:

— Сез эшләпәгезне онытып калдыргансыз, алыгыз! — ди.

Рәхмәт сүзе мыгырдап, Н. Дәүли үги эшләпәсен алып китә.

— Ярар,— ди ул.— Хәзер очкычка утырып очасы. Мин аны шунда калдырырмын!

Һәм самолеттан төшкәндә эшләпәсен алмый. Әмма вокзалга кереп киттем дигәндә генә Н. Дәүлине стюардесса куып җитә:

— Гражданин пассажир, эшләпәгезне самолетта калдыргансыз!— ди.

Рәхмәтләр әйтеп, Н. Дәүли эшләпәне кимичә генә, кулына тотып китә һәм аны вокзалдагы урындыкта калдырып, шәһәргә чыгарга була. Чыккач, күрә: тышта коеп салкын яңгыр ява.

— Әһә, минә кирәгең чыкты,— дип, Н. Дәүли эшләпәсен калдырган җиргә йөгереп килә. Килсә, эшләпәдән җилләр искән!

## Ярулла җиләне

Утызынчы елларда Минзәлә төбәгенең Тулбай авылында яшьләр «Габсаттар картның колхозга керүе» исемле пьеса куярга булалар. Киемнәрне өйдән-өйгә кереп, халыктан җыймакчылар икән. Иң кирәкле кием — җилән булып чыга. Эзли торгач, җилән дә табыла. Ләкин җилән хуҗасының хатыны аны «артистларга» бирдертми. Шулай да хатынына сиздерми генә яшьләр җиләнне хуҗадан алып китәләр. Кичен «театр карарга» дип, әлеге җиләнне бирмәскә тарткалашкан хатын да ире белән иң алгы рәткә килеп утыра.

Спектакль башлана. Залда халык шыгрым тулы. Бервакыт яшертен генә алынган җиләнне киеп, яшь егет сәхнәгә чыга. Шул чак җилән хуҗасының хатыны кычкырып җибәрә:

— Карагызсана, бу артисттә безнең Ярулла җиләне түгелме соң?

Зал бердәм көлә башлый.

— Ярулла җиләне шул,— дип ду куба әлеге хатын.— Валлаһи, билләһи, Ярулла җиләне. Әнә, ямаулыгыннан таныйм, тәки безнең җиләнне урлаганнар, чукынмышлар!

Ярсыган хатынны тынычландыру шактый озакка сузыла, халык спектакльдән битәр хатын «тамашасыннан» көлеп хәлдән тая. Спектакльне яңадан башлыйлар. Әлеге егетнең җилән киеп сәхнәгә чыгуы була, халык тыела алмый тагын көлә башлый. Спектакль бик зур уңыш казана.

Тулбай авылы халкы бу кызык тамашаны әле дә булса хәтерли, әле дә булса «Ярулла җиләне»н искә төшереп, рәхәтләнеп көләләр, ди.

## Серле Солтан

1971 елда, әнисе каты авыру сәбәпле, Зәйни Шаһиморатовның «Раушан» пьесасында баш роль — Солтанны уйнаучы артист гастрольдән кайтып китә. Гастрольне өзү һәм финанс, һәм спектакльләр планы ягыннан театр өчен файдалы түгел, шуңа күрә, кайтып киткән артист урынына тиз генә Минзәләдән башка бер артистны җибәрергә тиеш булалар. Юл ерак, артист берничә көннән генә килеп җитә ала. Тик ятмас өчен артистлар спектакльне Солтансыз гына уйнарга карар кылалар. Солтан сүзләрен һәркем үз җаенча:

— Менә Солтан бу урында шулай-шулай дип әйтер иде! Солтан сиңа шулай дип әйтергә кушты! — дип сөйләргә тиеш була.

Спектакльне шулай Солтансыз гына уйнап чыгалар. Халык бик канәгать кала. Ләкин, сәхнә артына кереп, кызлар сорый:

— Солтан да, Солтан диделәр, их, шул Солтанның үзен күрергә иде!

Аңа каршы артистлар:

— Ие, үзебез дә шул Солтанны күрәсебез килеп тилмерәбез! Һаман килеп җитми бит әле Солтан! — диләр.

## Бусагадан базга

Кышкы чатнама суыкта Минзәлә театры артистлары тун-толыпларга төренеп авылдан-авылга йөриләр икән. Авылларда кунак өйләре булмау сәбәпле, кайвакытларда артистлар үзләре фатир эзләп йөрергә мәҗбүр булганнар.

Рабига Терегулова исемле артистка бер өйнең ишегеннән керә дә ачык базга төшеп китә. Төшсә, ни күрсен, бер хатын сукыр лампа яктысында чиләккә бәрәңге тутырып маташа икән. Каршысына егылып төшкән ят хатынны күргәч, хуҗабикә:

— Әстәгафирулла,— дип куя.— Каян җил ташлады сине?

— Апа! — ди Рабига.— Фатирга кертмәссезме икән, ә?

— Соң, апаем, аны базга төшеп сорамасаң, мин чыкканны көтәрлек тә тәкатең калмадымы? — ди хуҗа хатын.

*«Кызыклы хәлләр»не журналга Батулла әзерләде.*

# 1984 ЕЛДА ЖУРНАЛДА БАСЫЛГАН ӘСӘРЛӘР


**Советлар Союзы Коммунистлар партиясе Үзәк Комитеты Пленумы турында информацион белдерү. № 3.**

**КПСС Үзәк Комитеты Генеральный секретаре иптәш К. У. Черненко рече. № 3.**

**КПСС Үзәк Комитеты Политбюросы члены, СССР Министрлар Советы Председателе иптәш Н. А. Тихонов рече. № 3.**

**КПСС Үзәк Комитеты Политбюросы члены, КПСС Үзәк Комитеты секретаре иптәш М. С. Горбачев чыгышы. № 3.**

**Константин Устинович Черненко. № 3.**

**КПСС Үзәк Комитеты, СССР Верховный Советы Президиумы, СССР Министрлар Советының Коммунистлар партиясенә, совет халкына Мөрәҗәгате. № 3.**

*КПСС өлкә комитеты бюросы, Татарстан АССР Министрлар Советы карары*

**1984 ел өчен Татарстан АССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премияләрен бирү турында. № 8.**

**Татарстан комсомолының М. Җәлил исемендәге премияләре лауреатлары. № 12.**


## ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫНЫҢ X СЪЕЗДЫ


Галиуллин Т. **Шигърият үрләре. № 3.**

**Казанышлар һәм бурычлар.** Иҗат секцияләрендә. **№ 5.**

Миңнуллин Ф. **Ил белән, халык белән. № 5.**

Мөхәммәдиев Р. **Якты идеалларыбыз хакына. № 5.**

**Яңа биеклекләр яулаганда. № 4.**

Ахунов Г. **Партия белән, халык белән. № 11.**

Галиев Ш. **Киләчәккә очар канатлар. № 11.**

Галиуллин Т. **Тәнкыйть һәм әдәби процесс. № 11.**

Зарипов М. **Алгы сызыкта булыйк. № 11.**

Михалков С. **Яңа биеклекләргә. № 11.**

Миңлебаев К. **Ана телендәгечә укылсын. № 11.**

Миңнуллин Т. **Югары идеяне — зур осталык белән. № 11.**

Мәһдиев М. **Прозабыз ни хәлдә! № 11.**

Орешина Н. **Максатлар уртак. № 11.**

**Татарстан язучыларының X съезды резолюциясе. № 11.**

Юзеев И. **Күкрәгеңдә шигырь утың саумы! № 11.**


## ПРОЗА


Бәширов Г. **Кезге ачы җилләрдә.** Повесть-истәлек. **№ 3, 4.**

Вәлиев М. **Дулкын.** Повесть. **№ 7.**

Галиев Г. **Карлыгачлар оя кора.** Хикәя. **№ 1.**

Галиев М. **Нигез.** Повесть. **№ 11.**

Галиев Ф. **Командировка.** Повесть. **№ 10.**

Ганиев А. **Габделхак.** Повесть. **№ 5.**

Камалов Б. **Өметең өзелмәсен.** Роман. **№ 1, 2.**

Кутуй Р. **Ява карлар.** Хикәя. **№ 12.**

Латыйп К. **Төньякта да күбәләкләр яши.** Хикәя. **№ 6.**

Мәһдиев М. **Мәңгелек яз.** Роман. **№ 5, 6.**

Мөхәммәдиев Р. **Беренче умырзая.** Повесть. **№ 3.**

Низамиев Р. **Көнбагыш.** Хикәя. **№ 5.**

Сабиров С. **Хатлар язам сагынып.** Повесть. **№ 4.**

Сафин А. **Күз карашы.** Хикәя. **№ 12.**

Тельпугов В. **Биш минут.** Хикәя. **№ 4.**

Тимбикова К. **Ярлар биек.** Повесть. **№ 12.**

Фәизов Р. **Җыр хакына.** Хикәя. **№ 6.**

Фатхетдинов З. **Ак «Жигули» эз югалта.** Мажаралы повесть. **№ 8.**

Хәбибуллин М. **Кубрат хан.** Роман. **№ 8, 9, 10.**

Шамов А. **Язны көткәндә.** Хикәя. **№ 4.**

Шәмси С. **Нихал, дустым!** Хикәя. **№ 2.**

Шәфигуллин Ф. **Өй салуның ние бар!** Повесть. **№ 7.**


## «БАТЫРЛЫК ДӘВАМ ИТӘ» КОНКУРСЫНА


Вәлиев Д. **Мәрхүмнәр көяшы.** Хикәя. **№ 9.**

Гаффар Ә. **1945 елгы хат.** Хикәя. **№ 12.**

Садриев Ф. **Авыш басу нигә?** Хикәя. **№ 12.**

Хафизова Р. **Урак эсте.** Хикәя. **№ 7.**

Шамов А. **Якташым.** Хикәя. **№ 11.**

Әмирханов М. **Гармун. № 6.**


## ЮМОР ҺӘМ САТИРА


Исхак Ә. **Автобус һәм трамвай вагоны.** Мәсәл. **№ 5.**

Рафиков Б. **Начальникны көткәндә. № 5.**

Нури З. **«Шинельле юмор» дәфтәреннән.** № 7.

## ПОЭЗИЯ

Арсланов Н. **Учларымда кояш.** Шигырьләр. № 9.
Афзал Г. **Шатланды күңел, сафланды.** Шигырьләр. № 5.
Баянов Ә. **Иделдә җәй.** Шигырьләр. № 4.
Баттал С. **Вакыт дисциплинасы.** Шигырьләр. № 6.
Вәлиев Р. **Безнең иман.** Шигырьләр. № 7.
Галиев Ш. **Шигырьләр.** № 5.
Газизов М. **КамАЗлар эргәсендә.** Шигырьләр. № 6.
Гыйззәтуллина Ф. **Ишет, дөнья!** Шигырьләр. № 11.
Гәрәй Рәшит. **Йөрәктәге учаклар.** Шигырьләр. № 1.
Гәрәева С. **Урал сәламнәре.** Шигырьләр. № 3.
Измайлова Н. **Шигырьләр.** № 5.
Игәнәй Я. **Шагыйрь.** Шигырьләр. № 6.
Латыйп Г. **Хәрби оркестр.** Шигырьләр. № 10.
Мадьяров Н. **Туган як моңнары.** Шигырьләр. № 7.
Маннапов Ш. **Күңелемә кага иген кыры.** Шигырьләр. № 8.
Мансуров З. **Акка күчерү.** Шигырьләр. № 9.
Минһаҗева А. **Туфанны көткәндә.** Шигырьләр. № 12.
Миңнуллин Р. **Җайдаклар без.** Шигырьләр. № 4.
Мостафин Э. **Туган якка кайтып барышлый.** Шигырьләр. № 10.
Мәхмүдов Ә. **Яшәеш уты.** Шигырь. № 10.
Мөхәммәтшин Г. **Дүрт юллык хис.** Шигырьләр. № 10.
Низамиев Р. **Канатлы җыр кирәк кешегә.** Шигырьләр. № 10.
Рәхим Гәрәй. **Шигырьләр.** № 3.
Рәхимова Б. **Авылда иртә.** Шигырьләр. № 3.
Сибгатуллин К. **Пошилар.** Шигырьләр. № 9.
Сәсәнбаева Э. **Кассандра.** Шигырьләр. № 3.
Фәйзуллин Рөстәм. **Неон уты.** Шигырьләр. № 6.
Фәйзуллин Р. **Су асты көймәсендә.** Шигырьләр. № 7.
Харис Р. **Гүзәл гөмбәз.** Шигырьләр. № 8.
Халиков Х. **Хисмәт белән кисмәк.** Шигырьләр. № 1.
Хәким С. **Күгн.** Поэма. № 7.
Шакирҗанова Л. **Башланмаган тормыш.** Шигырьләр. № 3.
Шәрифуллина Э. **Бер кычкырды кәккүк.** Шигырьләр. № 3.
Юзеев И. **Олы юлның каены.** Поэма. № 2.
Юзеев И. **Кайтавазы сыман Тукайның.** Шигырь. № 4.
Юнысов Р. **Җирдә яшим.** Шигырьләр. № 12.
Яруллин Ф. **Галиҗәнап.** Шигырьләр. № 6.
Әхмәтҗанов Рәшит. **Кошлар бәйрәменә чакыру.** Шигырьләр. № 6.
Җиһангирова Ш. **Кечкенә чагымда.** Шигырьләр. № 12.

## ДРАМАТУРГИЯ

Гыйләҗев А. **Ефәк баулы былбыл кош.** № 11.
Мингалим Р. **Кайда сез, ирләр!** Моңсу комедия. № 5.

## ӘДӘБИЯТЛАР ДУСЛЫГЫ — ХАЛЫКЛАР ДУСЛЫГЫ

Ю. Бондарев. **Дала кояшы.** Хикәя. № 12.
Е. Евтушенко. **Казан университеты.** Поэмадан өзекләр. № 12.
В. Портнов. **Фронтовик агачлар.** Шигырьләр. № 12.
Н. Думбадзе. **Хазарула.** Хикәя. № 12.
О. Вациетис. **Балалар өчен шигырьләр.** № 12.
А. Емельянов. **Хырвар дигән тын авылда.** Хикәя. № 12.
Ю. Семендер. **Карт солдатны күмү.** Шигырьләр. № 12.
П. Афанасьев. **Су эзлибез.** Шигырьләр. № 12.
Л. Мартьянова. **Нахак сүзләр әйтеп.** Шигырьләр. № 12.
А. Хузангай. **Йөз мең сүз...** (Әдәби тәнкыйть). № 12.
Й. Гәрәй. **Сармаш ярында.** Шигырь. № 12.
Ш. Биккол. **«Җир казуы — авыр эш»,— диләр.** № 12.

## ЯЗУЧЫ УЙЛАНУЛАРЫ

Миңнуллин Т. **Кызыл тышлы дәфтәрдән.** № 4.

## ОЧЕРК ҺӘМ ПУБЛИЦИСТИКА

Баянов Ә. **Ватан тойгысы.** № 12.
Орешина Н. **Ватанымның көчле канатлары.** № 12.
**Сүзебез мәктәпләр турында.** Түгәрәк өстәл янында сөйләшү. № 9.
Чанышев Я. **Каләм һәм бомба.** № 2.

### КПСС ҮЗӘК КОМИТЕТЫНЫҢ ИЮНЬ (1983 ЕЛ) ПЛЕНУМЫ КАРАРЛАРЫН ТОРМЫШКА!

Низамов И. **Китап! Китап! Китап.** № 10.
Фасеев К. **Болганчык дулкын** (капитализмның рухи кризисы). № 5.
Фарукшин М. **Җиңүчән чынбарлык һәм дошмани уйдырмалар.** № 1.

### КПСС ҮЗӘК КОМИТЕТЫНЫҢ ДЕКАБРЬ (1983 ЕЛ) ПЛЕНУМЫ КАРАРЛАРЫН ТОРМЫШКА!

Зарипов М. **Тәвәккәл таш яра.** № 6.

### АЗЫК-ТӨЛЕК ПРОГРАММАСЫ — БӨТЕНХАЛЫК ЭШЕ

Бәдретдинов Х. **Бишьеллыклар төсе.** Очерк. № 8.
Галләмова Ә. **Калаларга карап...** № 6.

Гыйльметдинов Ф. Туар көннәр яктылыгы. № 6.

Гәрәй Рәшит. Ык буеның «Яңа юл»ы. № 7.

Дәрзаман Җ. Күңел җылысы. № 12.

Закирова Г. Күтәрелү. № 6.

Мәһдиев М. Агыйделнең бу ягында... № 11.

Саттаров Г. Мулиле — муллык иле. № 2.

Усманов Г. И. Бүгенгедән киләчәккә карап... № 1.

### УНБЕРЕНЧЕ БИШЬЕЛЛЫК КЕШЕЛӘР ҺӘМ ЭШЛӘР

Васильева Г. Алмагачлар илендә. № 3.

Елизарова М. «Әти кебек булыр идем!» № 4.

Латыйпов К. Тормыш ияре — һөнәр. № 4.

### БӨЕК ҖИҢҮНЕҢ 40 ЕЛЛЫГЫНА

Зиннурова Л. Хезмәткә җыр кушылса. № 7.

Салихов Г. Идел егете. № 12.

Хамматов Ш., Тәхау К. Фронтовик әдипләр. № 5.

Хамматов Ш. Муса Җәлил — халык күңелендә. № 8.

Хәмзин К. Безнең бабайлар. № 10.

Шакир С. Хәйруллин утравы. № 2.

### ӘДӘБИ ПОСТ — АЭС

Гайнетдинов Х. Кеше кадере. № 1.

Ларичева Э. Атомнарга атом бәйләнер. № 3.

Мостафин М. Киңәшле эш таркалмас. № 5.

Әһлиуллин М. Яңыгызга кайтыр идем!.. № 7.

Әмирханов М. АЭС кызлары. № 10.

## ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Маннапов С. Чынлап та шулаймы соң! № 9.

Мансуров З. Халыкка бөек эшләрендә булышучы... Поэзиядә проблемалылык турында уйланулар. № 6.

Миңнуллин Ф. Шагыйрьнең прозасы. № 8.

Мөхәммәдиев Р. Илем кояш чыгышында. № 12.

Сверигин Р. Тормышның үзе кебек. № 5.

Урманчиев Ф. Татар әдәбияты — Венгриядә. № 4.

### ИЛЕБЕЗ ТӘНКЫЙТЬЧЕЛӘРЕ ТАТАР ЯЗУЧЫЛАРЫ ТУРЫНДА

Дементьев В. Ялкынлану бәхете. № 4.

Кулумбетова А. Әхлак проблемасы үзәктә. № 4.

### БҮГЕНГЕ ПРОЗА: ГЕРОЙЛАР, ПРОБЛЕМАЛАР

Мәһдиев М. Җиләкле аланнар эзлим. № 3.

Салихов Р. Поэтикага игътибар кирәк. № 2.

Сәлахов Б. Кыюлык кирәк! № 3.

Хисматуллин Р. Тема да бик мөһим. № 3.

Хөсәенова Ф. Әле дә күз алдымда... № 1.

Әхмәдуллин А. Уңай герой — төп юнәлеш. № 2.

Әхмәдуллин Ш. Максатка реаль нигез. № 1.

### БИБЛИОГРАФИЯ

Галимуллин Ф. Ихлас хисләр гәүдәләнеше. № 9.

Галиуллин Т. Җиргә бер сүз. № 1.

Игъламов Р. Үрнәк булырлык хезмәт. № 5.

Идрисов Р. Аяз күктә карлыгачлар. № 2.

Измайлов Р. Партия солдаты. № 4.

Мостафин Р. Сез бу хатны минем укыганда... № 10.

Мәхмүтов М. Китап турында китап. № 6.

Сәхапов Ә. Якты моң. № 2.

Сәхапов Ә. Тынгысыз хисләр җырчысы. № 12.

Тимбикова К. Өметләр аклану. № 4.

Юнысов Р. Исемнәр артында нәрсә! № 6.

Әхмәтҗанов Р. Давыллы чор ядкарьләре. № 7.

Әшрәфҗанов Х. Тәрәзәләр кая карый! № 7.

### ЯҢА ӘСӘР УКЫГАЧ

Надиров И. Шигъри әкият. № 5.

### СССР ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ТӨЗЕЛҮГӘ 50 ЕЛ

Гыйззәтуллин Н. Әдәби оешмалардан — бердәм союзга. № 7.

## ЮБИЛЕЙЛАР

### А. М. ГОРЬКИЙНЫҢ КАЗАНГА КИЛҮЕНӘ 100 ЕЛ

Рухи яктан мин Казанда тудым. № 8.

Гайнуллин М. Горький һәм татар әдәбияты. № 8.

Гарифҗанова Р. Хатларны актарганда... № 8.

Такташ Һ. Киләчәккә хатлар. Поэмадан өзек. № 8.

Лопатина М. Хәтер сөйли. № 8.

Әдһәмова С. Бөек язучы рәхмәте. № 8.

Игелекле кайгырту. № 8.

### РИЗА ФӘХРЕТДИНЕВНЕҢ ТУУЫНА 125 ЕЛ

Госманов М. Катлаулы чорның каршылыклы вәкиле. № 1.

Хәйруллин Ә. Галимнең кулъязма мирасы. № 1.

Риза Фәхретдиневнең эшчәнлегендә халыкара иминлек мәсьәләләре. Документлар. № 1.
Әхмәтҗанов М. Риза Фәхретдинев шәҗәрәсе. № 1.

ТУКАЙНЫҢ 100 ЕЛЛЫГЫНА

Зуева Т. Казанда Тукай урыннары. Рәсемнәр. № 1—12.
Гобәйдуллин Х. Тукай автографы. № 4.
Гыйләҗетдинова А. Габдулла Тукай турында истәлекләр. № 4.
Зәбиров Х. Тукай һәм аның тирәлеге. № 6.
Кайбицкая Г. Безгә кадерле йорт. № 7.
Нәфиков Р. Тукайның иптәшләре һәм танышлары. № 5.
Рәсулева З. Тукай эзләреннән. № 1, 2, 3.
Сафин Ф. Тукай АЭСта. Шигырь. № 8.
Шәмси С. Шүрәлеләр кайдан таралган! № 8.
Якубова Э. Габдулла Тукай һәм татар музыкасы. № 12.

ИЛЬЯС КУДАШЕВ-АШКАЗАРСКИЙНЫҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ

Гобәйдуллин Х. Башлап йөрүчеләрдән. № 3.
Мәхмүтов Һ. Сәхнә фидакаре. № 3.

СӘЙФИ КУДАШКА — 90 ЯШЬ

Еники Ә. Аның йөге — ил милке. № 10.
Кудаш С. Хәсән Туфанга шигъри хатлар. № 10. Халкыбызның каһарман бер кызы. № 10.

ФӘРИТ ЯРУЛЛИННЫҢ ТУУЫНА 70 ЕЛ

Гобәйдуллин Х. Яшьлек хатирәләре. № 1.
Ильская Ф. Үткер күңел күзе. № 1.
Литинский Г. Ут эчендә. № 1.
Музыка сәнгатебезнең горурлыгы. № 1.
Таһиров Г. Фәрит Яруллин. «Шүрәле». № 1.
Хәйруллина З. Өч очрашу. № 1.
Яхин Р. Йөрәк түрендә. № 1.

Шәрипов Ә. Гыйлем — нурдыр. (Утыз Имәнинең тууына 230 ел.) № 11.
Нури З. Шевченконы укып уйланам. (Тарас Шевченконың тууына 170 ел). № 6.
Шевченко Т. Ага су зәңгәр диңгезгә. Шигырьләр. № 6.
Попова М. Халык шагыйре. (М. Ю. Лермонтовның тууына 170 ел). № 10.
Нигъмәтуллин Ә. Әдипнең үсү юлы. (Шәриф Камалның тууына 100 ел). № 2.
Хәмидуллин Л. Бәхетле язмыш. (Фәйзулла Туишевның тууына 100 ел). № 12.
Һибәтулла Салиховның тууына 190 ел. № 12.
Муса Акъегетнең тууына 120 ел. № 12.

Арсланов Г. Сәхнә йолдызы (Х. Уразиковның тууына 90 ел). № 2.
Ибраһимова Ф. Яктылыкка омтылып. (Г. Сөнгатинең тууына 90 ел). № 3.
Мөхәррәмов М., Гыйззәтуллин И. Халык бәхете хакына (К. Якубовның тууына 90 ел). № 3.
Насыйров Т. Революционер һәм журналист (Вәли Шәфигуллинның тууына 90 ел). № 10.
Сәйдәшева М. Ленинның тугрылыклы шәкерте (С. Сәетгалиевнең тууына 90 ел). № 2.
Хаков В. Яшәү һәм хезмәт үрнәге (Профессор Л. Җәләйнең тууына 90 ел). № 12.
Галиуллин Т. Фидакарьлек (Хәмит Ярминең тууына 80 ел). № 6.
Гайсин Н. Атым... Шигырьләр (Нур Гайсинга 70 яшь). № 11.
Шакиров М. Шәмдәлләрдә генә утлар яна... (Мөнирә Булатовага 70 яшь). № 6.
Әхмәтов Ф. Моңлы якташыбыз (Х. Вәлиуллинга 70 яшь). № 2.
Камалов Б. Җан җылысы. (Скульптор Васил Маликовка 60 яшь). № 12.
Мөэминова Э. Күзгә чәчәк. Шигырьләр. (Энҗе Мөэминовага 60 яшь). № 4.
Сафиуллин Ю. Гел истә (Р. Бикчәнтәевнең тууына 60 ел). № 3.
Хәсәнов А. Уйлап язсаң гына... (Рафаил Төхфәтуллинга 60 яшь). № 1.
Шакир С. Яңгыр тамчысы. Шигырьләр. (Самат Шакирга 60 яшь). № 4.
Әхмәт Р. Саба җиледәй... (Аллаһияр Вәлиуллинның тууына 60 ел). № 7.
Гаффар Ә. Игелекле эш кешесе (Тәрҗемәче Вил Ганиевка 50 яшь). № 7.
Госманов М. Язма мирасыбызның күтәреләсе катламнары. (Миркасыйм Госмановка 50 яшь). № 5.
Илялова И. Үз хакыйкатеңне ачу. (Марсель Сәлимҗановка 50 яшь). № 11.
Якты юл. (Фәрваз Миңнуллинга 50 яшь). № 8.

## ӘДӘБИЯТЫБЫЗ ҺӘМ КУЛЬТУРАБЫЗ ТАРИХЫНА

Алишев С. Мәгърифәт учаклары. № 4.
Алишев С. Пугачев полковнигы. № 7.
Вәлиев Ф. Борынгы сәнгатебез сәхифәләреннән. № 6.
Зәйнашева Г. Зур педагог. № 2.
Зәйнуллин Җ. «Кәлилә вә Димнә» — татар әдәбиятында. № 6.
Зәкиев М. Казан татарлары ни өчен марича — суас, удмуртча — бигер! № 5.
Илялов И. Ике хатирә. № 6.
Кадыйров Р. Гали Мәхмүдов — хаттат. № 10.
Кутуева Г. Якты хатирә. № 5.
Кәримуллин Ә. «Гасыр» нәшрияты. № 7.
Миңнуллин Җ. Рухи мирасны барлаганда. № 12.
Мостафин Р. Җәлил — әдәби тәнкыйтьче. № 12.
Мәхмүдов М., Кәримуллин Ә. Мәгърифәтче Шиһап Әхмеров. № 10.

Мөхәмматшин Җ., Хлебникова Т. **Шәһре Болгар. № 7.**
Туфитулова Р. **«Яшь ленинчы»га 60 ел. № 10.**
Әхмәтҗанов М. **Г. Кандалыйның яңа табылган әсәрләре. № 9.**

## СӘНГАТЬ

Блинов Л. **Музыка: сәләт бөреләре ничек ачыла! № 5.**
Миңлебаев К. **Совет Татарстанының сынлы сәнгате. № 2.**
Рахманкулов Ш. **Цирк кабызган йолдызлар. № 6.**
Сәлимҗанов М. **Театр кайдан башлана. № 12.**

### БЕР СОРАУГА — БЕР ҖАВАП

Равил Фәхретдинов, Зөлфәт, Нурихан Фәттах. **№ 1.**
Госман Х., Җиһанов Н., Шакиров И., Сәлимҗанов М. **№ 5.**
Әхмәтҗанов М. **№ 6.**

### КАЛӘМДӘШЛӘРЕБЕЗ — СССР ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫНЫҢ ЯҢА ӘГЪЗАЛАРЫ

**Ф. Гыйльми, К. Кәримов, С. Маннапов. № 5.**
**Р. Вәлиева, Г. Кашапов, Хәйдәр. № 9.**
**А. Вергазов, Я. Иганәй, Ә. Махмудов. № 10.**

### ФОЛЬКЛОР

Маннапов Ш. **Сүз эчында ятмый. № 6.**
**Кызыклы хәлләр. № 1, 2, 4, 5, 6, 7, 9, 10, 12.**

### УКУЧЫ ФИКЕРЕ

Газизҗанов З. **Әсәрне чын иткән нәрсә. № 9.**
Гыйльметдинов Ф. **Әрамәнең эше. № 12.**

# ӘРӘМӘНЕҢ ЯМЕ

Барлас Камалов киң катлау әдәбият сөючеләргә үзенең повестьлары, мавыктыргыч хикәяләре белән яхшы таныш. Аның узган ел дөнья күргән «Ярсөяр әрәмәсе» дигән җыйнак повесте да[1] шундый мавыктыргыч әсәрләр рәтенә керә.

Әсәр башыннан ахырынача гуманизм идеясе белән сугарылган. Кешелеклелек сыйфатларын үзенә мул туплаган баш герой Госман Галиев әсәрдә калку фонда сурәтләнә. Повестьны укый башлау белән үк ул укучы күз алдында уңай кеше буларак ачыла бара.

«Басу карап йөргәндә гомерлек механизаторның күңеле шатлык белән тулы иде. Яз шатлыгы белән... Әйе, җир ябага койды. Табигать кыш белән саубуллашты...»

Әнә шулай итеп безгә Галиевнең табигатьне, андагы тереклек йәләрен үлеп яратканлыгы мәгълүм була. Язучы, төп геройның озын кышлардан соң туган якларына әйләнеп кайтучы киек казларга карап хозурлануы белән генә чикләнеп калмый, ә Госманның кошлар язмышы өчен чын күңелдән борчылуын да исбатлап бирә. Галиев олы башын кече итеп колхоз рәисеннән киек казлар өчен азык сорый, председательне дә кошларны туйдыру кирәклегенә ышандыра. Беренче карашка төп образның бу гозере һәм күллекләр буена барып кошларга бөртек сибеп йөрүе берникадәр мәзәгрәк тоелса да, чынлыкта моның нигезендә ихласлылык, самимилек, олы җанлылык ята. Гөнаһсыз җан ияләренә кул күтәргән, мал дигәндә теләсә нинди адымга барырга әзер торган Кадим картны Госман җинаять урынында тота, һәм үз вөҗданына тугры калып, әлеге бәндәне, үзенә бабай тиешле булуга да карамастан, атып алган кыр казы һәм мылтыгы белән авыл советына илтеп тапшыра. Укучы Госманның берничди мәкерсез-ялгансыз булуына аз гына да шикләнми.

Иш янына куш дигәндәй, әйтелгәннәрне ныгытучы, төплерәк итүче тагын бер деталь — үзен фронтта разведкага баргач ярым үле хәлдә ташлап калдырган кешенең кызы — үз малаеның сөйгәне икәнлеген белгәч тә, ул капылт кына карар кабул итми. Бу турыда хәтта сөекле тормыш иптәше Галимәгә дә белдерми, башлап олы улы белән киңәшә. Зөлфәтнең дә киңәше үзе уйлаганнарга куәт биргәч, ул яшьләргә язмышларын бәйләү мәсьәләсендә комачауламаска була.

Б. Камалов әсәрләренең күбесенә хас сыйфат — өлкәннәр белән яшьләр язмыштормышын бергә бәйләп алып бару, яшьләрне өлкәннәрдән үрнәк алу сыйфатында манзаралау. Бу — игътибарга лаек алым. Бу алым тагын да тирәнрәк башкарылып, киңрәк планда яктыртылган тәкъдирдә — язучының уңышлары зураер.

Соңгы вакытта байтак кына язучыларыбыз повестьларында ни сәбәпледер бер образны гына ныклап торып игътибар үзәгенә алалар да калган образларга дикъкатьне шактый ук киметәләр. Әйтергә кирәк, кирәгеннән артык киметәләр. Әсәрнең аксый төшүенә китерә бу. Сүз дә юк, персонажлар арасында берсе аеруча нык күзгә бәрелеп, ягъни аерылып торырга тиеш: шуның өчен дә ул баш герой. Ләкин моның белән генә эш бетми бит әле, аның калганнары да, һич югы икесе-өчесе киңрәк

[1] Камалов Б. «Ярсөяр әрәмәсе». Татарстан китап нәшрияты. 1983.

масштабта күз уңына алынырга тиеш шикелле. Шулай булган очракта, миңа калса, әдәби әсәрдә фикер сөреше саллырак, вакыйгалар барышы үтемлерәк, Камаловның үз теле белән әйтсәк, сүллерәк булып укучы хөкеменә килеп басар иде.

Әйтик, менә ни өчен Миннәхмәт Сөнгатуллин образына күбрәк басым ясамаска? Авыр хәлдә иптәшен ташлап калдырган бу кешене укучы куркак, вак җанлы булырга тиеш дип фараз кыла. Ташбуага килеп тә, Яртуган авылына барып чыкмый Сөнгатуллин. Билгеле, ул вөҗдан газабы кичергәндер. Шулай икән, анда кешелеклелек сыйфатлары бар. Өстәвенә, ул бүгенгесе көндә ил өстәленә мул итеп ризык кую өчен көннәрне төнгә ялгый. Кызы Сәвияне дә яхшы тәрбияле итеп үстергән. Укучыга тагын фараз итәргә кала: шулай да нинди кеше ул — Миңнәхмәт Сөнгатуллин? Кайберәүләр: «Тагын нәрсә, ризыкны чәйнәп үк каптырырга кирәкмени?» — диярләр. «Азык бик тупас булганда, аңа карата тиешле чаралар күрү зыян итмәс иде»,— дияр идем мин.

Аннары Кадим карт хакында берничә сүз. Укып, без аның төзәтеп булмаслык бозык адәм икәнлегенә ышанабыз. Әтисе юлыннан килеп ул өлешчә муллалык белән дә көн күрә. Тик аңарга карата җәмәгатьчелек нинди караштa, нинди чаралар күрелә, укучы боларның берсе хакында да хәбәрдар түгел. Хәтта кияве Госман җинаять өстендә эләктереп, авыл советына илтеп тапшыргач та, җәзага тартылганмы, юкмы — белмибез. Бу образга да игътибарны арттыра төшәргә кирәк иде кебек. Гомумән, әсәрнең киң колачта, зур күләмдә язылырга хакы бар. Күтәргән проблемасы белән ул моңа лаек. Туган як табигате, җир кешеләренең аңарга мәхәббәте, эшне сөюләре, гади һәм катлаулы да булган игенче хезмәте белән ил-көн күрүләре — болар бар да бүгенге көн үзәгендә торган күпкырлы бурычның үзәк өлешләреннән берсе. Повестьта коры сөйләп китү белән генә чикләнгән урыннар да юк түгел. Ышанасы килә, Б. Камалов әле бу әсәрен һичшиксез тулыландырыр, киңәйтер һәм чын әдәби әсәр үрнәгенә җиткерер.

**Фирдәвес ГЫЙЛЬМЕТДИНОВ.**
Алабуга районы Илмәт авылы.

## ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ПАРТИЯ ОЕШМАСЫНДА

24 августта Татарстан Язучылар союзы партия оешмасының ачык җыелышы булып узды.

Язучылар алдында Татарстан Авыл хуҗалыгы министрлыгының баш агрономы Ю. А. Силов республика кырларында иген уңышы җыюның торышы турында сөйләде, язучыларның сорауларына җавап бирде.

Соңыннан СССРның Азык-төлек программасын үтәү юлында Татарстан язучыларының бурычлары хакында принципиаль сөйләшү булды, язучылардан оештырылган «Уңыш-84» иҗат бригадасының эше каралды.

## ҖӘЛИЛ һӘМ ҖӘЛИЛЧЕЛӘР ИСТӘЛЕГЕНӘ

24 августта Советлар Союзы Герое, Ленин премиясе лауреаты Муса Җәлил һәм аның көрәштәшләренең фашистлар тарафыннан җәзалап үтерелүенә кырык ел тулуга багышланган митингка Казанның Беренче Май мәйданындагы Муса Җәлил һәйкәле янында партия, совет һәм җәмәгатьчелек оешмалары вәкилләре, язучылар, сәнгать эшлеклеләре, күп санлы казанлылар җыелды. Анда патриот-шагыйрьнең тормыш иптәше Әминә Җәлилова, кызы Чулпан һәм оныгы Таня да килгәннәр иде.

Муса Җәлил һәйкәленә чәчәк бәйләмнәре куелганнан соң, шигъри митингны кереш сүз белән РСФСРның М. Горький, ТАССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премияләре лауреаты шагыйрь С. Хәким ачты. Аннары Әминә ханым Җәлилова, Җәлил һәм җәлилчеләрнең көрәш юлларын өйрәнүче язучы һәм тәнкыйтьче Р. Мостафин, шагыйрьләрдән З. Нури, Ш. Галиев, Р. Фәйзуллин, Рәшит Әхмәтҗанов, Р. Низамиев, артистлардан Р. Сабиров һәм Р. Тажетдинов иптәшләр чыгыш ясады. Беренче Май мәйданында Муса Җәлилнең ялкынлы шигырьләре, шагыйрьләребезнең Ватаныбыз иминлеге өчен гомерләрен дә кызганмаган каһарманнарга, халыклар дуслыгына, тыныч хезмәткә дан җырлаган әсәрләре яңгырады.

Мәскәүнең Измайлово исемендәге культура һәм ял паркының концерт залында Муса Җәлилгә һәм аның көрәштәшләренә багышланган кичә булды. Бу кичә аларның фашистлар тарафыннан җәзалап үтерелүенә кырык ел тулуга багышланган иде.

Кичәне СССР Язучылар союзы члены Анна Бок ачып җибәрде. Ул шагыйрьнең тоткынлыктагы күрсәткән батырлыгы, иҗаты турында сөйләде.

Кичәдә Мәскәүнең эстрада артистлары М. Җәлил әсәрләрен башкардылар.

## ДУСЛЫК НЫГЫЙ

Татарстан Язучылар союзы Идел буе республикаларының иҗат коллективлары белән тыгыз элемтәдә тора. Әле июнь аенда гына безнең әдипләр Чувашстанда әдәби атналык уздырып кайтканнар иде. Ә 3—8 сентябрьдә язучы Р. Кәрәми, Татарстанның атказанган артистлары Мингол Галиев һәм Г. Сәйфуллин составындагы иҗат бригадасы Мари АССРның Бәрәңге районында булып кайтты. Алар хезмәт коллективларында очрашулар, әдәби-музыкаль кичәләр үткәрделәр.

Татарстанның иҗат вәкилләрен КПСС-ның Бәрәңге район комитеты беренче секретаре В. Н. Мөхәммәтгалиев кабул итте һәм район хезмәтчәннәренең Азык-төлек программасын үтәүдәге тырышлыклары, ирешелгән уңышлар хакында сөйләде.

## БӨТЕНСОЮЗ КОНФЕРЕНЦИЯСЕНДӘ

Казахстанның Алма-Ата шәһәрендә «Чирәм җырләрне үзләштерүдә халык батырлыгы, Азык-төлек программасы һәм бүгенге әдәбиятның бурычлары» дигән темага Бөтенсоюз конференциясе булып узды.

Илебезнең күренекле язучылары һәм чит ил әдәбиятлары вәкилләре катнашкан бу конференциядә Татарстаннан шагыйрь Р. Фәйзуллин булды һәм чыгыш ясады. Ул шулай ук Казахстанның Уральск, Тургай өлкәләре хезмәт ияләре белән очрашуларда булып, бүгенге татар әдәбияты турында сөйләде, үзенең әсәрләрен укыды.

## ИҖАТ СЕКЦИЯЛӘРЕНДӘ

Шагыйрьләр секциясенең 28 сентябрьдә узган чираттагы утырышында яшь шагыйрьләр Э. Шәрифуллина, Р. Зәйдуллин, Л. Зөлкарнәевләрнең Татарстан китап нәшриятында басылып чыккан беренче китаплары тикшерелде. Яшь шагыйрьләрнең иҗатларына Рәшит Әхмәтҗанов, Ф. Зөлкарнәев һәм Зөлфәт кузәтү ясадылар.

Фикер алышуларда шагыйрьләр һәм язучылар Л. Ихсанова, Г. Зәйнашева, А. Гыйләҗев, Н. Фәттах, Ә. Рәшитов, И. Юзеев, Ф. Сафин, Р. Вәлиев, М. Әгъләмов, М. Вәлиев, Р. Низамиев катнаштылар. Яшь шагыйрьләр бертавыштан СССР язучылар союзына тәкъдим ителде.

31 октябрьда Язучылар союзының яшьләр белән эшләү бүлеге һәм шагыйрьләр секциясенең киңәйтелгән утырышында яшь иҗатчылар Д. Салихова, А. Гайфуллина, Р. Корбанов шигырьләре турында фикер алышу булды. Яшьләрнең иҗатларына шагыйрьләр И. Юзеев, Г. Зәйнашева, Рәшит Әхмәтҗанов, Р. Мингалимов, Р. Гатауллин, Р. Низамиев, З. Мансуров җентекле анализ ясадылар һәм киләчәк иҗатлары өчен файдалы киңәшләр бирделәр.

4 октябрьда проза секциясенең чираттагы утырышы булды. Анда катнашкан прозаиклар һәм тәнкыйтьчеләр совет халкының Бөек Ватан сугышында җиңүенә 40 ел якынлашу уңаеннан «Татар әдәбиятында сугыш темасы һәм аның чагылышы» дигән темага сөйләшү алып бардылар.

Кереш сүз белән проза секциясе председателе М. Мәһдиев чыкты. Фикер алышуда язучылардан А. Расих, Ш. Рәкыйпов, В. Нуруллин, Р. Мостафин, Р. Миңнуллин, С. Шакир, М. Хуҗин, М. Вәлиев, К. Латыйп, Р. Кәрами, Л. Хәмидуллин һ. б. катнашты.

29 октябрьда тәнкыйтьчеләр секциясенең чираттагы җыелышы татар әдәбиятын үзәк матбугатта яктыртуның торышы мәсьәләсенә багышланды. Тәнкыйтьчеләр секциясе председателе Ф. Мусин, җыелышны ачып, мәсьәләнең актуаль булуына игътибарны юнәлтте. Тәнкыйтьче С. Маннапов үзенең докладында проблеманың күпкырлы булуын, аның төрле формалары барлыкка килүен анализлап, бу өлкәдәге казанышларга һәм кимчелекләргә тукталды. Язучылар Г. Ахунов, Р. Харис, Ә. Рәшитов, танылган галимнәр — филология фәннәре докторлары Х. Госман, Н. Юзиевләрнең чыгышларында, тикшерелә торган проблеманың мөһимлегенә басым ясалу белән бергә, аның аерым яклары игътибар үзәгенә алынды, мәсәлән, татар әдәбиятының башка туганлаш әдәбиятлар белән бәйләнешен җанландыра төшү мәсьәләсе күтәрелде, аның күпмилләтле совет әдәбияты хәзинәсенә керткән өлешен лаеклы яктырту буенча конкрет тәкъдимнәр әйтелде.

## ШАГЫЙРӘ ХӨРМӘТЕНӘ

20 сентябрьдә Әлмәттә күренекле татар шагыйрәсе Саҗидә Сөләйманова иҗатына багышланган шигърият бәйрәме үткәрелде. Анда катнашыр өчен Әлмәт, Казан һәм Брежнев шәһәрләреннән шагыйрьләр, композиторлар, үзешчән сәнгать осталары җыелды.

Алар Г. Тукай һәйкәленә һәм С. Сөләйманова каберенә чәчәкләр салдылар. СССРның 50 еллыгы исемендәге Зәй ГЭСында булдылар, энергетиклар белән очрашып, бүгенге әдәбият турында сөйләделәр, шигъри митинг үткәрделәр.

Кичен Әлмәттәге Тәзүчеләр техника сараенда зур шигърият бәйрәме булды. Аны Әлмәт язучылар оешмасының җаваплы секретаре Әхәт Гаффар алып барды. Кичәдә шагыйрьләр Г. Афзал, Ә. Маликов, ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе композитор һәм җырчы М. Имашев, язучылар К. Тимбикова, Г. Кашапов, Брежнев Язучылар оешмасының җаваплы секретаре драматург Р. Хәмид, шагыйрьләр Г. Зәйнашева, К. Булатова, К. Сибгатуллин, Ф. Хәлиуллина һәм үзешчән сәнгать осталары чыгыш ясады. 21 сентябрьдә шигърият бәйрәме Сарманда дәвам итте.

## УТЫЗ ИМӘНИГӘ БАГЫШЛАП

Быел август аенда күренекле татар шагыйре һәм галиме Габдерәхим Утыз Имәнинең тууына 230 ел тулды. 19 сентябрьдә СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты Гыйльми советының киңәйтелгән утырышы әнә шушы датага багышлап уздырылды. Утырышта Утыз Имәни иҗатының тарихи роле һәм әһәмияте турында филология фәннәре кандидаты М. Гайнетдинов, шагыйрьнең тормышы, иҗат юлы һәм аның әдәби мирасын өйрәнүнең бүгенге торышы турында Алабуга педагогия институты доценты, филология фәннәре кандидаты Ә. Шәрипов доклад ясады. Докладлардан соң фикер алышуларда филология фәннәре кандидатлары Ф. Фәсиев, Ш. Абилов, РСФСРның халык рәссамы Бакый Урманче һ. б. катнашты. Алар Утыз Имәнинең татар әдәбияты һәм иҗтимагый фикер тарихында әһәмиятле урын тотуын билгеләп үттеләр, шагыйрьнең тормыш юлын һәм әдәби мирасын тагын да җентекләп өйрәнү кирәклеген әйттеләр, аның исемен мәңгеләштерү уңаеннан төрле тәкъдимнәр керттеләр.

# ТӨСЛӘР КАЙЧАН ҖЫРЛЫЙ

Шатлыклы якты сәнгать... РСФСРның халык художнигы, СССР һәм ТАССР Дәүләт премияләре лауреаты Лотфулла Фәттаховның иҗаты турында сөйләгәндә әнә шундый сүзләрне еш кулланалар һәм аның сәнгатен сугыштан соңгы чорга хас күренеш рәвешендә билгеләп үтәләр. Чыннан да сынлы сәнгать остасының әсәрләре яшәү матурлыгына мәдхия җырлыйлар, һәм аларда сугыштан соңгы катлаулы тормышның сулышы, тыныч хезмәткә сусаган халыкның көчле рухы бөтен тулылыгы белән чагыла. Фронтовик-художник сугыштан нәкъ менә шундый хыял, ягъни совет кешеләренең тыныч тормышта күрсәткән батырлыкларын данлау теләге белән кайта.

Шулай ул җиң сызганып эшкә тотына, әмма профессиональ тәҗрибә җитмәү сиздертә башлый. Куллар үзләрен ничектер иркен «тотмыйлар» шикелле. Сугыш гаепле. Алты ел буе сугыш коралына күнеккән кулларны ничек карандаш яки пумалага өйрәтергә? Ышанычлы дусты һәм сәнгатьтәше Харис Якупов белән бергәләп эшләү профессиональ осталык дәрәҗәсенә күтәрелергә булыша. Аларның иҗади хезмәттәшлеге милли сынлы сәнгатьнең илленче еллардагы үсешенә дә шифалы йогынты ясый. «Татарстан АССР төзелү турындагы Декретка В. И. Ленинның кул куюы»... Гаять мөһим тарихи тема буенча иҗат ителгән әлеге картина өчен Х. Якупов белән Л. Фәттаховка СССР Дәүләт премиясе бирелә.

Беренче казаныш яңа уңышларга канатландыра, һәм Л. Фәттахов үз күңеленә иң якын темаларның берсе — аны тудырган, үстергән, зур дөньяга чыгарган авылны сурәтләүгә ныклап тотына. «Кучмә лаборатория янында», «Игеннәр өлгерде», «Сабан туе»... Колхоз авылы хезмәтчәннәре турында бөтен бер серия иҗат ителә. Шулар арасында «Сабан туе» исемлесе рәссам иҗатында үзенә күрә бер этапны билгеләүче әсәргә әверелә. Татар әдәбияты һәм сәнгате декадасында (Мәскәү, 1957) оештырылган күргәзмәдә зур уңыш казана.

Сугыштан соңгы колхоз авылы «Яңа буралар» картинасында (1959) аеруча тормышчан итеп гәүдәләндерелә. Моның шулай булуы табигый, чөнки әлеге әсәр авторның туган ягы — Горький өлкәсендәге Анда авылында алган тәэсирләр нигезендә иҗат ителгән. Яңа буралар калка. Нигезләр яңара. Яңа гаиләләр туа. Тормыш тагын да матурлана. Картина менә шундый уйлануларга этәрә. Рәссамның яшьлек дусты — сугыш ветераны, балта осталары бригадиры Идрис Бәдретдинов композициянең үзәген тәшкил итүче образ итеп алынган. Күренеп тора: баһадирларча кыяфәтле әлеге оста, ачык йөзле, илгәзәк, хезмәт сөючән булуы белән берләттән, уен-көлкегә дә хирыс, иң әһәмиятлесе, бөтәннәрне эшкә җәлеп итә белә, хезмәтнең бәйрәм икәнлеген җанын-тәнен белән тоярга булыша.

Алтынсу бурәнәләр... Алардан хуш ис аңкып тора шикелле. Гомумән, картинада образ-детальләр, төс нюанслары бик оста файдаланылган. Камиллек дәрәҗәсендәге композиция, аерым алганда, пейзажның әсәргә шигърилек бирүе Л. Фәттаховның оста колорист булуын раслыйлар. Һәм, әйтергә кирәк, «Яңа буралар» картинасы Лотфулла Абделмәновичның зур уңышы булып танылды һәм татар сынлы сәнгатенең алтын фондына кертелде.


**Вера ЦОЙ,**
Татарстан сынлы сәнгать музееның бүлек мөдире.

**Тышлыкның дүртенче битендә:** Г. Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясенең симфоник оркестры.

**Рөстәм МАНСУРОВ** фотолары.

Цена 90 коп.

Индекс 73210



КАЗАН УТЛАРЫ
(ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ
(на татарском языке)